ИНДЕКС
73210

ISSN 0206-4189

№4
2014

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

# КАЗАН УТЛАРЫ



**ТР МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЫ А.М.СИБАГАТУЛЛИН:** «КАЗАН 2014 ЕЛДА ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ ИТЕП БЕРТАВЫШТАН ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ».

**АПРЕЛЬ – ТУКАЙ ҺӘМ ШИГЪРИЯТ АЕ.** БӨЕК ШАГЫЙРЬГӘ КЕМНӘР ҺӘЙКӘЛ КУЯ? КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМНӘРЕБЕЗНЕҢ ФИКЕРЛӘРЕ БЕЛӘН ТАНЫШАБЫЗ.

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ҮЗЕНЕҢ 80 ЕЛЛЫГЫН БИЛГЕЛӘП ҮТӘ.** ӘЛЕГЕ АБРУЙЛЫ ОЕШМА ӘГЪЗАЛАРЫН НИЛӘР БОРЧЫЙ?

№4 (1098) 2014

# БУ САНДА:



«Бәләкәй Тукай».
Хаҗиморат Казаков рәсеме


## Фарук НӘФИЕВ:

«Кайчак Хаҗиморат абыйдан әлегә хәтле беркемнән ишетмәгән мәгълүматлар белеп гаҗәпкә кала идем. Мәсәлән, Мирсәет Солтангалиевнең егет чагында, Бакуда революцион яшьләр белән аралашып торган елларда ук, төрле оешмаларны, байларны талап һәм банкларны басып йөргән банда башлыгы Иосиф Джугашвили белән танышлыгы турында башкача каян белер идем?!»

157

## ПОВЕСТЬЛАР КОНКУРСЫ

### Рабит БАТУЛЛА
### Ике җүләр



**«Җүләрләр арасындагы акыллы кешене гел җүләргә санаганнар! Әнә, карагыз, бөтен пәйгамбәрләрне тилегә санаганнар! Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәлламны да үз халкы башта «җүләр», дигән».**

73

# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**КАЗАН — 2014 ЕЛДА ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ**

Дүсен КАСЕИНОВ. ТӨРКСОЙның нигезе — телебез, тарихыбыз һәм мәдәниятебез. ....3

Айрат СИБАГАТУЛЛИН. Төрки дөнья Казанга төбәлгән. ....5

Разил ВӘЛИЕВ. Мәдәният елы — канатлы ат елы. ....8

Бергә — берәгәйле! *(«Казан утлары» журналы редакциясе сорауларына Марсель ТАИШЕВ, Илдус ТАРХАНОВ җаваплары).* ....13

**КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН**

А.Акбаш, Н.Ф.Кысакүрәк, Б.Мәшраб, Чулпан, М.Җомабаев, М.Беппайланы, Д.Османов, Т.Дәүләтбирдина, П.Хузангай шигырьләре. ....17

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

АХИР. Таш калада баш кала... *Роман.* ....23

Марсель ГАЛИЕВ. Күзалла да уйлан үзалдыңа... *Шигырьләр.* ....67

Рәшит БӘШӘР. Баш очымнан шаулап чор ага. *Шигырьләр.* ....89

**КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ**

БАТУЛЛА. Ике җүләр. *Повесть.* ....73

Әхтәм ЗАРИПОВ. Хатирәләрем — хәзинәләрем. *Документаль бәян.* ....93

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Зөфәр РӘМИЕВ. Тукай энциклопедиясен төзү юлында. ....128

Резеда ГАНИЕВА. Габдулла Тукай иҗатында төрек мотивлары. ....132

Фәридә ХӘСӘНОВА. «Тамырлы Тукай» *(Флёра Гыйззәтуллина иҗатында Тукай).* ....139

Нурфия ЮСУПОВА. XX гасыр татар поэзиясендә Тукай образы. ....143

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНӘ 80 ЕЛ**

Рафис КОРБАН. Милләткә хезмәт итәбез. ....149

**СӘНГАТЬ**

Фарук НӘФИЕВ. Моңсу бер тарих. *(Хаҗимөрат Казаковның тууына 100 ел).* ....157

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Ике халыкның былбылы. ....166

**ТАРИХ**

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Беренче Бөтендөнья сугышында Алманиядә мөселман әсирләре. ....168

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Хәзинәдә әз димә... *(Сәхифәне Марсель Галиев әзерләде).* ....174

**АК ҖИЛКӘН**

Факил САФИН. Тулган ай. *Бәян.* ....178

Илфат МӨГЫЙНОВ. *Шигырьләр;* Инзилә МӘҖИТОВА. *Хикәяләр.* ....187

«Казан утлары» архивыннан. ....126, 164

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
ачык акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фаттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(җаваплы сәркатип)*
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Ләйсән Солтанова.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флёра Сабирова.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
: *Баш мөхәррир — 222-05-50.*
*Җаваплы сәркатип, компьютер үзәге — 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст.5).*
: **Факс** — (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.03.2014, график буенча 31.03.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-823. Тираж 3550.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2014 ел

# ТӨРКСОЙның НИГЕЗЕ — ТЕЛЕБЕЗ, ТАРИХЫБЫЗ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕБЕЗ



ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы үзенең эшчәнлеген кайчандыр төрки халыкларны берләштереп торган элементларне янадан торгызудан башлады. Бүген ТӨРКСОЙ — мәдәни дипломатиянең Европа, Көнчыгыш илләрендә, Америка Кушма Штатларында, Кытайда халыкара багланышларны гамәлгә ашыра, төрледән-төрле чаралар үткәрә торган бик абруйлы оешма. Үзенең эшчәнлегендә ул ЮНЕСКО, ИСЕСКО һәм Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенең гуманитар хезмәттәшлек дәүләтара фонды белән күптәнге эшлекле элемтәләренә таяна.

2013 елда ТӨРКСОЙ оештырылуына 20 ел тулуны билгеләп үтте. Ике дистә ел дәвамында фәнни форумнар, пленэрлар, сынчыларның симпозиумнары, фоторәссамнарның очрашулары, театр, опера фестивальләре, әдәби журналларның конгресслары, кичәләр, концертлар, күргәзмәләр кебек бик күп халыкара проектлар уңышлы төстә гамәлгә ашырылды. Нәшрият эшчәнлеге дә киң җәелдерелде. Әлеге эш-гамәлләрнең максаты — төрки дәүләтләрнең мәдәни багланышларын киңәйтү белән бергә төрки мәдәниятне дөнья җәмәгатьчелегенә күрсәтү һәм аңа карата ихтирам уяту.

Соңгы елларда төрки дөньяда иҗади, мәдәни багланышларны ныгытуда тупланган тәҗрибә безнең оешмага яңа, масштаблы идеяләрне һәм чараларны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. 2010 елдан һәр елны безнең халыкларның күренекле мәдәният эшлеклесе, зур шәхес исеме белән бәйлибез. Мәсәлән, 2011 ел Тукай елы булды. ТӨРКСОЙның Татарстандагы, Россиядәге, Төркиядәге һәм башка илләрдәге дәүләт структуралары мәдәният учреждениеләре белән даими элемтәдә торуы нәтиҗәсендә бу елда чараларны гомумтөрки масштабта үткәрә алдык. Бөек татар шагыйренең тууына 125 ел тулу уңаеннан аның иҗатын өйрәнүчеләр Анкара, Истанбул, Баку, Казан, Уральск, Алматыда үткәрелгән фәнни симпозиумнарда очрашты, үзара фикер алышты, шагыйрь әсәрләренең төрки телләргә өр-яңа тәрҗемәләре басылып чыкты, төрле иҗат коллективларының чыгышлары күрсәтелде. Анкарада Г.Тукайга бюст куелды, шигъри традицияләргә бай кала — Тарсуста аның исемендәге бульвар ачылды.

Бөтен төркиләрне берләштерүче тагын бер бәйрәм — Нәүрүз. Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль ассамблеясының 2010 елның 23 февралендә кабул иткән карары нигезендә 21 март — Халыкара Нәүрүз көне дип игъдан ителде. 2009 елда Нәүрүз ЮНЕСКОның кешелек дөньясының матди булмаган мирасы исемлегенә кертелде. Монда 1995 елдан Нәүрүзне бөтен төрки дөньяда бәйрәм итүче ТӨРКСОЙның да өлеше зур.

2010 елда Нәүрүз әләмен ЮНЕСКОның Париждагы штаб-квартирасында күтәрдек. 2011 елда бәйрәм, океаннарны үтеп, Америкага барып житте, бай һәм күпкырлы төрки мәдәният белән танышу өчен күпләргә юл ачты.

Һәр елны Төрки дөньяның мәдәни башкаласын игълан итү — ТӨРКСОЙның яңа проекты. Әлегрәк бу традицияне Ислам дөньясы күтәреп алды. Мәдәни башкала Ислам хезмәттәшлек илләренең мәдәният министрлары карары белән билгеләнә иде. ТӨРКСОЙның Генераль секретариаты төрки халыкларның мирасын кадерләп саклый, XXI гасырда төрки мәдәниятне үстерүгә зур өлеш керткән шәһәрләр — яңа каламы ул, борынгымы — мәдәни башкала була ала дип саный. Без иҗади һәм фәнни хезмәттәшлекне активлаштыру, яңа талантлар ачу, мәдәниятне үстерү өчен көчләрне берләштерүне максат итеп куйдык. Беренче мәдәни башкалалар — Астана белән Искешәһәр дә менә иреште. Алар, төрки мирасның байлыгын бөтен дөньяга күрсәтү белән бергә, үсеш, янарыш, хезмәттәшлек һәм интеграциягә сәләтле булуларын да күрсәттеләр.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миннехановка рәхмәт! Ул 2012 елның маенда, ТӨРКСОЙның штаб-квартирасына визиты вакытында, Казанның 2014 елда дәрәҗәле титулны кабул итәргә лаеклы булуын әйтте һәм аны тәкъдим итте. 2013 елның сентябрендә Уфада ТӨРКСОЙ илләренең министрлары бу тәкъдимне хуплады.

Казан — Россиянең чын мәгънәсендә мәдәни үзәге, бөтен татарларның мәркәзе. Ул төрки дөньяга Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәшев, Бакый Урманче һәм башка бик күп бөек язучыларны, галимнәрне, музыкантларны, рәссамнарны, актёрларны бирде. Үз вакытында шәһәр бик күп тугандаш төрки халыкларның рухи үсеше, Россиянең Көнчыгышына белем һәм мәгърифәт тарату үзәге булды. Хәзер дөньяның мәдәният эшлеклеләре Казанда Шаляпин, Нуриев, Мөселман киносы кебек дәрәҗәле халыкара фестивальләрдә очраша. Казандагы мөселман киносы һәм «Созвездие-Йолдызлык» фестивальләрендә махсус приз тапшыруны ТӨРКСОЙ үзенә зур дәрәҗә итеп кабул итә. Төрки дөньяның мәдәни башкаласы исемен Казан лаеклы рәвештә аклар, барлык тугандаш халыкларга чын бәйрәм бүләк итәр дип ышанам.

**Дүсен КАСЕИНОВ,**
*ТӨРКСОЙ халыкара төрки мәдәният оешмасының Генераль секретаре*

# ТӨРКИ ДӨНЬЯ КАЗАНГА ТӨБӘЛГӘН



Меңьеллык тарихы һәм күпмилләтле уникаль тарихи мирасы булган шәһәрлә Казан каласы ТӨРКСОЙ төрки мәдәнияте халыкара оешмасына кергән илләрнең мәдәният министрлары даими советының 2012 елның 7 сентябрендә Уфада узган утызынчы утырышында «2014 елда Төрки дөньяның мәдәни башкаласы» итеп бертавыштан игълан ителде.

Казанны 2014 елда Төрки дөньяның мәдәни башкаласы итү турындагы мәсьәлә ТӨРКСОЙ оешмасына кергән илләрнең мәдәният министрлары даими советы көн тәртибенә ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның агымдагы елның 30 маенда ТӨРКСОЙ оешмасында булган вакытта әйткән тәкъдиме нигезендә кертелгән иде.

Астана кебек өр-яңа башкала һәм Искешәһәр кебек бик борынгы каладан соң Казаныбызның «Төрки дөньяның мәдәни башкаласы» титулын кабул итеп алуы бик табигый.

Казан — Европа һәм Азия чигендә урнашып, көнбатыш һәм көнчыгышны очраштырган, ике бөек мәдәни традицияне саклаучы кала. Бу җәһәттән, халыкларны матди яктан гына түгел, сәнгати һәм мәдәни яктан да тоташтырган Бөек ефәк юлын гына искә төшерик. Казан мәһабәт Кремле, борынгы мәчетләре һәм бай мәдәни мирасы белән горурланырлык меңьеллык кала булуы өстенә, Россиянең иң тиз үсүче, янаручы шәһәрләренең берсе икәнлеген дә билгеләп үтми мөмкин түгел. Әйтик, Казан Кремле ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәни мирас объектлары исемлегендә булса, тарихы ерак гасырларга тоташкан Сөембикә манарасы ханбикәбез символы буларак күңелләребезне нурландырса, Казан ханлыгының легендар мәчете хөрмәтенә торгызылган өр-яңа, мәһабәт Кол Шәриф Европаның иң эре һәм затлы мәчетләреннән берсе санала. Казан туристлар өчен дә кызыклы кала, соңгы елларда Татарстанга туристлар агымы Болгар каласы һәм Свияжск утрау-каласы хисабына тагын да артты.

Татарстан — халыкара оешманы гамәлгә куйган Төркия, Казакъстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан, Төркмәнстан һәм Үзбәкстаннан соң, Россиядәге төрки республикалар арасыннан беренчеләрдән булып ТӨРКСОЙ төрки мәдәнияте халыкара оешмасы белән килешүгә кул куйган республика. Хәзер Татарстан Алтай, Башкортстан, Тува, Саха (Якутия), Хакасия республикалары белән бергә халыкара оешмада әгъза-күзәтче булып тора. 2012 елның февралендә ТӨРКСОЙ һәм РФ Мәдәният министрлыгы арасында хезмәттәшлек турында Меморандум имзаланды.

Шунысы игътибарга лаек: төрки телле илләрне берләштерүче ТӨРКСОЙ оешмасының асыл максаты — төрки халыкларның гомуми матди һәм мәдәни мирасын саклау, үстерү һәм киләчәк буынга түкми-чәчми тапшыру өчен төрки халыкларның үзара хезмәттәшлек итүенә ирешү.

Әлеге максатка ирешү өчен оешма нинди юнәлештә эш алып бара? Төрки республика буларак, Татарстан аның белән ни дәрәҗәдә хезмәттәшлек итә һәм бу хезмәттәшлек нәтиҗәсендә нәрсәгә дә булса ирешәме? Ирешә аламы?

Билгеле булганча, 2011 ел Татарстан Республикасында Габдулла Тукай елы дип игълан ителгән иде. Шунысы куанычлы: ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы да 2011 елны

төрки телле илләрдә Г.Тукай елы дип игълан итте. Татар әдәбияты һәм хәзерге татар теленең чишмә башында торган шагыйрьнең 125 еллыгына багышланган чаралар Россиянең һәм чит илләрнең татарлар яшәгән төбәкләрендә булып узды.

Шуларның кайберләрен искә төшереп үтик. 2011 елның гыйнвар аенда Анкарада — ТӨРКСОЙның штаб-квартирасында Татарстаннан килгән делегация катнашында Тукай елын тантаналы ачу мәҗлесе үткәрелде. Соңрак Анкарада Тукай бюсты куелды, Тарсуста Тукай бульвары ачылды һәм шәһәрнең бер урамына Тукай исеме бирелде. Истанбулның тарихи районында Габдулла Тукай паркы ачылды. Мәскәүдә Тукайга һәйкәл куелды, ә Ульян өлкәсенең Димитровград шәһәрендә шагыйрьнең бюсты булдырылды. Азәрбайҗанда Тукайның шигырьләр җыентыгы азәрбайҗан телендә дөнья күрде, әдәби-музыкаль кичәләр уздырылды. Уральск, Астана, Алматы, Шымкент шәһәрләрендә күпсанлы бәйрәмнәр үткәрелде. Алар арасыннан Габдулла Тукайның туганнан туган сеңлесе София Гали кызы Зәбирова катнашында әдәби кичә, өлкә казакъ театрында — концерт, волейбол буенча яшьләр турниры, шигъри кичәләрне санап үтәргә була. Ташкентның «Туркестон» сараенда үткәрелгән әдәби кичәдә Татарстаннан килгән сәнгать әһелләре катнашты. Казакъстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан кебек төрки илләрдә генә түгел, Финляндия, Польша, Аргентина, Литвада да югары дәрәҗәдәге чаралар үткәрелде.

2012 елны ТӨРКСОЙ Николай Катанов елы дип игълан итте. Төрки дөньяның танылган тюрколог-галиме Н.Катанов Казан университеты профессоры булганлыктан, бу чаралар да Татарстанның катнашыннан башка үтмәде. Мәсәлән, ТР Милли музеенда күргәзмә ачылды, конференцияләр үткәрелде, галимнәребез Хакасиядә уздырылган фәнни чараларда да актив катнаштылар.

ТӨРКСОЙ Халыкара оешмасы Казан халыкара мөселман киносы фестивалендә 2007 елдан бирле махсус призын тапшыра. Приз «Төрки дөньяның кинематографиясенә үз өлешен кертүе өчен» дип атала. Төркиядә Татарстан мәдәнияте көннәре дә ТӨРКСОЙ белән берлектә әзерләнгән чара. Моннан бер ел элек — 2013 елның апрель аенда эшләгән «Серле хәзинә. Классик төрек сәнгате» исемле халыкара күргәзмәне Татарстан өчен шактый киң яңгыраш тапкан вакыйга дияр идем. Бу — Төркия белән Татарстан Парламентлары дәрәҗәсендә алып барылган хезмәттәшлек.

2013 ел дәвамында — бер Нәүрүздән икенчесенә кадәр — Татарстанның фән һәм сәнгать эшлеклеләре, яшь талантлары, журналистлары, рәссамнары, язучылары Төркиянең Искешәһәр провинциясендә «Мәдәни башкала» программасы кысаларында үткәрелгән күпсанлы чараларда актив катнашты. Әлбәттә, бу Казан өчен зур сынау алдыннан тәҗрибә туплау, әзерлек тә булды. Быел — 2014 елда Казан үзе төрки илләр мәдәнияте өлкәсендә кызыклы проектларны тормышка ашыру урынына әйләнәчәк.

Әлеге проектларның кайберләрен санап үтү урынлы булыр.

Мәдәни мирас турында фикер йөртсәк, рухи байлыгыбыз «Түгәрәк уен» фестивале аша күрсәтеләчәк. Фестиваль татарларның аутентик фольклорына багышланган һәм ул халкыбызның төрле этник төркемнәренең иҗат коллективларын бер үзәккә туплау максатын куя. Ул гадәттә татарлар күпләп яши торган Россия төбәкләрендә оештырылып килде. Быел ул Болгарда узачак. Ә инде матди мирас турында сөйләшәбез икән, Болгар форумы хакында да әйтеп узарга кирәктер. Форум кысаларында төрки дөньяда ислам традицияләре буенча конференция, «Төрки дөньяда тарихи һәйкәлләрне саклау тәҗрибәсе», «Евразия интеграциясенең нигезе буларак төрки-славян симбиозы» дип аталган семинарлар үткәреләчәк. Мәдәният тарихына килгәндә, «Төрки халыкларның әдәбият һәм музыка чыганаклары һәм эволюциясе» халыкара фәнни-гамәли конференциясен дә атап узарга кирәктер. Фәнни-гыйльми конференциягә дөньяның төрле почмакларыннан галимнәр килүе көтелә. Шунысы да игътибарга лаек: ТӨРКСОЙ 2014 елны төрки илләрдә төрекмән шагыйре һәм философы Мәхтүмкули елы дип игълан итте. Мәхтүмкулинең шигъри мирасы төрекмән милләтенең генә түгел, бөтен төрки халыкларның мәдәни байлыгы дияр идем. Шуңа күрә конференциянең бер секциясе Мәхтүмкули иҗатына багышланачак. Әлеге фәнни чарага Төрекмәнстаннан да белгечләр киләчәк.

Мондый уртак чаралар, һичшиксез, ике тугандаш халыкның бәйләнешләрен ныгыта. Төрек партнёрларыбыз белән берлектә «Төрки дөньяның күренекле мәгърифәтчеләре Мәхмәт Акиф Эрсой һәм Габдулла Тукай» халыкара симпозиумы узачак. Бу симпозиумда Төркиянең, Азәрбайҗанның, Казакъстанның, Грециянең, Кыргызстанның, Үзбәкстанның абруйлы галимнәре, дәүләт һәм мәдәният эшлеклеләре катнашачак, алар үзләре белән бай материал да алып киләчәк. Эрсой һәм Тукай иҗатын өйрәнүчеләр дә үз фикерләре белән уртаклашачак. Алар үзләре үк бай материал да алып киләчәк. Симпозиум уңаеннан зур күргәзмә дә оештырырга ниятлибез. Монда татар мәгърифәтчеләренең XX гасыр башында Төркиядә басылып, хәзер Төркия Республикасы фондларында саклануы хезмәтләре урын алачак. «Уртак тел — билге» дип аталган күргәзмә дә, ТӨРКСОЙ скульпторларының халыкара симпозиумы да, «Төрки дөньяда каюлы күн» сәнгате фестивале дә, «Төрки дөнья» музыка фестивале дә төрки кунакларыбыз күңеленә хуш килер дип ышанабыз. Мәсәлән, «Уртак тел — билге» күргәзмә проекты төрки халыкларның көнкүреш үзенчәлекләрен сурәтләгән «Традицион костюм», «Йорт», «Бала тәрбияләү», «Һөнәр һәм кәсеп», «Ышанулар» дип аталган тематик комплексларны берләштерә. 250дән артык экспонат Россия этнографик музееннан кайтартылачак. Музей эшчәнлегенә килсәк, «Казан Кремле» музей-тыюлыгында зур күргәзмә ачылачак. Монда традицион мәдәниятнең барлык юнәлешләре дә чагылыш табачак. Ягъни төрки халыклар турында бай мәгълүматлы экспозиция булачак.

Төрки дөнья белән бәйләнешләр турында сүз барганда, милли театрның күренекле шәхесләре — Марсель Сәлимҗанов һәм Шамил Закиров тарафыннан торгызылган һәм Татарстан җитәкчелеге ярдәме белән Казанга беркетелгән Төрки халыкларның «Нәүрүз» халыкара театр фестивален искә алмый мөмкин түгел. Фестиваль төрки телле театрлар арасында мәдәни бәйләнешләр булдырырга ярдәм итә, аның гаять әһәмиятле театраль мәйданчык вазифасын башкаруы бәхәссез. Милли республикалардагы төрки телле театрларның күбесе шактый авыр чор кичергәндә, кайберләре хәтта телләрен югалту алдында торганда, кыйблаларын табалмаганда, татар театрының алар өчен лидерга әверелүе, үзенчәлекле локомотив роленә керүе дә табигый. Әлеге фестиваль Татарстанда киң колач белән ике елга бер мәртәбә уздырыла. «Нәүрүз»нең төрки театрлар арасында ни дәрәҗәдә популярлыгын һәм әһәмиятен күреп, без фестиваль белән чикләнмәскә булдык — ике фестиваль арасында театраль форум үткәрелә башлады. Быел «Казан — Төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасы кысаларында нәкъ менә «Нәүрүз» театраль-агарту форумы үтәчәк. Форум кысаларында төрки драма театрларының халыкара киңәшмәсе әзерләнә. «Нәүрүз» театраль-агарту форумының быел да театрлар арасында элемтәне ныгытучы, артистларга үзара аралашырга, тәҗрибә уртаклашырга мөмкинлек бирүче, спектакльләрнең эстетик югарылыгына уңай тәэсир итүче, яңа формаларны булдыручы, милли драматургияне популярлаштыручы иҗади мәйданчык булачагына иманым камил.

2014 ел азагында — ноябрь аенда ТӨРКСОЙ әгъзасы булган илләрнең министрлары советының чираттагы XXXI утырышы көтелә.

«Казан — 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы» программасы безгә нәрсә бирәчәк?» — дип сорарга ярата журналистлар.

Беренчедән, «Россиянең өченче башкаласы» титулын йөрткән Казан быелгы «мәдәни башкала» статусы аша Россияне төрки телдә сөйләшә торган гаять зур төрки дөнья белән бәйли. «Казан — 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы» программасының милли һәм мәдәни үзенчәлекләребезне саклауга юнәлтелгән булуы да зур кыйммәткә ия. Ниһаять, Казан — дөньяның төрле кыйтгаларына сибелеп яшәгән татарларның уртак йорты, кыйбласы. Бар татарлар өчен кадерле булган башкаланың төрки дөньяның мәдәни үзәгенә әверелүе һәр татар өчен горурлык.

**Айрат СИБАГАТУЛЛИН,**
*Татарстан Республикасы мәдәният министры*

# МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ — КАНАТЛЫ АТ ЕЛЫ



Адәм баласына исем кушкан кебек, елларны да нинди дер исем белән атау инде бик борынгы заманнардан килә. Шәрекъ илләрендә һәр яңа елга бер җанвар исеме биреп, аны шул җанварга охшатып, анда шул җанвар сыйфатларын күрергә тырышканнар. Мәсәлән, Кытай календаре буенча быелгы ел — Ат елы. Бик хуп, ат — татарлар өчен дә бик кадерле җан иясе, шуңа күрә бу елны без зур өметләр баглап, халкыбызга уңышлар китерәчәк ел дип кабул иттек. Ә инде шуның өстенә Россия һәм Татарстан президентлары тарафыннан 2014 ел «Мәдәният елы» дип игълан ителгәч, бу өметләребез тагын да бөтәебрәк, тулыланыбрак киткәндәй булды.

Безнең бабаларыбыз борын-борыннан атлы кавем булган, алар ат белән тормыш иткән, атка менеп яу чапкан, кыскасы, ат аларны туендырган да, киендергән дә, бөек дәүләтле дә иткән. Шунысы кызганыч: тора-бара без иярдән төшеп, җәяүле язмышка дучар булганбыз, сонрак машина шаукымына бирелгәнбез, татарны татар иткән аттан акрынлап аерылганбыз. Яшьрәк чакта мин, шушы хакта сыкранып, болай дип язган идем:

*Мине ташлап аргамагым качты,*
*Чабып китте дала ягына...*
*Ияренә менгермәсә дөнья,*
*Асылынып барыйк ялына!*

«Ир күнелендә иярле ат ятар», — диләр безнең халыкта. Мин моны бераз үзгәртеп: «Татар күнелендә канатлы ат ятар», — дип әйтер идем. Ә ул канатлы ат — безнең әдәбиятыбыз, сәнгатебез, көй-моңнарыбыз, гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз, иманыбыз, кыскасы — Мәдәниятебез. Димәк, быелгы Ат һәм Мәдәният елы — икеләтә безнең ел, пар атта җилдерәсе уңышлы елыбыз булырга тиеш. Тиешен тиештер дә, ә ул чыннан да шундый булсын өчен без үзебез ниләр эшләргә тиеш соң?

Соңгы елларда республикабызның икътисади нигезе шактый ныгыды, ил каршында дәрәҗәсе дә үсте, шәһәр һәм авыл урамнары шәхси машиналар белән тулды, тормышыбыз да бераз көйләнде, юллар, күперләр салынды, яңа мәктәпләр, балалар бакчалары, Мәдәният йортлары калкып чыкты. Бер караганда, барысы да хәрәкәттә, үсештә кебек. Әмма ләкин...

Ходай Тәгалә һәр нәрсәне парлы итеп яраткан. Очар өчен кошларга ике канат биргән. Кешенең, кешелекнең дә ике канаты бар: аның берсе матди тормыш булса, икенчесе — рухи дөнья. Кошлар кебек, халыклар да бер канатта оча, күккә күтәрелә алмый. Соңгы елларда безнең бер канатыбыз — рухи дөньябыз шактый зәгыйфьләнде, халкыбызның милләтебезнең рухи җирлеге какшады. Ә рухи яктан нигезе нык булмаган халыкның киләчәге өметсез. Моны исбатлап торуның хаҗәте дә юктыр, чөнки һәрберебез шаһит: соңгы елларда яшьләр арасында итагать, тәрбия мәсьәләсе зур проблемага әверелде. Дәүләт Советына да балалары төрмәләргә эләккән, хокук саклау органнары күзәтүендәге ата-аналар бик еш мөрәҗәгать итә. Кызганыч ки, аларның саны даими артып тора. Итагатьле, тәртипле гаиләләрдә үскән балаларның да шундый афәткә очравы аеруча гаҗәпсенү уята.

Бүген ата-ана бала тәрбияләүгә тиешенчә игътибар бирә алмый. Өч яше тулгач,

алар улларын, кызларын балалар бакчасына тапшыра, аннары мәктәпкә, югары уку йортына «тәрбиягә бирә». Ә үзләре көн саен эштә. Чөнки гаиләне туендырасы, киендерәсе бар. Элек бала-чага күбрәк әби-бабай тәрбиясендә үсә иде. Хәзерге яшьләр әти-әнисеннән аерым яшәүне хуп күрә. Шунлыктан мондый гаиләләрдә әби-бабай оныклар тәрбияләү белән бөтенләй диярлек шөгыльләнми. Югыйсә тормыш тәҗрибәләре бик зур, алар оныкларына ныклы тәрбия бирә алыр иде. Ләкин әби-бабайлар белән яшәгән гаиләләр бүген бик сирәк шул.

Спорт та, бер караганда, әйбәт тәрбия чарасы. Ул күпмедер дәрәҗәдә яшьләрнең вакытын, дәрманын ала. Әмма спортка кереп китеп тә урам малаена әйләнеп, кеше кыйнап йөргән яшьләр турында да ишетеп беләм мин. Алар арасында «мин көчле, бүтәннәрдән өстен, теләсә-кемне сугам да егам», дип йөрүчеләр дә очрый әле. Спорт кирәк, бу турыда бернинди бәхәснең булуы мөмкин түгел. Ләкин кешенең рухи нигезе нык булмаса, аны спорт кына коткарып кала алмый.

Ни кызганыч, бала күңеленә рухи байлыкны иңдерү мөмкинлеге елдан-ел кими бара. Чөнки балаларның күбесе әдәбияттан-сәнгатьтән бизде. Укучылар әдәбият дәресләренә бигүк теләп йөрми. Әдәбият дәресләренең саны да азайды. Гомумән, безнең җәмгыятьтә әдәбиятка, сәнгатькә игътибар бермә-бер кимеде. Дөрес, соңгы елларда дәүләтебез мәгарифкә игътибарны арттырырга тырыша. Бу җәһәттән төрле гамәлләр кылынды, программалар, законнар кабул ителде, укытучыларның хезмәт хакы артты. Хәзер мәгариф тармагында уртача хезмәт хакы 28 мең сумга житеп килә. Бусы яхшы. Ләкин мәгарифнең туганы булган мәдәниятка игътибар артмады. Авыл җирләрендә бүген мәдәният хезмәткәренә аена уртача 7-8 мең сум түлиләр. Ә республика буенча мәдәният хезмәткәренең уртача эш хакы 14 мең сум. Хезмәткә түләү аз икән, анда инде югары әзерлекле профессиональ кадрлар килми. Шуңа күрә эшнең сыйфаты да түбән була.

Бюджет кабул иткән сессиядә мин: «Мәдәниятка акчаны 1 сумга кимрәк бирсәк, киләчәктә хокук саклау органнарына 10 сум артыграк бирергә мәҗбүр булачакбыз», — дигән идем. Юк, җинаятьчелеккә каршы көрәшүгә, хокук саклау органнарын җитәрлек дәрәҗәдә финанслауга һич тә каршы түгелмен. Әмма җинаятьчелекне бетерүнең бердәнбер чарасы полициягә яңа форма-кием тектерү, импортный күсәк сатып алу яисә яңа төрмәләр төзү генә дип уйлау да дөрес түгел. Культурасыз, мәдәниятсез җәмгыятьнең беркайчан да җинаятьчелектән башы чыкмасына иманым камил.

Соңгы елларда бездә Президент фәрманы белән клублар, Мәдәният йортлары төзелә башлады. Әмма шушы Мәдәният сарайларында эшләргә әзерлекле белгечләр җитми. Бу хакта күптән түгел Президент үзе дә искәртте. Татарстан Дәүләт Советы әлеге уңайдан тәкъдимнәр белән дә чыкты. Бюджет хисабына укып, вуз тәмамлаучыларны эшкә билгеләү хакында Россия Дәүләт Думасына закон проекты да эшләп җибәрдек. Совет чорында уку йортын тәмамлаучыларны эшкә тәгаенләү, өч елга эшкә җибәрү, минемчә, начар нәрсә түгел иде. Яшьләр дөнья күреп, тормышны өйрәнеп кайталар иде. Кайберләре шунда төпләнеп тә калды. Ә хәзер уку йортын тәмамлаучылар эш таба алмыйча Казан урамында киләп сарып йөри яисә базарда сату итә. Әнә, Ветеринария академиясен тәмамлаучыларның дүрт проценты гына авылга кайтып эшли икән. Югыйсә сыерлар, сарыклар Казанда түгел, авылда бит. Авыл хуҗалыгы университетын тәмамлаучыларның да, рәсми мәгълүматларга караганда, 40 проценты гына үз белгечлеге буенча эшли. Чынлыкта ул тагын да азрактыр әле. Болай укытуның хөкүмәткә дә, халыкка да файдасы юк. Халыктан җыйган налог хисабына укучы кешене халыкка хезмәткә җибәрергә кирәк. Әгәр үз акчаны түләп укыйсың икән, анысы инде башка мәсьәлә. Билгеле, белгечне авыл-район җиренә җибәрәсең икән, аңа уңайлы торак, тиешле хезмәт хакы бирү, эш шартлары тудыру зарур. Әмма безнең бу тәкъдимебез Россия Дәүләт Думасында тулаем яклау тапмады. Бәлки, мәсьәлә киләчәктә уңай хәл ителер. Чөнки бу мәсьәләне чишүнең бүгенгә башка юлы юк.

Белгечләр белән тәэмин итү ягыннан шәһәрләрдәге мәдәният учакларының хәле күпкә яхшырак. Театрларыбызның да матди хәле шактый яхшырды. «Әкият» Курчак театрына менә дигән итеп яңа бина салып куйдылар. Г.Камал, К.Тинчурин, В.Качалов, Опера һәм балет театрлары биналары ремонтланды. Г.Кариев театрының

гына әлегә хәле авыр. Озакламый бу мәсьәлә дә хәл ителергә тиеш. «Әкият» театрында бер буш зал бар. Театр әлегә анда кереп торачак. Офицерлар йорты бинасы ремонтлангач, Г.Кариев театры шунда күчәчәк.

Мәдәниятнең әле тагын бер бик тә четерекле өлкәсе — иҗат берлекләре бар. Муллаcыз, мәзинсез мәчет булмаган кебек, язучысыз, композиторсыз, рәссамсыз милләт тулы канлы, цивилизацияле милләт була алмый. Дөрес, хөкүмәтебез һәр ел саен бюджеттан иҗат берлекләренә җан асрарлык кына булса да өлеш чыгарып тора. Әмма инфляция һәм бәяләр арту сәбәпле, бу акча аларның иң кирәкле ихтыяҗларын капларга да җитми. Ә инде гонорар мәсьәләсенә килсәк, эшләр тагын да катлаулырак. Инде ике дистә елдан артык республикабызда гонорар системасы игътибардан читтә калып килә. Бүген бездә гонорар хисабына гына профессиональ язучы, профессиональ композитор яисә рәссам булып яшәү, гаилә асрау мөмкин нәрсә түгел. Ел саен бюджет хезмәткәрләренең эш хакы беркадәр артса да, гонорар нишләптер арттырылмый, индексацияләнми, киресенчә, аның күләме елдан-ел кими генә бара, җитмәсә, авторлар шушы барлы-юклы акчаны да еллар буе ала алмыйча тилмерә. Ә югыйсә гонорар ул күктән иңгән әсәр өчен бирелгән сәдака да, хәер дә, бүләк тә түгел. Гонорар ул — иҗат кешесенең төн йокыларын, елларын исраф итеп, йөрәк каны белән язылган, иҗат ителгән әсәрләре өчен түләү, димәк, аның хезмәт хакы. Әгәр дә моны белмәүчеләр яисә аңламаучылар булса, үзләре эштән соң төн утырып роман яисә поэма, симфония яисә картина язып-ясап карасыннар иде. Әгәр дә тиз арада тиешле чаралар күреп, гонорар түләү системасын уңай хәл итмәсәк, тәртипкә салмасак, безнең профессиональ сәнгатебезнең тагын да авыррак хәлгә калуы, мәдәниятебезнең тулаем һәвәскәрлек, үзешчәнлек дәрәҗәсенә тәгәрәве мөмкин.

Кайсы тармак турында сүз алып барсак та, коллективның хезмәт хакына, матди нигезебезгә әйләнеп кайтабыз. Башкалабыздагы берничә театрдан кала әлегә күпчелек сәхнә хезмәткәрләренең дә эш хакы мактанырлык түгел. Авылларда клубларыбыз тиешенчә җиһазландырылмаган. Хәтта бер гармун белән генә «мәдәниятебезне үстерергә» тырышып утырганнары да бар. Андыйларда эш ничек гөрләп барсын ди инде?! Киләчәктә мәдәният өлкәсендәге мәсьәләләрне эченә алган дәүләт программасы булдыру кирәк. Бездә моның матур үрнәкләре дә бар инде. Мәсәлән, мәгарифне үстерү өчен — «Киләчәк», балалар бакчалары буенча «Бәләкәч» программалары кабул ителде. Аларны гамәлгә ашыруга ел саен бюджеттан миллиардларча сум акча бирелә. Мәдәниятне үстерү буенча безгә үзебезнең тәкъдимнәребезне бергәләшеп республика җитәкчелегенә җиткерергә кирәк.

Татарстанда шактый еллардан бирле дәүләт телләрен һәм республикада яшәүче башка халыкларның телләрен үстерү программасы эшләп килә. Узган елны без аның чираттагысын, киләсе 7 елга исәпләнгән шактый камилләшкән вариантын кабул иттек. Аны гамәлгә ашыру өчен тиешле механизм да эшләнде, акчасы да шактый мул бирелде. Чөнки беләбез: телебез бетсә, милләтебез дә юкка чыгачак. Бу — һәммәбезгә дә билгеле. Ә менә музыкасыз, моңсыз, көйсез милләт була ала микән? Бу турыда да уйланырга вакыт. Республикабызда музыка сәнгатен үстерү буенча да шундыйрак программа эшләнергә тиеш. Югыйсә хәзер күпчелек музыкаль әсәрләрнең кайсы халыкныкы икәнен дә аңлап, аерып булмый. Аңа нинди телдә текст язсаң да барыбер, чөнки аның милли нигезе юк. Концерт оешмаларына, радио-телевидениегә талымлырак булу, җырларны да, җырчыларны да сәхнәгә һәм эфирга сайлабрак чыгару зарур.

Бүген татарча иң мәгънәсез сүзне ишетәсең килсә, эстрада җырларының сүзләрен тыңла. Көйләренең дә төрлесе бар. Ә сүзләренең туксан тугыз проценты бер нәрсәгә дә ярамый, анда шигъриятнең исе дә юк. Хәзер кайбер җырчыларыбыз юньле җыр юк дип зарланалар, яна, яхшы җырларның табадан төшүен көтеп яталар. Нишләп бездә яхшы җырлар булмасын ди? Мәсәлән, 50-60-70нче елларда иҗат иткән классик композиторларыбыз онытылып бара. Заһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи, Хөснулла Вәлиуллин, Александр Ключарёв, Мансур Мозаффаров, Исмай Шәмсетдинов, Аллаһияр Вәлиуллин, Мирсәет Яруллин, Фасил Әхмәтов язган искиткеч җырлар бар лабаса! Алар — безнең җыр сәнгатенең алтын фонды. Ник аларны җырламыйлар? Әйтик, Җәүдәт Фәйзинең Һади Такташ сүзләренә язган «Урман кызы» — ул бит

классика. Аны мин көн саен иртәдән кичкә кадәр тыңларга әзер. Чын татар жыры менә нинди булырга тиеш! Салих Сәйдәштән, Солтан Габәшиләрдән башланган жыр мәктәбе ул. Аның соңгы могиканы Фасил Әхмәтов булгандыр. Фасил Әхмәтовтан соң инде татар моңы сүнә, жырыбызда миллилек көннән-көн кими башлады. Дөрес, алардан соң да Резеда Ахиярова, Луиза Батыр-Болгари, Рәшит Абдуллиннар матур-матур жырлар ижат иттеләр. Ә бүген миллилек инде бөтенләй юк диярлек. Рухи дөньябызда, жыр-моң, музыка өлкәсендә иң зур бәлабез дә шушында — дәвамлылык, эзлеклелек бетүдә. Бу яктан караганда, безнең консерваториябез бүген бик зәгыйфь. Казан консерваториясе Татарстанда булса да, татарныкы түгел. Дөрес, анда кулдан килгән кадәр тырышалар, азаплана-азаплана милли музыка факультеты да ачтылар. Әмма ул факультет хәзергә зур бер чиркәүнең почмагында намазлык җәеп, намаз укып утырган мөселман агае хәлендә генә.

Мәдәният дигәндә без шәһәрләребезнең һәм авылларыбызның архитектурасына да җитәрлек игътибар бирмибез. Бүгенге архитектурабызда бөтенләй диярлек милли чалым юк. Мин берничә тапкыр Казакъстанга, аның башкаласы Астанага барып кайттым. Астана бик матур. Үзе заманча, үзе милли. Башкала монда күчкәч, алар бүгенге заман шәһәр төзелеше буенча Япониянең иң оста архитекторын чакырганнар, ә милли бизәкләр эшләүне үз осталарына кушканнар. Япон һәм казакъ архитекторы бергәләп эшләгәч, матур бизәлешле, милли рухлы, менә дигән заманча шәһәр барлыкка килгән. Безгә дә мондый тәҗрибәне кулланырга кирәктер. Ләкин бу хакта ныклап уйлаган кеше күренми әлегә. Дөрес, рухы белән безгә якын шәрекъ илләреннән булмаса да, Испаниядән һәм Голландиядән архитекторлар килгәләде, ләкин әлегә аларның да нәтиҗәләре күренмәде. Универсиаданы каршылау чорында Казанда шактый эшләр башкарылды башкарылуын. Аерым алганда, Иске Татар бистәсен торгызуга керештеләр. Дөрес, хәзергә ике урам гына тәртипкә китерелгән. Әмма алар да Казанга нур өстәде кебек. Элек кунаклар килгәч, кая алып барырга, нәрсә күрсәтергә дип аптырый идек. Хәзер Сөембикә манарасын, Кол Шәриф мәчетен һәм Татар бистәсен теләсә-кемгә горурланып күрсәтергә була.

Алабугада да шәһәрнең 1000 еллыгы уңаеннан шактый уңай үзгәрешләр булды. Ләкин анда татар чалымнары бик аз. Ул, нигездә, урыс шәһәре буларак торгызылды. Югыйсә Алабугада гомер бакый татарлар күпләп яшәгән. Гомумән, республикабыз шәһәрләре бер-берсенә нык охшаган. Урамнарда йөргәндә, кайчак кайсы шәһәрдә икәнлегенне дә онытып җибәрәсен.

Төрки халыкларның мәдәни дөньясын берләштерүче ТӨРКСОЙ оешмасы 2014 елда Казан каласын үзенең Мәдәни башкаласы дип игълан итте. Бу инде, нур өстенә нур булып, безнең мәдәни елыбызның эчтәлеген баетыр, яңа вакыйгалар, яңа төсмерләр өстәр дип уйлыйм. Ел дәвамында Казанга төрки халыкларның мәшһүр иҗат коллективлары, күренекле шагыйрьләре, язучылары, галимнәре, рәссамнары, музыкантлары киләчәк, сентябрь аенда Мөселман киносы фестивале узачак. ТӨРКСОЙ бәйрәменә кунаклар җыелгач, бер-беребез белән ныклап аралашу, үрнәк алу, тәҗрибә уртаклашу мөмкинлеге туар. Әлеге чараларга мин аерым бер игътибар булыр дип исәплим. Без — төрки халыклар, бер-беребезгә тартылабыз. Чөнки бердәм булсак кына милләтләребезне саклап кала алачагыбызны яхшы аңлыйбыз. Дөньяда бит славян халыклары да, инглиз телле халыклар да глобализация чорында бер-берсен яклау өчен шулай бергә туплана. Аларның махсус оешмалары да бар. Төрки халыкларның ТӨРКСОЙ оешмасы да нәкъ шундый максат белән төзелде.

Узган елны Универсиаданы каршылау көннәрендә Казанның Яңа Савин районында бер бик яхшы гамәл кылынды — Истанбул паркы ачылды. Бу Истанбулда Тукай паркы ачылуга үзенчәлекле җавап булды. Мәдәният елында Үзбәкстанның да, Казакъстанның да, Төрекмәнстанның да, Кыргызстанның да, Азәрбайҗанның да бездә парклары, скверлары, урамнары булдырылсын иде. Татарстанда ул халыкларның күпләгән вәкилләре яши, иҗтимагый оешмалары да бар. Шәһәр-район җитәкчелеге белән бергәләп алар бу урыннарны карап, кайгыртып торырлар иде. Мондый чаралар туганлаш халыкларыбызны тагын да ныграк якынайтыр иде. Әнә, азнакайлылар Төркиянең Тартус шәһәре белән дуслашканнар. Азнакайда Тартус паркы бар, ә Тартуста Азнакай паркы ачылган. Югыйсә «без — кардәш,

тугандаш халыклар», дип сөйләнеп йөрүдән генә әллә ни үзгәрмәячәк. Казанда төрек мәдәнияте үзәге оештырылса да яхшы булыр иде. Төрекләр бу турыда күптән хыяллана. Билгеле, Казанда Төркиянең генераль консуллыгы бар, ул шактый актив эш алып бара. Ләкин болар гына аз.

Бу елга иң зур теләгем, өметем — ниһаять, мәдәнияткә игътибар артсын иде. Матди яктан да, финанслау ягыннан да. Әмма мәдәнияткә караш әлегә төрле районда, төрле шәһәрдә төрлечә. Китапханәләргә китап алу өчен ун мең сум акча бирмәгән районнар да юк түгел. Ә кайберләре исә мәдәният өчен дистәләгән, йөзләгән миллионнар сарыф итә. Мәдәният йортлары сала, аларга җиһазлар ала. Мәдәният елында район башлыкларына бу өлкәдә таләпне тагын да арттыра төшәргә кирәк. Тагын шунысы да бар: һәр районнан, авылдан диярлек зур җитәкчеләр, зур табышлы эшкуарлар чыккан. Билгеле, алар да туган төбәкләрендә мәдәниятне үстерүгә ярдәм итә алырлар иде. Андый кешеләрне барлау, очрашып киңәшү шулай ук район хуҗаларының бурычы.

Мәдәниятнең язмышы бүген кемнәр кулында? Зинһар өчен, бу сорауга «мәдәният министры кулында», дип әйтергә ашыкмагыз. Ул заманнар узды. Мәдәният министрлыгы бүген, нигездә, республика оешмалары өчен генә җавап бирә. Чөнки ул оешмаларга каралган акча гына аның кесәсе аша үтә. Ә районнарда һәм шәһәрләрдә мәдәният проблемалары белән тулысынча хакимият башлыклары шөгыльләнә. Әгәр хакимият башлыгының күңеле культурага ята икән, әгәр ул чын мәгънәсендә халык язмышын кайгыртучы зыялы, белемле интеллигент кеше икән, димәк, районда мәдәнияткә, мәгарифкә, туган телгә, гореф-гадәтләргә игътибар булачак. Әгәр дә инде хакимият башлыгының йорты райондагы Мәдәният сараеннан да мәһабәтрәк, ә авылдагы клублары ташландык хәлдә икән, әгәр аның рухи ихтыяҗы мәҗлестә гармун тартып, «Баламишкин»ны җырлап утыруга гына кайтып кала икән, димәк, бу районда мәдәниятнең хәлләре мөшкел булачак.

Мин Кремльдәге Президент сараена барган саен, андагы рәсемнәргә, картиналарга карап сокланып йөрим. Ә сезнең менә кайсы да булса район хакимияте бинасында шундый зәвык белән тупланган картиналар галереясын яисә югары сәнгатьле бизәлешне күргәнегез бармы? Әйе, Чаллы һәм Түбән Кама мэриясе биналарын, Сабадагы элекке хакимият бинасында ачылган чын мәгънәсендәге сәнгать йортын атап һәм тагын шундый берничә мисал китереп буладыр. Әмма алар гына аз, бик тә аз. Президентыбыз, депутатларыбыз киләчәктә хакимият башлыкларын сайлаганда, аларның эшлеклелек сыйфатлары белән бергә культура дәрәҗәсенә, рухи дөньясына, мәдәнияткә, мәгарифкә, туган телгә булган мөнәсәбәтләренә дә игътибар итсәләр иде.

Соңгы елларда республикабызда йөзләгән мәчет салынды. Әмма бүген аларның шактыенда имамнар юк. Имам булмагач, халык мәчеткә йөрми. Авылга килгән имамнарга да шартлар тудырырга кирәк бит. Кызганыч ки, мона кадәр атеизм чорында 70-80 ел имансыз яшәдек, хәзер исә имамсыз яшибез, диярге генә кала. Ә дин безнең рухи дөньябызның аерылгысыз өлеше бит.

Мәдәният елына без бик зур өметләр баглыйбыз, аннан бик күпне өмет итәбез. Безнең быел ук Чаллы һәм Түбән Кама калаларында театр биналары салынуын, Милли китапханә өчен, ниһаять, Казанда махсус бина төзелүен, янадан корылган «Болгар» кунакханәсендә «Тукай мемориалы» оешуын, «Шәрекъ клубы» бинасында театр музее корылуын, элекке Матбугат йортында зур китап кибете ачылуын, республиканың һәр район үзәгендә китап сәүдәсе булдырылуын һәм шуның кебек тагын йөзләгән куанычлы мәдәни вакыйганы күрәсебез килә. Әмма боларның һәммәсен дә бер елда гына эшләп булмасын да яхшы аңлыйбыз. Безнең быелгы Мәдәният елыбыз шушы игелекле эшләргә нигез салучы, старт бирүче бәрәкәтле ел булып тарихка кереп калсын иде.

**Разил ВӘЛИЕВ,**
*Татарстанның халык шагыйре,*
*Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән,*
*мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе*

# БЕРГӘ – БЕРӘГӘЙЛЕ!

*1. Төрки дөньяда, шул исәптән Төркия – Татарстан арасында да озак еллар буена өзелеп торган бәйләнешләрне торгызу-ныгыту максатында, Сез Татарстан Республикасы мәдәният министры булып эшләгән чорда нинди эш-гамәлләр башкарылды? Шуларны искә төшереп алсак иде.*

*2. Төрки дәүләтләрнең бөтен дөньяга сибелеп-чәчелеп килгән әдәби-мәдәни һәм рухи мирасын барлау, аларны бергә җыю максатында, быел төрки дөньяның мәдәни башкаласы булуын күздә тотып, Казанның бүгенге мөмкинлекләре һәм алардан файдалану турында тәкъдимнәрегез нинди?*

*Без әлеге сораулар белән ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы нигезләнгән һәм эшчәнлеген җәелдерә барган дәвернең төрле елларында Татарстан Республикасы мәдәният министры булып эшләгән шәхесләргә мөрәҗәгать иттек.*



*1985-1999 елларда*
*Татарстан Республикасының мәдәният министры*
**Марсель ТАИШЕВ:**

Демографик мәгълүматларга караганда, бүген планетада төрки халык саны 200 миллионнан артып китә. Төрек дөньясы Евразия континентының саллы өлешен алып тора, аның күпгасырлык мәдәнияте һәм бай мирасы гомумкешелек цивилизациясендә биниһая зур урын били.

Бу мирасны саклау, рухи байлыкны арттыру, мәдәни бәйләнешләрне ныгыту һәм киңәйтү максатында ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы төзелде. 1993 елның 12 июлендә Алматы шәһәрендә Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Төркия һәм Үзбәкстан республикаларының мәдәният министрлары шул хакта килешүгә кул куйды. Шул ук елны Татарстан ТӨРКСОЙга күзәтүче статусында кабул ителде. Соңрак безгә Алтай, Башкортстан, Саха (Якут), Тува, Хакас, Гагауз (Молдова) һәм Төньяк Кипрның Төрек республикалары кушылды.

Әлеге оешманың җитәкче органы — төрки илләр мәдәният министрларының Даими советы. Ул елга ике тапкыр җыела. Башкарма орган — ТӨРКСОЙның генераль секретариаты. Ул — Анкарада.

ТӨРКСОЙ аша оештырылган халыкара чаралар кайсы гына өлкәгә багышланмасын — театр, музыка, опера-балет, сынлы сәнгать, кинематография, әдәбият, мәгарифне үстерүме — Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы аларның һәркайсында актив катнашты. Төрледән-төрле фестивальләрдә, бөек шәхесләрнең юбилейларына багышланган кичәләрдә татар халкының мәдәниятен күренекле артистларыбыз белән бергә талантлы яшьләребез, югары уку йортларында укучы мәдәният һәм сәнгатьне юлдаш иткән студентлар да калку итеп күрсәтте. Чит илләрдә гастрольләрдә төрек дөньясы сәхнәләрен профессиональ театр коллективлары, дәүләт ансамбльләре белән бергә үзешчәннәр дә лаеклы тотты.

1994 елның февралендә мәдәният министрларының Мәрмәристә (Төркия) уздырылган киңәшмәсендә опера фестивале үткәрү турында карар кабул ителде. Әлеге чара ТӨРКСОЙ тарихында күркәм традициягә әверелде. Һәр елны Кипрда үткәрелә торган бу фестивальдә республикабызның опера җырчылары да, Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе студентлары да бик теләп катнаша.

Төрки халыкларның гомуми мәдәни мирасы буларак ЮНЕСКО исемлегенә кертелгән Нәүруз бәйрәме дә — әһәмиятле вакыйга. Ул кайда гына үтмәсен, аның

кысаларында оештырылган концертлар — жыр-бию тантанасы, учак ягу, тимер сугу, йомырка буяу, милли ризыклар белән сыйлау кебек борынгы символик йолалар, гомумән, төрки дөньядагы бихисап бизәк-төсләрнең гаҗәеп балкышы, мәдәни мирасыбызны, гореф-гадәтләребезне киләчәк буыннарга тапшыруның матур үрнәге.

Төрки илләр рәссамнарының 1998 елда ачылган халыкара иҗат лабораторияләре — шулай ук ТӨРКСОЙ кысаларында үткәрелә торган кызыклы проектларның берсе. Анда рәссамнар үзара тәҗрибә уртаклаша, сынлы сәнгать проблемаларын уртага салып сөйләшә, яшь рәссамнарның иҗатына бәя бирә. Бу чараларда катнашкан рәссамнарыбызның байтак эшләре бүген ТӨРКСОЙның сынлы сәнгать коллекциясендә саклана.

Берничә ел Төркия шәһәрләрендә, шулай ук дөньяның Лондон, Париж, Нью-Йорк, Мәскәү кебек калаларында рәссамнарыбыз иҗатына багышланган күргәзмәләр ачылды. Татарстан Республикасының сынлы сәнгать музеенда ачылган күргәзмәгә дә ТӨРКСОЙ илләре рәссамнары һәм фоторәссамнарының иң яхшы әсәрләре куелды.

Китапханәләр арасындагы элемтәләрне ныгыту, музейлар эшчәнлеген камилләштерү дә — киң колачлы уртак эш. Бу максатта уздырылган фәнни-гамәли конференцияләр, семинарлар, очрашуларда республикабыз фәнни хезмәткәрләре актив катнашты. Басма продукция, шул исәптән газета-журналлар, китаплар алмашу төрки илләр китапханәләре арасындагы бәйләнешләрнең матур традициясенә әверелде.

Төркиянең Измир, Адана, Искешәһәр, Анкара, Болу шәһәрләрендә узган курчак һәм күләгәләр театрларының халыкара фестивальләрендә республикабызны «Әкият» татар дәүләт курчак театры лаеклы рәвештә күрсәтте.

1998 елда Татарстан Республикасында туган төрки халыкларның «Нәүруз» халыкара театр фестивале, озын иҗади юл үтеп, зур популярлык казанды. Узган ел аның унберенчесе үткәрелде. Сүз дә юк, мондый киң колачлы фестивальнең, анда төрки театрларның төрледән-төрле спектакльләрен күрсәтүнең үзара элемтәләрне ныгытуда, тәҗрибә уртаклашуда, милли драматургиянең, театраль культураның эстетик дәрәҗәсен күтәрүдә, төрки дөнья мәдәниятен үстерүдә, аның яңарышын тәэмин итүдә ярдәме зур. Шунысын да искәртү кирәк: «Нәүруз»не гамәлгә куючыларның берсе — ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе дә ТӨРКСОЙ илләре белән элемтәләрне киң җәелдерде. 1995 елдан башлап Төркия, Казакъстан, Кыргызстанның архив хезмәтләре белән хезмәттәшлек итү турында килешүләр төзелде, соңрак Азәрбайҗан, Үзбәкстан архив ведомстволары белән мөнәсәбәтләр җайга салынды. Россия Федерациясенә кергән төрки республикалар да игътибардан читтә калмады. 1999 елда Башкортстан Республикасының Архив эшләре буенча идарәсе белән килешү төзелде. Уртак эшнең нәтиҗәләре дә озак көттермәде. Соңгы ике дистәгә якын ел эчендә республикабыз архивларына төрки илләрдән Татарстан Республикасы һәм татар халкының тарихына кагылышлы меңгә якын документның төп нөсхәләре һәм күчермәләре керде. Төркия архивлары белән дә эш уңышлы барды. Күп кенә кыйммәтле документларның күчермәләрен алдык (бушлай). Бу илнең архив хезмәткәрләре тарафыннан «Казань в османских документах» дигән җыентык та нәшер ителде. Бездә аларның ярдәме белән «Документы по истории Волго-Уральского региона XVI-XIX веков из древнехранилищ Турции» һәм «Восточная Европа Средневековья и раннего Нового времени глазами французских исследователей» дип аталган җыентыклар дөнья күрде.

ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге төрки илләрдәге хөкүмәтнең даими ярдәменә бәйле. Бу җәһәттән Төркия Республикасы Президенты Сөләйман Демирель белән очрашуларны искә алмый мөмкин түгел. Аның дөньякүләм сәясәт, төрки халыкларның культурасы, Җир шарында тоткан урыны, ТӨРКСОЙ халыкара оешмасының максатлары һәм бурычлары, Россия Федерациясендә һәм элеккеге Союздаш республикаларда яшәүче кардәшләребез турындагы уй-фикерләре онытылмаслык тәэсирләр, ихлас кызыксыну һәм бу кешегә

хөрмәт уятты. Азәрбайжан, Казакъстан, Кыргызстан, Татарстан һәм Башкортстан Президентлары белән очрашулар, аларның төрки дөнья мәдәнияте проблемаларына игътибарлы һәм кайгыртучан мөнәсәбәте шулай ук ихтирамга лаек.

ТӨРКСОЙ халыкара оешмасын оештыруда һәм аның эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә ирешүдә үзеннән зур өлеш керткән тагын бер шәхесне әйтеп китми булмый. Ул — мәдәният проблемаларын тирәннән белгән, Төркия хөкүмәте вәкилләре белән аралашканда, үзен чын дипломат итеп күрсәткән (ТӨРКСОЙ бинасы төзелешенә акча күчерү мәсьәләләре турында сөйләшергә Төркия Республикасы финанс министрына бергәләп кердек), югары квалификацияле белгеч, ышанычлы дус һәм иптәш, ТӨРКСОЙ оештырылган көннән 2008 елның маена кадәр аның Генераль секретаре Полад Бюльбюль углы. Ул чакта Азәрбайжан Республикасы мәдәният министры, хәзер Азәрбайжан Республикасының Россия Федерациясендәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе.

Төрки илләр мәдәният министрлыклары ТӨРКСОЙ кысаларында бергәләп эшләгән елларда яуланган уңышлар — үзара аңлашу, дөньяда төрки халыклар мәдәниятләренең позицияләрен ныгыту теләге белән яну нәтиҗәсе. Казан шәһәренең 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы булуы күпмилләтле Татарстан Республикасының мәдәнияттә ирешкән зур уңышларын тану дип бәяләргә кирәк. Киләчәктә казанышларыбыз тагын да зуррак булыр, Казан төрки илләрнең мәдәниятен, шул исәптән республикабызның һәм халкыбызның рухи мирасын, интеллектуаль-эстетик кыйммәтләрен дөньяга таныткуга үзеннән зур өлеш кертер дип ышанып калам.



*1999-2005 елларда*
*Татарстан Республикасының мәдәният министры*
**Илдус ТАРХАНОВ:**

Интеллектуаль-эстетик һәм рухи-әхлакый кыйммәтләргә бай булган төрки дәүләтләр дөнья цивилизациясе үсешендә әһәмиятле роль уйнады һәм уйный. Бу җәһәттән гуманитар өлкәдә үзара эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруда һәм бердәм Евразия мәдәни киңлеген формалаштыруда максатчан, конструктив адымнар ясаучы ТӨРКСОЙ халыкара оешмасының ролен бәяләп бетерү мөмкин түгел. Аның күпкырлы эшчәнлеге нәтиҗәсендә 1995-2005 елларда төрки халыкларның милли мәдәниятләрен үзара баету процессы сизелерлек тизләнеш алды.

Республикабыз да моңа үз өлешен кертте. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгына Россия Федерациясе субъектларындагы төрки халыкларның мәдәният буенча Координацион советын булдыру проектын яклауны сорап мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы һәм аның күпмилләтле халкы ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы эшчәнлегенең шифалы җимешләрен шушы чорда ук татыды. Мәсәлән, 1995-2005 елларда, әдәбият, мәдәният һәм сәнгать җәүһәрләре «Идегәй» эпосын һәм болгар-татар цивилизациясенең язма һәйкәл-истәлекләрен бастырып чыгару, «Нәүрүз» халыкара театр фестивале, Рудольф Нуриев исемендәге халыкара балет сәнгате фестивале дөньякүләм әһәмияткә ия зур тарихи вакыйгалар буларак бәяләнергә хаклы.

Республиканың татар һәм башка халыкларның күп буыннары барлыкка китергән мәдәни потенциалы, куәте ТӨРКСОЙ халыкара оешмасының арадашчы эшчәнлеге нәтиҗәсендә дөнья мәдәни киңлегендә үз урынын алды.

Төркия Республикасы белән мәдәни элемтәләребез елдан-ел ныгый барды. Татарстан Республикасы сәнгать осталарының Төркия театр һәм концерт мәйданнарында чыгыш ясавы инде күркәм традициягә әйләнде. Республикабыз иҗат коллективлары ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы гына түгел, ә Төркия Республикасының муниципаль һәм республика органнары тарафыннан да үткәрелә торган халыкара фестивальләрдә, конкурсларда бүген дә катнашып килә.




Шушы чорда татар язучыларының шигырьләре ТӨРКСОЙ әгъзалары булган илләр шагыйрьләренең традицион халыкара очрашуларында яңгырый башлады. Татарстан Республикасы рәссамнары да төрки илләр рәссамнарының халыкара күргәзмәләрендә даими катнаша.

ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы алдында торган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән эшчәнлекнең тагын бер төре — китапханәләр арасындагы бәйләнешләр. Шушы чорда Татарстан Республикасы китапханәләре Төркия, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан һәм башка илләрнең китаханәләре белән актив хезмәттәшлек итә башлады.

Шунысы бәхәссез: 2003-2004 елларда иң мөһим һәм истәлекле вакыйгаларының берсе Россиянең татарлар тупланып яшәгән төбәкләрендә милли бәйрәм — Сабантуйны үткәрү булды. Бу бәйрәм шушы ике елда Россиянең 53 төбәген колачлады. Сабан туе профессиональ сәнгать осталары катнашында Төркиядә, Латвиядә һәм Казакъстанда зурлап үткәрелде.

Төрки дәүләтләрнең бөтен дөньяга сибелеп-чәчелеп килгән әдәби-мәдәни һәм рухи мирасын барлау, аларны бергә җыю максатында, республикабызның һәм халкыбызның бай мәдәни мирасыннан файдаланып, көчләребезне берләштерергә кирәк дип саныйм.

Евразия дөньясы алдында торган иң мөһим бурычларның берсе — үз илләрен Көнбатышның техник куәте белән Көнчыгышның табигый байлыклары очрашкан урынга әйләндерү. Икътисади интеграция безнең илләрнең мәдәни уртаклыгы нигезенә таянырга тиеш.

ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы эшчәнлеге кысаларында, евразиячелек идеяләрен ТӨРКСОЙның төп идеяләренә бәйләп, көчләрне берләштереп, төрки халыкларның иҗтимагый сәнгать академиясен булдырырга вакыт җитте дип саныйм (бу тәкъдим минем тарафтан «ТӨРКСОЙ» халыкара оешмасы Даими советының Астана шәһәрендә узган XXI утырышында әйтелгән иде).

**Али АКБАШ,**
*төрек шагыйре*

## Тукай

Телендә — сүз энҗеләре,
Энҗегә ул бик бай иде,
Ачылыр бер чәчәк иде,
Үксез бер тай иде
Тукай.

Саз итте ул үз күнелен,
Моңланганда сазга дәште,
Күнеленең хәзинәсен
Бар дөньяга чәчте
Тукай.

Үзен Йосыф дип санады,
Базарларда да сыналды,
Газапларга да чыдады...
Чыра булып янды
Тукай.

Идел белән алышты ул,
Тел белән дә ярышты ул,
Дәрьяларга ябышты ул...
Тере инеш иде
Тукай.

Курай кебек жансыз иде,
Газапларда ялгыз иде,
Күктәге бер йолдыз иде,
Вакытсыз атылды
Тукай.

Ак-карадан юл сызды ул,
Шәм кебек эреп сызды ул,
Теге дөньяга узды ул...
Жилгә охшап калды
Тукай.

Өзелде бер алтын яфрак,
Кабул итсен кара туфрак,
Милләт алдында йөзе ак,
Тик язмышы кара
Тукай.

И Казан, и газиз Казан,
Угыллар тудыр, дан казан!
Шагыйрь үксез, мәхрүм наздан...
Жәннәт кошы инде
Тукай.

*Р.Миңнуллин тәржемәсе*

**Нәжип Фазыл КЫСАКҮРӘК,**
*төрек шагыйре*

## Җырыбыз

Кырылыр да беркөн бөтен тешләләр,
Бер көйләнер шанлы тәгәрмәч безнен.
Күктән бер кул яшьле күзләрне сөртер,
Жанланыр өебез, көйләнгәч безнен.

Үрне кичеп, жиргә салырбыз эзне
Һәм табарбыз мәңге сүнмәс көндезне.
Хыялыбыз очар иярт ми күзне,
Башка галәмнәргә юлыбыз безнен.

Котылыр тел, тарих, әхлак вә иман,
Күрерләр: нинди ул, ни ул каһарман.
Жир вә күк су бирмәм дигән бу заман
Һәр арыкта суга юлыгыр безнең.

Китәрбез, нур тулы эздән китәрбез.
Бәгырьдә таш, сулар тездән, китәрбез.
Беркөн ахшам булыр, без дә китәрбез.
Калыр телләрдә тик җырыбыз безнең.

*Р.Зәйдулла тәрҗемәсе*

**Бабарәхим МӘШРАБ,**
*үзбәк шагыйре*

## Кызгансаң иде...

Йөрәгемне биргәнмен шәфкатьсез жанга —
Чиксез газаптан килә алмыйм һаман аңга.

Кызгансаң иде син мине, кара күзем,
Шундый авыр йөк күңелдә, ничек түзим?

Назлар көткән жаным әрнү-газап күрә,
Аллаһыма ялварамын, укып сүрә.

Ни хәл итим, сөюем җавапсыз калгач,
Бәгыремә сызлап торган яра салгач?

Керфекләрең үткен ук булып кадалды,
Ялган сүзеңә ышанып, нык алдандым.

Шуна Мәшраб хәсрәт утларында янды —
Төз гәүдәдән кара күмер генә калды.

*Ф.Тарханова тәрҗемәсе*

**Чулпан,**
*үзбәк шагыйре*

## Кит!..

Кит, күземне алдаган — чынлыктан нур!
Кит, утлар янган дөньямнан ары йөр!

Кит, зәһәрле гөлләреңне ыргытма;
Күңелдә соңгы өметне юк итмә.

Кит, илаһи вөжданымны болгатма,
Потлар белән чолгап, аны чуалтма!

Кит, әй, мисле пәри, гүзәл кара кош,
Утлар янган күкрәгемнән читтә оч.

Кит, сөюнен зур дошманы, күренмә!
Ләгънәт чәчеп яннарымда йөренмә...

**2**

Иске дуслар юл адашып үлделәр,
Яңа дуслар моннан бары көлделәр.

Яңа юлга аяк басмый туктасам,
Бу юлларда котылулар юк, дисәм,

Син ул чакта кайсы юлга өндәрсең?
Фәләк-язмышны нинди юл җинәр соң?!

Синдә тупас җан кыйнаучы холык бит.
Мәңгегә юк булсын синең барлык, кит!

Кит, мәләкләр дастанын да укытма,
Кит, мәгънәсез табышмаклар тукыма.

Кит, сөюе чын күкрәккә тынычлык бир,
Кит, синең өчен кочак ачкан — кара җир.

Кит, җанымны кыйнаучы сихерче-хур,
Кит, күңелемнән, әй алдаучы ялган нур!

*Р.Гаташ тәрҗемәсе*

**Магҗан ҖОМАБАЕВ,**
*казакъ шагыйре*

## Ут

Көннән туган баламын,
Яндырамын, янамын, —
Көнгә генә багынам.
Үзем — көнмен, үзем — ут,
Сүзем, кысык күзем ут, —
Үз-үземә табынам.
Җирдә ялгыз тәңре — ут.
Уттан башка тәңре юк.

Ялкын йомшак сөядер,
Сөйгән җирең — көядер, —
Ялмап-сыйпап юмалар.
Очраганны ут кылыр,
Ут кабынып юк кылыр.
Аның аты — Ут булыр.
Мин дә утмын — кабынам.
Ут — син, Тәңрем, — табынам.

Адәм — күкнең ялкыны,
Кысыр сулыш аркылы
Ялкын йоткандай тоям.
Гаиләм, өем, котыма,
Тиңсез тәңрем-утыма
Вакыт-вакыт май коям.

Май коямын — ут лачын
Күккә җәя колачын...

Көйде елан чорналып,
Көйде аждаһа ялманып —
Яндын, чыгар кем синнән?
Чынында мин үзем — ут.
Кысык кара күзем — ут.
Мин, уттанмын, ут — миннән.
Яндырамын, янамын,
Уттан туган баламын.

Караңгылык батканда,
Кояшы калыкканда,
Көн утыннан туганмын.
Йөрәгемне, җанымны,
Иманым, вөҗданымны
Ялкын белән юганмын.
Йөрәгем, җаным да — ут,
Иман, вөҗданым да — ут!

Ут яндырып туганга,
Бугазымнан буганга,
Караңгылык — дошманым.
Шул явызны юк итсәм,
Сукыр күзен ут итсәм
Үтим Тәңре кушканын:
Алып чыккан Алтайдан
Балкайгача — Кытайдан —
Барган юлым шул булыр...

Көннән туган баламын,
Яндырамын, янамын.
Үзем — Кояш, Үзем — Ут.
Сүзем, кысык күзем — Ут.
Үз-үземә табынам.
Җирдә ялгыз Тәңре — ут.
Уттан башка Тәңре юк!

*М.Әгъләм тәрҗемәсе*

**Моталип БЕППАЙЛАНЫ,**
*балкар шагыйре*

## Минем сөю

Бу фани дөнья
Сагыштан тора.
Әйләнә-тирәм
Гел сагыш кына.
Шатлык — сагышлы,
Кайгы — сагышлы.

Барыннан зуррак,
Ин олы сагыш
Ул — минем сөю,
Сөям дип көю!..

***

Ташландым мин
Кыядан
Шигырь яза башлаган
Көндә.

Шуннан бирле һаман
Очам...
Гел очам,
Житеп булмый жиргә.
Һаман очам...

## Кайгы

Сугышта һәлак булган
Улы кайгысыннан
Елап шашкан
Ананы күреп,

Таудан аска
Очышыннан
Кинәт
Туктап калды таш та...

## Кем соң мин?

Аллага да,
Шайтанга да
Ышанмый кеше.

Мина да бит
Ышанмыйлар.
Мин соң кем ише?..

## Кызгандылар

Сырхауланып,
Ятагыма аудым.
Тыз-быз килеп башта
Уйларым

Бер тәмугка,
Бер җәннәткә очты,
Гомеремне минем
Кызганып.

*Р.Корбан тәрҗемәсе*

**Диләвәр ОСМАНОВ,**
*кырымтатар шагыйре*

## Кырымым – Казаным

*Дустым Фәрит Солтановка багышлыйм*

Кырымым — туган йортым!
Синдә халкым, бабаларым.
Синдә тамырым,
Чал тарихым, зиратларым.
Синнән еракта жырларым,
Тик сина илтә уйларым.

Сине сагынып, саргаеп,
Казан илендә жырладым
Тукай жырларын.
Шунда эчтем Идел суларын.
Шунда сөйдем Сәйдәш моннарын,
Зәнгәр күзле татар кызларын.
Шунда таптым газиз дусларым,
Ләкин онытмадым
Кырым йолдызларын.

Кырымым, дисәм,
Көнләмә, Казаным!
Ике якта ике канатым сез,
Күктә, һавада.
Ике хәсрәтем, ике өметем
Бу дөньяда.
Берсе — газиз Ватаным,
Берсе — кардәш Казаным!

Тәнзилә **ДӘҮЛӘТБИРДИНА,**
*башкорт шагыйрәсе*

## Тел генәм

Сөйдергән дә, көйдергән дә
Гөлдәй асыл тел генәм!
Сандугачтай сайрар кошым
Җилфер, жиләс жил генәм,
Әй, тел генәм, тел генәм.

Ил генәмнең йөзек кашы,
Халкымның күз карасы.
Эзли күрче, таба күрче
Телне яклау чарасын.

Ата-бабам мирас иткән
Байлыгының иң мулын.
Аңга сеңгән сөекле тел,
Хәзинәгә тиң булып.

Бетмәслек бай хәзинәгә
Зыян салмасын яшьләр.
Алар белсә тел кадерен —
Милләтем дә мең яшәр!

*Г.Бәйрәмова тәрҗемәсе*

Петер **ХУЗАНГАЙ,**
*чуваш шагыйре*

## Татар шагыйрьләренә

Сөембикә манарасы тора
Казансуның яры буенда.
Татар шагыйрьләре! Башым иям,
Һичкайчан таш йөртмим куенда.

Төрткәләшеп алганбыздыр кайчак
Азиянең ишек төбендә.
Идел суы кызаргалап куйган
Һәм тапталган кырда игеннәр.

— Әссәламегаләйкем! — дим бүген,
Чын күңелдән заман әйттерә:
Тарих уртак безнең. Ни язсаң да,
Шул ике сүз: «коллык» һәм «көрәш»...

Мөһим түгел — кем бабасы болгар,
Кемнең хәзәр... Безгә дәшәсе:
— Яшәсеннәр Республикалар безнең!
Татар белән чуваш яшәсен!

Сөембикә манарасы тора,
Сүрелсә дә ае югары.
Татар шагыйрьләре! Башым иям,
Өем сездә, сезгә — юлларым.

*Р.Зәйдулла тәрҗемәсе*



Ахир

# ТАШ КАЛАДА БАШ КАЛА...

РОМАН

## 5

Кунаклар кичкә генә җыелып беттеләр. Аңа хәтле Мәхмүтнең кәләше Алсинә килеп, Инсафларның аш ягында матур итеп табын әзерләп китте. Мәхмүт Инсафка анасы ягыннан туган тиешле кеше иде. Алар яшьтән үк, балачактан ук бер-берсенә: «Туганым!» — диеп яшәделәр, кыскасы, бергә уйнап үстеләр. Аларның дуслыгы Инсаф төрмәгә утыргач кына өзелде. Мәхмүт әллә кайларга ыргылмады, армиядән кайтуга ук, районлагы милиция бүлегенә эшкә урнашты. Озак кына өйләнмичә йөргән иде, инде менә үзеннән биш яшькә кечкенә Алсинә белән өйләнешергә булганнар. Кәләш тә тумышы белән шушы яктан, шушы авылдан иде. Инсафның Мәхмүткә әзрәк үпкәсе бар: төрмәгә утыргач ул туганын бөтенләй онытты. Соңрак ул аны үзенең эчке органнарда хезмәт итүе, милициядә тоткыннар белән аралашуны бигүк хуп күрмәүләре белән аңлатырга тырышты. Инсаф бар булган үпкәләрен авылга кайтуга ук онытты, туганы белән кабат дуслашты. Хәер, туганы әллә ни эреп китмәде, шулай да Инсафның чакыруына каршы килә алмады.

Кунакка аның белән бергә укыган яшьтиләре дә килде. Сылу, Хәмдия һәм Хәсти. Алар барсы да авылда яшиләр. Хәсти белән алар бер класста һәм хәтта бер партада утырып укыдылар. Бик тә авыр укыды, дәресләрен дә гел башкалардан гына күчереп яза торган иде. Инсаф отличник ук булмаса да, дүртле һәм бишлегә генә укыды, шуннан түбән төшмәде. Нәселләрендә әбисе (сүз Хәлимә турында бара!) укытучы булгангамы, әллә үзе бик ушлы булып тугангамы, егет мәктәптән яхшы аттестат белән чыкты. Хәстине көч-хәл белән тартып чыгардылар. Шуңа күрә дә ул читкә китәргә ашыкмады, башта комбайн ярдәмчесе булды, аннан, авылга инвесторлар килгәч, фермага терлек караучы булып урнашты. Бүген ул фермада сыерларның асларын чистарта, ат җигеп, тирес чыгара. Холкы белән ул шактый шук, мәзәкчән һәм күңелле кеше иде. Тиктомалдан гына берәр кызык нәрсә сөйләп куя да, көлдерә-көлдерә, артына утыртып китә. Ул әле һаман да өйләнмәгән, өйләнергә уенда да юк, күрәсең. Авылдагылар (дөрес булса!) бик яшьли кияүгә чыгып, ике баласы белән тол калган Хәмдия тирәсендә чуала икән дип тә сөйлиләр. Сыер савучы Хәмдия

*Ахыры. Башы узган саннарда*

Инсафтан бер класска югары укыды, мәктәпне алданрак бетерде. Ул Инсафлар урамында, ике йорт аша гына тора, алар хәзер бер-берсе белән һәркөн диярлек күрешеп, исәнләшеп китә торганнар иде. Хәмдия жор күңелле, сүз эзләп кесәгә керә торган хатын түгел, әйтсә, сүзен чартлатып әйтә торган иде. Бу яктан алар Хәсти белән бик тә охшашлар, икесе дә бертөрле булгач, бер-берсен төрттереп алып, бәхәсләшергә һәм хәтта ачуланышырга да күп сорап тормыйлар иде. Сылу Инсаф белән яшьтәш булса да, ул авылда түгел, район мәктәбенә йөреп укыды. Бишкүлдән районга биш кенә чакрым, шуңа күрә бик күп бала үзәккә барып укыды. Ләкин Сылу, нихәтле генә яхшы укыса да, калага китәргә ашыкмады, салада калды. Педагоглар тәрбияли торган училищеда экстерн белән генә укып чыкты да, авылга кайтып, балалар бакчасына эшкә урнашты. Башта ул Мостафа атлы авыл егетенә кияүгә чыкты, ләкин ул бик нык эчә һәм сугыша башлагач, аңардан аерылды. Мостафадан бер ир бала да тапты, ләкин ул, чирле булып, озак яшәмәде, өч яшендә үлде. Мостафа Сылу белән аерылышырга теләмәгән, хәтта бер мәлгә эчүен дә ташлап торган, янәдән кушылуны сорап, аңа килеп ялынып та караган, тик хатын барыбер эремәгән. Бер кискән икмәк телеме кире ябышмый, янәсе! Ул Сылуны бик нык мыскыл итеп, каргап ук киткән һәм әнә шунын каргышы яшь балага төшкән, диләр, шуннан соң ул бала озак тормаган, жан тәслим кылган. Дөресме бу, хакмы, ансын тәгаен генә беркем дә белми. Шул хәлдән соң хатынын каргаган ир бөтенләй түбән тәгәрәде, эчеп, исереп, урамнарда, койма буйларында кунып йөрде. Бу хәл әле дә дәвам итә һәм инде кеше кыяфәте калмаган Мостафаны Инсафка берничә мәртәбә урамда һәм клуб буенда очратырга туры килде. Инсаф төрмәдән чыгар алдыннан гына Сылу үзенә яңа пар тапты, Үзбәкстаннан шабашкага дип килгән бер үзбәк егете белән танышты. Авылда алар яңа мәктәп салдылар, ул шунда штукатур эшләре белән шөгыльләнде. Үзбәкнең Ташкент якларында үз гаиләсе, үз балалары бар икән, дип тә сөйлиләр, ләкин бу сүзләрнең ничаклы дөреслеккә туры килүе әлегә берни белән дә расланмаган иде.

Табын аш ягында әзерләнде. Табынның иң кызган вакытында гына Мәхмүт Алсинәне зал ягына алып чыкты.

— Мәхмүт, нишләп син мине монда алып чыктың? — дип сорады аңардан кыз.

— Кысан анда, ә монда иркен! — дип җавап бирде әзрәк кенә аракы каккан егет һәм ул шундук Алсинәне кочаклап та алды.

— Ялгызың каласың килдемени соң?

— Ансы да бар инде! — Мәхмүт Алсинәне кочып үбә генә башлаган иде, аш ягыннан кинәт кенә Инсаф килеп керде.

— Мәхмүт! Алсинә! Нишләп качтыгыз?! — диде аларга хуҗа егет.

— Менә... Алсинәгә аңлатып торам әле, — дигән булды Мәхмүт.

— Мәхәббәтеңнеме? — дип елмайды Инсаф.

— Юк... бу якта кин дә, иркен дә!

— Сон, әйдә, өстәлне бу якка алып чыгабыз! — дип шар ярды хуҗа. — Кызлар, егетләр! Әйдәгез, өстәлне түр якка алып чыгабыз! Житте анда сезгә кысылып утырырга!

Үзбәк белән Хәсти, аш-су тулы табынны өстәле белән бергә күтәреп, түр якка алып чыктылар. Хәмдия белән Сылу, өстәлдәге ризыклар идәнгә коелмасын дип, өстәл артыннан ияреп, саклап килделәр. Ниһаять, мөхтәрәм өстәл түр якның уртасына барып урнашты. Барсы да шунын янына тезелешеп утырдылар. Бер Инсаф кына басып калды. Ул башланган яртыдан гади генә рюмкаларга кабат аракы салып чыкты һәм, шуларның берсен кулына алып, болай диде:

— Егетләр, кызлар! Мин бу көннәрне бик озак көттем. Сез минем якын

дусларым! Мәхмүт минем туганым, Аллага шөкер, ул инде тиздән башлы-күзле булырга тора. Ходай аларның икесенә дә бәхет өләшсен! Сылу белән инде без гомергә аралашып яшәдек, яхшы дуслар булдык. Егет белән кыз арасында дуслык була алмый, диләр, була, ник булмасын, безнең бу дуслык — шуның бер матур үрнәге. — Сылуның җиңелчә генә иңеннән сыйпап, ул аның янында утырган үзбәккә ишарә ясады. — Гафу ит, иреннең исемен белмим...

— Шамил! — диде Сылу. — Үзбәкстаннан килде...

— Шамил түгел, Шаман ул! — дип көлде тешсез Хәсти.

— Да... Хасти... дурусайта! — диде Шаман, аз гына да үпкәләмичә.

Аракыны якын дусты итеп күргән Хәсти, Инсафның тост әйткәнен дә көтмичә, гопылдатып эчеп тә куйды. Аның һәр адымын тикшереп торган Хәмдия, ярсуланып, усал гына карап куйды. Шук җүләр шундук телләнә башлады һәм, тамак астына чиртеп, Инсафның тостын тыңларга әзерләнгән үзбәктән:

— Карале, Шаман, сездә бу нәстәне тоталармы, юкмы? — дип сорады. — Хәсти маймыллана: ул аның белән бергә фермада эшли, аның аракы белән дус түгеллеген дә, үзбәк халкының ничек һәм ни күләмдә эчкәнен дә әйбәт белә, бу очракта ул, кызык табып, фәкать публика өчен генә уйный иде...

— Үзем үчмәгәч, низнай, айталмыйм! — диде үзбәк, алдында торган рюмканы читкә этеп.

— Сездә чәйгә салып эчәләр икән аны! Мин шулай дип ишеттем!

— Житте инде, бүлмә кешене! — дип акырды аңа Хәмдия. — Әйтсен сүзен!

— Хәсти белән без бергә уйнап үстек, бер класста укыдык! —дип дәвам итте Инсаф.

— Тиндәш, без синең белән гел сугыша идек, име!

— Свулыч, — дип кычкырды ул аңа шаяртып. — Син бит минем битемә агач шәйбе атып, борынымны җимердең. Шуның эзе менә әле дә тора...

— Ә син агач кылычың белән селтәнеп, чак кына күзне чыгармадың... уң күзне... әле дә шул күзем тартышып тора! — дип көлде Хәсти.

— Хәмдия белән сезнең мөнәсәбәтләр ничектер, ансын белмим... — диде Инсаф.

— Өйләнешергә торабыз әле! — диде Хәсти. Әйе, ул шулай әллә кем булып кыланырга ярата иде.

— Да-а-а!

— Ие... арттан йөри, малай, ал мине, дип!

— Кем?! Минме? — Хәмдия чәчрәп торып басты. Кулына тоткан рюмкасын Хәстинең башына чәпәргә дә әзер иде. Ул шуның белән селтәнде дә хәтта, Хәсти, куркып, башын иеп калды. Табындагылар көлештеләр. — И, җаным, син җүләргә кияүгә чыкканчы, мин лучше Чурныш урысына чыгам!

— Ярар, көлештек, аңлаштык, — диде Инсаф бу юлы басынкы, калын тавыш белән. Табын тынып калды. — Мин нәрсә әйтәсем килә. Сез минем кайдан кайтканымны барыгыз да яхшы беләсез. Һәм инде... ни өчен утырганымны да беләсез. Бер гаепсезгә утырдым мин. Ни өчен шулай килеп чыкканын сезгә сөйләп тормыйм, тора-бара барсы да ачыкланыр. Иң мөһиме ул нәрсә түгел. Шунда утырганда, исән-сау гына авылга кайтып җитә алсам, дусларны, туганнарны җыйнап, бер чәйләп утырырбыз дип хыялланган идем. Аллага шөкер, исән-сау әйләнеп кайттым. Һәм менә күрешү минутлары да килеп житте: мин кабат сезнең янда, дусларым, сезнең янда! Мин бу дөньяның әшәкелеген дә, яманлыгын да күп күрдем. Менә шушында, туган авылымда, туган нигеземдә калырга һәм яшәргә дип кайттым. Минем чынлап та авылда каласым, сезнең

белән бергә авылда яшисем килә. Әйдәгез, күтәрик шушы бокалларны! Авыл өчен, туган нигез өчен!

— Авылда да хәзер җәннәт түгел! — Сүзгә Мәхмүт кушылды. Ул шулай кайчак акыллы булырга, кирәкмәгән җирдә бака боты кыстырырга ярата иде. — Минем дус авылда агроном булып эшли, инде ярты ел хезмәт хакы күргәне юк. Хәер, дәүләт эшендә дә күп тамызмыйлар. Житмәсә, өйләнәсе ел! Авылга участковый булып кайтмыйча булмас инде!

— Шаһит итеп туена мине чакыр, — дип кысылды Хәсти. — Акча сорамам!

— Син дивана шту ли! — дип кычкырды аңа Хәмдия.

— Ә нәстә! Минем менә дипломым да юк, аттестатым да югалды. Фермада эшлим: көрәп акча алам!

— Алган, ди, бар бирәү!

— Правды... Шаман миннән күбрәк ала. Менә шуны аңламыйм...

— Ышту? — дип сорады аңардан Шаман.

— Синең кебек эчеп йөрми ул, хезмәтен җиренә житкерә! — диде Хәмдия.

— Егетләр, кызлар! — диде рюмкасын күтәргән Инсаф. — Мин тост әйттем!

— Әйдәгез! Әйдәгез! — диештеләр табындагылар.

— Әйдәгез, күтәрик инде! — дип көлдерде Хәсти. — Кеше арасында күңелле була ул! — Эчкәне эчте, эчмәгәне тукталып торды.

— Инсаф! — Ниһаять, Сылуның да теле ачылды. — Безнең кәләш кая соң әле? Раушания кая соң? Килмәдемени?

Кунаклар, аптырашып, бер-берсенә карашып куйдылар, шуннан соң шаулашырга тотындылар. Бу мәсьәләгә һәркем үз фикерен тыгарга тырышты...

— Зарар юк, — дип бүлде аларны Инсаф. — Мин турысын сөйләргә яратам. Раушания белән безнең бар да тәртип. Прусты... ул шундыйрак инде... Үпкәләмик ана, яратмый ул шау-шулы кичәләрне, бары тик шул гына. Йөрәге кабул итә алмый...

— Да! Аның йөрәге! — дип искәртте Хәсти. — Әйдәгез, дуслар, Раушания исәнлегенә!

Шулчак урам ягында тәрәзә каккан тавыш ишетелде. Кисәк кенә. Барысы да шым булып калды. Кы-ы-зык! Кем булыр икән бу? Инсаф тиз генә утны сүндерде. Тәрәзәгә капланып, урам ягына күз ташлады. Тик анда беркем дә күренмәде. Кабаланып, ул янә ут кабызды. Ни күрсеннәр — ишек төбендә Ландыш басып тора иде! Барысы да моңа шаккатып, берникадәр вакыт эндәшә алмыйча тордылар. Дөресен әйткәндә, кунакта утыручыларның берсе дә (Инсафтан башка!) Ландышны яратып бетермиләр иде. Бишкүлдә килмешәкләрне болай да бик өнәп бетерми һәм аның әле, житмәсә, Латыйп хатыны булуы да нәфрәт хисен икеләтә көчәйтә иде. Авыл халкы Латыйпны яратмый, чөнки ул инде ничәмә кешенең башына житте. Каяндыр күченеп кайтып төшкән Ландышны да халык аның сөеклесе, законлы хәләл җефете итеп түгел, ә Латыйпның кара күләгәсе, койрыгы итеп кабул итте.

Беренче булып урыныннан Хәсти кузгалды, ул кыланчыкланып, тәрәзә буйларын, ишек артларын карап чыкты һәм хәтта кием шкафлары эченә дә башын тыкты...

— Юк...

— Нәрсә эзлисең син анда? — дип сорады аңардан Инсаф.

— Латыйп килмәгән микән дим...

— Нишләп?

— ...хатыны артыннан ияреп...

— Ландыш... — Инсаф үзе дә каушап калган иде. — Кер... әйдә, ишек төбендә торма...

— Исәнмесез! — диде Ландыш, үз-үзен бик тиз кулга алып. Оялу-каушау дигән нәрсә ят иде ана, әрсезлек, кыюлык житәрлек иде, күрәсен, үзендә. — Тиктомалдан килеп керүемә исегез китмәсен, мин белеп килдем...

— Нәстәне? — дип сорады Хәсти.

— Аулак өйне...

— Аулак өйгә, между пручим, ирле хатыннар йөрми! — дип төрттерде Хәмдия.

— Ә без нәрсә? — диде Сылу.

— Сезнең никах кына, — диде Хәмдия. — Сез бит әле ЗАГСта язылышмаган.

— Никах — ЗАГСтан жугарырак! — дип фикер йөртте Шаман.

— Дөрес һәм бик дөрес! — дип куәтләде Хәсти анын сүзен.

— Хәсти, бар әле, бутама кешене! — Инсаф Ландыш янына килде һәм аңа кулын сузды. — Ландыш, әйдә, утыр безнен янга! Бергә күңелле булыр...

— Ие... кеше янында! — дип өстәде Хәсти.

— Рәхмәт, — диде хатын.

— Әйдә, табынга утыр! — дип кыстады аны хужа.

— Юк, утырмыйм, — дип кырт кисте ул. — Аракы куелган табынга утырмыйм!

— Ой, ой, каян килгән мулла кызы! — Бусы Мәхмүт иде. Бу анын үзенчә Ландышны кабул итмәве һәм үртәве иде.

— Юк, мин сезнең янда дини кеше булып кыланмыйм, биш мәртәбә намаз да укымыйм! — диде Ландыш. — Шуны гына әйтәм: аракысыз да күңел ачарга була!

— Нишләргә кушасың? — дип сорады Мәхмүт.

— Аулак өй, дисез бит...

— Аулак өй дигәч тә, нәстә, йөзек салыш уйнатмакчы буласыңмы?

— Ә нишләп уйнамаска?! Күңелне табын артында түгел, ә биеп-жырлап, уйнап ачарга да була, шулай бит?!

Табындагылар кабат тын калды. Авылда яшәгәч, Ландышның кайбер сәер гадәтләрен беләләр иде. Башта, килгән шәпкә, ул клубта сәнгать житәкчесе булып йөрде. Анда бер ел гына эшләде, ире бик каты көнләшкәч, китапханәгә күчте. Ләкин шул бер ел эчендә генә дә ул клубта нинди генә чаралар уздырмады. Кичәләр, дискотекалар, аулак өйләр, театрлар... Йоклап яткан клуб уянды. Клуб ишеген каян ачылганын да онытакан, барсалар да тәртип бозып, инвентарь жимереп йөргән яшьләр кичләрен клубка жыела башлады, яңа клуб мөдире оештырган чараларда бик теләп катнашты. Ландыш теләсә кем белән уртак тел таба белә, сөйләшә белә, ул тырыш һәм актив. Ходай аңа оештыру сәләтен кызганмаган иде. Авыл яшьләре аны яратып, инде үз итеп кенә өлгергәннәр иде, Латыйп, көнләшеп, клубтан чыгарттырды. Бер ярты еллар эшсез утыргач (өйдә утырырга яратмады), китапханәгә урнашты һәм хәтта анда да тик тормады, кичәләр оештыру белән мәшгуль булды...

Инсаф бу очракта әйдаманлыкны үз кулына алырга тиеш иде һәм ул шулай итте дә. Күңел түрендә әле яңа гына жылы хисләр калдырган хатынны уңайсыз хәлгә куярга ярамый иде. Ә нишләп?! Ландыш хаклы! Нигә әле бер жилләнеп алмаска? Кая әле анын якын дусты? Ул сандык өстендә торган тальян гармунын кулына алды, бармак очлары белән анын телләрен сыпырып куйды. Гармун

дусты телгә килде. Хәсти Инсафның ниятен бик тиз аңлап алды һәм: «Без бит Бишкүл егетләре, Бишкүл кызлары! Без биергә, җырларга тотынсак, безне, җаннарым, туктатам димә инде!» — дип сөйләнә-сөйләнә, тиз генә гармунчы каршына урындык китереп куйды. Урындык өстен сөлге белән сөрткәндәй итте. Янәсе: «Рәхим ит, утырып уйна, сөекле гармунчыбыз!» Инсаф урындыкка утырып, башына ни килсә, җаны ни теләсә, шуны уйнап, шуны җырлады. Җыр җаннарны актарып атты, күңелләрне җилкенсендерде, чөнки ул җыр чын авыл җыры иде:

Бездә биек таулар бар ла,
Тау астында таллар бар.
Талда — яфрак, бездә — сагыну,
Сездә нинди хәлләр бар?

Күңел ачып, әзрәк кызарга өлгергән яшьләрнең күбесе Инсафка кушылды. Кайсы, урындык алып, аның янына утырды, кайсы идәнгә, келәм өстенә чүкте. Хәсти Ландышка урындык китереп бирде, ләкин ул утырмады, урынында басып калды...

Биек тауның башларында
Җил түгел, давыл бит ул.
Ефәк түгел, җилгә очмый,
Кайгылар авыр бит ул...

Һәм тагын:

Сызылып таңнар аткан чакта,
Кош куна тирәгемә.
Ефәк булып уралдың ла
Яшь кенә йөрәгемә...

Ниһаять, гармун тынды, гармун белән җыр да тынды.
— Бигрәк монсу җыр, прәме үзәкне өзә! — дип такылдады Хәсти.
— Күпме өзәргә була үзәкне! — дип зарланды Мәхмүт. — Күңел ачармын дип килгән идем, булмады!!!
— Әйдәгез, уеннар уйныйк! — Мондый тәкъдимне Ландыш ясады.
— Зинһар, йөзек салыш кына уйнамыйк! Клубта күп уйнадык! Га-а-рык!
— Минемчә, бер әйбәтләп салырга да таралышырга кирәк! — дип өстәде Хәсти Мәхмүтнең сүзләренә.
— Хәсти, җитте сиңа! — дип Хәмдия аның авызын япты.
— Бетте, карчык, бетте!!!
— Карчык! Нинди карчык булыйм ди мин сиңа?!
«Карчык» дигән сүзгә нигәдер ачуы чыккан хатын кинәт кенә Хәстигә ябышты, тегесе, аңардан качып, урынга барып ауды. Хәмдия аның башын җитез генә мендәр белән каплады. Чәчәкле-чуклы мендәр шактый зур, күперенке иде, Хәстинең чак кына тыны капланмады. Ләкин ул, әйләнеп алып, инде өстенә менеп кунаклаган Хәмдияне идәнгә тәгәрәтте. Эчтән җылы ыштан, калын кара колготки кигән Хәмдиянең арт шәрифләре шыр булып ачылып киткәч, кунаклар шырык-шырык килеп көлешергә тотындылар. Ә ялгышын төзәтергә теләгән шук Хәсти Хәмдиясен, җәлт кенә идәннән күтәреп торгызды...
— Егетләр! Кызлар! — дип Ландышның сүзләрен күтәреп алды Инсаф. — Җә! Кем нинди уен белә?!

— Белгәнне уйнарга инде! — диде Сылу.

— Жырлап уйнасак кына инде! — дип кушылды Алсинә.

— Алсинә дөрес әйтә! — диде Ландыш. — Барыбызга да таныш бер уен бар...

— Нинди?

— Аралашып уйнау. Әйдәгез, болай итик...

— Нәстә нитик? — Бусы Хәсти иде.

— Кызлар бер якка, ә егетләр икенче якка бассын!

— Беләбез, безне өйрәтергә кирәкми! — дип кычкырды Хәсти.

Алар бу уенны клубта күп тапкырлар уйнаганнар иде инде. Шуна күрә беркемгә дә аңлатып, өйрәтеп торырга туры килмәде. Егетләр, кызлар, аерым-аерым, каршы якка басып, сафка тезелделәр.

Ландышнын күзе инде күптәннән Инсафта иде, ул, бернигә дә карамыйча, төркем арасыннан Инсафны чыгып алды. Авыл хатыны булса да, Ландышнын уч табаннары, бармаклары су кебек йомшак иде. Инсаф менә шуны кулыннан ычкындырырга теләмәде, анын кулын ныгытып тотты. Бу уен әле шактый дәвам иткән булыр иде, ләкин Инсаф белән Ландышнын бер-берсенә гашыйк булып, сөешеп карап торганнарын күргән яшьләрнен кинәт кенә уенга күнелләре сүрелде. Хәсти өстәл янына килеп, бер рюмка аракыны каплап салды да идән кырына куелган тальянны кабат Инсафнын кулына китереп тоттырды. Инсаф, гармунны алып, урындыкка утырды.

— Их, дуслар, әле дә ярый сез бар! — диде ул, үзенчә хыялланып. — Мин бит сезне сагынып кайттым, сезне! Бар да әйбәт кебек, бар да күнелле. Әйе, без бит яшь әле, без яши генә башладык. Тик менә авыл гына картаеп бара. Әле бер йорт ябыла, әле икенчесе. Кайсы таза, кайсы череп ята... теге авыздагы, казнадагы черек тешләр сыман... Без... яшьләр, без моңа юл куярга тиеш түгел, шулай бит...

— Таш дивар эчендә утырып, тәмам философ булып беткәнсен, туган, — дип бүлдерде аны Мәхмүт. — Яшә әле син башта авылда, аннан әйтерсен. Эш юк, акча юк. Яшьләр хәзер әти-әнисенен, әби-бабасынын пенсия акчасына яши. Беләсенме, авылда кемнәр кала?

— Кемнәр?

— Калага китеп урнаша алмаганнар...

— Туктале, дустым! — дип бүлде аны Хәмдия. — Син бөтен кешене дә бер себерке белән себермә, яме!

— Дөресе шул бит! — дип тәкрарлады Мәхмүт. — Бирсеннәр берәрегезгә калада фатир, тапсыннар берәрегезгә офиста яхшы урын, иманым камил, шул ук көнне авылдан китеп барасыз!

— Син үзенне күреп сөйлисенме сон?! — дип каршы төшеп маташты ана Инсаф. Шайтан! Мәхмүтнен сүзләрендә әзрәк хаклык та бар иде кебек.

— Үземне түгел, сине сүлим, — диде район үзәген инде шәһәр итеп күргән милиционер туганы. — Менә синен кебекләр башта авылга мәдхия жырлыйлар, сонынннан чыгып качалар...

— Ие, ие, нәкъ шулай булып чыга да инде! — дип сүзгә кысылды Хәсти. — Күп сайрадылар, сайрый-сайрый, кошлар сымак читкә очып беттеләр... берәм... берәм... ие...

— Мин!? — дип каршы төште Инсаф. — Аллам сакласын! Ходай мине шушы туган йортымнан, туган нигеземнән аермасын...

Һич тә тынып торырга теләмәгән гармун кабат телгә килде, кабат монсу жыр агылды:

...Аерма мине
Туган илемнән,

Кара икмәгем,
Сөтле чәемнән...

Беренче булып Мәхмүт кузгалды. Ул, Инсафның уйнап бетергәнен дә көтмичә: «Ярый, кызлар, егетләр, аулак өй шуның белән тәмам, таралышыйк по домам!» — дип, Алсинәне култыклаган хәлдә, ишек ягына атылды. Бу үзенчә котырту кебегрәк килеп чыкты. Җитмәсә Алсинәсе дә: «Соңгысыдыр инде бу, башка җыелып булмас!» — дип өстәп куйды.

— Нишләп соңгысы булсын! — дип каршы төште Инсаф. — Әле тагын җыйналырбыз, Аллаһы бирсә! Мәхмүт!

— Әү?

— Мин синең милициядә хезмәт итүеңне бер дә хуп күрмим.

— Нигә?

— Мин анда бармас идем, мәсәлән!

— Ә анда сине алмыйлар да, син бит...

«Син бит...» — Болай да төрмә сакчыларын, милицияне күралмаган Инсаф бу сүзне авыр кабул итте. Моннан җиде ел элек җинаять кылган урында бер ул гына түгел, ә Мәхмүт тә бар иде бит. Җиде-сигез авыл егете. Аңа берни дә булмады, ул әнә хәзер әллә кем булып, җинаять эшләрен тикшереп йөри. Ә туганы төрмәдә җиде елын калдырып кайтты...

— Кит син аннан! Ни өчен шундый киңәш биргәнемне син бик тә яхшы беләсең!

— Нәрсә беләм мин... берни дә белмим... әллә кайчан булганны! — дип хафаланды Мәхмүт.

— Безгә дә белик, безгә дә кызык! — дип арага кысылды Шаман.

— Тик кенә тор, Шаман! — дип кычкырды аңа Хәсти.

— Авырдыр сиңа анда, — дип дәвам итте ярсуын яшерә алмаган Инсаф. — Кешене хөкем иткәндә, күз алдына килеп басудан курыкмыйсыңмы? Вөҗданың газапламыймы?

— Нәрсә сөлисең? Нинди вөҗдан?

— Хайван сөякләре дыңгычлап тутырылган канлы авыз! — Бар да шым булды. Өйдә шом барлыкка килде. Хәтта һәрбер сүзне мәзәккә әйләндерергә яраткан Хәсти дә сөйләү сәләтен югалтып, дәшмичә, өнсез торды. Ике туган арасында көрәш башланырга тора һәм аның яхшылык белән бетмәячәген кунаклар яхшы сизенделәр...

— Син нәрсә, мине шуның өчен чакырдыңмы? — дип төкерекләрен чәчте Мәхмүт. — Шушы сүзләрне әйтер өченме? Җаныма пычрак атар өченме?

— Ничек яшәргә уйлыйсың син... иманыңны?! Син бит Латыйпны өстерүче, шул мескен малайны кыйнатучы син иден бит, син!

Матур гына башланган кичәнең шулай җәнҗалга әйләнүен беркем дә көтмәгән иде, билгеле. Инсаф туганына булган күптәнге үпкәсен бүген дуслары, авылдашлары алдында чыгарды. Ә кирәк булды микән? Ашыкмадымы? Соныннан үкенерлек булмасмы?

Туганына бик нык ачуы чыккан, аждаһадай кабарынган Мәхмүт кисәк кенә Инсафка ташланды, ләкин Шаман белән Хәсти аны тотып калдылар...

— Мин түгел, ишетәсеңме, мин түгел!

— Тынычлан, — диде Инсаф Мәхмүткә. — Син түгел, син түгел...

— Алла! Нәрсә соң инде бу? Күпме булыштым үзенә! — дип чәпчеде үзен Мәхмүтнең законлы хатыны итеп сизә башлаган Алсинә. — Нигә җыйдың безне? Тавыш чыгарыр өченме?

— Юк, нигезне күрсәтер өчен...

## 6

Хәер, Мәхмүт, бик нык кызып, Инсафка янап чыгып китсә дә, кичәнен яме кителмәде. Калган кунаклар ана рәхмәтләрен әйтеп таралышты. Бераздан аулак өйдә Инсаф белән Ландыш кына утырып калды. Ул, гармунын кулына алып, кабат уйнап та, җырлап та карады, тик нигәдер уен да, җыр да бармады.

— Сина кайтырга вакыттыр бит инде? — диде ул Ландышка.

— Куасыңмы?

— Юк, кумыйм... киресенчә... балаң, ирең бар... Көтә торганнардыр...

— Әлегә мине беркем дә көтми, өйдәгеләр йоклый. Каенанам да, улым да, ирем дә. Безнең Латыйп иртә ята, иртә тора...

— Әгәр дә Латыйбың минем янда икәнеңне белсә...

— Нишләтә?

— Муенынны борып ата.

— Куркып туйдым инде мин! — Ландыш горур гына башын өскә чөйде. Чибәр генә түгел, хәтәр дә хатын икән әле ул! — Минем, беләсеңме, нишлисем килә...

— Нишлисең?

— Үч аласым килә.

— Кемнән?

— Латыйптан.

— Үч? Нинди үч?

— Көчләп өйләнде. Көчләп өенә алып кайтты. Мин аны бервакыт хәтта күрә алмас хәлгә җиттем. Яратмадым! Яратып чыкмадым. Күрәсең, ул аны сизде. Ярты ел да үтмәде, ул югала башлады. Төннең бере, ә Латыйп юк. Авыл ирләре дә йөри икән, дигән сүзгә ышанасым килмәде. Ышандырды! Иреңне яратсаң-яратмасаң да, көнләшү хисе барыбер үзенеке итә икән. Житкерделәр: авызына аракы кергәә үк, ирем «ГАЗ»игын кабыза да күрше авылга җиллерә икән. Машинасының көпчәге җиргә тисә тия, тимәсә юк. Җен урынына куа. Әйтерсең лә аны анда айдагы Зөһрә кыз йә хатын-кыз җенесендәге гүзәл фәрештә көтеп тора! Юк бит! Фермада дуңгыз карауч Әлфинур исемле бер хатын янына ияләшкән бу. Ире юк, үлгән. Болар ире исән чагында Латыйп белән бик дус булганнар. Ире аның Казанга йөри торган булган, калада бер мәгъшукасы булган, шуның яныннан кайтканда, аварияга эләгеп үлгән. Дусты үлгәч, тол хатынның күнелен кем күрсен дә кем юатсын, ди! Ә Латыйп — тут как тут! Чибәр, матур булса, бер хәл иде, гөберле бакага охшаган бит ул хатын, чат гөберле бака!

Инсаф үзен нindидер бер әкияти дөньяда утырган сыман хис итте. Әйтерсең лә ул хан, бөек хан, ә янында әсире, чибәр хатын Шаһрезадә аңа искиткеч әкият сөйләп утыра. Ул Диюне яманлый, ә шул Дию — Инсафның кан дошманы. «Шаһрезадә» анардан үч алырга тели, Инсаф та нәкъ шундый ук уйлар белән яна...

— Каладан кунакка каенанамның оныгы кайткан иде. Пачти бандит! Төшеп миндә ул Әлфинур янына, тормышның кай тарафка акканын аңлатты ул аңа! Шуннан соң иремне бусагасыннан да атлатмады. Хикмәт! Латыйп беразга тәүфыйклы песигә әйләнде. Хәтта тезләнеп, миннән гафу үтенде...

— Гафу иттеңме соң?

— Мин аны бөтенләй йөрәгемнән сызып аттым. Болай да яратмыйм үзен, инде бу хәлләрдән соң... Нишлисең! Яшәргә кирәк. Бала атасы бит... Ә үч алу теләге калды. Шулчак эчемнән генә: «Ул үрдәгенә бер каз ясыйм әле мин синең!» — дип үз-үземә сүз бирдем. Беләм... үч алуның икенче ягы да бар... начар ягы да. Үчләнү беркайчан да яхшыга алып бармый, анысын да беләм...

— Ә ничек үч алмакчы буласың?

— Ничек? — Ландыш, назланып, Инсафка карап куйды. — Бүген минә мин дә өйгә кайтмыйм!

— Кая барасың?

— Синдә калам.

— Миндә?!

— Әйе, җаным, синең янда.

— Шулай итеп...

— Үч алу дип кенә әйтә алмыйм мин моны... — Ландыш, төртелеп, башын аска иде. — Яшермим...

— Нәрсә?

— Син ошадың миңа.

— Ошадым?

— Әйе, ошадың...

— Ни өчен?

— Белмим... тик шуны беләм...

— Нәрсә?

— Бу әле ярату түгел, чын ярату түгел...

Ландыш Инсафның иңенә сарылды. Инсаф җилкәсе белән аның тән авырлыгын сизсә дә, чибәр хатынның кагылуыннан чиксез бер тәм һәм ләззәт тапты. Ул хатын-кызга, хатын-кыз назына бик нык сусаган, түзеп булмас дәрәҗәдә сусаган иде! Кемгәдер табынып, еракта яратып яшәүдән инде туйган, аның бүген үк чын-чынлап, шашып яратасы, яраткан кешесен кочаклап, ирләрчә рәхәтләнеп бер сөясе килә иде. Бу әле теләк кенә, ләкин аны тормышка ашыруы җиңел түгел, чөнки озак еллар ирегеннән мәхрүм ителгәч, ул әлеге мәсьәләдә шактый кыргыйланган һәм андый мөнәсәбәтләрдән бөтенләй читләшкән иде...

— Сине беренче күргәч үк, әллә нишләп киттем! — диде хатын.

— Нишләп?

— Син минем беренче мәхәббәтемә охшагансың.

— Яраттыңмы аны?

— Чын ярату дип әйтә алмыйм мин аны... Минем моңарчы беркайчан да чын-чынлап ятарканым булмады. Ә минем яратасым килә, Инсаф! Әгәр дә мин аны бик каты теләсәм, үлеп-бетеп шуның белән җенләнсәм, мине берни дә туктата алмаячак... ышанасыңмы?

— Синнән теләсә нәрсә көтәргә була...

— Син мине җиңел акыллы дип уйлыйсыңмы?

— Юк, алай дип уйламыйм, — дип төзәтте сүзен егет. — Минем моңарчы ирле хатыннар белән йөргәнем булмады. Аны... бик зур гөнаһ, диләр...

— Мәхәббәттә гөнаһ юк, җаным!

— Бәлкем... шулайдыр да... Ләкин...

— Әйтеп бетер!

— ...минем ярәшкән кызым бар. Раушаниям бар.

— Яратасыңмы?

— Кемне?

— Раушанияне?

— Яратам...

Шулай диде ул... тик ничектер икеләнебрәк әйтте. Ландыш янында ярәшкән кызын гына түгел, ә үзенең кем икәнлеген дә оныта башлады бугай. Бу чибәр хатын, ана елан сыман сарылып, акрынлап куенына, куеныннан җанына төшеп бара кебек...

— Алдашма, Инсаф!

— Нишләп алай дисең?

— Күзләреңнән күрәм.

— Нәрсәне?

— Ни кызганыч, син аны яратмыйсың. Яратасың килә, ләкин ярата алмыйсың. Аңлыйм, ул синең өчен якын кешедер дә... Әйбәттер ул. Ул, бәлкем, синең җан дустыңдыр да. Ләкин ярату аның белән генә чикләнми шул. Ярату ул бөтенләй икенче нәрсә. Синоптиклар әйтмешли, аңа прогноз биреп булмый.

— Каян беләсең?

— Күзләреңнән күрдем... Әнә шул күзләрең, төпсез зәңгәр күзләрең әсир иттеләр дә инде мине. Бир, җаным, үбим әле шул күзләреңне бер, бир! — Кунак хатыннан бу хәтле үк шуклык вә әрсезлек көтмәгән Инсаф йөзен читкә алды, ләкин хатын барыбер үзенекен итте, аның зәңгәр күзләреннән үпте...

— Яратам, дисең инде?!

— Әлегә яратам, дип әйтмәдем...

— Ә мине яратырга буламы соң? Син бит беләсең минем армиядән кайтмаганымны!

— Мин барсын да беләм. Ничә ел утырганыңны да беләм. Ләкин безнең мәхәббәткә моның бер катнашы да юк. Минемчә, син үзеңне бер дә кирәкмәгәнгә кимсетәсең кебек. Кимсенмә! Кимсенгән саен кеше үзенә бары начарлык кына ясый, тормышы уңышсыз була. Дөньяның начар ягын гына күрергә ярамый, аның яхшысын да күрә белү кирәк. Позитив булсын, позитив! Син менә дигән егет! Авырлыклар артта калды! Синең киләчәгең якты! Кил әле, качма, кил!

— Кил-дем...

— Кил... — Инсафны кулыннан тартып, Ландыш идәнгә тезләндерде һәм үзе дә аның каршына тезләнде. — Әгәр дә Раушанияң сине минем кебек ярата алса, сиңа якын да килмәс идем, арагызга кермәс идем. Тик ул сине минем күк беркайчан да ярата алмаячак, аңлыйсыңмы?! Әйе, ул сиңе карар, сиңа балалар табар, тик ярата алмаячак...

— Нишләп шулай дисең?

— Ул синең назга, сөюгә сусаган җаныңны аңламый һәм аңлый да алмаячак. Менә мин аңлыйм! Мин сине аңлыйм!

— Каян беләсең?

— Мин Раушанияне бер генә тапкыр күрдем һәм аның кем икәнен аңладым. Дөресме?

— Әйе, мин әле яшь, минем яратасым килә, — диде егет һәм, башын аска иеп, аның кулыннан алды. Ландыш (Инсафтан яшьрәк булса да), баласын сөйгән шәфкатьле, назлы аналар сымак, егетнең башыннан сыйпады. Бу сабый «бала»га, күз яшьләрен сыгып, инде елыйсы гына калды. — Чынлап та... шулай... ялгыз бит мин. Атам да, анам да юк. Читен миңа аларсыз, белсәң икән, шундый читен! Кайчак үкереп елыйсыларым килә! Шуңа күрә дә тизрәк башлы-күзле буласы иде, өйләнәсе иде. Кемгә булса да, тик ялгызым гына калмаска...

— Мин бар, мин сине ташламам...

— Сүз дә юк, син миңа ошыйсың, бик тә ошыйсың. Дөрес әйттең син, Раушания турында бик дөрес әйттең. Егет белән кыз арасында була торган ярату юк безнең арада, юк. Дуслык бар, әйе. Төрмәдә чагымда ул мине ташламады. Ярдәм итте. Көтте. Анда мин гел аның турында гына уйладым...

— Аңлыйсыңмы...

— Әйе...

— Төрмә — читлек бит ул, чокыр ул... упкын... Син чокырда яткан, тирән, төпсез упкында яткан... Чокырның, упкынның өске башыннан кем кычкырса

да, кем генә ярдәм кулы сузса да, шул кеше сиңа фәрештә булып күренгән. Ә хәзер син иректә. Үз иркеңдә. Сиңа кем кирәклеген аңлар вакыт житте...

— Миңа шундый рәхәт синең белән...

— Миңа да...

— Ландыш...

Инсаф ана тагын нидер әйтмәкче иде, хатын учлары белән егетнең авызын томалады. Әйтәсе сүз әйтелмичә калды, сөю дәрте икесен дә үзенең назлы кочагына тартып алды...

— Инсаф!

— Әү, жаным?!

— Ал мине!

Инсаф, кабаланып, Ландышның күлмәк изүен чишәргә тотынды. Үч иткәндәй, ул күлмәк изүе вак кына төймәләргә беркетелгән булып чыкты. Бер ун-уникеләп төймә... Ләкин бик нык дәрте уянган, әсәрләнгән егетнең соңгы ике-өч төймәне чишеп торырга тәкате калмады, ул аларны өзеп кенә атты, күлмәк бер урыннан чыртлап ертылды һәм аның изүе китте. Өзелгән төймәләр, күнелле чылтырап, берәм-берәм идәнгә коелдылар, караватһәм өстәл асларына тәгәрәделәр. Ландыш моңа көенмәде, андый вакытта чүпрәк белән хисаплашып торалар димени инде, ул сөенә-сөенә көлде генә, ә Инсаф, аның жуйган кешедәй, күкрәгеннән сөт исе аңкып торган тансык хатынның жылы кочагына чумды. Иреннәр иренгә кушылды. Егет, жинелчә хәрәкәт ясап, хатынны урынга аударды. Ландышның лак сибеп ныгытылган озын кара чәчләре мендәр өсләренә чәчелде, шул ефәк сыман бер тотам чәчне егет, бармаклары белән әләктереп алып, иреннәренә тидерде, шашып үпте. Аннан соң аларны учы белән жыйнап, бер күч саламны жилгә очырган сыман, Ландышның жилкәсенә атты. Үбешү янәдән кабатланды, аның теле Инсафның теле белән унисонга биеде, тәннәр буйлап иксез-чиксез рәхәтлек дулкыны йөгереп узды. Инсафның куллары, назлап, хатынның дәртен, теләген тагын да көчлерәк кузгатып, аның тәнен өйрәнде. Ландыш, әсәрләнеп, башын артка чөйде, егетне кабат үбешергә чакырып, муенын алга сузды. Инсаф аны жиңде, Ландыш аңа үзе теләп бирелде. Ике гашыйк, бер-берсен сөя-сөя, караңгыга убылды һәм алар алдында гаҗәеп мәхәббәт капкасы ачылды кебек. Бары тик ышык почмактан Инсафның колагына ата-анасының: «Улым, улым, нишлисең син, нишлисең?!» — дип эндәшкән жан авазлары гына ишетелеп калды...

## 7

Инсаф соң гына уянды. Тәнендә нык арыганлык сизсә дә, ул озак кына, урыныннан кузгалырга теләмичә, кулларын иркен сузып, төнлә чит хатын белән кичергән ләззәтнең рәхәтен, тәмен тоеп ятты. Иртәнге дүртләрдә кисәк кенә ашыгып чыгып киткән жанашы әле дә матрац белән ак жәймә жәелгән агач караватта ята кебек тоелды аңа. Ул шуны теләде, шуны уйлап хыялланды. Ләкин бу татлы хыялларын Раушания килеп бозды. Шулай алдан белгертми-нитми килеп керер дип аның башына да килмәде. Ишектән төнге кунагы кереп килә дип уйлады ул башта, әле дә ярый ялгыш: «Ландыш, килдеңме, жаным?!» — дип әйтеп ташламады. Бертөрле генә киенеп йөргән кыз бүген бөтенләй матур итеп киенгән, яңа сатып алган алсу төстәге күлмәк өстеннән үзенә бик нык килешеп торган юка гына джемпер кигән. Ничектер кәефе дә күтәренке, күнеле ачык иде кызның. Раушаниянең килүенә ул артык көенмәде, ләкин артык сөенмәде дә. Инсаф, өйдә эшсез тормас өчен, асрарга дип ике сарык алган иде. Сарыкларны сатып алды, дип әйтсәк, бигүк дөрес булмас, аңа аларны дуслары китерде. Сарыкларын

һәркөн иртән торып ашаткан-эчерткән хужа кеше бүген вакытында тора алмыйча йоклап калды шул...

— Хәерле иртә! — дип сәлам бирде ана Раушания. Тавышы чишмә суыдай чылтырап чыкты, ә йөзендә бәхетле елмаю балкыды. Табигатьтән ак чырайлы кызның битләре кызарып, тулышып киткән иде...

— Хәерле... Ёлки... сәгать ничә?

— Унбер. Тор, әйдә!

— Унбер?! Сарыклар...

— Йөрмә, мин салдым инде.

— Син...

— Ашарга пешкән... кухняда...

— Мин сине яңа гына килгәнсең дип торам...

— Өйдә тәртип. Урынны гына җыясы бар...

— Рәхмәт, ансын үзем...

— Килүемә шат түгелме?

— Шат... билгеле...

— Син әле һаман да йокыннан айнып җитмәгәнсең, татлы йокыннан.

— Ансы шулай! — диде егет, киерелеп.

— Бар, юынып кер!

Раушания урындык башында торган ак сөлгене Инсафка атты. Җәймә астында шәп-шәрә яткан Инсаф караватастына тәгәрәгән трусигын кулы белән капшап табып алды да, кунак кызы анда-монда йөргән арада, аны шыпырт кына киеп тә куйды. Аннан торып, урын җәймәсен рәтләп куйгандай итте. Ләззәт төне узган ятак өстен ул Раушаниядән яшерергә теләде. Ләкин ирләр беркайчан да урынны хатын-кыз кебек пөхтә итеп җыя алмыйлар. Шуңа күрә хужа егет юынырга дип аш ягына чыгып китүгә, Раушания урынны яңа баштан җыярга тотынды. Караваттагы ак җәймәләрнең чат-чатларын тартып, мендәр-күпчекләрен күпертеп, кабат урынны җәйгәндә, күзе ятак өстендә яткан сыңар колак алкасына төште. Колак алкасын күреп алгач, кызның йөрәге чәнчеп куйды. Ул арада, муенына сөлгесен урап, юеш чәчен сөртә-сөртә, Инсаф килеп керде. Кыз аңа әнә шул табылдык колак алкасын сузды. Хәер, егет аптырап калмады, үз-үзен бик тиз кулга алып:

— Нәрсә бу? — дип сорады.

— Колак алкасы.

— Кемдер калдырган, күрәсең.

— Караватыңнан таптым...

— Кичә кеше күп иде, — дип акланды егет һәм, колак алкасын кызның учыннан алып, бәллүр савытлар тезелгән иске сервант алдына куйды. — Берәрсе онытып, төшереп калдыргандыр...

— Ашыйсыңмы? Чәй кайнаган! — диде кыз, әлеге табылдыкка артык әһәмият бирмәскә тырышып.

— Аха! — Алар аш ягына чыктылар. Өстәлдә самавыр кайнап тора, кыз ике төрле салат ясаган, табада яңа бәрәңге кыздырган. — Раушания...

— Әү?

— Мин сине танымыйм, ни булды сиңа?

— Утыр!

Инсаф өстәл янына утырды. Кыз аңа чәй ясады. Ләкин аның эчәсе дә, ашыйсы да килмәде, ул кыздан күзен алалмады. Үзгә иде ул бүген, үзгә. Ниһаять, кыз үзе дә табын янына утырды һәм әз генә чәй йотып куйды.

— Беләсеңме, мин бүген төне буе йокламадым, — диде Раушания.

— Нигә?

— Сине уйладым. Сине генә түгел, билгеле, үземне дә. Һәм мин шундый фикергә килдем...

— Нинди, әгәр сер булмаса?

— Мин дөрес яшәмим бугай. Сиңа карата мин дөрес гамәлдә түгелмен. Менә шуны аңладым. Үзем сине яратам, ә үзем сине читкә этәрәм. Кичә кунакка килсәм, ни була инде? Каприз, җүләр каприз! Мин килмәгәннән берни дә булмады: кунакларың килде, аулак өең гөрләде. Шулай бит?

— Шулай! — диде Инсаф, чәй йотып. — Кыстати... Мәхмүт тә... Хәсти дә... э... э... Сылу да... барсы да сине сорадылар. Кая ул, нишләп килмәде, диделәр?!

— Шулаймы?

— Ә син кая идең соң, бәгърем?

— Синең янда идем...

Беркатлырак иде аның Раушаниясе, самими, саф күңелле, нәрсә әйтсәң дә, шуңа ышана. Менә хәзер дә ул яраткан Инсафының кичәге гөнаһын һәм хыянәтен яшереп, аның алдында уен уйнап утырганын сизми, сизсә дә (хатын-кызлар ул нәрсәгә бик тә сизгер!), беләсе һәм шуңа ышанасы килми. Раушания, чәен ташлап, Инсаф алдына килеп утырды. Ничектер җайсыз килеп чыкты ул: егет тә аны теләмичә генә кочты һәм, ирексездән, сәгатькә карап куйды.

— ...күңелем белән, — дип дәвам итте кыз. — Үз-үземә сүз бирдем: мин сине хәзер бер генә минут та ялгызың калдырмаячакмын. Син шуңа ризамы?

— Риза, — дип төксе генә җавап бирде егет һәм тиз генә Раушанияне аягына бастырды. — Соңга калам...

— Ашыгасыңмы?

— Кибет янына бер дус килергә тиеш.

— Кем ул?

— Дус.

— Нишләп ул өйгә килми?

— Андый кешенең монда күренмәве хәерлерәк.

— Янына дружокларың кайта башлаган, диләр. Син дөрес юлдамы соң, Инсаф?

— Мин һәрвакыт дөрес юлда, бәгърем! — Монысын ул ничектер ачу белән әйтте.

— Ачуланма... мин бит... болай гына...

— Ярый, мин хәзер кайтам! Китмә, өйдә бул!

— Инсаф! — Раушания инде киенеп китәргә торган егетне кабат туктатты.

— Нәрсә?

— Минем сиңа сөенечле хәбәр җиткерәсем килә...

— Нинди?

— Мин әти-әни белән ныклап сөйләштем.

— Җә?

— Яхшылап сөйләштем!

— Ну?!

— Алар риза.

— Нәрсәгә?

— Оныттыңмыни?

— Юк, онытмадым.

— Алар мине сиңа кияүгә бирергә риза. Ишеттеңме, алар риза! — Раушания, елмаеп-балкып, Инсафның кочагына сарылды. — Син нәрсә, сөенмисеңме?

— Сөенәм! — дип эндәште ул тешен кысып һәм ишекне бик каты итеп ябып чыгып та китте. Кыз бик нык аптырады. Нәрсә булган аңа? Нишләп

ул бер дә сөенмәде? Һәм бары тик шунда гына күңеле белән сизенә һәм нидер аңлый башлады кебек. Капылт кына өстәл янына утырып, суынган чәен янартты, дулкынланудан рәтләп эчә дә алмады, яртылаш түгеп бетерде. Аннан елады, елап туйгач, зал ягына йөгереп чыкты һәм сервант каршында яткан сыңар колак алкасын кулына алды. Учына салып, каты итеп кысып та карады, ләкин алка ямьшәймәде — яхшы сыйфатлы алтыннан коелган иде булса кирәк...

## 8

Раушания аның кергәнен сизми калды. Кулына китап тоткан Ландышны күргәч, бу очрашуның яхшылык белән бетмәячәген шундук сизенде. Колак алкасын вакытында яшерергә өлгерде, аны урманда төз наратлар сыман басып торган бәллүр бокаллар арасына шудырды. Өйдә Раушанияне күргәч, Ландышның кәефе кырылды. Булачак хуҗабикә белән ул бик коры гына күреште.

— Исәнме!

— Исән...месез...

— Хуҗа кая?

— Сез... Инсаф янынамы? Хәзер кайта, ул бер кеше белән күрешергә дип кенә китте.

Кунак хатын аны тыңламады да кебек. Кисәк кенә карават янында тулгана башлады, мендәр һәм җаймә асларын актарды. Сәер, бик тә сәер иде бу...

— Сез кем соң?

— Ландыш мин. Латыйп хатыны. Ишеткәнен бармы?

— Юк, мин бу авылдан түгел. Әлегә күп кешеләрне белмим.

— Мин дә бу авылдан түгел, — диде эзләнүен дәвам иткән хатын. — Син Раушания бит әле?

— Әйе, шулай, — диде кыз һәм аның ирексездән күкрәкләре киерелде. — Инсафның булачак хатыны. Каян беләсез?

— Инсаф әйтте. Үзем дә бер мәртәбә күреп калдым сине...

— Кайда?

— Китапханәдә.

— Әйе, мин аннан бер мәртәбә китап алган идем.

— Булачак хатын... хе... белмим, ул бит минә гашыйк... мәхәббәтен аңлатты...

— Инсафмы?! — диде ул, сискәнеп.

— Әйе.

— Кайчан?

— Бүген төнлә. — Кисәк кенә әйтелгән бу авыр сүзләр Раушаниянең йөрәген куырып алды. Имәндә икән чикләвек. Ничек була соң инде бу? Көтеп алган, өзелеп сөйгән егете аңа хыянәт иткән булып чыгамы? Төне буе шушы чит кеше хатыны белән мәхәббәт уйнап ятканмы? Шулай да аның күңеле моңа әле һаман да ышанып бетә алмый иде.

— Бүген төнлә... Аулак өйдәме?

— Әйе, аулак өйдә! — Ландыш, каударланып, ак җаймәне селкеп атты. Раушания инде барсын да күптән аңлаган иде...

— Эзләмәгез!

— Нәрсә эзләмә!

— Сез эзләгән әйбер менә монда. Мәгез, алыгыз!

Ул сервант эченә шудырган табылдыкны алып, Ландышка сузды. Ландыш, исе китмичә генә, колак алкасын кызның кулыннан тартып алды да сул

колагына тагып куйды. Уң колагындагысы исән, үз урынында иде һәм алар кабат пар булдылар.

— Рәхмәт!

— Низышты! — дигән булды эчендәге нәфрәт хисләрен яшерә алмаган кыз. Ул тәмам тулышкан, ярсыган иде.

— Әпсәләмовны менә монда калдырам! — диде хатын, китапны күренә торган жиргә, сервант алдына куеп. — Сау бул!

— Туктагыз! — дип чәчрәде кыз.

— Туктадым!

— Сезгә оят түгелме?!

— Оят! Ни өчен?

— Сез кияүдәге хатын, сезнең гаиләгез бар. Нишләп сез егет белән кыз арасына керәсез?

— Дөресен ишетәсең киләме?

Дөресен әйткәндә, Раушаниянең кыбырсуы Ландышның ачуын чыгара башлаган иде. Бу сөйләшүне ул озакка сузып тормаска, дөресен әйтеп, моңа бик тиз нокта куярга теләде. Бу хәлләрдән тәмам сулуы капкан Раушания әйе, дип тә әйтә алмады, фәкать баш кына селекте.

— Инсаф сине яратмый.

— Без... без... аның белән өйләнешәчәкбез...

— Әйе, ул сиңа өйләнер. Тик беркайчан да сине ярата алмас.

— Ә кемне ярата соң ул?

— Мине.

— Сезне?!

— Әйе. Мин дә аны яратам.

— Ышанмыйм. Инсафның сезне ратуына ышанмыйм!

— Ышанмыйсың?!

— Әйе...

— Әй, кызый! Дөресен әйттерәсең бит инде...

— Әйтегез...

— Әйтимме?!

— ...миңа барыбер...

— Без аның белән бүген төн кундык! — диде бераз тын алганнан соң Ландыш.

Баядан бирле ут йотып, күнеле сызланып торган кыз агарынып китте, хәлен жуеп, урындыкка сөялде. Ничек була соң инде бу? Ул Инсафның жиде ел буе төрмәдән чыкканын көтте. Әти-әнисеннән яшереп, сонгы акчасын жыйнап, качып-посып, аның янына свиданкага йөрде. Раушания үзенең саф, чиста күнеле белән яраткан егетенең бу кыланышын һич кенә дә аңламады. Чөнки (аның уенча) бу башка килерлек хәл түгел. Аны шулай рәнжетергә Инсафның бернинди дә хакы юк кебек иде. Кеше кайвакыт тау хәтле тау күчерә, тик шунын бер генә игелеген дә күрми. Кемдер жепкә салынган инәне (үзе салмыйча!) бер урыннан икенче урынга гына күчереп куя, ә шуннан тау чаклы игелек, дөнья хәтле файда күрә. Юк, бу болай була алмый, мондый кешелексез гамәлнең ахыры һәрчак начарлык белән бетә. Кыз шулай дип уйлады, ә бит аның шулай дип уйларга хакы бар иде.

— Ә ни файда сезгә монардан?

— Ялгышасың, — дип кырт кисте Ландыш. — Мин файда эзләмим. Мин сөю эзлим...

— Нишләп соң аны ирегездән эзләмисез?

— Иремнән тапмадым... кызганыч...

— Кызганыч...

Саташумы соң бу? Нишләп соң әле ул аны кызганырга тиеш?! Раушаниянең үз хәле хәл. Ә, юк... ул аны кызгана. Кемгә ышанырга соң ана? Кемгә? Яраткан кешенә хыянәт итү берни дә тормаган һәм андый гамәл зур гөнаһка саналмаган заманда ул кемгә ышанырга тиеш соң, кемгә?

— Мин елый да алмыйм, ишетәсезме, минем хәтта күз яшем дә чыкмый! — диде авырсынып урыннан торган Раушания. — Мин еларга, кычкырып еларга тиеш! Ә мин... мин елый алмыйм... бары тик бер күз яше... коткарса, ул гына... коткара... ала...

Баядан бирле йөзе чиста ак кәгазьдәй агарынган мескенкәй, чайкалып, сөрлегеп китте, аннан йөрәген тотып, идәнгә тезләнде. Мондый ук хәл килеп чыгар дип башына да китермәгән Ландыш, иелеп, кызны кулыннан тотты. Раушания кисәк кенә кулын тартып алды һәм йөрәк тирәсен уа башлады. Аның сөйләшер, хәтта эндәшер хәле дә калмаган, тыны кысыла иде...

— Сумкада...

— Кечкенә... сумкамда... нитра... глиц... ин...

— Анламадым...

— Сумкада...

Кыз йөрәген тотып чүкте, тынды. Коты очкан Ландыш нишләргә дә белмәде. Нишләргә? Үлә ич бу! Үлә бит бу кыз...

**9**

Инсаф бүген беркем белән дә очрашмады. Очрашасы кешесе белән инде күптән очрашты һәм мәсьәләне ачыклады кебек. Бу атасының аянычлы үлеме белән бәйле иде. Ул һәрвакыт, атасы Нариман үз үлеме белән үлмәгән, аңа кемнәрдер булышкан дигән уйда торды. Фактлар күрсәткәнчә, мәсьәлә ачыкланды да кебек, ләкин бу хакта әле соңрак, соңрак тагын бер кат уйларга булыр...

Кибеткә тәмәке алырга гына дип чыккан егетнең йөрәге, нидер сизенгәндәй, өйгә куды. Уйлаганы юш килгән икән. Идәндә аунап яткан Раушанияне һәм аның янында чарасыз буталган Ландышны күреп, Инсаф иң элек тораташ булып катты. Ландыш идәнгә ауган кызны әле һаман да күтәрергә итенә иде...

— Нишлисез сез?!

— Килгән идем... Әпсәләмовны күтәреп! — дип нидер бытылдады хатын. — Ә ул...

— Кагыл! Торма юлымда! — дип акырды ул Ландышка һәм, аны читкә этәреп, Раушания янына атылды. — Раушания! Раушания!

— Ауды ул...

— Чирле бит ул! Йөрәк чире аңарда! Аңа дулкынланырга да, борчылырга да ярамый. Ярдәм күрсәтмәсәң, китә дә бара! Даруы?

— Ә?!

— Даруы кая? Ул бер сүз дә әйтмәдеме?

— Сумкада, диде...

— Сумка? Ә! Сумка! — Раушаниянең сумкасы залга керә торган ишек катындагы агач элгечкә эленгән иде. Инсаф сумканы «төбе-тамыры» белән элгечтән йолкып алды да, чәчеп, эчендә ни бар, шуның барсын да идәнгә койды. Сумкадан хатын-кыз кирәк-яраклары — пудралар, кершәннәр һәм шулар белән беррәттән төрле зурлыктагы, төрле төстәге кечкенә таблеткалар да коелды. — Менә алар...

Инсаф Раушанияне күтәреп алды да, караватка яткызып, авызына көчләп диярлек дару каптырды. Ландыш стакан белән су китерде, егет кирәкми, дип,

суны кире какты. Бераздан Раушания җинел сулап куйды һәм аңына килде. Инсаф аның башыннан сыйпап, битеннән үпте: «Аллага шөкер!»

— Мин кайда? — дип сорады аңына килгән кыз.

— Бездә... ничек хәлең? — Ул аны кабат кочмакчы булды.

— Ор-рын-ма! — дип эндәште аңа кыз. Ул аны ярсып, кычкырып әйтмәкче иде, ләкин алай ук кычкырып әйтерлек хәле юк иде шул.

— Раушания... Раушаниям... бәгърем! — дип төчеләнгән булды тегесе.

— Кагылма! — Тәмам үлем хәлендә яткан кеше тиз генә торып та басты. Йөрәк авыруы шундый нәрсә шул инде ул: әле генә кеше үлеп ята, бераздан карыйсың, җир җимертеп чабып йөри...

— Син кая?

— Киттем...

— Бу хәлендә...

— Хуш!

— Тукта инде!

— Мин сине күралмыйм, ишетәсеңме, күралмыйм!

— Ни өчен?

— Әйтер!!!

Раушания кулы белән Ландыш ягына төртеп күрсәтте һәм ул уйлап өлгергәнче, сумкасын җыештырып, өйдән чыгып качты. Инсаф аның артыннан чыгып йөгермәкче булды, тик нигәдер тукталып калды. Йөгерүнең, ялынуның мәгънәсез икәнлеген аңлады ул. Андый горур холыклы, баш бирмәс кеше белән бу хәлләрдән соң сөйләшеп, нидер аңлатып торуның мәгънәсе юклыгын яхшы аңлый иде. Бертуктаусыз бүлмә буенча йөренгән егет тәмәке кабызмакчы булды, ләкин шырпысы яңгыр астында чыланган булып чыкты. Җене кузгалган Инсаф, каударланып, тәмәкесен тәрәзәдән атып бәрде.

— Күңелең булдымы инде?

— Аңламадым?

— Сөйләдеңме барсын да?

— Сөйләдем.

— Нигә?

— Ялганлый белмим, — дип турыдан ярды хатын. — Яшереп торганчы, турысын әйтүең яхшырак.

— Йөрәге авырту кызга, шулаймы?!

— Гафу ит, ансын уйламаганмын, мин аның чирле икәнен белмәдем.

— Белсәң, әйтмәс идең инде?

— Белмим, әйтә алмыйм.

— Алай гел дөресен генә сөйли торган кеше булгач, нишләп соң иреңә дә сөйләмисең?! — дип кызып китте Инсаф. — Ирем, иркәем, әйтмичә булдыра алмадым, мин сиңа хыянәт иттем, аулак өйдә, айлы төндә яшь егет кочагында яттым! — дип нишләп соң иреңә кайтып әйтмәдең?

— Борчылма, — дип тынычландырды аны яшь бичә, — тиздән анысы да билгеле булыр, авылда андый хәбәр бик тиз тарала.

— Кая барабыз без? Кая тәгәрибез?! — дип өзгәләнде егет.

— Упкынга, Инсаф, упкынга...

— Упкынга?!

— Әйе. Тик әле соң түгел. Син Раушанияңне кайтара аласың. Минем белән дә, ирем белән дә сиңа кыенлык булмаячак. Әгәр дә...

— Нәрсә?

— Әгәр дә син мине хәзер үк куалап кайтарсаң!

— Куалап? Сине?!

— Ку мине! Ку!!! — Инсаф Ландышны куарга дип талпынгандай булды, тик аныңа килеп, шундук артка чигенде. — Слабо, да?!

— Мин сине куа алмыйм, ишетәсеңме?! Син минем бөтен җанымны, бар күңелемне яулап алдың. Тәнемә рәхәт, җаныма сихәт өстәдең. Синнән башка яши алмыйм мин хәзер, ишетәсеңме?

Алар кисәк кенә кочаклаштылар. Аннан Инсаф аны караватка аударып, кочаклады, үпте. Ландыш сискәнеп сикереп торды.

— Нишлисең син?! Безгә сак булырга кирәк!

— Әй, буласы булган... — Ул Ландышны кабат урынга сөйрәде...

— Шулай да! — Ул Инсафның назын кире какты.

— Ә кемнән куркырга тиеш соң без? Иреңнән?! — Инсаф урыннан торып, стаканга салып су эчте. Комсызланып, йотылып эчте. — Беләсең килсә, мин синең Латыйбыңнан грамм да курыкмыйм! Ул миннән курыксын, ул!

— Нишләп алай дисең?

— Ул бурычлы минем алда.

— Ничек?

— М...м... озак аны сөйләргә...

— Шулай да? — Инсаф озак кына бер сүз дәшмичә, бүлмә буенча йөренде. Барсын берьюлы әйтеп, ачып салу җинел нәрсә түгел. Дөресен әйткәндә, ул аңа бигүк әзер дә түгел иде.

— Төрмәдә мин түгел, ә синең Латыйбың утырырга тиеш иде.

— Ничек?

— Мин аның өчен утырдым.

— Син?! Аның өчен?!

— Кабатлап әйтәм: мин аның өчен утырдым.

— Ә ул ни өчен утырырга тиеш иде?

— Газизне мин үтермәдем, аны синең ирең үтерде.

— Димәк, үтерүче син түгел. Үтерүче — минем ирем. Кызык... Ә Латыйп миңа башкачарак сөйләде. Кайсыгызга ышанырга соң?

— Ансын үзең кара инде...

— Син... кешеләрнең күз алдында бер зәгыйфь, мескен баланы имгәтеп аткансың... Бу — Латыйп сүзләре... Мин моңа алдан ышанган идем, ә менә синең үзеңне күргәч, үзеңне белгәч, шик-шөбһәләрем юкка чыкты...

— Җылы сүзең өчен рәхмәт...

— Димәк, төнлә булды бу хәл...

— Әйе, төнлә клуб бакчасында. Ләкин мин түгел, синең шакалың үтерде аны. Кыйнап үтерде. Бер сүз өчен, ишетәсеңме, бер сүз өчен!

— Нинди?

Сорау катгый һәм ул җавап көтә иде. Инсаф Ландышка менә ниләр сөйләде...

Латыйп шул кичне клубка соңга калып төште. Бик каты эчкән иде ул, ә эчкәч, ни кыланганын да белештерми. Ярсып-ярсып, клуб рәшәткәләрен ватарга тотынды. Авыру чырайлы, нәүмиз җанлы Газиз ана: «Үзебез яшисе авыл, саклыйк клуб бакчасын!» — дип ялгыш кына әйтеп ташлаган иде, тегесе, дуамалланып, шул мескен егетне кыйнарга да тотынды. Латыйпка кушылып, Газизне башкалары да типкәләделәр. Инсафтан башка! Кызык бит! Мескен кешене аны кем дә таптый! Яшь бит әле алар! Бар да гайрәтле: Мәхмүт тә, башкалар да шунда иде... Иң аянычы шул! Шул нәрсә Инсафның әле һаман да күз алдыннан китми... Бакчада нindidер шыксыз хайван сөякләре аунап ята иде. Латыйп шуларның берсен Газизнең авызына тыкты. Төя-төя, акырта-акырта тыкты! Газизнең авызындагы бөтен алгы тешләре сынып чыкты, авызы

ертылды, аннан шаулап кан акты... Түзеп торышлы гына түгел иде моңа! Егетләр Газизне, Латыйптан тартып алып, урам кырына чыгарып салдылар. Ул анда, ыңгырашып, шактый озак ятты. Шуннан соң йөк машинасына салып, хастаханәгә алып киттеләр. Ләкин табиблар аңа ярдәм итә алмадылар. Ике-өч сәгатьтән ул җан тәслим кылды. Иртән егетләрнең барсын да, машинага төяп, районга, милиция бүлегенә алып киттеләр. Сигез кеше арасыннан Инсафны гына утырттылар. Инсаф үзе шуны теләде, аның гына шуңа көче җитте. Әгәр шул сигез кеше арасыннан берәрсе бу җинаятьне үз өстенә алмаса, барысы да төрмәгә утырачак, тагын да зуррак сроклар алачаклар иде. Шул исәптән Латыйп та. Тикшерүчеләр аларга шул нәрсәне сөрде. Сүз дә юк, курку хисе көчле булды. Һәркемдә! Мескен малайны кыйнаганда, бөтенесе дә герой иде, ә җавап бирә башлагач, барысы да куркуга калып, пошаманга төште. Кыскача гына әйткәндә, барысы да куркак булып чыкты. Каян килеп чыкты соң Инсафта шундый кыюлык? Әле борын астына мыек та чыгарга өлгермәгән яшь егет бу мәгънәсез җинаятьне ничек итеп шулай үз өстенә ала алды соң?! Белми, аңламый аны Инсаф үзе дә. Эшнең зурга киткәнен аңлап алган Латыйпта да кеше төсе калмады, ул да куркып калды. Җүләр егет Латыйп кылган җинаятьне үз өстенә алгач, беренче мәртәбә аның әнә шул курку баскан чыраенда бәхетле елмаю хасил булды. Ә үтерүче ул иде бит! Үтергәнче кыйнады Газизне! Әгәр дә ул чын кеше, чын мужик булса, үз гаебен танып, үзе кылган җинаятьне гаепсез кеше өстенә ташламас иде, шәт! Калганнары анда карап торучылар гына булдылар. Егетләр дә Латыйпка шул турыда әйтеп, аңлатып карадылар. Юк! Курыкты! Төрмә белән буяласы килмәде. Ә менә Инсаф нигәдер курыкмады! Егет әлеге җинаятьне үз өстенә аласын белгәч, ул аның яныннан бер минут та китмәде. Боргаланды, сыргаланды, юмалады һәм ана ниләр генә вәгъдә итмәде. Инсафның әнисе ул вакытта бик каты авырый иде. Йөрәгенә операция ясар вакыт житкән. Латыйп аңа да акча табам дип ышандырды, антлар эчте. Аның сүзенә ышансаң, ул барсын да эшләячәк, тик Инсаф кына утырсын, Инсаф кына таш диварда чересен! Тик ул гына, Латыйп кына исән калсын да ул гына, корсагын киереп, ашап-эчеп, иректә йөрсен...

— Ирең әнә шулай исән калды, — дип нәтиҗә чыгарды Инсаф. — Чумды бәхеткә...

— Ничек?

— Малае бар, менә дигән чибәр, акыллы хатыны бар...

— Син аны бәхетле кеше дип уйлыйсыңмы?

— Белмим, — диде егет. — Тик шуны гына әйтә алам: биргән вәгъдәсенең ул нуль бөтен уннан берен дә үтәмәде. Әни өчен бер тиен дә бирмәде. Әнкәй үлде. Әтине кыйнаттырды. Минем янга ул бер генә тапкыр да килеп карамады, бер сынар передача да китермәде. Менә шуннан соң әйт әле, ничек итеп мин шул паганый иреңне хөрмәт итәргә тиеш соң, ә?!

— Әйе, — диде ирексездән уйга калган Ландыш. Ул бу сүзләрне Инсафның җилкәсенә башын куйган килеш, аның күзләренә туры карап әйтте. — Мин әле күп нәрсәне белеп тә, аңлап та бетермим икән. Дура я, наивная дура! Син шуны бел: Латыйпка караганда, мин сиңа күбрәк ышанам. Нигә? Яраткангамы?

— Шуңа күрә Латыйп алдында мин бернинди дә вөждан газабы кичермим, — диде хатынны кочагына кысып үпкән Инсаф. — Белсен: мин аның хатынын тартып алмыйм, ул минем ирегемне тартып алды. Мин яратам, беркемнән дә курыкмыйча яратачакмын!

— Мин дә...

— Тагын кайчан киләсең?

— Бүген кич, Алла теләсә!
— Мин сине көтәм.
— Яхшы. Мин сиңа китап алып килгән идем. Әнә, сервант каршына куйдым.
— Рәхмәт, укырмын...

## 9

Раушания белән аралары бозылуы Инсаф өчен эзсез узмады. Кыз аның хыянәтен кичермәде һәм инде берничек тә кичермәс кебек иде. Бу вакыйгалардан соң бер-ике атна вакыт узды, Инсафның Латыйп хатыны белән иснәшеп өлгергәнен кайбер озын телләр сөйли дә башлаган иде инде. Бу гайбәт сүзләр, ниһаять, аның дәү әнисенә дә барып иреште. Шуңа бик нык хафаланган Кәримә карчык беркөннәре Инсафны өендә эзләп тапты. Керүгә үк, оныгына аты-юлы белән акырырга тотынды:

— Нишлисең син, жаным, ә?!
— Нәрсә булды, дәвәни?
— Нәстә, Латыйп хатыны белән сөйрәлә башладыңмыни инде?!
— Каян беллен?
— Нишләп һаман синең янга йөри ул?
— Китап кертә... укырга!
— Хәзер! Укытам әле мин синең арт сабагыңны! Атаң-анаң урнына калган кеше мин! Оятсыз син! Сабакы! Өтермәдән жүнле нәстәгә үрәнеп кайтмаган икән син! Ү-ү-үтерәм!

Өстәл өстендә яткан агач уклауны эләктереп, ул оныгын куып китте. Дәү әнисеннән мондый ук әрсезлек көтмәгән Инсаф баштa аптырап калды, Кәримә апай, Инсафның туктап калуыннан файдаланып, уклавы белән шәп кенә итеп аның аркасына томырды.

— Ай! Төрмәдә конвойлар да бу хәтле каты кыйнамыйлар иде.
— Мә, башың беткере!
— Дәвәни, бәлкем, житәр!

Кәримә шук, житез оныгы артыннан артык ыргыла алмады, кирәгеннән артык юанайган карчык, аягы авыртудан зарланып, ухылдап, урындыкка утырды. Инсафның исенә төште: балачагында бик шәп итеп шулай бер кыйнаган иде аны дәү әнисе! Ни өчен кыйнаганын хәзер инде ул хәтерләми, мөгаен, шуклангандыр.

— Нишләп син шулай кеше рәнжетәсең, ә?! — дип бытылдады сулуы капкан карчык.
— Кемне?
— Раушанияң миңа килде.
— Сиңа?
— Ие. Ике атна күрешмәгәнсез бит инде. Нигә дип рәнжеттең син аны? Ул шуна лаек баламыни суң?
— Юк, ул аңа лаек түгел.
— Шулай булгач. Бар, барып монда алып кайт үзен! Гафу үтен үзеннән, ишетәсеңме!
— Нишләп сиңа килде соң ул? Миңа килмәде?
— Жәяү, үз аягы белән менгән. Хәзер йөрәге авыртып тора. Йә авылына төшереп бир, йә үзеңә алып кит. Үтерәсең бит инде син аны! Синең өчен кызым шулай кайгырып үлде. Инде Раушанияне дә үтермәкче буласыңмы? Сине яратып, синең өчен жан атып йөргән кыз бала бит ул! Латыйп хатыны сымак теләсә кемнең муенына асылына торган салам сыйрак түгел! Алып кайт

Раушаниянне! Озакка сузмыйсың — үктәберләрдә өйләнәсең. Акча юк дип борчылып йөрмә, табарбыз, кассада әзрәк җыйган акчам бар...

— Дәвани, тыңлале...

— Тынлыйсым да килми!

— Син бит әле үзең дә каршы идең. Раушаниягә өйләнмә, дип колак итемне ашадың...

— Ие, шулай. Башта шулай дип уйлаган идем. Сине сау-сәламәт, тап-таза, дөньясын ялт иттереп торган, менә дигән хатынга өйләндерәсем килде. Тик хәзер фикерем үзгәрде. Раушанияне рәнжетергә ярамый, юк, берничек тә ярамый...

— Дәвани, әзрәк аякка басмыйча өйләнә алмам, ахрысы!

— Никах белән булса да торып торыгыз!

— Аның ата-анасы никах туена гына риза булмаячак, син әле аларны белмисең...

— Ярар, анысын үзеңә кара! — диде Кәримә. — Тик син хәзер безгә барасың. Раушания янына!

— Яхшы! — диде егет, башына тиз генә кепкасын каплап. — Мин әзер.

— Тукта! — дип кычкырды Инсафның каршысына барып баскан карчык. Кәримә бик тә ярсулы иде бүген, аны бу ярсуыннан туктатыр өчен галәм көчләре кирәк иде. Егет башта берни дә аңламады. — Туктале син... кеше хатыны янына йөрүдән! Атап әйтәм: яхшыга алып бармый бу! Латыйпның кем икәнен беләсең! Бик тә явыз адәм бит ул... нәселләре белән шундый алар...

— Бер Латыйпка гына каршы тора алырбыз ансы!

— Нинди кире кеше син, ә! Атаң да мондый кире кеше түгел иде, җайлы иде. Кабатлап әйтәм: шаярма ут белән. Хәбәре бөтен авылга таралачак, инде таралмаган булса. Кияүне, Нариманны, Латыйп кына харап итте, син моны белеп тор, яме! Белеп тор...

— Беләм, дәвани, беләм...

Әйе, Латыйпның Нариманны кыйнатканын малае инде күптән белә иде. Ничек булганын барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр.

Ләкин шул көнне Инсаф Раушания белән күрешеп сөйләшә алмады, аны Кәримәләр йортыннан «Ашыгыч ярдәм» машинасы белән район хастаханәсенә озаттылар.

## 10

Латыйп, Латыйп... Сүз һаман да шул кеше тирәсендә бара. Инсафның кайтканын да белә, югыйсә, ә ул юк, күренми дә, килми дә. Егетнең аның янына баш иеп барасы килмәде һәм ул бармады, бармаячак та!

Ә Латыйп үзе килде, кыш уртасында тиктомалдан килде дә керде. Ул бәлкем Инсаф янына килмәгән дә, аңа кермәгән дә булыр иде, әгәренки авыл тирәсендә хатыны төрмәдән кайткан егет белән йөри, дигән гайбәт сүзләр таралмаса. Хәер, хуҗа егет тә аптырап калмады, кунак килүгә, аңа башта концерт куйды, чып-чын концерт. Латыйп кары көрәлгән тар сукмактан атлап өйгә кергәндә Инсаф рәхәтләнеп гармунда уйнап утыра иде. Күрәсең, ул Латыйпның өйгә кергәнен күреп калган һәм гармунны да кулына шуңа махсус алган иде. Латыйпка шулай тоелды. Егет кунакны күз кырые белән генә күзләп алды да, аңа ни кул бирмичә, ни утырырга урын тәкъдим итмичә, җүләр кеше сыман, гармунда уйнавын дәвам итте. «Җүләр»нең гармун уйнаганын тыңлап, карап, Латыйп озак кына ишек төбендә кагаеп торды. Авыл җирендә әле аны берәү дә шулай санга сукмыйча, мыскыл иткән сыман ишек төбендә тотканы булмады! Чырай сытылды, кәеф бозылды. Бераздан түзмәде — тамак ярып акырды ул:

— Карале, тиндәш, мин бит монда үзешчән сәнгать концерты тыңларга дип килмәдем!

— Нигә килдең? — дип сорады Инсаф, гармунны әкертенрәк уйнап.

— Сөйләшергә, аңлашырга дип килдем!

— Сөйләшеп кенә аңлаша алырбыз микән? Кредит доверия исчерпан, брат!

Шул сүздән соң Инсаф тагын да катырак уйнарга тотынды, уйнап кына калмады, җырлый да башлады. Ул моңлы, мәгънәле җырлар җырларга ярата иде. Бу юлы исә ул әлеге җыры белән чакырылмаган кунакны кечерәйтеп, мыскыл итебрәк җырлады кебек...

Бер тауда ун чишмә,
Унысы ун төстә.
Берсе тиз болгана,
Берсе тиз моңлана
ком-ташта...

Латыйп инде торып китәргә торганда гына, гармунчы уйнавыннан туктады һәм гармунга өргәләгән булып, аны сак кына сандык өстенә утыртты. Ниһаять, ул Латыйпны бөтен мөчәсе, төсе-кыяфәте белән күрде. Урамда ерактан гына бер-ике мәртәбә күзгә чалынды ул, ләкин анда җүнләп күреп бетерә алмады. Үзгәргән, олылар кыяфәте кергән. Аларның яшь аралары әллә ни зур түгел, шулай да Инсаф әле аның янында шактый яшь булып күренә иде. Латыйпка чынлап та олылар төсе, ир-ат кыяфәте кергән иде. Юанайган, корсак чыккан. Карап торышка ул май баскан бурсыкка охшаган, әрсез җан, оятсыз чырай. Холкы да шактый бозык — кызып китеп, һәр сүзгә бәйләнергә генә тора. Элегрәк авылда ата хулиган булып саналса, хәзер ул үзен авылның иң зур, иң бай кешесе итеп хис итә иде. Акчасы бар, чит ил машинасында гына йөри, бригадасы эшләп тора, заказлар җитәрлек. Авылдашлары алдында: «Фәлән хәтле колхозчыга эш урыны ачтым мин!» — дип мактанып йөрергә дә ярата...

— Сөйләшергә дип килдең түгелме соң?

— Килдем, тик...

— Каршы алуым ошамады, шулаймы?! — Латыйп, белмим дигән сыман, җилкәсен җыерды.

— Ә ничек каршы алыйм мин сине? Әгәр җүнле бәндә булсаң, кайтуга ук яныма кергән булыр идең, өенә чакырып, кунак итәр идең. Юк бит! Жиде ел төрмә шакшысын җыйдым. Аңлыйсыңмы? Ә син миңа нинди игелек кылдың? Әнкәйгә ярдәм итәм дип вәгъдә бирдең дә...

— Сәбәпләре булды, — дип акланды кунак. — Ул чакны мин бу кадәр үк аякка басмаган идем. Бригадам булса да, шабашкыларым юк иде. Ни белән ярдәм итим? Бетем беләнме?!

— Юк кына нәрсәдән дә кешенең күнеле була. Синнән әнине больницага илтергә дип машина сорап кергәннәр, ә син машина кабызырга да бензин юк, дип әтине кире борып чыгаргансың. Әнине пожарный машинасында алып барганнар. Ике сәгатькә соңга калган. Син бит, авылда булып та, әнине күмәргә дә килмәгәнсең. Әйтерсең лә әни дә юк, мин дә юк...

— Әйтәм бит...

— Әйтмә! Мин бит кайтуга синнән фатир да, иномарка да сорамадым. Игътибар, кешечә игътибар гына кирәк иде...

— Туктале! — дип бүлдерде аны кунак. — Мин синең яныңа бүген акланырга

да, якланырга да килмәдем. Мин, беләсең килсә, шул ялгышны төзәтергә дип килдем.

— Кызык. Ничек итеп?

— Ә менә ничек...

— Ничек?

— Буш кул белән дә килмәдем...

Җылы өйдә эсседән эреп тирли башлаган Латыйп башта кара пуховигын салып элде һәм шуның кесәсеннән бер калын гына конверт чыгарды. Конвертны, сөеп-назлагандай, озак кына учында угалап торды, соңыннан шапылдатып өстәлгә китереп салды.

— Нәрсә бу? — дип сорады Инсаф.

— Акча.

— Акча?!

— Ие. Йөз дә илле мең. Элек юк иде миндә андый акчалар. Ә хәзер бар. Хәзер, бр-р-рат, мин дөньяның артына тибеп яшим! Ал, сиңа ул!

Инсаф, кызыксынып, конвертның чатын ачып карады. Конверт эчендә чынлап та таслап төрелгән эре акчалар ята иде.

— Ал! Синеке! Аздыр дип уйламыйм...

— Рәхмәт! — диде егет берникадәр уйнап. Ул кызык өчен хәтта конвертның тышын үбеп, чатын иснәп тә куйды. — Бик вакытлы китердең. Как раз өйләнергә йөрим... Ах! Акчаның исе юк, диләр... Бар икән бит, бар!

— Акчаны аласың. — Латыйпның хәтта тавышы да үзгәрде, хуҗаларча басынкыга әйләнде.

— Әйе...

— Бер шартым бар...

— Нинди шарт?

— Акчаны аласың да, авылдан таясың!

— Син миңа андый шарт куя алмыйсың! — дип кычкырды аңа Инсаф һәм конвертны кире өстәлгә бәрде. — Шартны мин үзем куям, аңладыңмы?! Курыкмыйм, сиңа гына көчем җитәр. Мин синең үзеңне туган авылыңнан куам! Мин түгел, ә син китәчәксең авылдан, ишетәсеңме, син!

— Нәрсә, гаебем зурмыни соң шул тиклем синең алда?!

— Зур.

— Яшьлектә ни генә булмый, кардәш. Син бит үз теләгең белән барып кердең анда. Сине беркем дә көчләмәде. Аласың юк иде үз өстеңә булмаган гаепне, нишләп алдың соң?!

— Мин хет кеше булып калдым. Ә син...

— Нәрсә мин?

— ...опустился.

Латыйп эшнең кая барганын яхшы аңлады. Әйе, Инсаф алдында аның гаебе зур иде. Ул аның җинаятен үз өстенә алды. Ни өчен алганын аңлавы кыен. Чынлап та, ул вакытта Латыйп яшьләр арасында авторитет иде. Ләкин аңардан куркып кына бу саф күңелле егет шундый юлга баргандыр дип тә әйтеп булмый. Моның төбендә Латыйп аңламаган икенче бер нәрсә ята, тик аны һич кенә дә аңларлык түгел. Күрәсең, ул моны аңларлык дәрәҗәдә түгел иде әле...

— Әтине ник үтердең? — Бу гаепләү сүзләре алдагысына караганда да зәһәррәк яңгырады.

— Нахак сүз. Мин Нариман абыйны үтермәдем. Аллам сакласын! Батып үлде ул!

— Беләм, син аңа бармак белән дә тимәгәнсең.

— Дөрес, мин аңа тимәдем.

— Тик ул шул ук бер нәрсә: син аны кеше аркылы кыйнаттыргансың. Заказал ты его, анлыйсыңмы?!

— Юк, дөрес түгел бу...

— Ни өчен икәнен дә әйтимме?

— Авыл халкы шулай дип сүли инде. Имеш, мин анардан арзан бәядән тана сораганмын. Җүләр бу халык, ә! Мин Латыйп башым белән, нәстә, шул хәерче атанның танасына калганмы?!

— Юк, аның өчен генә түгел. Ярты елга түләнмәгән хезмәт хакын сорап килгән өчен, шунар эшләүче егетләрне дә котырткан, дип кыйнаткансың син аны. Ул ярты елдан артык синең бригадыңда эшләгән. Кулсыз, гарип кешегә канау казыткансың бит син, мәнсез!

— Казымыйча да булмый... Акча җинел генә таммый...

— Үзе өчен казымады ул: мина ярдәм итәр өчен казыды. Яхшы тормыштан түгел. Ә син аны борып җибәрден, син аңар бер тиен дә түләмәден!

— Ну... ялгышлар булган инде, нишлисең! — диде ул, конвертка күрсәтеп. — Шунар күрә менә...

— Нәрсә?

— Ялгышымны төзәтергә дип килдем.

— Әтине ни өчен рәнҗеткәнеңне яхшы беләм, — дип дәвам итте Инсаф. — Нәселне корытырга теләден. Менә шушы йортта, шушы туган нигезебездә беркем дә калмасын дигән мәкерле уй белән, буш хыял белән яндың син. Йорт бушап калгач, нигез чери башлагач, бик каты сөенден. Мине кайчан да булса монда кайтыр дип уйламадың. Ялгыштың, брат! Мин кайттым. Барыбер кайттым. Ка-а-айттым, ишетәсеңме?!

— Яшермим. Мин сине шунда дөмегерсең дип уйлаган идем.

— Туры сүзең өчен рәхмәт! Менә син мина хәзер ошый башладың...

Ә Латыйпка болай сөйләшү бер дә ошамый иде, билгеле. Төрмәдән чыккан ниндидер бер әтрәк-әләм (әллә кем булганмыни!) Латыйп хәтле Латыйп белән шулай әрсезләнеп, оятсызларча күкрәк киереп сөйләшеп торсын әле! Авылда мондыйларны ул беренче күрә. Ул бит аңа яхшылык белән килде, әзме-күпме акча күтәреп килде. Тукта! Нишләп әле ул Латыйп башы белән шушы маңка малай алдында җебеп төшәргә тиеш, аның җырын җырлап, аның көенә биергә тиеш соң әле?! Юк, болай булмый, дөньялар болай барса, бу төрмә кошы озакламый аның башына да җитәргә мөмкин.

— Менә син Нариман абыйны кыйнаттырдың, дип мина яла ягасың! — дип кисәк кенә башлады үл сүзен. — Каян чыгып әйтәсең син моны? Кем дә булса күргәнме аны, кем дә булса беләме, әйт?

— Белә.

— Кем?

— Калунны беләсеңме?

— Калун?! — диде Латыйп, белмәгән сыман кыланып. — Кем ул?

— Без аның белән күрештек. Ул кайчандыр синең бригадыңда эшләгән. Син аны кудың. Ул барсын да күреп торган, күзәтеп йөргән. Төнлә кап-караңгы фермада изгәннәр әтине. Сыразы гына бирешмәгән, кәнишне, каршы торып караган. Ләкин бер кул белән генә, бер кулга гарип килеш, өч кешегә, өч подонокка каршы торып була димени?! Үтергәнче үк кыйнамаганнар, билгеле, әле тагын ике ай яшәрлек гомерен калдырганнар...

— Күрәм! — дип үпкәләгән сыман кузгалды кунак. — Синең белән сүләшеп булмый икән!

— Тукта! — Латыйп кисәк кенә туктарга мәҗбүр булды. — Ал акчаңны!

— Биргәнне кире алмыйлар...

— Төрмәдә утырганда, бер сорау баштан китмәде, — диде Инсаф һәм акчалы трофейны кулына алды. — Нигә дип кыйнадың инде син ул Газизне? Аның сиңа ни зыяны тиде соң? Авызына сөяк тыга-тыга кыйнадың бит син аны, җир бит! Нигә? Ни өчен?

— Яшь вакыт, җүләр вакыт, диләрме әле? — диде тегесе кайгыны уртаклашасы, ялгышын таныйсы урынга ничектер ясалма кыткылдап. — Нәрсә кыланганны да белми идек бит! Хәзерге чагым булса, бармак белән дә тимәс идем. Аннан ул үзе дә гаепле...

— Ни өчен?

— Авызын белеп ачсын иде!

— Ә мин, беләсеңме, хәзер нишләр идем?! — дип кинәт кенә ярсыды егет. — Менә шушы кәгазь конвертны, акчалары белән бергә авызыңа төеп тутырыр идем! А-а-авызыңа, ишетәсеңме?!

— Эш нидә соң? Нәрсә комачаулый? — дип астыртын гына елмайды тегесе. Ләкин ул елмаю тиздән эреп юкка чыкты, аның яхшы ашаудан симергән майлы иякләре алга таба асылынды.

— Хатының...

Латыйп «аңламадым», дип иңен җыергандай итте. Гаҗәп иде бу...

— Әйтимме дөресен?!

— Әйтеп кара инде...

— Аны яшерүдән мәгънә юк. Барыбер билгеле булачак...

— Әйт соң, тыңлап карыйк...

— Мин синең хатының белән йокладым.

Бу сүз аяз көндә яшен суккандай яңгырады. Латыйп, ни әйтергә дә белмичә, тораташ булып шок хәлендә торган арада Инсаф конвертны акчасы белән бергә аның аяк астына ташлады. Гаҗәеп читен һәм уңайсыз хәлдә калган кунак, авыр булса да, иелеп, идәнгә ташланган конвертны күтәрергә мәҗбүр булды. Әйтерсең лә ул акчаны түгел, ә үзенең түбәнсенүен күтәрде. Пуховигының төймәләрен каптырырга да онытып, кунак, һөҗүмнән качкан дошман сыман, өйдән чыгып чапты. Инсаф сандык өстендә торган тальянын алып, ярсып-ярсып уйнарга тотынды:

Бер тауда ун чишмә,
Сереңне син чишмә,
Сереңне чибәрләр
Дөньяга сибәрләр,
сибәрләр...

Латыйп чыгып киткәннән соң, ул нигәдер аның турында түгел, ә якты дөнья белән вакытсыз хушлашырга мәҗбүр булган Газиз турында уйланды. Бик яшьли гомере өзелгән, әле бу дөньяны җүнләп аңлый да алмыйча калган яшь егетнең язмышы нишләп шул хәтле ачы булды соң? Инсаф бу җинаятьне үз өстенә алып, үтерүче исемен алгач, Газизнең әнисе Хәмидә аны елый-елый каргаган. Гаепсез кешегә каргыш төшми, диләр, ләкин бу очракта алай дияргә ярамый. Атасы Нариман белән анасы Зөмәрәнең әнә шулай вакытсыз үлүләре дә яшьли үтерелгән бала анасының каргышы белән бәйле түгел микән әле?! Хәмидә апасы әле дә исән, тик ул аның янына барып, аның алдында да, Ходай каршында да үзенең гаепсез түгеллеген исбатларга һаман да базмый иде. Аңламас, куып чыгарыр, бусагасыннан да уздырмас кебек тоела иде. Кеше бит ул ихлас сүзгә, җан кушуына түгел, ә иң элек мәхкәмә чыгарган законлы карарга ышана.

Гармунын кочаклап утырган хәлдә ул барыннан да бигрәк әнә шул изеп,

таптап, кыйнап үтерелгән Газизжанны кызганды. Нишләп соң аны беркем дә яклый һәм шул вәхши кулыннан йолып ала алмады? Инсаф үзе нишләде, кая карады? Димәк, Газизнең үлемендә аның да гаебе бар, ул бөтенләй үк гаепсез түгел. Вөҗдан газабы белән газапланган җаны аны шушы дөнья сагышы белән бергә елардай итте. Китми, күз алдыннан һич кенә дә китми ул яшь егет! Авызы каерылган, авызыннан шаулап кан аккан яшь Газизне ул, бу якты дөньяда күзе йомылганчы, гомерендә дә хәтереннән сызып ата алмас шикелле.

## 11

...Алар иртән таңда килеп керделәр.

Латыйп белән очрашканнан соң әле өч кенә көн вакыт узган иде. Инenә сөлгесен салган Инсаф, көзгe каршына басып, юынып, кырынып тора иде. Башта кулына папка тоткан Мәхмүт килеп керде, бу юлы инде ул милиция киеменнән иде. Аның артыннан ияреп кергән Латыйпны ул башта шәйләмәде, бөтен игътибары өлкән лейтенантка күчкән иде. Мәхмүт, ниһаять, Алсинәгә өйләнде, Инсаф аларның туйларына да чакырулы иде, ләкин ул, юк-бар сәбәп табып, туйга бармады. Аулак өйдән соң аралары шактый салкынайды аларның. Берсе милиционерларны яратмый, икенчесе аңа «төрмә кошы» дип кимсетеп карый иде. Лейтенант үзен бик дәрәҗәле, вәкарь тотты. Әйтерсең, туганының өенә түгел, ә ниндидер җинаятьче качып яткан тамуг оясына килеп керде.

— Исәнме!

— Исән... Котлыйм! Участковый итеп куйганнар икән үзеңне!

— Куйдылар. Менә хәзер синең эшең килеп чыкты, шуңа протокол тутырырга куштылар.

— Минеке?! — дип гаҗәпләнде егет. — Мин эшемне төрмәдә бетереп чыктым, туган. Так шту — шито-крыто!

— Яңа эш. — Мәхмүт өстәл янына утырды. Ул, өстәл өстендә тулып яткан савыт-сабаларны читкә этеп, кулындагы папкасын ачты. — Гражданка Ландыш Фәтхуллина синең өстән гариза язган.

— Ландыш? Фәтхуллина?

— Әйе, ул! — Шулчак өй эченә Латыйп үтеп керде, утырмакчы булган иде, тик беркем дә аңа урын тәкъдим итмәгәч, кергән урынында басып калды. Тик ул нигәдер бик тынычсыз иде, аның күзе гел ишек ягында булды...

— Ландышның ирен дә чакырдым, — диде Мәхмүт, сытык елмаеп. — Латыйп Фәтхуллин. Ул шаһит буларак кайбер нәрсәләргә ачыклык кертергә тели.

— Нәрсә дип гаепли инде ул мине, гражданка Ландыш Фәтхуллина?

— Менә аның гаризасы. — Лейтенант папкадан бер кәгазь кисәге чыгарып, аны Инсаф кулына тоттырды. — Укы.

Гаризаны чынлап та Ландыш язган иде. Аның кулы, таныш кул. Ул Инсафны үзен кыйнауда гаепли. Шаккаткыч, искиткеч хәл бу! Нәрсә, нәрсә, ләкин үз тормышында мондый текә борылышлар булыр дип уйламаган иде ул. Ничек була соң бу? Сөйгәне аның өстеннән донос яза! Юк, үзе теләп язмаган ул аны! Тик кайчан кыйналган соң ул? Кыйналган килеш күрмәде дә бит ул аны. Гаҗәп иде бу! Инсаф башта кычкырып көлде, шуннан соң Латыйпка текәлде. Бу адәмнең төссез чыраенда ниндидер мәкер ятканын аңлап алган егет шулчак Латыйпка ташланды, юынган сөлгесе белән аның муеныннан чорнап алды...

— Син нәрсә уйлап таптың тагын?! Буам, сволычь!

— Тукта! Син нәрсә! — Мәхмүт (милициядә өйрәткәннәр, күрәсең!) яшен

тизлеге белән Инсафның кулыннан борып алып, аны башы белән идәнгә терәде. — Житте! Тынычлан!

— Яхшы... җибәр...

— Мәхмүт... иптәш лейтенант... моны да пратакулга керт... ул миңа һөҗүм итте! — дип мескенләнде шаһит. Латыйп, явыз Латыйп бу минутларда нигәдер үз-үзенә охшамаган иде. Хәер, аны да аңларга була, ялганчы үзенең кайчан да булса фаш ителүен аңлап, андый вакытларда куркакка әйләнә.

— Ә кая соң үзе? — дип сорады егылган җиреннән бик тиз торып баскан гаепләнүче.

— Кем?

— Потерпевшая?

Мәхмүт, бер сүз дә дәшмичә, эре кыяфәт белән кабат өстәл янына килеп утырды, папкасын ачып, кәгазьләрен барларга тотынды.

— Кая ул? Чакыр монда! — дип әмер бирде ул Латыйпка. Милиционер роле Мәхмүткә яхшы бара, ул үзе дә шул рәсмилектән ниндидер тәм таба кебек иде. Әле ул кайчан шулай Латыйпка, бөтен авылны кулда тотып торган Латыйпка, әмер бирә алыр иде икән?! Тегесе дә бер сүз дәшми, Мәхмүт кушканны гына үти. Ул салкын чоланда басып, туңып беткән Ландышны алып керде. Инсаф аның йөзен күрмәде. Ниндидер карачкыга охшаган иде ул, шул кыяфәте белән барсын да сискәндерде. Башына җылы шәлъяулык бөркәнгән, ияк аслары капланган, өстенә гомер кимәгән ниндидер иске яшел пәлтә, ә аягына башлары тишелер хәлгә җитеп, шактый гомер күргән һәм җир төсенә кергән шакшы киез итекләр кигән иде. Йөз кыяфәтләре шешенгән булса кирәк, тик ул аны беркемгә дә күрсәтми, яшереп тота иде.

— Әй, жаным, — дип балаларча беркатлы сөйләнде Латыйп. — Утыр, әйдә, утыр, кара син аны, карарлык жирен дә калдырмаган. Вәхши! Да... зрә генә төрмәгә утыртмыйлар икән!

— Ландыш, ни булды сиңа? — дип тартылды Инсаф хатын ягына. Латыйп, кулын сузып, аның юлына аркылы төште. Ландыш, урынга утырудан баш тартып, түргә каршы аркасы белән борылды...

— Тукта! — дип кычкырды участковый. — Әйт, кыйнадыңмы син Ландыш Фәтхуллинаны? Юкмы?

— Юк, билгеле. Нишләп кыйныйм мин аны, минем башыма тай типмәгән! Ландыш, әйт, кыйнадыммы мин сине, әйт? Нигә дәшмисең?

— Ул сөйләшә алмый, — диде Латыйп, хатыны берни дә эндәшмәгәч.

— Нигә?

— Син бит аның сугып ияген сындыргансың!

— Аның дәшмәскә хакы бар, — дип кысылды лейтенант. — Гаризада барсы да язылган.

— Мин аны үзе язган дип уйламыйм, — дип каршы төште гаепләнүче. — Ана көчләп яздырганнар. Ландыш, әйт дөресен! Кем кыйнады сине, әйт?!

Латыйп хатынын көчләп диярлек участковый каршына китереп утыртмакчы иде, ләкин Латыйпның бу теләгенә каршы килгән Ландыш өйдән бөтенләй чыгып качты. Инсаф исә аның артыннан: «Күрдегезме инде?!» — дип кычкырып калды.

— Син миңа туган тиешле кеше, мин сиңа начарлык теләмим, — диде Мәхмүт, берникадәр йомшарып. — Ләкин аңла: гариза кергән, без аны тикшерергә, ачыкларга тиешбез.

— Ачыкла, бер сүзем дә юк! Синең икмәгенә тимим! Минем үземә дә бик кызык булып тоелды әле бу! — дип күнелле генә җавап кайтарды Инсаф.

— Әгәр дә җинаятең ачыклана икән, синең өчен яхшы нәрсә түгел бу, туган!

— дип куркытты ул Инсафны. — Син бит инде бер мәртәбә җәзага тартылдың, икенчесен алу беренчесенә караганда җинелрәк булыр. Сине тагын җавапка тартырга мөмкиннәр...

— Кемнәр?

— Органнар.

— Тартсыннар! Минем гаебем юк, туганым, минем органнардан куркыр киемнәрем тузган.

— Кыйнадыңмы? Җавап бир!

— Соравыңа сорау белән җавап бирергә рөхсәт ит, иптәш участковый. Ни өчен соң мин аны кыйнарга тиеш? Әйт, ни өчен?

— Аулак өй харап итте аны, аулак өй! — дип сүзгә кушылды Латыйп.

— Причум монда аулак өй? — диде Мәхмүт. Үзе дә шунда булганга күрә, аның аулак өйләрне искә төшереп утырасы килмәде.

— Эш монда болай, — дип дәвам итте Латыйп. — Менә бу егет тегеннән кайтуга ук, минем турыда авылда гайбәт сүз таратты. Имеш, ул минем өчен утырган, имеш, минем аркада җәфа чиккән. Ул гына кеше, ә Латыйп — бандит. Ләкин моның дөреслеге әлегә берничек тә расланмаган. Мондый хаксызлыкка, миннән дә бигрәк, хатынның бик нык ачуы чыкты. Мина берни дә әйтмичә, ул менә шушы бәндә янына килгән. Килде бит?

— Килде... тик...

— Ә ул, күрәсең бит, нервный, сүз күтәрми. Тоткан да минем хатынга суккан! Башта эченә типкән, аннан ияген җимергән...

— Мәхмүт, син шуна ышанасыңмы? — дип кычкырды Инсаф.

— Мин фәкать фактларга гына ышанам, — дип җавап бирде участковый.

— Эй, туган, син дә шушы бәдбәхетнең җырын җырлагач, белмим инде...

— Эшең харап, туган, адвокат ялларга туры килмәсен сина. Харап, харап...

Шулчак өйгә тиктомалдан гына Кәримә килеп керде. Кара бишмәтен кигән, кулына өч литрлы пыяла савыт тоткан. Аның ничек килеп кергәнен беркем дә аңламады. Соңыннан ачыкланды: Инсафның күршеләренә сөткә (үзе сыер асрый алмый) кергән икән, шунда капка төбендә милиция машинасы күргәч, ашыга-ашыга монда кереп житкән. Капкадан кергәндә аңа әле Ландыш та очраган...

— Ыдвакаты бар аның! — дип бөтен йорт эченә сөрән салды ул.

— Кем? — дип сорады Мәхмүт.

— Мин.

— Чит кешеләргә монда урын юк! — дип такылдады Латыйп.

— Үз өемдә мин чит кеше түгел! Яраткан кызымның, киявемнен нигезе бу! Нәстә, минем улым өстеннән суд ясарга булдыгызмыни?!

— Суд булачак, — диде лейтенант. — Әлегә ачыклау бара. Аннан дело ачарлар, тикшерүчене дә билгеләрләр...

— Тикшерәм әле мин сезгә, тикшерәм! — дип янады Кәримә. Шулчак ул, Мәхмүтнең папкасын тартып алып, аңа кизәнә башлады. Лейтенантның күзләре шар булды. — Нәстә, участковый булдыңмыни?! Мин туган кеше дип тормам, бер сылап җибәрергә дә күп сорамам! Чыгып кит моннан!

— Дәвәни, акрын, ул бит участковый! — дип ялынгандай итте Инсаф. — Тикшерә бит...

— Участковый! — дип мыскыллы итеп көлде ул. — Аның кебек! Тикшерүче, җаным, син түгел, мин ул!

— Җитәр инде, тугани апа, булды! — диде тәмам кәефе кырылган Мәхмүт.

— Өйгә кергәндә, каршыга хатының килеп чыкты! — дип кычкырды карчык Латыйпка. — Жылый-жылый шешенеп беткән, мескен! Сатты ул сине: син бит аны үзең кыйнаган. Инсафтан көнләшеп. Шул мескен, кыйналган хатыныңнан куркытып гариза яздыргансың. Нинди бәндә соң син, ә?! Кеше кыйныйсың да башкага ябасың. Бар, ычкын моннан, бүтән күземә күренәсе булма!

— Менә нинди була ул тикшерүче! — дип шаяртты Инсаф. — Сиңа, дәвәни, органнарда хезмәт итәргә булган, органнарда!

— Дөресме бу? — дип сорады Мәхмүт Латыйптан. Ул инде аның белән бәйләнгәненә, иртә таңнан туганына килеп, аннан сорау алганына үкенә дә башлаган иде.

— Ялган... Хатынга кул күтәргәнем булмады...

— Чыгып китегез! Хәзер үк! Икегез дә! — дип кычкырды аларга Кәримә.

— Органнар белән алай тупас сөйләшмиләр, тугани апай! — дип сөйләнде лейтенант өйдән чыгып китәр алдыннан. — Ну, ярар, моны тикшереп бетерергә кирәк! Хәзер Ландыштан дапрус алабыз!

— Аны баштан ук шуннан башлыйлар! — дип кычкырды Кәримә.

— Киттек!

— Ну, дәвәни, бирдең кирәкләрен! — дип, «кара женнәр» чыгып киткәч шаклар катты оныгы.

— Улым! Сиңа оят түгелме?! Раушанияңне тагын бүлнискә алып киткәннәр, авыр хәлдә ята, ә син монда хатынлы ирләр белән сүз көрәштереп ятасың! — дип рәнжеде ана дәү әнисе.

— Ишеттем! — диде Инсаф. — Мин бит бүген районга барырга тора идем! Хәзер, дәвәни, хәзер барам!

— Белмим инде, исән калырмы ул бала, юкмы? Бик каты авырый бит! Мә, акча ал! Буш куллый барма, кучтәнәчсез кермә! — Ул Инсафка, янчыгыннан чыгарып, бишйөз сум акча сузды.

— Ярар инде, дәвәни...

— Ал биргәндә, ал! Синең бит акчаң юк!

— Язга тракторга эшкә урнашам, дәвәни! Инвестырлар белән сүләшенгән.

— Алла бирсә, диген!

— Алла бирсә!

— Улым!

— Әү?

— Бер ике-өч карчык жыйнап, өеңдә укытып алырга кирәк. Әтиен-әниеңнең дә рухлары шат булыр. Абыстайны чакырырбыз.

— Кем ул?

— Кем булсын, мулла хатыны.

— Әнисәме? Без бит аның белән бергә укыган идек. Ул хәзер нәстә, абыстай мыни?

— Абыстай, нинди генә абыстай әле! Мәчет каршында кыз-кыркынга дин сабаклары бирә. Кайчан жыябыз?

— Дәвәни, син үзең кара инде, мин андый нәрсәнең рәтен дә белеп бетермим...

— Әй, улым, шуңар күрә дә тормышыңнын рәте-чираты юк бит синең. Гөнаһка баттың, улым, гөнаһка...

Соңгы вакытта, картая, олыгая барганын сизепме, Инсафның әбисе дә дингә бирелде. Көнгә биш мәртәбә намаз укымаса да, кирәк дип тапканда, көндез китаптан сүрәләр укый, кичләрен тәсбихен тарткалый торган иде. Инсаф, киенеп, кышкы карлы-буранлы юлга чыгып киткәч, әбисе аның артыннан дога кылып калды...

## 12

Раушаниянең авыруы шактый озакка сузылды. Сентябрь урталарында башланган хаста газаплары кыш ахырына хәтле житте. Хастаханәдә ятып, әзрәк терелгәндәй була да, бераздан аны кабат «скорый» белән шунда озаталар. Операция ясатырга Раушаниянең дә, Инсафның да акчасы житми. Атасының акчасы юк түгел, ләкин кызның әле тагын ике энесе бар, аларны үстерергә, укытырга да дөнья кадәр акча кирәк. Авыл халкы андый нәрсәгә һәрчак кысмыр булды, бушлай операция ясатуны көтеп, шуны унай күрде. Инсаф, калага барып, таныш профессоры белән очрашты. Ул аңа бер айдан соң РКБда йөрәккә планлы операция ясау мөмкинлеге булачагын, шуна тиклем көтәргә кирәк булыр, дип аңлатты. Тик әле ул бер айдан соң гына була, ә операцияне тиз арада ясарга кирәк, чөнки Раушаниянең язмышы кыл өстендә тора иде.

Кыз егетнең хыянәтен бик авыр кичерде. Юк, аны бөтенләй какмады, ләкин үзенә артык якынайтмады да. Бу хәлгә нык аптыраган Инсаф, өметсезләнеп, икенче якка ташланды, ягъни Ландыш белән күрешүен туктатмады. Латыйп хатыны, халык сөйләвенә һәм дә иренең кара янып көнләшүенә, аны кагып-сугуына да карамастан, Инсафка чат ябышты. Яратты ул Инсафны, егет тә үзенең яратуын яшермәде. «Нинди заман житте! Ир хатыны буйдак егет белән зина кыла, совет заманы булса, халык суды ясап, урынына утырталар иде боларны!» — диеште усал телләр. Ләкин бу зина кылуны фәкать мәхәббәт хисләре белән генә акларга булыр иде. Ландыш әйтмешли: «мәхәббәттә гөнаһ юк!». Боларның барысын да белеп, ишетеп торган Раушания кичерә алыр иде микән соң аны? Юк, юк, билгеле. Тора-бара Инсаф аның өчен сөекле кеше булып кына түгел, ә дус булудан да мәхрүм калырга мөмкин иде.

...Буран жиле давыллап юл кырыена кар өя. Район үзәгендә дистәләгән кар жыю тракторы асфальт өстеннән кар көри, ләкин алар да өлгереп житә алмыйлар. Дәү әнисе биргән акчага Инсаф ни алырга да белмәде. Бер кибеткә керде, икенчесеннән чыкты. Ашарына-эчәренә бар иде кызның. Ул аңа чәчәк алырга булды. Аны районда бер генә жирдә саталар. Ак чәчәкләр алырга теләде. Керде, ләкин анда да — шымытыр. Кыш бит, жәй айлары булса, болыннан гына жыйнап кайтыр иде, Раушания кыр чәчәкләрен ярата. Көч-хәл белән өч чәй розасы жыештырып, шуны үтә күренмәле полиэтиленга төрделәр. Розаларның берсе сулган, көйгән иде инде. Шул букетны кыстырып, Инсаф кыз яткан палатага килеп керде. Ни хикмәт, палатада бүген ул үзе генә калган... Аңа кабат система куйганнар, гәүдәсе капельницалар белән уралган... Палата эче шыксыз, салкынча...

— Исәнме, Раушания! — дип кыюсыз гына эндәште ул.

— Исәнме... — Тыны авыр чыкты кызның. Күрәсең, авыруы көчле иде.

— Болары — сиңа! — Ул букетны таратып, чәчәкләрне ваза хезмәтен үтәгән өч литрлы сулы савыт эченә тыкты.

— Рәхмәт сиңа... Нинди... матур...

— Ак чәчәкләр алырга теләгән идем, сатуда булмады, — дип акланды егет. — Бу Әпсәләмне укый-укый тәмам женләнеп беттем бугай инде. Алганда бигүк ошап бетмәгән иде. Карап торырга ярыйсы икән...

— Рәхмәт... матур чәчәкләр...

— Жә, хәлең ничек? – диде дә, ул урындыкны этеп, Раушания каршына утырды.

Йөрәк приступларыннан жәфаланган кызның йөзе кәгазь төсле ап-ак булган, күз төпләре каралып чыккан. Ләкин шул хәлендә дә аннан нинди дер

сафлык, ихласлык ургылып тора, ул тагын да матурланып, чибәрләнеп киткән кебек тоелды.

— Приступларым үтте... Тик кабатланырга мөмкин. Табиблар шулай ди...

— Бер айдан соң, Раушания, бер айдан соң без сине калага алып китәбез, — дип сөйләнде Инсаф. — Хирург белән сөйләшенгән...

— Юк, юк! — дип өзгәләнде кыз. — Мин беркая да бармыйм! Алып кайтыгыз мине авылга, үлсәм, шунда үлим! Җылыда, үз өемдә, атам-анам янында...

— Раушания, зинһар, сүләмә шул үлем турында! Син әле яшәячәксең! Операция ясагачтын ук без синең белән өйләнешәбез! Матур итеп яшәрбез, балаларыбыз булыр, иншалла...

— Булыр...

— Әйе, җаным...

— ...синең булыр... ә минеке...

— Нишләп алай дисең?

— Үз хәлемне... үзем генә беләм...

— Раушания, кичер мине!

— Ни өчен?

— Йөрәгенә шундый авыр яра салган өчен. Нишлим, ялгыштым... ничек диләр әле... минутлык хискә исереп, сине, бердәнберемне, якын кешемне рәнҗеттем. Кичер...

— Акланма... кирәкми...

— Кичерә алмыйсың... димәк...

— Ходай үзе кичерер...

— Ә син?!

— Мин барыбер бәхетле, Инсаф! — диде ул, сүзне икенчегә борып. — Мин синең булуыңа сөенәм, менә син минем янымда... утырасың... Син булмасаң, кем утырыр иде, кем чәчәк күтәреп килер иде... Утыр... китмә... минем яннан... куркыныч... бер үземә... ишетәсеңме...

— Ишетәм...

— Китмә минем яннан! Китмә... яме...

— Монда мин, җаным, борчылма, мин беркая да китәргә җыенмыйм...

— Китәрсең... вакыты җитәр... Үзең үк китәрсең... беркем дә сине тотмас... тик әлегә китмә... Менә хәзер... хәзер син минем янда бит... иел әле... — Инсаф Раушания ягына башын салуга ук, кыз аны кочаклап үпте, аңа сарылды. Ләкин ул көчсез иде әле, аңа артык хәрәкәт ясау да шактый күп көч сорый иде. Үлем белән тарткалашкан, күзләре мөлдерәмә яшь белән тулган кызның шулай гасабиланып бәргәләнүен күргәч, Инсаф үзе дә, аңа күз яшьләрен күрсәтмичә, эчтән генә сыкранды, еламсырады. — Мин сине беркая да җибәрмим! Юк, җибәрмим!

— Җибәрмә мине, җаным, җибәрмә... — Алар ике бала, ике нәүмиз бала, сабый балалар сыман, кочаклашып еладылар.

— Мин бер генә нәрсәдән куркам, — диде Инсаф, берникадәр вакыт тын торгач.

— Нидән?

— Каргышыңнан.

— Каргышымнан... Ялгышасың... мин сине каргамадым. Мин кешене каргый белмим. Кеше ялгыша инде ул, ә ялгышкан өчен кешене каргамыйлар...

— Рәнҗисең бит инде барыбер... Рәнҗешеңнән куркам...

— Бәхил бул... Инсаф... Син минем беренче... күрәсең... соңгы мәхәббәтем... Онытма мине...

— Нишләп син һаман минем белән хушлашасың... Хушлашырга кирәкми... яшәргә кирәк...

— Анда... — Раушания хәлсез кулы белән караватянында гына торган кечкенә тумбочкага күрсәтте.

— Нәрсә анда?

— Анда... карарсың...

Инсаф ярты көн анының янында утырды. Шул көнне газизәсенә кабат приступ булды. Каударланып йөгереп кергән шәфкать туташы аны ачуланып куып чыгарды, ә авыруны реанимация бүлмәсенә кучерделәр. Раушанияне шуннан соң вертолёт белән Казан клиникасына алып киттеләр. Ана, ниһаять, операция ясадылар, тик файдасы гына булмады, ул операция вакытында җан тәслим кылды, пычак астында үлде. Табиблар: «йөрәге түзмәде», — дип акланды. Кыш аеның зәмһәрир суыгында аны туган авылына — Багышка алып кайтып күмделәр. Көннәр бик салкын торуга да карамастан, зират өстендә халык шактый күп җыйналган иде.

Инсаф, хастаханәгә мәрхүмәнең әйберләрен алырга баргач, астын-өскә китереп, палатадагы агач тумбочканы актарды һәм анда бихисап күп дарулар, таблеткалар арасыннан Раушания язып калдырган бер хат кисәген табып алды...

## 13

Язгы чәчү алдыннан, сөйләшенгәнчә, Инсаф тракторга утырды. Тракторы да андый-мондый гына түгел, чын немец тракторы. Җил-яңгыр, тузан-пычракны үткәрми. Оныгы чәчүгә чыккач, Кәримә дә нигезгә ешрак килә башлады. Егеткә ашарына пешереп торучы кирәк. Менә ул бүген төнге сменадан кайтып төште. Дәү әнисе аңа табын әзерләп куйды, тәмле ис чыгып торган тавык шулпасы янына оныгы үлеп яраткан итле пәрәмәчләр пешерде. Чәй эчкәндә, Инсаф кинәт кенә уйга калды, соңгы вакытта анын шулай тиктомалдан монсуланып, сагышланып ала торган гадәте барлыкка килде.

— Раушания сагындыра, — диде ул. — Ә ул юк. Ул булса, алып чыгып китәр идем хәзер... Яз көне син ул кырларның матурлыгын күрсәң иде, дәвәни!

— Бигрәкләр дә аз гомерле булды, жаным, — дип кызганды аны дәү әнисе. — Анаң гомерен дә бирмәде бит үзенә. Анаң хет кияүгә чыгып, бала табып, бала үстерергә өлгерде. Ә ул... нишлисең, гомере булмаган баланың, гомере...

— Авыр туфрагы җинел булсын инде...

— Амин, шулай булсын. Яңа хәбәр ишеттеңме?

— Нинди хәбәр? — дип шаккаткан булды ул. — Хәбәрләр ишетергә вакыт та юк!

— Латыйп милиция чакыртып, анасын өйгә җаптырткан.

— Ансы нигә инде?

— Бөтен гаепне анасында күрә хәзер. Янәсе, ул тарата авылга ялган хәбәрне. Анасын өйдән дә чыгармый. Өендәге телефонына яздыру хикмәте куйган, диләр. Кайткач, анасы кем белән сөйләшкәнен тыңлап, тикшереп чыга. Менә сиңа Латыйп!

— Мин аны янган дип ишеттем.

— Ие... Бригадасы таралды. Шабашкалары юк. Хатыны качты. Шул кирәк аңа, шул. Шул адәм актыгы гына синең тормышыңны җимерде, биографиянне бозды. Ходай каргады үзен, каргады!

— Дәвәни, кирәкми, андый нәрсәләр сөйләмә, зинһар! Кешегә начарлык теләмик!

— Әй, син дә тәмам мулла малаена әйләнеп беттең! — дип кул селтәде аңа дәү әнисе. — Аша, әйдә, күп сөйләмә, тәмлеме?

— Тәмле, дәвәни, рәхмәт сиңа, әле дә ярый син бар!

— Ярар, ярар, төчеләнмә, — дип урынына утыртты ул оныгын. — Шуны

уйлап торам әле: язы да бетәр, җәе артыннан көзе дә килеп җитәр, кышы да килер... Бу кышны да бик авыр чыктың. Өенә һаман да газ кермәгән. Газ кертергә иде, атаң Нариман шул газны кертә алмыйча калды.

— Белмим, дәвәни, белмим, — дип сөйләнде егет. — Минем әле башка планнарым да бар.

— Нинди?

— Мин калага китәргә уйладым.

— Урнаштың бит инде, тракторда йөрисең.

— Урнаштым, ие, — диде ул, чәйгә ябышып. — Монда акчаны аз түлиләр. Ә мин яшь. Миңа үсәргә, кешечә яшәргә кирәк. Һаман шул синең пенсия акчаңа өметләнеп яши алмыйм бит инде!

— Бөтен авыл шулай яши инде, нишлисең...

— Ә мин алай теләмим...

— Кайтуың шул китүең белән бетәр дип уйлаган идем инде, ялгышмаганмын икән...

Соңгы вакытта авылдан китү уе Инсаф өчен котылгысыз булып тоелды. Авылда яшәүнең, хезмәт итүнең кызыгы калмады. Элеккеге заманнарда атасы Нариман эшләп йөргән колхоз бетте, миллионер колхоз таралды, авыл да бик нык үзгәрде, яшьләр калмый, карт-коры гына яши. Хәер, йорт сатып алып (йорт бәяләре чагыштырмача бик тә җүн!), авылга кайтучылар да һәм аны дача итеп торучылар да юк түгел. Тик кемнәр кайта соң авылга? Яшьләр кайтмый шул, каладан туйган пенсионерлар, карт-корылар гына кайта. Яшьләр кайтмагач, бала табучы аз, үрчем юк, урамнар буш, мәктәптә класслар тулмый, быел башлангычка бар булганы ике бала килгән...

Колхоз юк. Җир инвесторлар кулында. Алар хуҗа хәзер. Сүз дә юк, алар бай. Аларга дәүләт тә ярдәм итеп тора, ташламалар ясый, төрле программалар бар. Техникалары да күп. Җирне ашлар өчен ашламалары да җитәрлек. Тик нигәдер артык ышаныч тудырмый алар. Бу турыда ул бик күпләр белән сөйләшкәләп карады, чөнки авылның, җирнең язмышы, шушы якның баласы булгач, аны һаман да борчый иде. Иң истә калганы колхоз ветеринары Хәбетдин абзый белән булды. Пенсиягә чыгарга инде бер елы гына калган, элеккеге колхоз тормышын күргән, әле дә ферма тирәсендә селкенеп йөргән абзый, яңа хуҗалардан шикләнсә дә, туры килгән чагында үз сүзен әйтмичә калмый иде. Заманында югары уку йортын тәмамлаган, бөтен гомерен «ат духтыры» хезмәтенә багышлаган Хәбетдин әзрәк югары тонда, ягъни фәнни сөйләшергә ярата иде...

— Инвестырларга бит аңар синең җирең дә, авылың да, халкың да кирәк түгел, — дигән фикердә иде ул. — Аңар иң элек табыш алу кирәк. Авылның инфр... инфра... структурасына аларның бернинди дә катнашы юк, алар авылны үстерү, юлларны яңарту, халыкның тормышын яхшырту кебек изге хыяллар белән янып яшәмиләр. Табыш, табыш һәм янә табыш! Тугыз-ун кеше эшли техникада, ә калганнарга эш юк, калганнары бармак суыра. Табыш ала алмагач, банкротка чыгып, авылдан, җирдән качучы инвестырларыбыз да юк түгел. Хәзер банкрот сүзе бик модада, берәр нәрсә килеп чыкты исә, эш барып чыкмады исә, шундук банкрот ясыйлар да куялар. Элек безнең колхозның исеме «Башак» иде. Аннан аны ОО «Фәһимов» иттеләр. Өч елдан банкрот ясадылар. Инвестыр качты. Аның урынына яңасы килде. Хәзер тагын ОО «Башак»ка әйләнде. «Башак» кына булмады инде бу чистый... ашак булды! Элеккеге колхоздан берни дә калмады. Фермалар җимерелде, машина-трактор паркын куе чүп үләне басты. Авыл хәзер реана... реанимация хәлендә, дуслар, ни үлми, ни терелми...

«Ә авыл киләчәктә ничек яшәр соң? Шул турыда ни әйтә аласың?» — дигән сорауга ул болай дип җавап бирде:

— Авылның киләчәген колхозларда гына күрәм, ә аның өчен кабат колхоз системасын торгызырга кирәк. Халык кулында булмаса да, ул дәүләт кулында булсын иде. Районда бүгенге көндә ун-унбиш үк булмаса да, бер биш-алты яхшы колхоз эшләп торырга тиеш. Хөкүмәт ярдәме белән, кәнишне! Колхозны сүгүдән файда юк, колхозны аны, чын хезмәт кешеләрен, ягъни кулакларны куып, Сталин заманында ук төземәскә кирәк булган да бит. Кызганыч, ул инде төзелгән, авыл тормышы, начармы-яманмы, колхоз системасына көйләнгән, халык та шуңа ияләшкән, бүгенге көндә колхоздан баш тарту — ул зур ахмаклык! Фермерлар килде, дигән булдык! Ә кая соң ул фермерлар? Алары да бармак белән генә санарлык, бәрән-сәрән, алар да җәелеп китеп хезмәт итә алмыйлар, кул көчләре җитми, хөкүмәт аларны: салам биреп түгел, ә салым салдырып изә. Бусы җумор гына, кәнишне! Чынында исә менә шулай, дусларым... Шуны онытмыйк: авыл хуҗалыгында тир түкмичә генә беркайчан да чиста табыш алып булмый, запчастен икеләтә, ягулыгын өчләтә кыйбат булганда, сөтен-маен минераль судан да арзан булганда, житештергән итеңнән бернинди файда күрмәгәндә, иккән икмәгеңне юк бәягә дә сата алмаганда, амбарында, складында черeп ятканда, нинди табыш турында уйларга була?! Җә, әйтегез, кем хаклы? Минме, әллә...

Хәбетдин белән, билгеле ки, килешергә дә, килешмәскә дә була. Инсафның уе буенча авылның киләчәге колхозда гына түгел, ә аның җанындадыр. Авылны акыл белән генә аңлап булмый, авылның җанын тоеп яшәү мәгъкульдер. Үлгән кешенең иң элек җаны чыгып оча, беткән авыл да, нәкъ үлгән кеше сыман, җансыз кала. Авыл, авыру карчык сыман, тырыша да, тырмаша да, үзенчә шулай яшәгәндәй итә. Әйе, авылдан китәм дисәң, китәр сәбәпләр күп һәм алар шактый. Ләкин Инсаф өчен авылдан китүнең тагын башка бер сәбәбе дә бар иде шул...

— Сәбәбе ул гына түгел, дәвани, мин прусты авылда кала алмыйм, — диде оныгы. — Миңа монда тормыш булмаячак, дәвани, бул-ма-а-ячак!

— Латыйп хатыны аркасындамы?!

— Латыйп хатыны түгел ул хәзер. Юллары аерылды аларның...

— Аерылса да, ул барыбер Латыйп хатыны!

— Тиздән минеке булыр.

— И Аллам, яшь башың белән ирдән аерылган хатынга өйләнмәсәң ярамыймы?! Баласы белән, җитмәсә! Бернәрсә әйтимме?

— Әйт.

— Балалы хатынга иң әүвәл баласы якын була, шуны онытма. Мин сиңа моны хатын-кыз буларак әйтәм. Син аңа артың каплар өчен генә кирәк...

— Ашыкма, ул бер дә миңа чыгарга атлыгып тормый, башын бирмәс тай сымак, тартәгә тибәргә генә тора.

— Әйт әле, нигә кирәк ул сиңа?

— Ничек аңлатыйм икән сиңа, дәвани?! — Инсаф, чынаягын өстәлгә каплап, урыныннан торды. — Ошый ул миңа, ошый. Тарта, аңлыйсыңмы?! Та-а-арта! Аны болай гына әйтеп тә, аңлатып та булмый. Менә Раушания белән алай булмады. Мин аны хөрмәт итсәм дә, Ландышны яраткан кебек ярата алмадым. Ә ул башка. Тора алмыйм мин ансыз, аңлыйсыңмы? Минеке ул Ландыш, минеке, ул алдан ук минеке булырга тиеш булган, тик ялгышып Латыйпка эләккән, ялгышып, аңлыйсыңмы... Икебез дә бер-беребезне бик каты яратабыз. Нишлик соң инде?! Белмим, мәхәббәтме ул, әллә башка нәрсәме, сүз белән генә аңлата алмыйм мин сиңа аны, дәвани...

— Аңладым. Яшь чакта үзем дә шул нәрсәгә тап булдым. Әһрулла бабаңны хәтерлисеңме?!

— Хәтерлим, билгеле. Бала чакта ул мине балыкка алып бара иде. Кармак ясый, җим сала...

— Гомере генә озын булмады. Карап торырга бер ямьсез генә кеше иде шунда. Мин үзем ярыйсы идем. Артымнан кемнәр генә чапмады. Колхоз рәисләре, парторглар. Барсы да кәчтүм-чалбар киеп, галстук тагып кына йөриләр. Бар да матур чырайлы, кыяфәтле. Ә бабаңның кыяфәте дә әллә ни түгел: тукмак борын, кәкре аяк. Фермада тирес түкте. Ысвиданиягә дә ат тизәге каткан иске пиджәген киеп килә иде. Авызыннан аракы, абау да яман сасы тәмәке исе килә үзенең! Тәки шулай йөри-йөри, үзенә каратты бит, заразы! Хәер, үкенмим! Эчү белән бик кыланмады, чит хатыннарга карамады. Ул заманда йөрү дигән нәрсә юк иде бит, хәзер генә ул... Әнә, парторг хатыннары талашып, аерылышып, кәмәхуа килеп беттеләр. Шуна күрә дә аңлыйм мин сине, улым, аңлыйм. Үзенә кара инде! Аллага тапшырган. Йә, әйдә, бер дога...

## 14

Утырып, тыныч кына дога кылырга язмаган икән шул. Кәримә дога кылырга гына тотынганда, ишектән Ландыш килеп керде. Өстенә чәчәкле юка күлмәк кигән, һәм иң гаҗәбе шул: Ландыш кулына ландыш чәчәкләре тоткан иде. Ул аларны бүген урманнан җыеп кайткан икән. Кәефе күтәренке иде, ләкин Кәримәне күргәч, әзрәк сүрелде. Карчык, билгеле ки, аңа артык сөенмәде, бүленгән догасын кызганып, урыныннан күтәрелде.

— Исәнмесез, вакытсыз йөрим, ахрысы! — диде хатын, читенсенеп.

— Әпсәләмне алырга кергән, — дип акланды оныгы.

— Әпсәләмне алырга түгел, сине күрергә дип кергән ул, — дип төрттерде карчык. — Кер, әйдә, кызым, кер, тартынма! Сез бит инде бала-чага түгел. Син кияүдә булган хатын, Инсаф өйләнер яшькә җиткән егет. Уртак фикергә килергә вакыт җиткәндер инде сезгә. Ярар, комачау итмим, сау булып торыгыз!

Кәримә чыгып киткәч, Инсаф белән Ландыш бер-берсенә карашып алдылар да кисәк кенә кочаклаштылар. Күрешмәгәнгә ике-өч көн вакыт узган, шактый сагынышканнар, бу кочаклашу, күрешү татлы булды.

— Сагындыңмы? — дип сорады егет.

— Сагындым. Эзләп тә килмәдең...

— Кая килим? Телефоның ватык. Китапханәгә кергән идем, Әпсәләмне тапшырырмын, дип. Син анда да юк...

— Мин ял иттем.

— Латыйп янына килеп керә алмыйм бит инде...

Ландыш инде күптәннән Латыйптан китеп, вакытлыча клуб мөдире Әкълимәләрдә тора иде. Әнисе белән икәүләшеп аның җанын талаган йортта ул, билгеле, хәзер яши алмады. Аның ире бөтенләй кешелеген югалтты. Юк, ул аны кыйный алмый, аңа кул күтәрергә курка. Милиция белән ясаган кыйналу комедиясе дә барып чыкмады. Ул хатынын сүз белән үтерде, авыр, нахак сүз белән. Бригадасы таралгач, өйдә яткач, ул көннәр буе хатынының нервысында уйнады. Шуңа күрә дә Ландыш түзмәде, китте.

— Латыйптан китеп, дөрес иттең, — диде Инсаф.

— Дөресме, юкмы икәнен бер Ходай гына белә.

— Син үзеңне гаепле сизәсең кебек?!

— Әйе, гаепле.

— Нишләп алай дисең?

— Мин гөнаһ кылдым. Иремә хыянәт иттем.

— Кем әйтте әле миңа?!

— Нәрсә дип?

— Мәхәббәттә гөнаһ юк дип? Син түгелме?!

— Син шуны онытма: минем балам бар. Мин баламны авыр хәлдә калдырдым.

— Ничек?

— Латыйп баланы миңа бирми. Аның әйтүенчә, мин йөремсәк, азгын хатын, шуңа күрә минем бала тәрбияләргә хакым юк.

— Малай анарда, димәк?

— Анда. Ул аны миңа бирмәячәк.

— Бирмичә, кая барсын, бала ана янында калырга тиеш.

— Ансы шулай. Ләкин ул аны суд аркылы хәл итәчәк. Аннан... кем соң мин? Анам исерек, атам җүләрләр йортында! Торырга урыным да, йортым да юк...

— Миндә торырсың.

— Мондамы?

— Никах укытырбыз.

— Тәкъдим ясавыңмы бу?

— Син каршымы?

— Юк, каршы түгел. Моңа Латыйп каршы булачак.

— Булсын! Ул хәзер синең ирең түгел! Аерылышырга дип гаризанны яздың. Жаны чыксын! Мин аңардан курыкмыйм, ул миннән курыксын!

— Яшәтмәячәк ул безне бергә, аңлыйсыңмы?! Аның акылында да бар кебек, әзрәк алышына башлады. Төннәр буе йокламыйча чыга, саташа, ыңгыраша. Бер ята, бер чыгып китә. Мендәре астына пычак тыгып йоклый. Чарын акыртып, балта кайрый. Ул мине шулай итеп куркытты...

Шунда Инсаф үзенең калага китәргә теләге барлыгын әйтте. Хәер, калага китеп, аның атасы Нариман да әллә ни бәхетле була алмаган, каланы, беренче хатыны Динәсен ташлап аннан кире кайткан. Атасы һәрвакыт: «Син авыл баласы, улым, синең бәхетең шушында, бәхетсезлегең — читтә», — дип әйтә торган иде. Әйе, атасы, бәлкем, хаклыдыр да, ләкин тормыш шактый катлаулы нәрсә, дөнья беркайчан да син теләгәнчә генә бармый. Ул үзе белән Ландышны да алып китәргә тели. Дөньялар тынычлангач, тормышлар түгәрәкләнгәч, алар әле монда әйләнеп кайтырлар, бөтен авыл халкын көнләштереп, шат һәм бәхетле яшәрләр!

— Юк, — диде Ландыш, — мин баламны калдырып беркая да китмим.

— Соң... ал балаңны үзең белән!

— Бирми!

— Урнашкач, соңыннан кайтып алырбыз!

— Юк, алай булмый... Син... кит... миңа карама!

— Нишләргә уйлыйсың? Һаман да шул завклуб хатында ятмакчы буласыңмы? Чит кешенең ачык чырае өч көнгә генә бара, шуны да онытма...

— Мин, бәлкем... — Ландыш башын аска иде. Ул үзе теләп ясаган кискен адымыннан, Инсафка булган ирекле мәхәббәтеннән инде шикләнә һәм икеләнә дә башлаган иде.

— Нәрсә булды?

— Кире иремә дә кайтырмын әле.

— Анысы ни өчен тагын?

— Бала өчен, бала хакы өчен.

— Дәвани хаклы булган икән... Димәк, бала безнең сөюдән дә югарырак булып чыгамыни инде? Баланы безнең арага куярга кирәкми. Бала ул — бала, ә мин ул — мин. Аңлыйсыңмы?

— Аңлыйм.

— Димәк... бала... шулаймы?

— Әйе... бала. — Әйе, Ландыш озак уйлап тормады, җавабын бик тиз тотты. Инсафның җен ачулары кузгалды, үзен чак-чак кына тыеп торды.

— Алайса бар, кайт! Кайт, сөекле ирең янына! Мәңге кыйналып, сугелеп яшә!

— Син миңа шуны телисеңме?

— Теләмим, син үзең шуны әйттерәсең!

— Ярсыма, Инсаф. Аңла, мин барсын да уйларга, төптән уйларга тиеш. Бу бит, башыңны юләргә салып, кияүгә чыгу гына түгел, бу бит бар булган тормышыңны җимереп, яңа тормыш кору, яңа язмыш язу дигән сүз...

— Кайтасыңмыни?

— Кайтам...

## 15

Латыйп инде ничә ай үз-үзенә урын табалмый. Әле бар да әйбәт иде кебек, гөл кебек иде. Ә хәзер нәрсә? Бригада таралды, гаилә таркалды. Катмыш авылында йортның түбә башын япканда, аның бер эшчесе икенче каттан егылып төште һәм аягын сындырып, ике ай хастаханәдә ятып чыкты. Эшкә чыкмагач, хуҗасы аңа бер тиен дә түләмәде. Ә ул мәхлук (берәрсе котырткан, мөгаен!) шул ике ай өчен аңардан компенсация акчасы сорый башлады. «Мин сине екмадым, син үзең гаепле, үзең егылып төштең!» — дип, Латыйп аның белән сөйләшмәде дә. Эш мәхкәмәгә хәтле барып житте. Ләкин аңа хәтле үк Латыйпның саранлыгыннан, кансызлыгыннан туйган эшчеләр аңардан әкренләп китеп беттеләр. Ул аларның (яхшы осталар булсалар да!) берсен дә тотмады, яңа бригада җыйнарга уйлады. Латыйп осталарын күрше авылдан икенче бер кеше үзенә алды, ул тагын да көчәйде һәм аның заказлары артты. Авылда яхшы осталар табуы җиңел нәрсә түгел, ә Латыйп бригадасына, үч иткәндәй, җыен әтрәк-әләм җыйналды. Бер акчалы объектны алганнар гына иде, эшен җиренә житкереп башкара алмагач, Латыйпның бөтен бригадасын куып кайтардылар. Үзара талаш-кычкырыш, бер-берсен гаепләүләр китте. Шуннан бригада да үлде. Латыйп заказсыз, акчасыз калды. Әлегә ул алдан җыйнаган байлыгы белән генә яшәп ята иде.

Аның өчен бу бәхетсезлекләр авылга Инсаф кайтып төшкәннән соң башланды. Әлеге бәхетсезлекләрнең башында шул төрмә кошы торганын ул яхшы аңлады. Әле шуның өстенә Латыйпның хатынына ябышуын, Ландышны тәмам үзенә каратып, аның белән йоклавын Латыйп кичерә алмады, билгеле. Хурлык бит бу, чын хурлык! Начармы-яманмы, ул хатынын яратты, аңа яратып өйләнде. Әгәр Ландыш аңа яратмыйча кияүгә чыккан икән, ул барыбер ирен шулхәтле хурлыкка калдырырга тиеш түгел иде кебек. Шулай бит ир хатыны, аның моңа хакы да юк. Шулай дип уйлады Латыйп һәм шулай дип фикер йөртте. Ярар, өйләнгәннән соң, ул мәрхүм дустының хатыны янына берничә мәртәбә төшеп тә менде, ди, әйтик, Ландышына хыянәт тә итте, ди, ләкин ул бит вакытында туктады, хыянәт итүнең гөнаһ икәнлеген аңлап туктады. Анда да бит хатыны белән талашкан вакытта гына, хатыны кәҗәләнгән чакта гына читкә йөрде. Шуңа үч итеп йөрде. Ә болар юк, болар туктарга уйламыйлар да! Хатыны, баласын, ирен ташлап, өйдән чыгып китте, инде аерылышырга дип гариза да язган. Хәзер шул себерке аркасында бөтен авыл, бөтен дөнья аңардан көлә сыман. Моңа ничек чыдап, түзеп булсын, ди! Латыйп та тимер түгел, менә ул да эчә башлады, ә аңа эчәргә ярамый, ул «запойный» иде.

Ике-өч көн бер дә айнымыйча эчкән, соңгы төнен өенә кайтып житә алмыйча, бер танышының караңгы сараенда уздырган Латыйпның чыраена

карарлык та калмаган иде. Май айлары булып, тышта жылы көннәр торса да, ни өчендәр калын кара куртка кигән, ул куртканың жинсәләре ертылган, якалары таланган. Кырынмаган битендә пычрак эзләре калган, ана таш булып балчык валчыклары каткан. Авызын аран гына ачкан, әйткән сүзләрен авырлык белән генә ирештергән Латыйп, Инсаф белән Ландышны бергә күргәч, шаяртkандай булды: «Сез һаман бергә икән, сез һаман бергә икән, сез...» Бу аның үзенчә жырларга маташуы иде. Ләкин ул көчен чамалап житкерә алмады, аягы мич белән дивар арасына тартылган яшел чаршауга чорналып, бушлыкка ауды. Инсаф аны көч-хәл белән генә күтәреп торгызды. Шуннан соң ул кухня ягында торган иске кәнәфи өстенә барып егылды. Кабат торырга теләде, кулларын бутап акырды, ләкин ничек кенә көчәнсә дә, ауган урыныннан торып китә алмады.

— Латыйп, ни булды сиңа? — дип дәште аңа Ландыш. Иренен хәле өчен борчылып түгел, билгеле, сүзсез калмас өчен генә дәште.

— Ә нәстә...

— Эт таламагандыр ич үзеңне!?

— Юк... эт таламады... Сез... сез... икәү таладыгыз мине... Сез минем жанымны таладыгыз... Ну... ярый... шул кирәк миңа, бүгенге көндә... мин шунар лаек... Шулай бит... әйеме...

— Куртканы харап иткәнсең, Латыйп! — диде хатын.

— Әй... булсын ла... яңасын алырмын... вакланма... Әнкәйнең пенсиясе артты... Хәзер бөтен авыл ялкавы әнкәйләр, әткәйләр, әбиләр, бабайлар пенсиясенә яши... Менә мин дә хәзер шулар армиясеннән...

— Латыйп, ни кирәк сиңа, бездән ни кирәк? — дип сорады анардан Ландыш.

— Берни дә...

— Нәрсә булса да уйлап килгәнсең бит инде син монда?

— Дөрес, нәкъ өстенә бастың, — дип елмайды ул. — Килүем дә шул... Мин үз гаебемне... танырга дип килдем. Менә бу егет минем аркада газап чиккән... Мин гаебемне таныйм... Теге югым жанны... кем әле... Газизжанны... чыннан да ул кыйнамады, аны мин үтердем, мин... Миңа каршы бер кыек... сүз әйткәне өчен... бер бөртек... сүз әйткәне өчен, мин аны тормышыннан мәхрүм иттем. Үкенәмме мин, үкенмимме... ансы сезнең өчен караңгы... Главный... мин үземнең гаебемне танырга әзер. Хәзер үк... Чакырыгыз милицияне... полицияне... Кая Мәхмүт? Чакырыгыз Мәхмүтне!.. Алып китсен мине өтермәгә... Минем утырасым килә... Хет менә шушы жаным... шунда тыныч булыр иде...

— Латыйп, житәр сиңа, маймылланма! — диде Ландыш. Ә Инсафның йөзендә исә: «Синең дә жаның бармыни?!» — дигән мыскыллы күз карашы чагылып китте.

— Кит! Кит син дә! — дип акырды аңа урыныннан торырга маташкан ир. — Син барыбер минеке түгел! Син бит баштан ук минеке түгел идең! Дөресе шул... син бит миңа яратып чыкмадың... аптыраганнан чыктың... Ә беләсеңме... ни өчен чыктың син миңа? Әйтимме? Белсең яраткан кешең дә! Әйтимме?!

— Әйт!

— Барыр юлың... ябык иде синең чибәрем... чигенер юлың... Атаң кырык яшеннән психбольниста ята, анаң эчеп йөри... Синең яктан туйда утырырлык жүнле туганың да юк иде бит... Куйма син үзеңне әллә кемгә, ишетәсеңме, куйма! Чибәр генә булсаң да, әллә кем түгел! Чибәрлек ул бер көнлек, ә исәрлек... гомерлек... мин... мин кеше иттем сине, ул түгел, ә мин! Аңа карама... су... ка... миңа кара... мин... мин сине упкыннан тартып чыгардым, мин... Анаң сине бер яртыга чит мужикларга сатырга әзер иде бит... бер шешә аракыга...

ха-ха... кая... бармы яртыгыз... Әчәсем килә... үтереп эчәсем килә... Биш... биш ел бер грамм аракы капмыйча яшәдем... биш ел... Теләсә кем булдыра алмый аны... Ә Латыйп булдыра... Латыйфулла... мин инде ул... барсын да булдыра... Әйбәт кеше ул чөнки... Латыйп... ие... җүләр үзен мактый, ди... Кая? Бармы?

— Юк, мин монда кала алмыйм! — дип ярсыды хатын.

— Кит! Ләкин мин малайны сиңа бирмим! Үлсәм үләм, ләкин Кирамны сиңа бирмим!

— Ансын суд хәл итәр...

— Суд та минем яклы: азу алган ананы... бер генә суд та якламаячак... ха... ха... ха...

Бала сүзе Ландышны чыгырыннан чыгарды. Нәрсә, нәрсә, ә баланы ул гомердә дә ирендә калдырачак түгел! Ландыш, кулын уйнатып, Латыйпка ташланды. Үзендә әзмәверләр көче тапкан мужик, күкрәген киереп, кәнәфидән күтәрелде һәм һөҗүм итүче, диварга бәрелеп кире атылган борчак сыман, артка атылды.

— Бар! Кит! — дип кычкырды Латыйп. — Ирләр сүләшкәндә, хатын-кыз кысылмасын иде!

Инсаф Ландышка кит дип кулы белән ишарә ясады. Ландыш озак кына чыгып китә алмыйча, моңсуланып Инсафка карап торды. Әйтерсең лә ул Инсаф белән мәңгегә хушлаша, аны соңгы мәртәбә күрә иде. Күрәсең, ул күңеле белән нидер сизенгән, фаҗига килеп чыгасын сизгән, ләкин менә шуны тоткарлый алмавын аңлау аның күңеленә чиксез моңсулык иңдергән. Хатынын озаткач, Латыйп та үзгәрде, ул айнып киткәндәй булды, исерек булып кыланулары да азайды...

— Да, брат, мин сине котлыйм!

— Нәрсә белән?

— Син җиңдең, ә мин җиңелдем, — диде ул, кәнәфидән өстәл ягына күчеп. — Мин бөтен нәрсәмне дә югалттым, ә син менә, киресенчә, таптың. Котлыйм, син җиңдең! Белмисез хәлемне, белмисез... Ә бит сез гаепле монда, сез! Сез минем авылда яшәрлегемне дә калдырмадыгыз. Бөтен авыл көлә миннән хәзер! Нәрсәдән дисеңме? Мөгеземнән көлә минем, менә шушы мөгеземнән! — Латыйп баш очында кул бармакларын атландырып, болан мөгезе ясап күрсәтте. — Мөгезле мин... ха... ха... ха... мөгезле эре терлек... тармакланып тора менә, күрәсеңме... һәрберсе, бармак төртеп, миңа таба күрсәтә кебек. «Әнә, әнә, күрәсезме, Латыйп килә, хатыны аңа мөгез куйган!» Урамнан барган детсад малае исәнләшеп узса да, сискәнеп, калтыранып куям, әйтерсең, ул минем белән исәнләшми, ә миннән, «мөгез»ең исәнме, абый, дип сорый кебек... Авыл җирендә булмаган хәл бит бу — ирле хатынның буйдак егет белән йөрүе... булмаган хәл... Менә шушындый хәлдә мин авылда ничек яшәргә тиеш? Мин хәзер бер генә нәрсәгә үкенәм, ишетәсеңме, бер генә нәрсәгә...

— Нәрсәгә?

— Моннан җиде ел элек миңа барсын да үз өстемә аласы калган. Үлмәс идем әле, ничек тә чыккан булыр идем. Менә син чыктың бит әле! Тормышның кадерен белеп, аңлап чыктың...

— Нишләп утырмадың соң?

— Курыктым. Курку хисе көчлерәк булып чыкты. Ә хәзер мин курыкмыйм, миңа барыбер!

— Син курыктың, ә нишләп мин курыкмадым?! — дип кычкырды Инсаф аңа ачу белән.

— Батырайма, син герой түгел! — дип үчекләде аны Латыйп. — Сарык

бәрәне бит син! Сарык бәрәне кебек, син үзең караңгы киртәгә барып кердең! Кермә идең! Кем сиңа кушты?

— Син! Син сүзеңне чамалап сөйлә, яме! Юкса!!! — Инсаф кесәсеннән шәп итеп үткенләгән юка гына пәке тартып чыгарды һәм, Латыйпның чырае каршында уйнатып, бар көченә агач өстәл өстенә кадады. Бераз шүрләп калган кунак шул пәкегә ябышты. Тик никадәр генә көчәнеп тартса да, аны кадалган җирдән тартып чыгара алмады.

— Нәрсә бу?

— Заточка.

— Заточка?!

— Ие... Пәке! Тегеннән алып чыктым. — Латыйп өстәл яныннан китеп, почмак чатына барып басты. — Син кая?

— Хәлем начар... Бу хәлдә әни янына кайта алмыйм. Тагын койма буенда ятасы килми... Хатын юк... яхшы беләсең... Беләсеңме, ә мин сине гаепләмим, гаеп хатынның үзендә... әгәр ул теләмәсә...

— Нәрсә теләмәсә?

— Ну... шулай бит инде?!

— Беттеме сүзең?! Сиңа тагын ни кирәк?

— Берни дә... ятып торыйм синдә бер-ике сәгать... Тегендә... залда... Аннан китәрмен яме... үз юлым белән...

— Теләсәң нишлә...

## 16

Көндәшен һәм дошманын үз түшәгенә яткызып, үз өендә, үз нигезендә калдырган Инсаф урындыкка сөялгән килеш кинәт кенә уйга калды. Раушаниясе үлгәннән бирле, ул кирәгеннән артык монсулана, уйчанлана башлады кебек. Авылда, шаулап-гөрләп, чәчү эшләре баруга да карамастан, Инсаф (бәйрәм көннәрендә), зиратка менеп, ата-анасының кабер яннарын карап төшәргә вакыт тапты. Каберләре янәшә генә аларның, икесенә бер таш куелган. Акча җыйнап, әлеге кабер ташын дәү әнисе куйдырткан булган. Үзе белән себерке, тырма алып менгән Инсаф башта кабер өстен бер кат чистартып чыкты, кыш буе череп яткан каен яфракларын тырмалап алып, бер зур капчыкка тутырды, тузан, пычрак кунган кабер ташын чишмә суы белән юды. Шулчакны ул зират эчендә, якында гына басып, кагаебрак торган бер ханымны шәйләп алды. Ханым да аны танып алды булса кирәк, әкрен, салмак адымнар белән егет янына килде. Ул Динә ханым булып чыкты. Атасының беренче хатыны. Көннәр җылы торуга да карамастан, өстенә сары плащ кигән, башына калын яулык бәйләгән ханым Инсафка шактый ябык булып күренде. Ул аны алданрак та күргәләде, тик ул элек бөтенләй икенче иде. Яшь иде әле, чәчәк кебек матур иде. Яңа ирен ата-анасына күрсәтергә кайтканда күреп калган иде ул аны. Клубка ниндидер концерт карарга төшкәннәр иде алар. Күпне белгән авыл яшьләре: «Менә бу — Динә апа! Атаңның беренче хатыны!» — дип Инсафның колак итен ашаганнар иде. Динә ханым шактый үзгәргән, бик нык ябыккан, суырылган, коры сөяккә калган иде. Аның атасы Салих абый да шуннан ерак түгел генә җирләнгән, ә әнисе Сафия апа, олы яшьтә булса да, әле һаман да исән, авылда яши, Динә, вакыты булганда, аның янына кайткалап йөри иде.

— Син Нариман малае бит, әйеме? — дип сорады ул чардуган каршында басып торган егеттән.

— Әйе, — диде Инсаф. — Ә сез Динә апа, шулай бит?!

— Әйе, мин Динә апаң булам...

— Безгә кунакка керегез, — дигән булды ул, — сөйләшеп утырырбыз, өйдәге сүзне зиратта сөйләшергә ярамый...

— Мин синең дәү әниең янында булдым, бер сүз дә әйтмәдемени?

— Юк, әйтмәде.

— Нишләп икән?

— Хәтере начарайды...

— Синең жиде ел төрмәдә утырганыңны белдем, гафу ит, мин сиңа ярдәм итә алмадым...

— Ә ни өчен сез миңа ярдәм итәргә тиеш?

— Акчам юклыктан түгел, төрмә тирәсендә йөрүдән курыктым...

— Ихтыярыгыз...

— Инсаф!

— Әйе!

— Бәлкем, бу безнең соңгы күрешү булыр, дөнья хәлен белеп булмый, энем, минем сиңа бер кинәшем бар, шуны әйтмичә булдыра алмыйм. Китмә авылдан, ташлама туган нигезеңне! Атаң кыска гомерле булды, тик барыбер үз бәхетен авылда тапты. Атаңнан соң мин ике мәртәбә кияүгә чыктым, ләкин берсеннән дә бала таба алмадым. Ходай мине кичермәде, авылдан китүемне кичермәде, мине бәхетсез итте... Ялгышлар күп булды. Атаңны, Нариманны гомерем буе яраттым, аны яраткан кебек мин башка беркемне дә ярата алмадым...

— Нишләп алай дисез?

— Исеңдә тот, үскәнем: хатын-кыз үз гомерендә бер генә мәртәбә ярата, бер генә ир-егетне, ә калганнары аның мавыгулар гына, мәхәббәткә охшаш мавыгулар...

— Сез әле һаман да калада яшисезме?

— Юк, кала һавасы миңа килешмәде, без ирем белән фатирны сатып, Казаннан утыз гына чакрым ераклыкта йорт сатып алдык. Авыл инде ул. Хәзер шунда яшәп ятабыз. Әнине дә үзебез янына алырга дип кайткан идек, каршы килде. «Үлсәм, кызым, шушы нигеземдә генә үләм!» — диде. Хәер, ул хаклы. Ә үзем монда кайтып тора алмыйм, авылга кайтарырлык көч табалмыйм үземдә. Авылдан бер чыгып киткәч, кайтыр юллар бик тә ерак, шактый ерак була икән шул...

— Бүген китәсезме?

— Әйе, китәм, — диде бик нык монсуланган хатын. — Сине өйләнергә йөри икән дип ишеттем, өйләнгәндә акча күп кирәк була. Мин сиңа ярдәм итәргә булдым, — почта аркылы акча салдым...

— Юк! Миңа сездән акча кирәкми! — дип кычкырды Инсаф.

— Кирәк! Борчылма, аның җае бар. Мин бит атаң белән бергә сатып алган фатирны саттым. Анда атаңның да өлеше бар... Ал, өйлән, сезгә әз генә булса да ярдәмем булыр, ә миңа хәзер берни дә кирәкми инде...

Акча чыннан да килде. Почтальон хатын аның кулына извещение китереп тоттыргач, егетнең күзләре шар булды. Динә апасы аңа йөз мең сум акча җибәргән. Алмыйча да булмый, почта шуны таләп итә. Инсаф акчаны алып, шуның бер тиененә дә кагылмыйча, банкта үз исеменә салып куйды. Әнә шул акчаны хәзер барып алырга да Ландыш белән чыгып китәргә берәр җиргә, берәр ерак илгә! Тик юк шул: бала, бала комачаулый, баласыз аның сөйгәне беркая да китмәячәк...

«Беренче хатыным күнелле тормыш яратты, мине аңламады, чит ирләрне үз итте!» — дип әйткән иде Динә турында бервакыт атасы. Ләкин бу хатынны хәзер начар кеше, вакытын бушка аударучы җүнсез хатын дип берничек тә әйтеп

булмый. Ул үзгә. Ана акыл кергән. Дингә апасының: «Китмә авылдан, ташлама нигезеңне!» — дип әчкерсез әйткән сүзләре күңеленә нык кына сеңеп калды. Нәрсә соң бу? Бер чын хакыйкатьме? Әллә матур сүзләр генәме? Ташлама, дип әйтүе генә җиңел, ә чынында исә...

«Әй... нигез... туган нигез! — дип сыкранды Инсаф. — Мине иркәләп үстергән, бишеккә салып тирбәткән, шушы якты дөньяга күзем ачкан, күңелемдә мәхәббәт хисләрен уяткан туган нигезем, ни булды соң сиңа? Нишләп соң барсы да сине ташлый, барсы да синнән кача? Капка-ишегеңне тауда чана шуып кайткан сабый балалар, көянтә-чиләк күтәреп, чишмә суы ташучы апалар, кызлар түгел, ә җилләр, әче җилләр генә каерып ачалар...

Туган йортым, туган нигезем! Мин бит синең балаң, кадерле, сөекле балаң. Минем синдә каласым, синең кочагыңда иркәләнәсем, сиңа сыенасым, синдә яшәп, гомер итәсем килә. Үз сүземә тугры булырмынмы, үз-үземә хыянәт итмәмме, ачы язмыш җилләре мине синең җылы кочагыңнан тартып алганда, синең түр ягыңда йә бусагаңда булса да басып кала алырмынмы? Аңсы Ходай иркендә! Бәхет-шатлыкларым синдә артса, кайгы-газапларым синдә кимесә һәм соңгы сулышым шушында өзелсә, мин ничек бәхетле булыр идем! Җил-давыллардан, тормыш гарасатларыннан исән-имин чыккан, хәзергә тиклем имәндәй нык торган туган йортым, туган нигезем, инде мин сине югалтам кебек. Юк, юк, мин бит бөтенләйгә, мәңгегә түгел, бары тик вакытлыча гына китәм. Мин сиңа кайтачакмын, ышан, барыбер бер әйләнеп кайтачакмын...»

Өй эчендә шомлы тынлык урнашты. Хәтта түрдә түнеп яткан Латыйпның да гырылдаган тавышы тынды. Инсафның колагына шул куркыныч тынлык аша бөтенләй икенче төрле тавышлар, башка төрле авазлар килеп керде. Бу авазлар әти-әнисенең инрәп пышылдаулары, эндәшүләре аша яңгырады:

— Улым, улым, китәсеңмени?

— Китәм, әткәй, китәм...

— Безне ташлап... китәсеңмени, улым?

— Китәм, әнкәй, нишлим, китәм!

— Сау бул, улым, сау бул... сак бул... онытма безне... Туган нигезеңне, туган өеңне онытма, улым! Кайт, кире кайт... улым... нигезең көтә сине... нигезең...

— Кайтырмын, әткәй, кайтырмын, әнкәй, һичшиксез, кайтырмын...

«Юк... алдашам! — дип уйланды егет. Ул елады, күз яше чыгармыйча гына елады, чөнки күңеле, җаны елый иде аның. — Үз-үземә ялганлап утырам: беләм, мин монда бүтән беркайчан да кайтмаячакмын, әйе, әйе, беркайчан да әйләнеп кайтмаячакмын! Ул өй туйлары, ул күңелле мәҗлесләр, ул аулак өйләр башка беркайчан да кабатланмас! Авылдашлар, туганнар мине онытырлар... барсы да... онытыр...»

Инсаф, тәмам онытылып, тәрәзәдән урамга күз салды. Урам ягында кинәт кенә күңелле көй яңгырагандай булды. Яшьләрнең җыйнаулашып җырлаулары, күңел ачканнары ишетелде. Әлеге җыр тавышы өйгә бәреп керде:

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле бишне дә,
Сез дуслар җыелган җирдә
Җырламый килешми дә...

Инсаф, урыныннан торып, әнә шул тарафка юнәлде, илһамланып, кызарып баеган кояш нурлары төшеп торган тәбәнәк тәрәзәгә кулларын сузды. Ә юк!

Жыр ничек колакка килеп керсә, шулай тиз генә тынды да. Карале, чын нәрсә түгел икән бит бу, аның күзенә генә күренә икән! Күзенә генә...

Ул кабат өстәл янына килеп утырды. Куен кесәсеннән икегә бөгәрләнгән кәгазь кисәге тартып чыгарды, аны ачып, укый башлады. Бу палатадагы тумбочка эченнән табып алган Раушания хаты, тормышының иң авыр, иң кискен минутларында ул аны кат-кат ачып укый торган иде. Хат әллә ни искитәрлек түгел, ашыгып язылган, ләкин анда Инсафны тетрәндергән бер җөмлә, бер сүз бар һәм ул хат аңа шул сүзе белән якын иде...

Кадерлем Инсаф!

Сиңа дип язган соңгы хатым булыр. Китәсемне сизеп, аңлап ятам... Ни аяныч... кыска гомерле булдым. Ләкин шушы кыска гына гомеремне дә мин бәхетле яши алдым, сине яратып яшәдем. Язмышым үкенечледер... әйтмим... Син генә түгел, мин үзем дә гаепле. Кем белә, әгәр дә син чакырган көнне аулак өйгә килгән булсам, бәлкем, безнең тормыш бөтенләй икенче төрле юлдан кереп киткән һәм инде бу ямьсезлекләр килеп тә чыкмаган булыр иде. Минем җанда синең хыянәтең, синең өстеңдә көндәшеңнең яман кылычы эленеп тормас иде. Курыкма, кыю атла... Мин бирә алмаган бәхетне син китапханәче ханымнан ала алырсың дип ышанам һәм бу якты дөньядан мин тыныч күңел белән китәм... Бәхетле булыгыз! Раушанияң...

...Пәке (заточка) аның аркасын ярып керде. Көндәше аңа арттан килеп кадады. Ул авыртуны сизми дә калды, чөнки шундук аңын җуйды...

— Инсаф, мин китәм! Мин синең белән китәм! — Атылып диярлек өйгә килеп кергән Ландыш, идәндә, кан эчендә яткан Инсафын күреп, өнсез калды. Башын өстәл аягына терәгән, беләге, куллары канга баткан Латыйпның кулыннан Инсафның пәкесе төшеп китте. Ул җүләрләнеп көләргә тотынды һәм озак кына шул җүләрләрчә көлүеннән туктый алмады...

Ландыш белән алар ике айдан соң өйләнештеләр. Инсаф бер ай хастаханәдә ятып чыкты, табиблар аны теге дөньядан көч-хәл белән тартып чыгардылар. Мәрхүм Динә апасы (Инсаф савыккан арада аны авыл зиратына кайтарып күмгәннәр!) биргән йөз мең сум акча туй чыгымнарын тулысынча каплый алды, әзрәк яшәрләренә дә калды. «Төрмәгә, төрмәгә озатыгыз мине!» — дип тилергән Латыйпны нигәдер, мәхкәмә булганчы, төрмәгә түгел, ә җүләрләр йортына озаттылар. Себер ягыннан бик зур акча белән кайткан Шәмсегаян апайның улы Минназыйм, өмә җыйнап, иске нигез урынында өр-яңа нарат бура күтәртте.

Инсаф Ландышны малае белән бергә туган нигезенә алып кайтты. Бер елдан соң аларның кызлары туды. Аңа Динә дип исем куштылар.

*2012-2013 еллар*



Марсель
Галиев

# КҮЗАЛЛА ДА УЙЛАН ҮЗАЛДЫҢА...

## Чыдам тау да, үзән дә без...

Алтай-Саян бишегеннән калкып чыгып,
Кыйтгаларны инләп таралганбыз.
Әле Скиф, Камәр, әле Сармат булып,
Төрле исемнәрдә танылганбыз.

Татар бугазыннан Гибралтарга чаклы
Хәбәр юллап, сайрар ук атканбыз.
Атлы дәрья булып, Ауропаны
Йокы сөременнән уятканбыз.

Карабаир юргаларда жилеп кенә,
Тау-упкыннар аша ыргылганбыз.
Карпат, диеп, Алып, Татр, Әтил[1], диеп,
Кыяларга исем ыргытканбыз.

Һун-Сөн булып, илбашларын ак киездә
Кояшкача данлап күтәргәнбез.
Биек-саллы диварларын тез чүктереп,
Кытай тәхетенә үрләгәнбез.

Ак түрекләр, Күк түрекләр булып, янә —
Чиксез Себер, Идел, Уралдан без.
Бөркет кашлы каганатлар төзеп,
Ефәк юлын билгә ураганбыз.

Дәвер үткән... Сак-скифлар, Сармат рухын
Болгар булып тагын данлаганбыз.
Болгар иле... Ярымутрау... Нинди мәгънә —
Б а л к а н диеп аны атаганбыз.

[1] Атилла хөрмәтенә кушылган тау исеме (нем. — Etzel).

Марсель ГАЛИЕВ (1946) — *Татарстанның халык язучысы, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, 6 томлык «Сайланма әсәрләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Баллы, канлы язмыш... Күпме илләр төзеп,
Нигезенә мәрмәр таш булганбыз.
Җан-тән кушып, күпме кавемнәрнең
Үрчү кодрәтенә аш булганбыз.

Гасыр арты гасыр, меңьеллыклар кичкән
Төрле халык, диеп атамагыз!
Таргитайлы, Атиллалы, Кубрат ханлы халык —
Бер тамырдан, бер үк атадан без!

Ә соңгарак... Кыпчак, нугай, казак булып,
Дала күкрәгендә таркалганбыз.
Колач җәеп, аерым-аерым үсәбез дип,
Киңәергә теләп, тар калганбыз.

Терек халык! Чыдам тау да, үзән дә без,
Нәсел чылбырларын өзгән дә без.
Телдән китә уртак Ана сүзләребез,
Дала төсен җуя күзләребез...

Курганнарны, күргәннәрне җәлләмибез,
Хәтерсезгә — хәтәр мәлләребез.
Балбаллары ауган япан далаларда
Әрнеп үскән әрем — хәлләребез...

Үзебезме теләп, и татарым, һаман
Соң чиккәчә җитеп чигенәбез?
Кем ул әйтә:
Олы тарих келәменә
Алтын язу белән чигелмәбез?!

Кайтавазлар инри, юашланып:
Бүгеннән без, бәлки... бөгелмәбез...

## Дүрт төс — дөньяның дүрт ягы

*Һун-төрки бабаларыбызның илбашы — Баһадур җания Кытайларга каршы сугышканда, кул астында 300 меңлек гаскәре була. Баһадур яңа эрага кадәр 209-174 нче елларда яшәгән. Бу бөек хакимне кайбер тарихчылар «Татариянең Ганнибалы» дип тә атаганнар. Дөньяның дүрт ягы кебек үк, атлы гаскәрнең дүрт төскә бүленү тәртибе төрки галәмендә сакланып, Чыңгыз хан дәверенә кадәр килеп җитә.*

Күкри дулкын, ак атлылар — ташкын,
Көнбатар як — Кояш баешы.
Саргаскәрнең аелында — бөркет.
Асылташлы камәр-каешы.

Күкри дулкын, күкбүз атлар — ташкын,
Көнтуыш як, ягъни Көнчыгыш.
Байракларда алтын бүре башы —
Ашинәгә изге багыныш.

Күкри дулкын, кара атлар — ташкын,
Кара ефәк — жирнең Төньягы.

Япан дала кытыкланып ала,
Тупырдаса мең ат тоягы.

Күкри дулкын, жирән атлар — ташкын —
Ялкын яллы Көньяк тарафы.
Дүрт төстә бу — түмән-түмән дәһшәт
Дала буйлап килгән таралып.

Жиһан күзе[2] — Татар даласы бу,
Кыйтга белән кыйтга арасы.
Күзалла да уйлан үзалдыңа,
Дала догаларын жуя барган
Атсыз атлы татар баласы.

## Тарихка караш

Ардырды дөнья хәтере...
Ялган яла ягылудан
Уна бара кадере.

Борыла тарих муены
Хакимнәр теләгәнчә.
Шулмы яшәү уены?

Яшерә дәвер чын йөзен.
Жир тетрәткән Жиһангир
Яклый алмый үз-үзен.

Галимнәр, тамак ялына
Бутап халык-дәверләрне,
Вөжданына абына.

Тарихчы арзан сатыла.
Ант бирдерсәң, көчсез калыр
Гиппократ анты да.

Дөнья белмичә өйрәтми:
Геракл да, ир-акын да,
Софокл да, саф акыл да
Бүгенгегә кирәкми.

Зиһенне томан ялмаган.
Ахырзаман исе килә
Хәтта кызыл алмадан.

Биектән Раббы карыйдыр.
Игә китералмый Жирне,
Бәлки, ул да арыйдыр...

Соңыннан кемнәр аныклар?!
Иблис ятьмәсенә керә
Гүя сөмсез балыклар, —
Балык түгел, көне, дене,
Теле сүнгән халыклар.

***

Мең яшә. Гасырларны кич,
Мең рәхәт чик, мең михнәт.
Жирдә бөек юаныч бар:
Бәллүр билле мәхәббәт!

## Башкала урамыннан килүче кыз

*Девушки в Казани*
*С летящими глазами...*
Р.Кутуй

— Гүзәллегем белән бәхетле мин,
Гүзәллегем белән бәхетсез.
Буйсынырдай бер яр эзләп киләм,
Күңелемдә уйлар хөсетсез.

[2] Жиһан күзе — Бөек дала борынгы язмаларда шулай аталган.

Сезме соң бу, дастаннардан чыккан
Үлмәс каһарманга тиң затлар?
Заманага ак перчатка ташлап,
Дуэльләргә чыгар ир-атлар,
Сезме соң бу?!

Бармы арагызда, күктән өзеп,
Шигъри тәлгәш алыр телдәрләр?
Хатын-кызга һәйкәл куяр өчен,
Мәрмәр җанын тыңлый белгәннәр,
Бармы арагызда?!

Йә, кайсыгыз чорның шаһзадәсе?!
Йөрәгемне учка саламын.
Тәхет тоткан шәрык кызларының
Яна миндә каны — дәвамы.

Сагаюлы ирләр, вагаюлы...
Ерып барам күзләр диңгезен.
Бу урамның үги шавы баса
Кайсы чорның шанлы нигезен?

Юксынсам да узган гасырларны,
Үксез булып анда калалмам.
Шаһгалидәй ирләр дөнья тулы.
Мин дә...
Сөембикә
булалмам...

## Күрше кызы

Күзәттем ни, сүз әйттем ни —
үземнең үз күңел эшем:
Чытлыкланып, кәз-кәз басып,
назлыкайның күр йөрешен:
Җилфер керләр эләргә дип
нәзакәтле үрелешен;
Күз карашын тәкатьсезләп,
сыгылма бил бөгелешен.

Нинди гадел чишкән Ходай
жете төсләр бүленешен:
Җир кызына өстәп биргән
ягымлы нур — Күк өлешен.
Бар барлыгы әйтеп тора
хисләренең түгелешен.

Күр әле син: үлән-чыкта
эзләренең чигелешен.
Ә егетнең койма аша
Үрелеп бер үбелешен.
Бу мизгелдә йөрәгендә
тылсымлы сүз тибелешен.
Белми әле: мәхәббәтнең
мең үлеп, мең терелешен;

Назлыкайнын, куллар болгап,
томаннарга күмелешен...

Бирмә, Ходай, мәхәббәттән
күнел дәрте сүрелешен.
Ул хәзергә белмәсен дә:
жинәм, диеп, жинелешен.

Күзәттем дә, сүз әйттем дә,
Мина нәрсә, күнел эшем:
Кайтар, Вакыт, назлыкайнын,
Ыспай басып, бер йөрешен.
Тик бер генә кабатлачы,
Шушы жәннәт күренешен.

## Ак яулыклы сабырлык

*Ничек соң мин яшь шаһзадә булып*
*Килалмадым сиңа ак атта?*
Рәшит Әхмәтжан

Нинди сөлгеләр элгәнсең
Гомер кашагасына.
Нинди мендәрләр тезгәнсең
Тәкъдирең ягасына.

Нинди догалар белгәнсең
Иблис өнсез калырлык...
Түзгән — иелмәс жанында
Ак яулыклы сабырлык.

Андый сабырлык төбендә
Сулкылдар сары алтын.
Нинди бизмәннәргә салып,
Кем үлчәп аклар хакын?!

...Хыялың — офык артында
Калган буразналарда.
Шул буразна үремнәре —
Киселгән толымнарда.

Томылып чаба, томылып,
Яшьлекнең чаптар аты.
Шунда бит, шунда ялгышның
Борылып кергән чаты...

Күндәмлеккә күнә барып,
Язмышың читлегендә
Нинди ярсулы назларның
Жене жуелган синдә.

Ак атлы яшь шаһзадәнең
Килерен көткәнсеңдер.
Чәмчәле читек чигешен
Төшләрдә үпкәнсеңдер.

... Ачыла хәтер, ябыла...
Нинди жил килеп кагыла
Капканның келәсенә;
Нинди бу — бөек ышаныч
Сөенеч киләсенә:
Ак атта, жилле жайдакның
Тупырдап керәсенә!

Янабаштан, бер айкалып,
Сөлгеләр эләсең дә...
Янабаштан, сөеп-сыйпап,
Мендәрләр тезәсең дә...
Нинди бу — рәхмәтле әрнү
Мәхәббәт сурәсендә?!

Куш мендәрең нәүмиз ята
Күнелең Кәгъбәсендә...

## Төштән — төшкә

Син кояшка кадәр тугансыңдыр,
Син кояштан соң да каласыңдыр,
Мәңге Сөю Тажым.

Мин төшемдә синең төшкә кердем,
Дөнья буйлап сине эзләп йөрдем,
Төнге Илаһ Назым.

Янгырады аһым, чөйде таулар,
Кайтты, сулгып, нәүмиз кайтавазлар,
Сине табалмадым.

Инде тәмам өмет өзгән халдә,
Төштән өнгә чыгып барган мәлдә,
Кинәт пышылдадың:

— Шулай эзләрсең дип белгән идем,
Мин бит синең төшкә кергән идем...
Синең Төнге Назың.

## ... идек, идек шул

Чыкты бәреп араннарны
Бу яшьлекнең тай чагы.

Зеңләми алтын кыңгырау —
Кесәләрнең сай чагы.

Тауны тауга сөзештерер
Көч-хыялның шай чагы.

Керфек кагудан кабынды
Бакый сөю учагы.

Валлаһи, дим, бүтән иде
Төн тажының Ай чагы!


Килде менә... индә гомер
Эскертенең тау чагы.
(Кесәләрнең бай чагы).

Гүзәллекне бәһаләргә
Чорының да жай чагы.

Әмма сиңа килешми шул
Дөньяның бу — шау чагы.

Әй, Чал акыл! Як, дөрләсен
Үкенечләр учагы.

*Журналыбызның 2нче санында игълан ителгәнчә, кыска күләмле бәяннар (повестьлар) конкурсын башлап җибәрәбез. Әсәрләр киләсе елның 30 апреленә чаклы кабул ителә.*



Батулла

# ИКЕ ҖҮЛӘР

ПОВЕСТЬ

Төньяктагы таулар Сарташ авылын салкын җилләрдән ышыклый. Шул тауның уртасында яшьләр уенга җыела торган «өстәл» бар. Чыгып торган өстәл янында мунча кадәрле сары таш калкып тора. Мең еллар тора инде ул сары таш. Шуңа күрә дә бу авылны борынгы бабаларыбыз Сарташ дип атаган, имеш. Сарташ тавыннан бик күп чишмә агып чыга. Киленнәр шул чишмәләрдән чәйлек су ташый торганнар иде.

Егет-җилкенчәк, кыз-кыркын түгәрәк уен уйнаганда, җыен бала-чага сары таш янында комнан өй ясап, шул ком өйләрне чүпрәк-чапрак белән бизәп, бераз су кушып комнан ясалган «пәрәмәч пешереп», бер-берсен кунакка чакырган булып, мәш киләләр. Бала-чага янында Габдулла исемле телсез-чукрак та уенга катнаша иде.

Хәзер тау уртасындагы сары таш юк инде. Ул аска тәгәрәп, буа суына баткан.

Бу авылның ике җүләре бар. Берсе әнә шушы Габдулла, аны Җүләр Әбдүш дип йөртәләр. Кызамыктанмы, чәчәктәнме сабый чакта ук телсез-чукрак булып калган. Аның әшәке, начар әйберләрне күргәч: «уһу, акка-бокка» сүзе бар, кәефе килгән чакта, ике баш бармагын күрсәтеп, айгылдап көлү гадәте дә бар. Әбдүшнең ата-анасы күптән үлгән. Ерак тутасы, алар йортына килеп, шул мәхлукны карап тора. Тутасы аны кыерсытмый, какмый-сукмый, ашата-эчертә. Габдулланың өс-башы гына ертык, ямаулы булыр. Бер елны башбатыр калгач, Сирайга арбалы матай бүләк иттеләр. Җүләр Әбдүш йөгереп килеп, матайның арбасына чумды. Шуннан соң Сирай аны гел матаена утыртып йөртә башлады, шуңа күрә Әбдүш аны бик ярата, Әбдүш кешеләр алдында ике баш бармагын һавага төртеп, Сирайны мактый. Сабантуйларында Сирай көрәшкәндә, Җүләр Әбдүш аның өчен җаната, кыргый тавыш белән кычкыра, хәрәмләшсәләр, үзенчә сүгенә.

— У-у, акка-бокка! — дип иләмсез тавыш белән кычкыра.

Сирай жинсә, шатлыгыннан котырынып, баш бармакларын тырпайтып, мәйдан уртасында йөгереп йөри.

Авылның икенче җүләре Сирайның үзе булыр. Ни өчен аны «Җүләр Сирай» дип атаганнардыр, беркем дә белми.

Сарташ тавы түбәсенә менеп, аска, тирә-якка баксаң, гаҗәеп матур табигать манзарасы ачыла. «Ялкын» калхузына кергән алты авыл күренеп тора. Әрәмәләр, буалар, иске тегермән хәрабәләре — уч төбендәге кебек.

Авыл үзгәрә бара. Авылдагы салам түбәле йортларны — дранча түбәлесе, дранчаны такта түбә алыштырды. Тактаны — калай, аннан соң — шифер, шифердан соң ни булыр йорт түбәләрендә? Куе таллар да карчыклар авызындагы тешләр кебек сирәгәйде. Аның каравы авылда алты почмаклы, сигез почмаклы йортлар күбәйде, гел харап, ташпулатлар арта торды. Хәленнән килмәгәннәр, авырулар, ялгыз карчыклар гына яңа өй салып маташмадылар. Җүләр Сирайның да каралты-курасы шул килеш кала бирде. Җүләр Сирайның да шәп йорт салып керергә көченнән килә иде, ләкин Сирайның хәттин ашканнарга исе китмәде, ул аларның алагаем олы йортларына да, «Волга», «девятка» кебек машиналарга утырганнарына да кызыгып бакмады. Ул хәтта Сабан туйларында батыр калып, матай, суыткыч, тәкә, келәм-палас отса да, өс-башын да җүнләп карамады, ни эләксә, шуны киеп эшкә китә, бәйрәм көннәрне генә чиста күлмәк-ыштан киеп чыга.

«Җүләр» дип әйткәннәренә дә аның исе китми, Сирайның җавабы әзер:

— Җүләрләр арасындагы акыллы кешене гел җүләргә санаганнар! Әнә, карагыз, бөтен пәйгамбәрләрне тилегә санаганнар! Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәламны да үз халкы башта «җүләр», дигән.

Сарташның кече урамындагы бер почмагына бәләкәй генә бер өй поскан. Тыйнак кына, матур өй. Ике тәрәзә — ике күз сагышлы карый. Бу өй дә, мөгаен, үзенең хуҗабикәсенә охшагандыр, ул да нәкъ шулай тыйнак-матурдыр, нәкъ шулай сагышлыдыр-моңлыдыр.

Бу Җүләр Сирайларның курасы. Өй әле нык, мунчасы яңа, каралты-курасы да тәртиптә, бер сыер, сугымлыкка бер бозау да, унлап тавык, бер оя каз, бәрәннәре белән жиде сарык, чия бакчасындагы карлыганнар арасында өч баш умартасы бар.

Анасы Гөлчәһрә белән ул әнә шул, үзләре кебек тыйнак өйдә яшәп ята. Эштән бушаганда, көзге туктамас яңгырларда, кышкы күзачкысыз буранnarда авыл кешесе кая барсын, өеннән чыкмый ята, телевизор бага, мунча керә, күршесенә биләмгә йөри. Сиражетдин Туктаров исә китап укый. Бәлки аңа китап җене кагылганга, «Җүләр Сирай» кушаматы такканнардыр? Аның үзенә күрә китапханәсе дә бар. Әле нинди генә! Үз кулы белән ясаган киштә-шүрлекләрдә Толстойның уникe томы, Әмирхан Еникинең китаплары, Галимҗан Ибраһимовның сигез томлыгы. «Новый мир» белән «Казан утлары» журналының әллә ничә еллык төпләмәләре — бар да бар. Бүлмәсенең түренә кадакланган келәмдә ау мылтыгы, бабасыннан калган кылыч, алтатар кобурасы эленеп тора.

— Кайда моның маузере? — дип кызыксынганнарга хуҗабай җавап кайтара:

— Рөхсәтсед утлы корал тотарга ярамай, дип күнтәпиләр апкитте. Апаем, ау мылтыгына минем рөхсәтем бар. Маудерның бабама именной бүләк ителгәнен дә әйттем, дукументын да күрсәттем, ударнигын атмаслык итеп эшләгәч килеп

алырсын, диделәр. Апаем, кеше үтерәсем килсә, мин аны ау мылтыгыннан да атып үтерә алам.

Сүзгә хужабикә Гөлчәһрә түти катнаша:

— Аның ауга чыгып та куянга, төлкегә атканы юк. Чангыга басып, мылтык асып, кар сәхрәләрен әйләнеп кайту аның өчен бер хозурлану гына ул. Абзар тулы малыбыз, бедгә нәмәгә кирәк ул куян ату?

Бәлки аны ауга чыгып та куян-төлке атмаганы өчен җуләргә саныйлардыр? Ни өчен Сирайга «Җуләр» кушаматы тагылып калгандыр, ул үзе дә белми, ахрысы. Укытучыларга җавап бирә алмаслык сораулар яудыргангамы, кыз урларга маташып та оятка калганынамы, белгән юк.

Мәктәптә укыганда ук Сиражетдин укытучыларын аптырата торган иде, техника турындагы бәхәсләре, әдәбият турындагы сораулары күп вакыт укытучыларны кыен хәлгә куя торган иде.

— Апа, ни өчен ай бедгә бер ягы белән генә карап тора? — дигән сорауга астрономия укытучысы Сәгъдия апа җавап бирә алмаган иде.

Үз соравына Сирай үзе җавап бирде.

— Айнын үд күчәрендә әйләнү вакыты Җир әйләнәсендәге хәрәкәт вакыты белән бер булганга!

Бервакыт әдәбият дәресендә, тугызынчыда укыганда булса кирәк, дәрес бетәр алдыннан укытучы Мәрдия апа:

— Сорауларыгыз бармы, балалар? — дип сорады. Сирай кул күтәрде.

— Апа! — диде ул, — Талстуй «Бал бәйрәменнән соң» хикәясе белән татарларны яклый бит, сед апа шул турыда әйтмәдегед. Иван Васильевич урамда бер вдвод салдатның бил тинентен чишенгән татарны кыйнап алып барганын күрә. Кыйнауны Иван гашыйк булып йөргән кыдның атасы полковник оештырган була. Шуннан соң Иван Васильевич полковникның кыдыннан вад кичә. Матур мәхәббәт татар кешесенең кыйналуы аркасында җимерелә бит.

— Дәрес бетте, балалар! — дип Мәрдия апа, һични әйтмичә кынгырау шылтыраганчы ук дәресханәдән чыгып киткән иде.

Бервакыт Сарташка язучылар килгән иде. Бик кызык булды ул очрашу. Әдәбиятны белүдә Сирай бөтен язучыларны шаккатырды. Аның сораулары мәгънәле һәм урынлы иде. Кичәдән соң алдан ук әнисе белән сөйләшеп, Сирай яшь язучыларны кунакка алдырды.

Иң башта хужабай затлы кунакларны мунчага алып китте. Каен, туйра себеркесе белән һәрберсен кат-кат чапты.

— Тәнгә — мунча, җанга — юк! — диде хужабай.

— Тукайны яттан белә бу! — диде шагыйрь Рөстәм.

Мунчадан соң бакча сәкесендә тәгам җыйдылар.

— Үлемнең умарта балы! — диде хужабай, бал савытын кунаклар алдына куеп. — Монысы да үдебеднең баллан ясалган! — Сирай чокырларга әче бал коеп чыкты.

Бал кортының ипие, сарышын катыштырып эшләнгән бал «кодачаның җуачасы»ннан да затлырак иде. Каклаган каз, бәлеш белән сыйланды кунаклар.

Язучылар бик тә канәгать китте. Шуннан соң язучылар белән Сиражетдинның өзелмәс дуслыгы башланды.

Сиражетдинның китапханәсен күреп, язучылар шаккатты.

— Әдәби зәүкы бар егетнең! — диештеләр кунаклар.

Бөтен авыл егылып эчкәндә, Сиражетдин авызына хәмер алмас, китап укып

ятыр. Бәлки башкалар кебек эчмәгәнгә, эчеп былагайланып йөрисе урында китап укыганга, аны Җүләр Сирай дип атаганнардыр?

Сирай кебек китап укыган кеше авылда юк, авылда гынамы, бөтен төбәгендә юктыр. Үзендә булмаган китапны ул китапханәдән алып укый. Китапханәгә иң еш йөргән ике кеше бар: берсе — Сирай, икенчесе — Гашия. Әллә китап белән дус булганга, әллә мөлаем булганга Сиражетдин Гашиягә гашыйк иде. Ләкин ул үзенең мәхәббәте турында кызга әйтергә кыймый. Юкса, Сабантуй батыры, куркак егет түгел, кызны күрсә, каушый да төшә. Алып гәүдәле Сирайны бәхетсез мәхәббәт сагышы бөкте. Шул сагыш аның гомерлек юлдашы булды.

Мәктәпне ул бар фәннән дә яхшы билгеләренә тәмамлады. Аны йә физматка яки сәнгатькә китәр, дип уйлаганнар иде. Ләкин Җүләр Сирай физматка да, сәнгатькә дә китмәде, армия хезмәтенә китте.

Гашия, чәтертән кыз, әллә юри, әллә котыртып кына Сирайга елмаеп карый иде. Шул елмаюны бичара Сирай «кыз мине ярата» дип кабул итә иде.

Армиягә киткәнче, Гашия-кыз клубта түгәрәк уен уйнаганда, Сирайга аеруча назлы елмайган иде. Уеннан соң ул Гашияне капка төбенә чаклы озата кайтты.

— Мин иртәгә салдатка китәм, хат җадарсыңмы, Гашия? — диде егет.

Кыз аның бу сүзен шаяруга алыптыр, ахрысы, челтерәп көлде дә әйтте:

— Язармын! — диде.

Гашия капкасыннан кереп китте, капканы ябып бетермичә, ул йөзен капка ярыгына куеп өстәде:

— Абыең рөхсәт итсә! — диде дә кычкырып көлә-көлә өенә кереп китте.

Шайтан белсенмени Хашим белән Гашиянең вәгъдәләшкәнен! Икенче көнне үк Сирай армиягә китте. Карантинда чакта ук ул Гашиягә хат язды.

«Исән-аманмысез, сезки ерак Сарташта яшәп ятучы сөеклем Гашия! Сәлам атаң-анаңа һәм абыйларыңа, сеңелләреңә, күрше-коланга, һәммә барчагызга да аермаенча кайнар сәламнәремне җибәреп калам. Сәлам тәмам, бераз сүзгә күчәм. Карантинда ятабыз, аннан соң чын салдат булып, присяга кабул итәбез. Служба бара. Синең хәлләр ничек, кая китәргә уйлыйсың? Медучилищега кер, Алабугага, аннан авылга кайтырсың безнең медпунктка. Мин монда механик-мотористлыкка укыячакмын. Армиядән кайткач, механик булырга исәп. Мин тракторда, комбайнда эшләрмен, син шәфкать туташы булып. Хезмәттән кайтуга ук мин сиңа яучы җибәрәм, Алла боерса. Син минем анама яхшы килен булырсың, минем анакай әйбәт ул, үзең беләсең. Без бик тату яшәрбез, балаларыбыз да күп булыр, иншалла! Мине зарыгып көт, Гашия җаным. Зөһрә Таһирын, Ләйлә Мәҗнүнен, Зөләйха Йосыфын көткән кебек көт мине. Кочаклап үбәм, чәченне, толымнарыңны үбәм, зар-интизар булып күрешү мизгелләрен көтүче Сиражетдинең булыр!»

Чукындырасыңмыни аны, бу хатны Гашиянең сеңелләре ачып укыган да җавап язганнар.

«И сөеклем Сиражетдин! Сез ки батырларча солдат хезмәтендә булгучы Сиражетдин Сабирҗан углы Туктаров, сезни бер күрергә интегеп яшәүче сөеклегез Гашия Тимергали кызы сәламли. Аллага шөкер, сыерыбыз игез бозау китерде, берсе тана, берсе үгез бозау. Чүбен салганын үзем тун киеп сагалап тордым. Хезмәтеңнән сау-сәламәт булып кайтсаң, туебызга ит мул булыр, Алла боерса! Сеңелләрем белән туй бүләгенә түрләмәләр, кульяулыклар, тастымаллар чигәбез. Хәлкәйләрең ничек, сөеклем, солдат хезмәте бик авыр түгелме, беләм, син көчле егет, Сабантуйда бил бирмәүче батыр бит син, шөкер. Кайтуыңны зар-интизар булып көтүче Тимергалинең сөекле кызы Гашия».

Сирайның куанганын күрсәгез! Ул беркатлы бичара хатны Гашия язганына

шундук ышанган иде. Байтак кына вакыт ике арада кап-кайнар гыйшык хатлары йөри торды, аннан соң хатлар кинәт туктады. Сирай нишләргә дә белмәде, янды-көйде, кат-кат язды, ләкин җавап килмәде. Ел узды дигәндә генә Хашимнан хат килеп төште: энем, мин өйләндем, туйны син кайтмыйча уздырмайбыз, диелгән иде хатта.

Танкны, техниканы ул нык үзләштерде, ул дивизиянең иң атаклы механигы булып китте.

Ачуыннан, хәсрәтеннән ул спортзалга кереп, җан тиргә батып күнегүләр ясый, җене өзелердәй булып классик көрәш белән шөгыльләнә, башта полкның, аннан бөтен хәрби частьнең чемпионы булды.

Хезмәтен тутыргач, ул ашкынып Сарташка кайтты. Һәм аны мунча ягып, бәлеш салып әнисе Гөлчәһрә, абыйсы Хашим белән җиңгәсе Гашия көтеп торалар иде.

Сирайның солдат биштәре кулыннан төшеп китте. Бу хыянәтне аның зиһене кичерә алмый иде. Гашия һични булмагандай, елмаеп тик тора. Ләкин Сиражетдин сер бирмәде, түзде, әмма аның мәхәббәте тагын да дөрләп кабынды.

Киңәш-табыш иттеләр дә Хашим белән Гашияне башка чыгарырга булдылар, йола буенча төп нигездә төпчек Сиражетдин кала, Хашим башка чыгачак иде.

Йорт кору эшләре башланды. Сиражетдингә эш житкезеп булмый иде, ул җене белән эшләде, җәй узды дигәндә, башка чыгучылар яна йортка күченде. Аларга бер сарык, бер тәкә, башмак тана, бер-ике тавык бирелде.

— Болай булгач, яшь башларга була! — диде абыйсы.

Ике дә уйлап тормыйча, Сирай авылда калды. Ялгыз анасын ташлап китә аламыни ул? Яхшы механик иде ул, нидер кирәк булса, Сирайга йөгерәләр, сабан көйләргәме, Казанга барып запчасть алып кайтыргамы — Җүләр Сирай кирәк, зажигание көйләргә Сирайга куш. Аннан башка калхузның эше бармас иде. Каралты-кура тирәсендә дә ул бөтен эшне үзе эшли, әнисенә чиләк тә күтәрттерми, монысының да сәбәбе бар, исенә төшкән саен әнисе өйлән инде, улым, дип җанга тимәсен өчен, булмаган килен эшен дә үзе башкара иде.

Бик өйләнәсе килә Сиражетдиннын. Булачак хатынын, анасының булачак киленен ул төшләрендә күргәли. Хәтта хыялындагы хатыны белән сөйләшеп тә йөри, Җүләр кушаматы ана әнә шул үзалдына сөйләнеп йөргәне өчен тагылды, бугай.

Ләкин Җүләр Сирайның анасына килен булырлык хатын авылда берәү генә иде шул. Анысы да кияүдә, абыйсы Хашимда, аның җиңгәсе Гашия иде.

Сабан туенда Сирай тагын батыр калды. Шәп көрәшә чукынмыш. Абзарда тагын бер тәкә артты. Суыткычы да комачау итмәс.

Ләкин Гашия Сирайның зиһененнән чыкмады. Ут йота иде Сирай. Абыйсының йортын өлгерткәч, Сирай калхузга механик булып урнашты. Аның кулыннан килмәгән эш юк иде, ләкин уенда-башында Гашия. Ул хыялланыр дәрәҗәдә аны ярата иде. Әллә ничә тапкыр аулак урында очратып сүз катты.

— Ни сөйлисең син, кайнем? — диде Гашия. — Минем сина хат язганым юк.

Сирай ярсыды, ул куеныннан хатлар чыгарып, Гашиянең йөзенә якын китерде:

— Ничек юк! Менә бу кем хатлары: сөям, дидең, көтәм, дидең?

Гашия хатларга күз йөртеп чыкты да:

— Ну, бу кызларны! — диде ачынып. — Моны минем сеңелләрем язган! Ну, кирәкләрен бирәм мин аларның!

Сиражетдин һаман ышанмады, аның яратуы тагын кыза төште, ул инде ничәнче тапкыр Гашиягә ялвара иде:

— Гашия, мин бит сине армиягә киткәнче үк ярата идем, мин сине тагын да ныграк яратам, аерыл Хашим абыйдан, ул синнән олы бит.

— Мин дә синнән ике яшькә олы! — диде Гашия.

Сирайның җавабы әзер иде:

— Ике яшь ерунда ул, Гашия! Сөекле пәйгамбәребед Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәламнең хатыны хәдрәти Хәдичә дә иреннән унбиш яшькә олы булган. Аяд Гыйләҗевнең Бибинуры сөеклесеннән әллә ничә яшькә картырак. Зөләйха да Йосыфтан олы булган. Мәхәббәт яшькә карамай ул!

Бу очрашуларны Гашия башта шаяруга алган иде, инде бу шаярудан узып бара, дип ул кырт кисәргә уйлады.

— Мин сине яратмыйм, Сиражетдин! — дип кычкырды кыз. — Син мине дә, абыеңны да, үзеңне дә адәм көлкесенә калдырасың, кеше арасында сүз чыгар, Аллам сакласын! Ташла бу эшеңне, кайнем. Минем йөгем бар, без бала көтәбез.

Сирай ярсып, Гашиянең ике иңеннән тотты:

— Йөгең белән алам, Гашия!

— Тилергән! Ни сөйлисең син, бөтен авыл алдында адәм ыстырамы ясыйсың бит. Мин абыеңа әйтәм, мин моны яшереп калдыра алмыйм.

— Әйт! Сөйлә! — дип кычкырды Сирай. — Әмма мин сине сөюдән вад кичә алмаем! Мин синнән башка яши алмаем! Аерыл Хашимнан!

— Кит юлымнан! Мин ир хатыны, йөкле хатын!

— Талстуйның Анна Кәрининәсе дә ир хатыны булган, баласы да булган, әмма чын мәхәббәт белән яраткач, иреннән аерылып, Вронский белән качып киткән. Чын ярату барысын да кичерә, Гашия. Монда торырга кыенсынсаң, башка җиргә күчеп китәрбед! Динһар, аерыл син Хашим абыйдан!

Кешеләр килә башлагач, Гашия йөгереп китте, Сирай нишләргә белмичә, алак-ярак карангалап калды.

— Исәнме, Сирай! — дип сыер савучылар аның яныннан узып китте.

Сирай җавап кайтармады.

Бу сөйләшүдән соң ике-өч ай уздымы, юкмы, бөтен авылны шаккатырган вакыйга булып алды. Тәвәккәлләп, Сиражетдин калхуз атларын караучы Садыр Гыйлемханы янына китте, кесәсендә бер шешәсе дә бар иде. Садырның тамагы да кычытып тора иде, Сирай алып килгән шешәне печән арасына качырып куйгач, Садыр әйтте:

— Ни йомыш, Сиражетдин энем? — диде.

— Гыйлемхан абдый, бу кичкә Турытаенны биреп тор әле...

— Ни йомыш?

— Кыд урларга барам.

— Кая?

— Урадбәккә!

— Кем кызы?

— Анысы хәрби сер, кайткач күрерсен, туемда түрдә утырырсын!

— Матри! — диде Садыр. — Атны имгәтсәң, пред икебезнең дә башны кимерер!

— Белми дә калырлар!

— Энгер-менгердә килерсен!

Ул күрше кызы Илгизәне чакырып чыгарып, алтын йөзек сузды.

Илгизә аптырап калды.

— Бу ни, Сирай абый! — диде кыз.

— Син беднең килен Гашияне сәгать тугылда капка төбенә чакырып чыгарсан, йөдек синеке! Мин чакырганны әйтмә, ахирәтләрен чакыра, диген!

Кыз «ни өчен» дип сораштырырга уйлаган иде, Сирай коры тотты, ул йөзекне Илгизәнең атсыз бармагына кигездә дә китеп барды. Кыз йөзекле бармагын сыпыра калды.

— Ярар, алайса, бер-бер кызык уйлап тапканмы соң бу Тиле Сирай! Чакырырмын сәгать тугызда! — диде кыз үзалдына.

Сирай әнгер-менгер житкәнне зарыгып көтте. Ул келәмнән мылтыгын алды:

— Әнкәй! Коймагынны пешерә тор, самавырынны куя тор! Мин килен апкайтам.

— Ай, Алла-Ходаем! Кем кызы, нигә бик ашыгыч, әзерлегем дә жук...

Жавап та бирмичә, Сирай, мылтыгын инсәсенә асып, ишектән чыкты. Урамда дөм караңгы. Садыр Гыйлемханы атны иярләп, көтеп тора иде. Сирай биеп торган айгырга атлангач, аны тыя төшеп, жинелчә юыртып китеп барды.

— Алла ярдәменнән ташламасын! — дип калды Садыр.

Сирай авылны чыккач, салмак юыртып байтак барды, аннан атны кире борды. Ул авыл йоклаганны көтә иде. Ат басу капкасыннан кергәндә, урам башында бер шәүлә күренде, бу Илгизә иде. Сәгать тугыз тулганда, алар Хашимнар капка төбендә иде. Илгизә кереп китте, тәрәзәдә ут яна иде әле, озак та узмады капкада ике хатын-кыз күренде. Сирай яшен тизлеге белән Гашияне күтәреп ияргә менгезде, үзе дә атка атланды, айгыр алга ыргылды, Гашия кычкыра, Илгизә кычкыра, этләр өрә.

Сирай өендә ут яна, анасы килен төшкәнне көтә, Сирай аттан сикереп төште дә һавага мылтык дөпелдәтеп, һичтуктаусыз чәбәләнүче Гашияне өенә алып кереп китте.

— Менә, әни, синең киленең! — дип кычкырды үзе.

— Әстәгъфирулла, бу Гашия түгелме соң? Нишләден син, бала? — дип каударланды әнисе.

Ул арада капка ягыннан кешеләрнең кычкырып сөйләшкәннәре ишетелде, озакламый ишекне каерып, өйгә Хашим килеп керде.

— Сирай, нишләвең бу? — дип кычкырды ул. — Жүләр Сирай, аһ, тиле Сирай!

Гашия яклау сорагандай, бер каенанасына, бер иренә сарыла иде. Үзе жылый, Гөлчирә түти дә нишләргә белми:

— Тилергән малай, тилергән Сиражетдин! — дип сукрана.

Өерелеп ирләр керде, барысы да аптырашкан иде.

— Вәт жүләр Сирай! — дип бот чабалар.

Мактау көтеп торган Сирай бөтен кеше үзенә ябырылгач, каушап калды, шул каушаудан файдаланып, Хашим анын кулыннан мылтыгын тартып алды да энесенә төбәде:

— Атам, эт баласы! — дип кычкырды.

Анасы кычкырып олы улына ташланды да мылтык көпшәсенә ябышты.

— Нишлисез сез, балалар? — дип үкси башлады. — Нәселдә булмаганны! Акылыгызга килегез, балаларым!

— Әнкәй, абый, мин аны яратам! — дип кычкырды Сирай, ачынып. — Мин аннан башка яши алмаем!

— Мин дә яратам, ул минем никахлы хатыным, булачак баламнын анасы! Мин дә аннан башка яши алмыйм! Китап укый-укый тилергәнсең син, Сирай!

Барысы да сабырлана төште.

— Әйдә! — диде Хашим хатынына, аннан соң мылтыкны өстәлгә куеп, ишек тарафына борылды.

Хатыны каенанасының кочагыннан чыкты да иренә иярде, башкалар да таралышты. Өйдә Гөлчирә түти белән төпчеге Сирай гына калды.

Өй эче тып-тын, сәгать тавышы гына ишетелә.

— И бала-бала! — диде ана сабыр гына. — Адәм көлкесенә калдырдың бит син нәселне.

Сиражи тирән көрсенде дә капка төбендә таптанып торган айгырны Садырга илтә китте.

Шау килде халык, Жүләр Сирайның кыз урлаганы турындагы хәбәр бөтен төбәккә таралды: сөйлиләр дә бот чабып көләләр; арттырып та җибәрәләр; булганын да, булмаганын да сөйлиләр. Сирай кешеләргә сүз әйтмәде. Ул һаман Гашияне ярата иде. Ә аның сөйгәне Гашия бала анасы булды, ул кыз олан алып кайтты.

Быел Сабан туенда Сиражетдин көрәшмәде. Бик боек йөрде бичара. Сабан туе таралгач, төшке бәлешләрне ашагач, халык сары таш янына көндезге уенга менеп китте. Сабыйлар инде күптән сары таш астында комнан йортлар корып, кунаклы уйный. Жүләр Әбдүш тә кызчыклар уенына кушыла, кечкенә чиләктән су биреп тора, кызлар су катыштырып, комнан «пәрәмәч пешерә». Яшьләр уенга җыела, кунак кызлары, кунак егетләре, гармуны, баяны, җырлыйлар, бииләр. Уенның иң кызган чагында гына кемдер чырыйлап кычкырып җибәрде, мең ел буе кузгалмаган сары таш кузгалып, Жүләр Әбдүшне баскан да туктаган. Габдулланың сул аягы таш астында калган, Габдулла илереп үкерә, балалар чырыйлап җылый, яшьләр дә таш янына атылдылар. Ләкин ташның янә кузгалып, Әбдүшне сытып, аска тәгәрәү куркынычы бар иде.

— Якын бармагыд! — дип кычкырды Сирай.

Сиражетдин, уйлап-нитеп тормыйча, таш янына атылды, Габдулланы сыттырмас өчен, аркасы белән ташка терәлде дә җан көченә ташны этә башлады, батырның муен тамырлары кабарды, күзләре акайды, нинди көч булгандыр ул, таш чак кына күтәрелгәндәй итте:

— Тартып алыгыз! — дип җан көче белән акырды Сирай.

Кемдер Габдулланы таш астыннан тартып алды, Сирай таштан читкә атылды, таш әле генә Сирай басып торган урыннан аска таба кузгалды, әкрен генә тәгәрәп, таудан аска төшә башлады, тизлеген арттыра-арттыра, мунча кадәрле таш, ком бураннары кузгатып, аска тәгәрәде, тәгәрәп төште дә буага чумды. Жүләр Әбдүш илаулап җылый, аның аягы имгәнгән иде. Сирай Габдулланы ике кулына күтәрде дә тау сукмагы буйлап авылга йөгерде. Матаен кабызып, авыруны күрше авыл хастаханәсенә илтте. Габдулланың аягы сынган, кулы тайган булып чыкты. Алланың рәхмәте, ул аягына тиз басты. Шулай да Жүләр Әбдүш сул аягына аксак калды.

Халык Сирайның батырлыгына сокланып туя алмады.

— Һи-и, Сирай, шунда үзеңне таш баскан булса, икегез дә сытылып үлә идегез бит! — диештеләр.

Ризасызлары да табылды:

— Жүләр Әбдүшнең шунда сытылып үлгәне яхшырак була иде. Тутасы да котыла иде, үзе дә котыла иде.

Сирай мактаганнарга да, ризасызларга да кайтарып сүз әйтмәде.

Бу вакыйга кыз урлау вакыйгасын оныттыра төште.

Урып-җыю вакытында Сирай басудан кайтып керми, шунда гына әбәт ясый. Ул комбайнның өзелгән каешын алмаштырып маташа иде, тыны-өне беткән пред сәпите белән килеп капланды.

— Сирай! Коткар! Уазикның коробкасы чыкты...

Капланырсың да нибуч, калхузда алты авыл, аралары ерак, бөтен басуларны тикшереп йөрергә уазигың булмаса, чуртымны кырырсың. Преднын хәлен бик яхшы аңлады Сирай.

— Егетләр, каешны үдегед кигертерсегед, мин киттем! — дип матаен кабызды.

— Утыр, Габдулла! — диде Сирай комбайн тирәсендә чуалган Әбдүшкә.

Җүләр Әбдүш шатлыгыннан кыргый мәче сыман ыйгылдап, матай арбасына утырды.

Пред Сирайның запчастьсез кайтмаячагын бик яхшы белә иде, Сирай бит ул кыенсынып тормый, мүкләк сыер кебек теләсә кем янына кереп китә, нәчәлникнең ишеге төбендә йоклап калса кала, теләгәнен алмый чыкмый.

Нәчәлникнең күзенә карап:

— Кирәк бит, апаем, үдем өчен түгел, калхуд өчен, сәвитләр быласты өчен сораем бит, апаем... — дип ялваргач, тилемсәрәк бу ирнең сагышлы, ялварулы карашын күргәч, нәчәлникләр аның йомышын үти торганнар иде.

— Кайтып життек, Габдулла! — диде Сирай.

Җүләр Әбдүш матайдан төшеп, капкадан узды.

— Әнкәй, кунак бар! — дип кычкырды хуҗабай. — Капкаларга әдерлә!

Әнисе болдырга чыгып, улы белән Әбдүшне каршы алды:

— И-и, Габдулла кунакка килгән икән! — диде олы кунак көткәндәй. — Коймагым да әзер, керегез!

Гөлчәһрә түти Әбдүшне өйгә алып кереп китте. Өйгә кергәч, Әбдүшнең кулларын сөннәтләтте.

— Хәзер чәй ясыйм! — дип мич тирәсендә әвәрә килде.

Матаен капка төбендә калдырып, Сирай өйгә атылды:

— Әнкәй! — дип кычкырды ул керә керешли. — Син әперти, кычыткан яфраклары җый әле, минем калага барасым бар.

Гөлчирә түти «олы кунак» алдына коштабак белән коймак куеп, сөтле чәй ясады, кунакның алдына бал савытын шудырды.

— Аша, балам Габдулла! — диде дә хуҗабикә, кәрҗин алып, ишегалдына чыгып китте.

Сирай тиз генә корбанга калдырган сарыгын суеп тунады, әнисе әрекмән, кычыткан яфракларын чайкап саркытырга куйган иде. Сирай түшкәне тоз белән яхшылап ышкып чыкты да кычыткан яфраклары белән төрде, кычыткан өстеннән әрекмән яфраклары белән каплап, аннан ак җаймәгә урады. Шулай иткәч, җәйге чилләдә дә ит бозылмый, озак саклана. Түшкәне матайның арбасына салып, өстеннән яңгырлык белән каплап куйды да, өйгә кереп, яшереп куйган урыныннан күпмедер акча алып, тиз генә капкалап, матаен кабызды, идарәгә барып юллама яздырып алды да Казанга очты.

Аның Казанда язучы дуслары күп иде. Китап ятратканга күрә, ул алар белән аралашып яши, авыл күчтәнәчләре белән сыйлый, язучы милләте Сиражетдинның Казанга килгәнен зарыгып көтеп ала, чөнки алар Сиражетдин акчасына сыйлана. Язучылар авылга килеп төшсәләр дә, Сирай акчасына сыйлана, Сирай калага килеп чыкса да, язучы халкы Сирай акчасына ресторанга керә. Шулай итеп, Җүләр Сирай язучылар арасында үз кеше булып китте. Ул хәтта язучыларның ел йомгаклары җыелышында

да катнаша иде. Авылдан килгән китап укучы буларак, аңа бер-ике тапкыр сүз дә әйттерделәр.

Дус язучылары (шаян халык) аны үзсендереп тә җибәрәләр иде.

— Син, Сиражи, әдәбиятны Галиуллиннан яхшырак беләсең! — дип алгысыталар иде.

Бервакыт язучылар җыенында:

— Төбәктән Сарташ авылы механизаторына сүз бирелә! — диде җыелышны алып баручы Мирсәй ага.

Күрәшче, механизатор, әдәбият сөюче Сиражетдин Туктаров сәхнәчектә торган мөнбәр артына менеп басты:

— Калхудчы седгә икмәк, сөт, ит бирә. Калхудчы ул, апайларым, халтурит итми, ә седнең арада халтуршиклар бар. Нигә калхудчының фидакарь хедмәтен мактап җадган романнар юк? Менә, апайларым, сед монда бик яхшы сүләйсегед, ә «Кадан утлары»гыдда укыр нәмә күренми. Седнең арагыдда иң шәп җадучы Әмирхан Женеки! Женекинең әсәрләрен укып туеп булмай, Габдрахман абый бит ул балалар җадучысы. Олгайгач, мин аның китапларын укып караган ием, кыдыгын тапмадым.

Калхузчы әдәбият тәнкыйтьчеләре өлешенә кереп, озак сөйләгәч, җыелышны алып баручы Мирсәй ага, графин кагып, Сирайны кисәтте:

— Калхузчы иптәш, кыскарак тотыгыз! — диде.

— Апаем, одак сүләмәем мин, Женеки кебек җадыгыд сед! — дип мөнбәрдән төшеп китте, урындыклар тыкрыгыннан барганда, бик каты алкышладылар. Бигрәк тә аның дуслары.

Бу юлы да Сирай турыдан-туры Язучылар йортына китте, ул вакытта Язучылар берлеге Бауман, 19да утыра иде. Анда аның дуслары эшли.

— Апайларым, — диде ул килеп керү белән.— Уазга коробка передач кирәк! Ит бирәм, бер тартма аракы алам, ярдәм итегед.

Егетләр чигәләрен озак кашыдылар, Рөстәм дигәне әйтте:

— Сельхозтехникага киттек! — диде.

Сельхозтехникада аларны складка юлладылар. Склад мөдире Зарифҗан Рөстәмне танып, егетләрне читкәрәк тартты:

— Бер коробка бар, егетләр! Ләкин ни акчага, ни иткә бирә алмыйм. Нәчәлник өзелеп кирәге чыкканда, дип калдырган коробка гына. Минем нәчәлникнең запас квартирасы бар, шуңа телефон кертә алсагыз, коробка сезнеке!

Егетләрнең сөмсерләре коелды. Бераз торгач, Рөстәм әйтте:

— Водоканалның элемтә бүлегенә — Фәриткә киттек! — диде.

Сарык түшкәсен алдына алып, Рөстәм арбага, склад мөдирен арткы утыргычка утыртып, Водоканалга киттеләр.

— Кыен эш, егетеләр! — диде телефон кертү остасы Фәрит.

— Кыен булса да эшлә, апаем! — диде Сирай. — Сиңа бер түшкә сарык, өч йөз сум акча, мәгәриче миннән.

— Квартирасы кайда? — диде Фәрит.

— Яна йортта! — Мөдир Зарифҗан егетләрне яңа фатирга алып китте.

Фәрит үзенең «Москвич»ына утырып, алар артыннан иярде.

Склад мөдиренең икенче ачкычы бар икән, ике бүлмәле өр-яңа фатир, яхшы җиһаз, суыткыч, суыткычта җаның теләгән эчемлек: коньяк, аракы, шәрабләр, төрле-төрле бозылмый торган кабымлыклар, тәрәч бавырлары, креветка консервалары, дистәләгән йомырка...

— Егетләр! — диде Фәрит, каядыр шылтыраткач. — Бу районда буш номерлар

калмаган. — Ике як ас-өс күршеләрне әйләнеп чыгыйк, телефонлы ялгыз карт-коры булмасмы?

Аскы катта сиксән яшьлек авыру әби яшәп ята икән, әбигә ике йөз сум акча биреп, блокировка белән номер куярга ризалык алдылар.

— Баста! — диде Фәрит. — Бер сәгатьтән телефонлы булырсыз. Яна чыккан телефонны куям.

Фәрит бик кәттә кыяфәт белән өр-яңа телефонын өскә күтәрде. Бу телефонның сан тәгәрәткеч тәгәрмәче юк, анда вак саннар язылган шакмакчыклар гына иде.

— Куй-куй! — диде Сирай. — Акчамын үдем түләем, апаем.

Фәрит кирәк-ярагын үзеннән калдырмаган иде. Ул кемгәдер шылтыратып, ризалык алды да монтаж эшләрен башлады. Эшне ул тиз тотты. Шылтыратып карадылар, аска төшеп, телефон автоматтан да шылтыраттылар, өр-яңа модель телефон төзек эшли иде.

Егетләр сыйланган арада склад мөдире нәчәлнигенә шылтыратып, сөенче алды.

— Лазарь Иванович, мин сезнең яңа фатирыгыздан чылтыратам! Нумирын әйтәм: 22-30-83...

— Китаннан! — дигән тавыш ишетелде. — Куй трубканны, хәзер үзем шылтыратам.

Бераздан соң телефон шылтырады, трүбкәне мөдир алды. Куаныштылар, котлаштылар.

— Егетләр, коробка сезнеке! Киттек! — диде мөдир.

Аска төшкәч, матай арбасындагы сарык түшкәсе Фәритнең «Москвич»ына күчте.

Сирай авылына төн уртасында гына кайтып керде. Ләкин ул предны уятып тормады, туп-туры гаражга китте.

— Синмени әле бу, Сирай! — диде йокыдан шешенеп беткән төнге каравылчы Әхрәй.

Сирай гаражның утын кабызды: түр почмакта ватык уазик моңаеп тора. Сирай өр-яңа коробканы күтәреп, машина янына килде.

— Әхрәй абзый! — дип кычкырды Сирай. — Кил әле...

Әхрәй ютәлли-ютәлли гаражга керде.

— Машинаны чокырга китерик әле! — диде Сирай. — Мин этәрмен, син рульгә утыр.

Машинаны чокырга турыладылар. Әхрәй йокысын дәвам итәргә каравыл кетәклегенә китте.

Байтак маташканнан соң, тизлек күчергеч коробкасы үз урынына утырды. Коробкага май салгач, Сирай машинаны кабызды, ишегалдына алып чыкты, тизлек терсәге йомшак кына эшли, барысы да ал да гөл иде. Уазикны чыгу ишеге янына ук китереп куйды да матаена утырып, йокларга кайтып китте.

Пред иртән торып гаражга килсә, машинасы төзәлгән, өр-яңа коробка урынына куелган иде.

— Жен икән бу Жүләр Сирай! — диде канәгать пред.

Шулай тагын бер ел узып китте.

Анасы башка бер кызларны да, ирдән аерылып кайткан хатыннарны да улына димләп карады, ләкин Сирай ишетергә дә теләмәде. Ул Гашияне оныта алмый иде. Гашия бала үстерә, тагын алты айлык корсагы бар.

Кышка кергәч, калхузчы механизаторларга сулыш алырга ара була. Кышкы ремонт башланганчы, Сирай Казанга дуслары янына китә, ул спектакльләр

карап, язучыларның ачык җыелышларында катнашып, егетләрне рестораннарга алып кереп сыйлап, Гашиягә булган мәхәббәт хәсрәтеннән бераз аерылып тора. Егетләр аны берничә яшь хатын белән таныштырып караганнар иде, барып чыкмады, кайсысы бу «мужикны» яратмады, кайсысын Сирай үзе өнәп бетермәде.

— Сын, апаем, Талстуй белән Женекине дә укып карамаган хатынны ничек яратаем инде мин! — ди иде Сирай дусларына.

Калхузның эшләре гөрләп барганда гына, сыер савучыларны ерак җәйләүгә йөртә торган автобус ватылды. Бисмилла белән генә йөри иде инде ул калтырча. Сирай да төзәтә алмагач, үтилгә генә чыгарып атасы моны, диделәр. Двигателен сүтеп янадан җыярга, ходовойларын яңа баштан карап чыгарга кирәк, бер айсыз автобусны сүтеп җыям димә: сөт фасылы яна, сөт яна. Пред тагын төн уртасында Сирайлар капкасын шакыды.

— Коткар, Сирай! Автобазада бер автобус бар, диделәр. Менә акча, таңнан путёвка алып юлга чык, ни кирәксә, шуны ал. Шәп булыр иде норковый бүрек алып барсаң. Менә адрес, промбаза. Аның мөдире... Алексей Матвеевич Шурыгин...

Казанына да барды Сирай, промбазаны да тапты Сирай, Шурыгинга преднның язуын күрсәтеп, норковый бүрек белән бер «Татарстан» торты да алды Сирай, шуларны күтәреп автобазага да барды, нәчәлнигенә дә керде, ләкин, инәсен корт чаксынмыни, керебеткән автобаза нәчәлниге Артемий Костров, сөйләшеп тә тормый, аны куып чыгарды.

— Сезнең район бөтен лимитен ашап бетерде инде, биш елсыз сезгә автобус тәтемәячәк, — диде мөдир.

Сирай нәүмиз булып кире чыкты, аның кыяфәте бик тә кызганыч, өметсез иде. Кая барырга инде, дип торганда, Сирайның башына даһианә бер уй килде.

«Мантыйкый фикер йөртсәк, Костров чәй эчәме? Эчә! Чәй эчә икән, аның печ итәсе килергә тиешме? Тиеш, әлбәттә! Һәм Костров, әбәзәтелни, әбрәкәйгә чыгарга тиеш!» — дип Сирай көтәргә булды.

Чиратта торучыларга күрсәтмәскәрәк тырышып тартмачыктан бүрекне алды да бәдрәфкә кереп китте. Озак көтте ул мөдирне, ниһаять, нәчәлник бәдрәфкә керде, писсуар янына килеп, бераз мыштырдады да рәхәт чигә башлады, Костровның ике кулы да буш булмаудан файдаланып, Сирай арттан килеп аның башына бүрекне кигезде дә үзе тиз генә чыгып та китте. Бераздан башына норковый бүрек киеп Костров чыкты, чыкты да Сирайга ымлап:

— Проходи! — диде.

Улан-Удэга тиешле автобусның документларын ул Сирайга тоттырып чыгарды.

Бу юлы Сирай матайсыз гына килгән иде, дус язучыларының күңелен күргәч, ул яңа автобуска утырып, кайтыр юлга чыкты. Өр-яңа автобусның исе дә җанга рәхәт бирә. Обкатка узмыйча, тизлекне арттырырга ярамый, Сирай бер җайга гына кайтып бара. Кәеф яхшы, Сирай кычкырып торып җырлый башлады. «Шофёр, син машинаң белән»нән соң «Һәй, Мөслим, инде нишлим?» янгырады.

Җырларсың да нибуч, зур җиңү, зур уныш иде бу.

Пред бөтен җыелыш алдында Сиражетдин Туктаровка мактау кәгазе белән премия тапшырды... Соңыннан клуб мөдире Хатыншак Сәхи президиумда утыручы бер кешегә күрсәтеп әйтте:

— Җәмәгать, хәдер атеистик пропаганда бүлеге мөдире иптәш Гайсин «Алла бармы, юкмы?» дигән темага даклат сүләячәк! Шаулашмыйчан гына тынлап

утырыгыд, шаулашмыйчан гына тынлап утырсагыд, Алланың бармы, юкмы, икәнен анларсыгыд! Таралышмагыд, соңыннан кансирт була.

Атеист Гайсин, кәгазьләрен кыштырдатып, мөнбәргә таба китте. Халык шаулаша-шаулаша тарала башлады.

— Тагын Алла белән авыз чайкыйлар инде! — диде кемдер.

Хатыншак Сәхи карандашы белән графин кагарга тотынды:

— Тауыш!

Шулчак Жүләр Сирай урыннан кычкырды:

— Иптәш ликтыр!

Халык, кызык буласын сизенеп, кире урынына утыра башлады, Жүләр Сирай әйтсә әйтә инде ул, диештеләр.

— Иптәш ликтыр, әйтегед әле, седнын үд тешләрегедме? — диде, мактау грамотасын төреп тоткан кулы белән сәхнә ягына төртеп.

Халык гөрләп көләргә тотынды.

— Минем лекциягә монын ни катнашы бар? — диде Гайсин.

— Юк, сед әйтегед, седнең үд тешләрегедме? — дип кабатлады Сирай.

Теләр-теләмәс кенә лектор:

— Әйе, — диде.

— Сед ничә ел атеистик темаларга ликсия укыйсыгыд? — дип сорады Сирай.

— Унбиш ел! — диде Гайсин, Сирайның кайсы якка таба борганын чамаламыйча.

Сирай тагын да кычкырыбрак әйтте:

— Ну, малай, унбиш ел чүбек чәйнәп тә тешләр исән калыр икән! — диде.

Хатыншак Сәхи күпме генә графин какса да, бүртенгәнче «тауыш» дип кычкырса да, халыкны тыеп булмый иде инде. Тәгәрә-тәгәри көләләр. Халыкны Сәхи тыя алмагач, пред торып басты:

— Шауламагыз! — дип кычкырды ул. — Башта лекторны тынлагыз, аннан сорауларыгызны бирерсез!

Халык тына төште. Гайсин тамак кырып алды, ләкин Жүләр Сирайны тыеп булмый иде инде.

Ул янә торып басты, артына борылып, кеше ишетсен дигән сыман әйтте:

— Ликтыр иптәш, әйтегед әле, Алла бармы?

— Юк! — диде лектор.

— Иптәш Гайсин, унбиш ел буена бер өдлексед булмаган Алла белән сугышу ул акыллылык галәмәте түгел! Жүләр Әбдүш белән Жүләр Сирай да Аллага тел тигермәй!

Халык айгылдап көлә, Катыншак Сәхи графин кага, күбесе клубтан чыгып китте. Предтан шүрләгәннәре генә калды.

Каушап калган лектор, үзенә ышаныр-ышанмас, сөйли башлады:

— Юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленин: «Дин — ул халык әфьюны», — дигән.

Дәһри Гайсин кәгазеннән һич аерылмыйча байтак сөйләде. Жүләр Сирай кыбырсый башлады һәм лекторны бүлдерде:

— Туктагыд әле, иптәш Гайсин! — диде ул. — Дин халык әфьюны булса да, татар халкы эчмәгән, ап-аек булган. Әле бед үскәндә генә авылда бер генә эчүче иде, анысы да бадар көнне генә. Хәдер бөтен Сарташ исерек! Сед халыктан динне тартып алдыгыд да кулына аракы тоттырдыгыд. Ат йөге, ат йөге аракы кайтартасыгыд. Эчсен халык! Халыкны әфьюн түгел,

сед Алласыдлар исерттегез! Алла каршысында җавап бирәсе булмагач, халык нәмәгә эчмәсен, апаем.

Шулай диде дә Сирай, кешеләрне аралап, чыгу ишегенә таба атлады, аңа Җүләр Әбдүш тә иярде, алар икесе бергә клубтан чыгып китте.

Шуннан соң тәртип бетте, лекторны берсе дә тыңламый иде инде. Калган халык та шаулый-шаулый, көлешә-көлешә кайтып китте, хәтта авыл үзешчәннәре концертына да калмадылар.

Сирайның район лекторына биргән сорауларын кабатлый-кабатлый, халык бу вакыйганы бик озак онытмады.

Пропагандист Гайсин төбәк мәркәзенә кайткач, Сарташ авылы кешеләре өстеннән әләк язып, райком секретарена кереп китте. Шуннан соң «Ялкын» председателен, партком секретарен чакыртып, «Халык арасында атеистик пропаганданың начар оештырылуына күрә» каты шелтә биреп кайтардылар.

Кыш кергәч, төбәк мәркәзеннән тагын бер лектор килде. Гайсин килергә тиеш булган да, ул Сарашка барудан баш тарткан:

— Сараш тилеләренә лекция укырга башыма тай типмәгән! — дигән, имеш.

Бу лектор урысча озак сөйләде, аның темасы «Среднестатистические данные уровня жизни тружеников села» иде. Унөченче елны уртача хезмәт хакы белән бүгенгесен чагыштырганда, авыл халкы баеп беткән, имеш: телевизоры да бар, матае да бар, хәтта машиналар да авылда күбәйгән икән. Калхузчының уртача эш хакы 150 сум икән, һәр ике кешенең машинасы яки матае бар ди.

Сирай урынында чыдап утыра алмады, лектор тарафына сорау ыргытты:

— Убажаемый ликтор! — диде ул. — Менә олы юл буендагы Русская Уратма авылында бер катын яшәй. Удгынчы-тудгынчы бөтен шофер шул хатынга кереп куна. Ул үд балаларының кайсы шофёрдан туганын да белмәй. Беднең авылда сиксән яшьлек ялгыд Халисә карчык та тол, аның беркеме дә юк. Если берит вашим словам, то старушка Халисә в средним тоже беләт что ли?

Халык егылды, өнсез калды, аннан көлә башлады, бу көлү генә түгел, каһкаһә шартлавы иде. Бичара Җүләр Әбдүш тә берни ишетмәгән, берни аңламаган килеш тә, халык көлгәнне күргәч, айгылдарга тотынды. Аның кыргый мәче тавышы чыгарып көлгәнен күргәч, халыкны тагын көлке шаукымы буып алды. Лектор каушауда иде, аның хәлен аңлап, хатыншак Сәхи халыкка кычкырып та карады, графинга да какты, халыкны тыеп булмый иде, Җүләр Сирай белән Җүләр Әбдүш тагын беренче булып кайтып китте, алар артыннан халык та таралды.

Бу юлы мәркәзгә Сиражетдин Туктаровның үзен чакырттылар.

— Бармаем! — диде Сирай. — Мин партиный түгел.

— Син бармасаң, мине асып куячаклар! — диде пред.

Пред бик ялынгач, китте Сирай төбәккә. Бичара райкомчылар алай иттеләр, болай иттеләр, куркытып та карадылар, мактап та бактылар, Сирай елмаеп тик утыра калды.

— Карале, апаем, — диде ул коммунист егеткә. — Син кем булдың әле ул кадәр абыенны өйрәтергә?

— Нигә син лекция вакытында клубны ташлап китеп, халыкка начар үрнәк күрсәттең? — дип кычкырды партийный егет. — Бу политическая ошибка!

— Бер мин генә чыкмадым клубтан, Әбдүш тә минем белән чыкты. Нигә аны чакыртмадыгыд?

— Әбдүш җүләр бит ул! — диде сорау алучы егет.

— Мин дә Җүләр Сирай бит! — дип, Сиражетдин рөхсәт ни сорап тормыйча, райкомнан чыгып та китте.

Шулай итеп, жәй дә узды, кыш та бетте, яз да килде.

Бу якларда боз озату көне була. Ташу кузгалыр алдыннан, боз өстенә учак ягалар. Боз кузгалгач, учаклар яна-яна әллә кайларга китеп баралар. Халык яр буена жыела, яз кояшы кыздыра, ватанына исән-сау кайткан кошлар өздереп сайрый. Бик күңелле бәйрәм ясый халык ташу вакытында. Яр өстендә дә учаклар яна, утлы күмер астында бәрәңге пешә.

Ташу кузгалганчы учакларны кабызырга дип байтак кеше боз өстенә керде, Жүләр Әбдүш тә учак ягыша, аксаклап-туксаклап, ярдан чыбык-утын ташый.

Шулчак боз чытырдый, ярыла башлады. Ташу кузгалыр вакыт житте.

— Чыгыгыз, боз китә! — дип кычкырды Сирай.

Анда-санда учаклар дөрләп кабына башлады.

Кемдер кычкырды:

— Югары тегермән буасы киткән! Ташкын килә-ә!

Барысы да яр ягына томырылды. Ташкынның шомлы гөрелтесе ерактан ук ишетелә, ләкин телсез-чукрак ишетми, ул учакка чыбык ташый. Ташкын боз кантарларын дәһшәтле тизлек белән күпергә таба куа, ярдан халык кычкыра:

— Габдулла-а!

Ташкын килеп басты дигәндә генә, Сирай итекләрен сала башлады, Габдулланың аяк астындагы бозы ярылды, ул куркырга да өлгермәде, суга егылды. Сирайның бата барган Габдулланы коткарырга ниятләгәнен аңлап, барысы да акыра:

— Сирай, йөрмә, кермә боз өстенә! — дип кычкыралар.

— Күрә торып кешене батырабызмыни? — дип кычкырды да Сирай боз өстенә атылды.

Бичара Әбдүш иләмсез тавыш белән чиный, карашында курку, ялвару: коткарыгыз, дип хәбәр салуы булгандыр инде.

Йөгереп килеп, Сирай яланкул боз кырыена ябышкан Әбдүшне тартып алып, яр тарафына ыргытты, Габдулла үрмәли-үрмәли куркынычтан ераклашты. Тик шулчак Сирай баскан боз чүмәләп китте, ташкын алдында килгән боз кантары Сирайны этеп екты, ул боз ярыгына барып төште, кантар бозваткыч кораб кебек, Сирай төшкән ярыкның өстенә менде, Сирайның кып-кызыл куллары гына күренеп алды да юкка чыкты, коточкыч ташкын субай баганаларына китереп бәрде, субай баганалары ыңгырашып янтайдылар.

Кешеләр Сирай яңадан калыкмасмы дип көтте, ләкин Сиражетдинның гәүдәсе күренмәде.

Барысы да тораташ булып каткан, берсе дә тын чыгармады, бары тик үлем тырнагыннан котылган Жүләр Әбдүш кенә, Сирай баткан якка карап, кулларын болгап, коңгырт тавыш белән үкерә иде.

— У-у, акка-бокка! Акка-бокка!

Сарташ авылы Жүләр Сиражисыз калды. Шул мизгелдә үк авыл халкы аның жүләр түгеллеген аңлады кебек. Барысы да жылый иде.

Бөтен авыл, мәет чыккан йорт кебек бушап, шомланып, сагышка батты. Колхоз, пред, халык, анасы — барысы да ятим калды.

Кичләрен, шәфәкъ баегач, Сарташ авылын шаукымга салып, Жүләр Әбдүш иләмсез аваз белән илаулый торган булып китте. Ул ташу киткән урыннарны әйләнә, бичара коткаручысын юксына. Ул тауларга менә, кайчандыр үзен сары таш баскан урыннарда озаклап йөри. Авыл өстендә аның иләмсез авазы ишетелгәләп куя. Жүләр Әбдүш ашамас-эчмәс булды. Еш кына ул Сирайлар өе каршысына килеп нидер сөйләгән шикелле мыгырданып тора. Кайгы баскан

Гөлчәһрә түти аны өенә алып кереп ашатмакчы булса да, Жүләр Әбдүш кермәде, алып чыккан ризыкларын да алмады.

— Акка-бокка! — дип үз юлы белән китеп барды.

— Алмашынды бу! — диделәр кешеләр.

Жүләр Әбдүшнең чирләгәне булмады. Өстендә кырык ямаулы бишмәт кенә булса да, ана беркайчан да салкын тимәде. Шушы хәлләрдән соң ул хәлсезләнде, ябыкты, нииндидер чир басты.

Анын үле гәүдәсен субай баганалы күпер янында таптылар. Ул нәкъ Жүләр Сирай батып үлгән турыда иде.

— Котылды, бичара! — диделәр кешеләр.

Жүләр Әбдүшне бөтен авыл гүргә иңдерде.

Иң нык жылаган кеше Гашия иде. Ул аларның икесенә дә: Әбдүшкә дә, Сирайга да атап дога кылды.

Ире Хашим хатынының жилкәсеннән кочты, алар сүзсез генә кайтып китте.

Әниләре Гөлчәһрә түти зиратка бармады. Беренчедән, йола кушмый, икенчедән, анын йөрерлек хәле юк иде. Хашим белән Гашия туп-туры төп йортка кайттылар. Күрше карчыклары кайгылы Гөлчәһрә янынннан китмәделәр анысы, ләкин олы улы белән килененең анын янында булуы бик тә мөһим иде. Гөлчирә түти бәргәләнмәде, сугылмады, хәтта ул жыламады да. Жылар өчен дә көч кирәк. Ул өстәл янында сүзсез генә утыра бирде. Анын алдында Сиражетдиннын яна сатып алган китабы ята. Ул Әмирхан Еникинең «Соңгы китап» исемле яна әсәре иде.

— Ачып карарга да өлгермәде, мәрхүм, — диде ана.

Кемдер сулкылдап көрсенде, кайсысыдыр әйтеп куйды:

— Түз, сабыр бул, Гөлчәһрәттәй! — диде.

— Юатмагыз мине! — диде хужабикә хәлсез тавыш белән. — Сиражетдиным белән Габдуллага багышлап, белгәннәрегезне укыгыз.

Өй тулы хатыннар-карчыклар булса да, тып-тын иде, ара-тирә пышылдап дога укыганнары гына ишетелеп куя.

Ишектән тын гына кереп, Хашим белән Гашия Гөлчәһрә түтинең икесе ике ягына утырды. Шул житкән хәсрәтле ана өчен.

— Ходаем, шул мәхлукны коткарырга кермәгән булса! — диде күрше хатын.

Ана жавап бирүче дә, кушылып сүз әйтүче дә булмады. Тагын тынлык урнашты.

Хужабикә, тынлыкны бозып, кайнар сулышы белән әйтте:

— Ул башкача эшли алмый иде!



Рәшит
Бәшәр

# БАШ ОЧЫМНАН ШАУЛАП ЧОР АГА

## Авылда

Яңа йорт җиткергән дус,
Күз тимәсен! Сокландым!
Печәнлегенә менеп,
Тәгәрәпләр йокладым.
Кыр чәчәкләре исе
Кытыклады борынны.
Төшемдә бер жыр суздым,
Бик моңлы жыр — борынгы.
Уяндым да сүзләрен
Төшералмый исемә
Уйланып ятам менә
Жылы авыл кичендә.
Шунсын беләм: халкымның
Бик зарлы жыры иде.
Бүгенгемә аваздаш
Замана жыры иде.
Печәнлегемә саркып
Керә йолдыз яктысы.
Керфекләремә йокы
Эленмәстер, ахрысы.
Яңа йорт җиткергән дус,
Бурычка бата-бата.
Ал кояш чыга... Бата...
Гасырлар моңы кайта.
Йолдызлы күк астында
Нигез мөнәжәт әйтә.

Рәшит БӘШӘР (1949) — *шагыйрь һәм прозаик; «Иртәгә дә яшисе бар», «Сандугачлы бишек», «Ачык капка», «Куаныч» һ.б. китаплар авторы. А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Чаллыда яши.*

## Сабый йокысы

Таҗларына кунып атынгач,
Гөл чыкларын эчте сандугач.

И дәртләнеп сайрый, чутылдый,
Сары түшкәендә нур уйный.

Моң агыла ачык ишектән,
Нур бөркелә көйле бишектән.

Чын пәһлеван булыр бер гәүдә
Мес-мес йоклый ап-ак биләүдә.

Ишетми ул һичбер шау-шуны,
Жил селкетә яшел чаршауны.

Очып килеп керде күбәләк,
Барып кунды аннан түргәрәк.

Ак күбәләк яшел чаршауда.
Тирбәлә ул сабый каршында.

Канатларын ян-янга җәеп,
Үзгә бер ямь! Тылсым! Гаҗәеп!

Сандугачлар сайрый өздереп,
Йоклый сабый тәмләп, изелеп.

Сандугачлы төшләр күрә ул:
Таң кошына оя үрә ул.

Кош мамыгы — нәни учында,
«Ән-нә» сүзе — теле очында.

Бөрештерә алсу иренен,
Хуҗасы ул татар өенең.

Моң агыла ачык ишектән,
...Кояш чыкты бүген бишектән.

## Якты кич

Аяк йөрми, күзләр күрми, ак чәчләре тузгыган,
Картаелган, үр менелгән, күпме юллар узылган.

Утыра ул, әйтерсең лә бернидә дә гаме юк,
Тездә яткан ак песиен сыйпарлык та хәле юк.

Кыштыр-кыштыр чыга әби, кулында ап-ак савыт:
— Кая киттең, сине, картым, эзләп тә булмый табып.

Савыт тулы кура җиләк, картына суза алып:
— Авызыңа тәм керер, мә, иплəп кенә куй кабып!

Кымшана да көрсенә карт, авыр итеп тын ала,
Бөршәйгән иреннәренә җиләк суы сылана.

— Керик әйдә, калтырата, нигәдер салкын елы.
— Син янымда булган чакта, миңа, карчык, бик җылы.

Ишегалдына тиз генә ак песи китә кереп,
Теркелдиләр икәүләп, шул ак песигә ияреп.

Теркелдиләр бер-берсенә: «Егылып китмә!» — дигәләп,
Әбинең ак күлмәгеннән төшеп кала тигәнәк.

Җиләк тулы ак савытта канатын җәя камка...
Әкрен генә шыгыр-шыгыр ябыла иске капка.

***

Көннәр көйсез, төннәр карангы.
Ут элдерәм кипкән чырага.
Ишетелә: үлән пышылдый,
Янәшәмдә елан ысылдый,
Баш очымнан шаулап чор ага.

***

Ай югалган кара төннәрдә
Сагынам мин көләч көннәрне.
Тайлар чапкан хәтфә болыннан
Агып килгән серле өннәрне.

Болыт баскан нурсыз көннәрдә
Сагынам мин якты төннәрне.
Иксез-чиксез галәм түреннән
Агып килгән серле өннәрне.

Жилләр шаулый. Сулар челтери.
Сагынам мин әллә кемнәрне,
Сагынам мин әллә ниләрне,
Баштан сыйпый серле жиһанның
Мәңгелектән иңгән өннәре.

## Мираж

Мин ялгызым эссе чүлдә өнсез калдым,
Телем кипте, тәмам шунда хәлсез калдым.

Баш әйләнә, күзләр тона, һава биек,
Очмый бер кош, чакмый елан, чапмый киек.

Исә дә жил, тузгыта тик кызган комны,
Ком таулары күмә бара узган юлны.

Кинәт кенә күрәм алда: балкый бер ил,
Әллә нинди шомлы бер ил, шәүлә ул гел.

Әләмсез ил, адәмсез ил — мираж бары,
Кипкән чүлдә күптән үле пейзаж бары.

Телсез ил бу, денсез ил бу — тәмам харап,
Мин туктадым, бармыйм алга, торам карап.

...Һәм уяндым. Жилләр исә. Кояш көлә.
Табигатьне яңгыр юып үткән төнлә.

Агып килә азан моны кыйбла яктан,
Хуш ис кенә аңкый монда һәр тарафтан.

Барча адәм бик бәхетле, йөзләр көләч,
Жәннәт илдә: һәммәсе тук, юктыр бер ач.

Туган телдә сөйли һәркем, юк бер ятим,
Үз-үзенә хужа һәркем, бар да хаким.

Кеше җаным, һәйбәтлән син, хушбуй сөртен...
Хыялланып үтеп китте тагын бер көн.

Көн артыннан килер, әлбәт, кап-кара төн,
Йоклар җиһан төшләр күреп... Дөнья тып-тын,

Төшләнеп җир, имәр җәйнең яшел сөтен,
Күлгә кунар учактагы аксыл төтен.

## Сагыш

Кояш нурыннан шуып,
Йөзгә куна пәрәвез.
Сары ишекне ачтык,
Янә көзгә керәбез.

Гөл сабагыннан әнә
Очты бер төклетура.
Оясыннан читтәрәк
Бер соры төлке тора.

Төрле төскә бизәлгән
Болыннан атлап калыйм,
Болынның һәр бизәген
Берәмләп ятлап калыйм.
Һәр авазны ишетеп,
Һәр төсне күреп калыйм.

Һәммәсен дә өшетеп,
Кышлар киләсен беләм.
... Ә хәзергә... Хәзергә
Уйныйм күбәләк белән.
Уйныйм күбәләк белән.

***

Тирәкләрнең иң гүзәлен генә сайлап,
Килеп кунды шунда бер кош сайрап-сайрап.
И сайрый ул, и шашына, җанны өзә,
Туктап калдым кереп барган чакта көзгә.
Нинди кош ул, исмен белмим, күргәнем юк,
Андый кошның барлыгын да белгәнем юк.
Мина ят бер серле илдән хәбәрме ул?
Очып китсә шул дөньяга әгәр дә ул,
Монсуланып калыр көнем, җаным бушар,
Син дә күккә ашарсың бит бер көн, Бәшәр.
Кошчык булып очарсың син еракларга,
Сайрап-сайрап тирбәлерсең куакларда.

Бик еракта... Бик еракта... Ерак ярда.

## Яшәү

Исәрләнеп карап торам учакларга
Күңелкәем канат кагар кош чакларда,
Җаным тыныч, күңелкәем хуш чакларда.

Учак сүнә, сүнә йолдыз офыкларда,
Күзләремдә агара да кара төнем,
Кочып ала мәшәкатьле яңа көнем.

Үз җиремдә, туфрагымда, илемдә мин,
— Һәммәгезгә хәерле көн! — димен дә мин,
Кереп китәм чираттагы көнемә мин.



Әхтәм
Зарипов

# ХАТИРӘЛӘРЕМ — ХӘЗИНӘЛӘРЕМ

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

...Гомеремнең алтмыш елын могҗиза көтеп, сәнгатькә багышлап, энтузиаст булуымны яшем сиксәнгә житкәч анладым. Хәерлегә булсын.

...Ялган тыйнаклык пәрдәсе бөркәнми әйткәндә, бик күп кирәкле эшләр эшләнгән, ниятләремнең күбесе гамәлгә ашырылган, тиешле кешесенә житкезеп барылган: яшьлектә актёр буларак, аннары радиорежиссёр, соңгы 40 елда телевидениедә режиссёр һәм сценарист буларак.

Нинди һөнәрче икәнлегемне радио-телевидение фондларында сакланып, әледән-әле эфирга үткәләгән фильм-спектакльләрне карап-тыңлап белергә була.

Иҗади хезмәтем нәтиҗәләрен көтеп алалар, яратып кабул итәләр, сагынып сөйлиләр иде. Димәк, мин теләкләренә ирешкән бәхетле иҗатчылар төркеменә дә керәмдер дип үземне юата алам. Шул юанычка таянып, үзем күргән, ишеткән, кичергән кайбер хатирәләрем белән уртаклашмакчы булам. Моның өчен сәбәпләр дә житәрлек.

...Фильм-спектакльләремне эфирга тәкъдим иткәннән соңгы тамашачылар белән очрашып сөйләшүләрдә бер үк төрле сораулар бирелер иде: «Булган хәлме бу?», «Режиссёр кем ул: актёрның тренерымы, фильмның конструкторымы?», «Ничек артист булырга?», «Укып талантка ирешеп буламы?» Мин, гадәттә, әңгәмәне уенга борырга теләп, шаярту белән җавап тан котылырга тырыша идем: «булмаганнан кино булмый ла», «режиссёр — образның бер канаты, артист — икенче канаты», «уку — талантлымы, түгелме икәнлегеңне ачыклау ул», «артист буласың килсә — юри дә артистланмаска кирәк», дигәндәй «бүре дә тук булсын, сарык та исән калсын» өчен генә җаваплар иде.

Ул чакларда «артистланмаска» дигәндә, ихтимал, ясалмалык чиренә бирешмәскә кирәк дигәнне күздә тотканмындыр. Кеше булган кешенең актёрлыгы — аның асылында булу фәлсәфәсенә кереп тормаганмындыр. Ә менә чын актёр, ягъни актёрлык һөнәрен камил үзләштергән кеше «артистланмый», ягъни уйнамый, чын актёр рольдә яши; ул вакытлыча башка кеше кабыгында яшәп ала.

Ә яшәү — озакмы, тиз арамы — ул көрәш! Иң элек үзең белән, аннары башка каршылыклар белән. (Роль, эш шартлары, мохит һ.б.)

«Яшәү — яшьнәү, яшәү — иҗат!» — дип юкка гына әйтмәгәннәр. Иҗат бар икән — анда ачыш, алгарыш, үсеш, янарыш. «Иҗат итте», дибез икән —

ижатчының яңа фикер әйтүен, яңа төсләр табуын, яңа аваз-тавыш яңгыратуын таныйбыз дигән сүз.

Хатирәләр язу, истәлекләр барлау ижатмы? «Ижат» дияргә — ижатта хыял-фантазия төпкә жигелгән ат: ул кая тартса — мичәү аты шунда. Хыялсыз ижат булмый, ижат хыялсыз булмый. Бу — аксиомадыр, мөгаен.

...Әрсезләнеп димме, кыюлыгым житеп димме, соңлаган бу язмаларым «Ничек артист булырга?» дигән сорауга җавап рәвешендә яңгыраса, мин бик шат булачакмын.

...Гомерен ижатка багышлаган кешенең, әгәр ул ниятләрен гамәлгә ашыра алган икән, һәркайсының үз юлы, үз алымы, үз мәктәбе. Ул мәктәпне тормыш, диләр. Дәресләре? Тормыш нинди сынаулар куйса, шулар шәхеснең максатларына ирешү юлындагы сабак-дәресләре. Алар минем санап бетергесез күп. Күпчелеген хәтерләп бетерү дә мөмкин түгел. Хәтердә сакланганнары бәлки, кемнедер «шаккатырырдай» тәэсирле дә түгелдер. Ләкин алар булган хәлләр һәм шулар жыенысы бергә миннән мине ясаганлыгы белән кыйммәтле.

Хыял катнаштырмый истә калганнар нигезендә генә язылган хатирәләрне, «иссез», «төссез», «тәмсез» булып чыксалар — «болар ижат җимеше түгел ич», дип акланып буламы? Юк — булмый! Чөнки кеше — үзе ижат җимеше. Аны замана, кануннар, йолалар, гореф-гадәтләр, дуслары-дошманнары ижат иткән. Пародокслар җыелмасы килеп чыгар дип уйламаганнар. Уйламасалар да, нәтиҗәсе шул: кеше — пародокслар җыентыгы.

Моның шулай икәнен кешенең үзе белмәгәненә башка кешене өйрәтергә омтылуы гадәтеннән дә сизәргә була.

Бер мәшһүр инглиз язучысының (русчага да тәрҗемә ителгән) «Стремление человека к своей некомпетентности» дигән китабында ышандырырлык исбатлана бу фикер.

Кеше заты имчәк сорап елаган беренче авазыннан үлем хәлендәге соңгы авазына кадәр уйнарга мәҗбүр. Гомере буе уйный кеше шулай, «артистлана». Имиджсыз, ниндидер битлексез кеше юктыр дөньяда.

Ә ни өчен соң кеше үзенең чын йөзен яшерергә мәҗбүр?

...Бу — аның тормыш — яшәү шартларына яраклашу әмәле.

Үзеннән кача-кача, үзеннән яраклаша-яраклаша, кеше тереклек дөньясының таҗына ия булган. Ул күтәрелмәс биеклек, ул төшмәс түбәнлек, ул ирешмәс максат юк дөньяда.

Әнә шундый капма-каршылыклар — пародокслар тупламасы инде без — адәми зат — кешеләр.

Шушы — үзем тулысынча аңламаганны башкаларга аңлатырга тырышып язуым да («Стремление к некомпетентности») пародокс түгелме?

«Кеше ышанмас сүзне чын булса да сөйләмә», — дисәләр дә, мин сөйләргә булдым. Хәер, мондый хата гамәлне мин генә кыламмыни?! Күпләр!

...Кайбер кешеләрдән ишеткәнем бар: имеш, алар үзләре турында ана карынында чакларыннан ук беләләр.

Кайберәүләр: «Тәпи йөри башлаганнан алып барысын хәтерлим», — ди. Ай-һай, шулаймы икән? Мин андый «хәтерлелек» белән мактана алмыйм. Күп аерым фактлар бер-берләренә ялганып искә төшәләр, кайберләренең елларын хәтерләү мөмкин түгел: картлык. Хәзинәдә ни бар — табынга шул куелыр, гаепләштән булмасын.

...Мин үземне 6 яшьлек чагымнан күз алдыма китерәм.

...Әнкәй сөйләве буенча, 1941 елның 22 июнь киче була ул. Уртанчы абыемнан башкалар ындыр күле буендагы кыяр, кабак түтәлләренә су сибә. Тирес өеме өстендәге түтәлгә сулы чиләк менгезәм дип тәеп егылганмын. Суны

кызганудан бигрәк, сыер тизәгенә таеп егылудан өстемнен нык пычрануы өчендер — әнкәйнең тиргәве хәтердә. Аның ачулануын өй кутәрмәсеннән карап, күзәтеп утырган әткәйне, каз оясындагы киез өстенә утырган 5 айлык сеңлемнең үкереп елый башлавын, «үкертмәгез шул баланы!» дип әткәйнең картыйга жикеренүен, шуның белән игътибарның миннән картыйга күчүен хәтерлим. (Күрәсең, килен — каенанай мөгамәлә кискен чак булган).

...Шул арада урамнан чапкын кычкырып узуы колагымда: «Немец сугыш башлаган!»

...Әткәйнең кулындагы сулы чиләген «дөп» иттереп жиргә ташлавын, әнкәйнең аңа таба баруын, картыйның елаудан туктамаган сеңлемне кулына алуын һәм «мәгез баланы», дип кычкыруын оныта алмыйм. «Мәгез!» — дигәне кемгә юнәлгән булгандыр — әткәйнең дә, әнкәйнең дә: «Елатасың килмәсә чирләтмәскә идең, үзең гаепле, өшкер баланы!» — дип картыйга ташланулары истә калган.

Минем ул вакыттагы аңлавымча, немецның сугыш башлавы — шул бала елау аркасында, ә аңа картый гына гаепле, имеш.

...1941 елның 22 июнь киче...

Кош тоткандай шатланып, кулына «Вараксин» гармуны тоткан кече абзый кайтып керә. «Ишеттегезме?» — ди. Тырма сабына төртелеп сынар күзен чыгарган олы абыем: «Нигә аңа шатланасың?» — ди. «Кайгырырга сәбәп юк: син сукыр, мин әле яшь, әткәй карт!» — ди кече абый. «Картайтырмын мин сине, биләмче! — ди әткәй, кече абзыйга кизәнеп, — ташла шул гармуныңны!» «Сиңа тимәсәләр, атаңның яше чыкмаган ич әле», — ди әнкәй, сеңелне кулына алып.

Сеңел елаудан туктый, арбага утырып әткәй елый башлый. Барыбыз да аның янына киләбез. Чөнки әткәйнең елаганын күргән юк.

— Елама, әткәй, синең өчен мин китәрмен, бер өйдән ике кешене алмаслар, — ди кече абзый.

— Авызыңнан жил алсын! Синең яшь житкәнче сузылыр дисеңме сугышны... Хәзерге корал белән раз-два вәссәлам... Ә менә мине... алачаклар...

— 46 яшең тулган булсадамы?

...Башта сынар күзле абыйны алдылар, Свердловск өлкәсенә, торф чыгарырга, диделәр. Әткәй, ниндидер «тазадегет» дигән дару эчеп, ашказанын боздырды да Андреевка участок больницасына кереп ятты, шунда күзенә трахома да йоктырды.

Кайгырасы урында әткәйнең шатланып йөргәне хәтердә: «Ике чир белән алмыйлар!» — янәсе. Алдылар! «Трудармия» дигәненә. (Китап битен ертып язылган справкасы миндә әле дә саклана: «Не годный для строевой службы», дигән). Чират кече абзыйга да житте...

...1925 елгы ул. Абыемның гармун уйнап, бик оста биегәне хәтердә. «Избач» булып эшли, диләр иде. Нинди эш булганлыгын белмим, әмма клуб ачкычы абыйда иде. Һәр кич шунда «вечер» ясыйлар, без — балаларны кертмиләр иде.

...Кече абый сугышка киткәнче 1941 елның көзендә, урак эшләре тәгәлләнүгә, безнең авылны гына түгел, бөтен районны шаккатырган вакыйга була: күрше Теләкәй авылы сельмагында күптәннән сатылмый яткан баянны Тәжәй авылының Исмәгъдам улы Әүдах ала икән, дигән хәбәр тарала. Ике сыер хакына!

...Яшәү белән үлем көрәшкәндә, «труддень»га тигән барлык икмәкне ике «бричка»га төяп, Груздевка заготзерносына тапшыралар да, кәпитәнсәсен баянга алыштырып, Зариповлар гаиләсе сыерсыз кала! (Шуннан соң абыйның Дүртөйле, Илеш колхоз-совхоз театрларында эшләп йөргәне хәтердә). Хәзергечә

әйткәндә, сенсация гына булмый бу хәбәр, ә бөтен авылны «шок» хәлендә калдыра. Күпләр ышанмый, ышанганнар «авызынны ачсаң, үпкәң күренергә торганда, шундый кыйммәтле гармун алып, «әртистләнеп» йөрү — ким дигәндә ахмаклык», дип, больнистә яткан әткәйне сүгәләр, «җебегән», дип әнкәйне, «беспутный», дип абыйны гаеплиләр.

Дөресен әйткәндә, ул баянны нинди максатлардан чыгып алуларына мин бүген дә җавап таба алмыйм: өйлек дип китерелгән 40 данә усак бүрәнә урамда череп ята, әткәйнең трудармиягә китәргә хәбәр көтеп, кат-кат комиссия узып дәваланып яткан чагы. Абыйның үзенең дә кыл өстендә генә колга уйнатуы: кыш булмаса, җәй «Хуш, авылым» көе уйналачагын фронттан килгән хәбәрләр раслап торганнардыр дип уйлыйм.

Кыскасы, «кулак» дигән кушаматыбызга «дурак» дигәнен өстәргә авылдашларга сәбәпнең саллысы табыла. «Ыштансыз күткә каеш бау» — безнең кебекләргә атап әйтелмәдеме икән?!

...Ике мәртәбә «раскулачиваться» ителеп сатылганнан соң яшәп яткан йортыбыз да «саманный кирпечтән» салынган балчык өй генә. Тирә-юнь авылларда бүтән андый йорт булмагандыр, күрәсең, урамнан тегермәнгә узучылар, тукталып, өебезгә карап «тел чертләтеп» торуларын мин әле дә яхшы хәтерлим.

Тагын шунысы истә: баянлы булып, ике-өч ай узуга, абыебыз шул балчык өйгә килен төшерү мәсьәләсен кабыргасы белән куя. Бу хәбәр авыл өчен чираттагы сенсация гына түгел — Базы елгасы төбенә кадәр туңып, тегермәнебез туктауны да оныттырган ахырзаман сигналы буларак кабул ителә.

«Юньлегә түгел бу», — диләр. Фронттан килгән хәсрәтле хәбәрләр икенчел планга күчә, чишмәгә суга төшкән хатын-кыз сөйләшә икән:

— Йосыфка Зөләйханы үбү дә насыйп булмаган, диләр. Ә боларның менә-менә...

— Аерым очрашканнары да сизелмәде, хәтта...

— Аны кем сиздереп эшли? Казлар гына кушылганчы ук дөнья бетереп кангылдашалар....

...Өйдә әнкәй сукрана:

— Табынга куярга бер калҗа итең, чәйгә сөтең булмаганда, алты кеше бер сәкегә көчкә сыешып, бер толыпны тарткалаганда, жиденче кашыкмы? Уф, Ходаем, сабырлык бир колыңа...

— Безнең икебезгә бер кашык житә. Ябынырга картыйның туны бар, барыбер кияргә ярамый.

— Кем соң ул килен дигәнең?

— Кәшифә!

— Күзгегә кара: мыек та чыкмаган үзенә!

— Йолыкканга!

— 16 яшендә өйләнгән кеше нәселебездә түгел, авылыбызда юк. Оныт!

— Булмаса булыр!

...Китәргә повесткасы кесәсендә булып, трахомадан күзен дәвалаган атлы булып больницада яткан әткәй әнкәйгә әллә уйнап, әллә уйлап язу язган, имеш: «Гармун уйнап туенсалар, ясасыннар кызыл туй! Ике тавык чалдырырсын да Миннеханны чакыртып никах укытырсың. Бездән бүләк шул булыр!» (Миннехан авылның тома сукыр мулласы).

...Пожаркада соңгы хәбәрләр белән уртаклашучы карт-коры, хәрби хезмәткә яраксыз гарип-гораба «фатиханы» үзенчә бирә икән:

— Ике тавыклык туй буламы?!

— Әүдах Кәшифәгә өйләнә, имеш.

— Кәшифә Әүдахка булмаса?

— Кәшифәсе сиклитар, Әүдахы артист булып качып калмакчыдыр сугыштан.

— Качарсың гыйфриттән... Жир астындагыны да күрә алар.

— Кәшифәсе көмәнледер, шуңа ашыгалардыр...

— Бала гына ич алар!..

— Баладан да бала туар замана килде, абзый.

— Алла сакласын!!!

...Балчык өйгә килен төшкәч, гайбәтләр тына. Сүз бетә. Хәсрәт арта. Киленле-жиңгәчәйле булу шатлыгын әткәйне озату хәсрәте томалый.

...Ерак жибәрмәсәләр дә, теләгән чакта очрашып күрешүләрдән мәхрүм ителгәч, әтисез яшәүнең тулы программасын үтәгәнбездер дип беләм. Авыр булды безгә. Аталары фронтта, хәрәкәттәге армиядә булган балаларга пособие бирелә, бушлай ашатулар оештырыла. Ә безгә — трудармияче балаларына андый ташлама-хәйрия бүләкләре юк. Шуңа өстәп безгә кимсетеп караулар, саңга санамаулар...

...Өйләнешүләренә тугыз ай дигәндә, ниһаять, кече абыйны да озатабыз... Аерылышуларын, язмышка буйсынгандай, «ах-ух» килмичә, тиешле бер мәжбүри йола үтәгәндәй кабул иттеләр алар. Тын гына күлмәк-ыштан алыштырганда, абыйның өстеннән салган күлмәкләрен кысып тотып, битенә куеп торганы күз алдымда. Бәхилләшүе шулай булгандыр, мәрхүмнең. Гадәттә, армиягә китүчеләр жырлар-елап атка утыргач, урам әйләнәләр иде. Ә безнең абыйлар кеше күрмәсен, кеше ишетмәсен дигәндәй, тавыш-тынсыз гына урамнарны әйләнделәр дә пароход пристаненә юнәлделәр. Абый миңа карап: «Баянны ватма, өйрәнергә тырыш, кайткач тикшерермен», — дип кычкырды... Әнкәй дә аларны озата китте. Авыл бушап, тынып калды. Ул көнне уеннарыбыз уен булмады, кулларыбыз әнкәйләр кушып калдырган эшкә бармады. Көн дә көтү каршылый торган идек. Бу көнне көтү киткәнне дә, кайтканын да хәтерләмим. Урамда адашкан бәрәннәр бәэлдәвен, савылмаган сыерларның бозауларын кинәнгәнче имезүләрен хәтерлим. Беркемнең беркемдә эше юк. Авыл жир тетрәгәч бушап калгандай боек, ямансу, караңгы...

...Әнкәйнең (кич кайткач) мине кочаклап елаганын хәтерлим. Авызында гел бер сүз иде: «Үтерергә алып киттеләр газиземне. Пароход киткән арада тиз генә бөрлегән жыеп чыгарга әрәмәгә кергән идем, шуны авыз иттереп бәхилләшергә дә өлгермәдем, алып киттеләр бәгъремне...» Шушы сүзләрне ул үзе үлгәнче һәркемгә сөйләр иде дә тавышсыз гына елар иде...

Абый эшләгән яки ясый башлаган һәрнәрсәне бик кадерләп, озак саклады ул. Әгәр без аларга тия башласак, үпкәләп елый иде.

Абыйның столярный станок итеп ясый башлаган такта эскәмиясе бар иде. Ул аны белеп, аңлап та ясамаган. Әмма әнкәй өчен ул бер шедевр иде. Шуны ул мунча алдында кар-яңгыр тидермичә озак саклады.

Аннары кече абыйның «Алкино» дигән жирдән салган бердәнбер хатын күкрәкчәсендә йөртеп саклавы игътибарга лаек.

«Менә — числосына карагыз, аларны әзерлексез-нисез, килгән көнендә үк сугышка кертәләр, шул көндә аның жанын кыркыйлар, немецлар түгел — үзебезнекеләр — явызлар», — дип өзгәләнә иде.

«1943 елның февралендә ярадан үлде», дигән хәбәрен почтальон мәктәптә үземә бирде. Укуны ташлап (заем откандай!) кайтарып бирдем похоронканы. Мине күрүче дә, ишетүче дә булмады. Кара хәбәрне өйдәгеләр инде ишеткән, елый-елый күзләрендәге яшь кипкән, әйтер сүзләре беткән иде.

Ара-тирә әнкәйнең «ичмасам баласы да калмады», «үләрен белеп киткәндер», дигән сүзләрен генә аңлап була иде.



*«Тукай» спектакленнән (Ә.Фәйзи) күренеш. Сулдан уңга: Тукай – Ибраһим Гафуров, Г.Камал – Нәҗип Гайнуллин. 1939 ел.*

Ә җиңгәчәй «бәлки исәндер», дигән өмет белән абыйның «үлде» хәбәрен алганнан соң да тугыз ай бездә яшәде. Кабат тикшертеп, хәбәрнең чынлыгы раслангач кына, үз әнисенә күчеп китте.

Балчык өйдә баян саклап Рәмүзә апам, 2 яшьлек сеңлем Дания, әнкәй, әткәйнең әнкәсе — 86 яшьлек сукырайган картый һәм 8 яшьлек мин генә торып калдык. Абыйның үлеме турында әткәйгә хатны миннән яздырдылар.

...Мәктәптән кайтуга өйдә көтеп торган эшләрнең иң яратмаганы, картый янына утырып, йон язышу булса, яратканы — баянның батып кала торган телләрен ремонтлыйм дип, аны сүтү, актарыну һәм янадан җыю. Күпчакта кайбер детальләре сыймый артып калса да, тора-бара җитми башладылар. Ниндидер пружинасы җитмәүдән басмыйча да кычкырып йөдәткән телләрнең тын чыга торган тишекләренә чүпрәк, мамык тыгарга өйрәндем. Гаҗәп алгарыш иде бу. Әткәйгә хат язганда, иң элек «баянны үзем төзәтеп уйный башладым», дип яза идем. Дәрес әзерләү, китап уку дигән мәшәкатьләр, хәзерге кебек, безнең чорда да булмады. Укытучыбыз авылга каяндыр килгән югары белемле Әсраров Мөбарәк дигән агрономның марҗа бичәсе Шура апа иде. Сугыш алдыннан гына килеп урнашканлыктан, Шура апа татарчаны юньләп белми, шуңа күрәдер, дәрес вакытында без теләсә нәрсә сөйләшеп утыра идек. Ул русча тирги, татарча сөйләшүне безгә калдыра. Ягъни укытуы дәреслек китабын укытуга кайтып кала. Бер үк теманы өчәр кат укытканнан соң, күп сөйләнеп утырган укучыдан эчтәлеген сөйләтә дә тагын укучыларга мөрәҗәгать итә: «Ну, как он рассказал — дуресме, тюгелме?» — ди. Без, әлбәттә, бер-беребезне сатмый идек: «Дурес», — дип акыра идек. Бер тавыштан җитмеш бала кычкыруга Шура апа ничек түзгәндер — безгә шул кычкыруыбыз кызык иде.

Хәтеремдә юк: укытучылар җитмәүдәнме, җылы бүлмәләр булмагангамы — 1 нче белән 3 нче сыйныф бер бүлмәдә, 2 нче белән 4 нче сыйныф икенче бер бүлмәдә утыра идек. Шулай укыганга без шундый «гыйлемияләре» булып чыкканбыздыр да инде. Тапкырлау таблицасын мин җиденчедә генә яттан белә башладым.

Яшьтәшләр белән сирәк булса да очрашканда, Шура апаны сагынып искә алабыз. Ничек түзгән ул? Ире сугышта, үзенең 4 баласы бар, өстендә җиенкышын бер соры шинель, аягында ирләр итеге. Туганнары да, дуслары да юк. ...Без 1935 елда туган малайлар гына да 35 бала идек! Параллель класста ничәү булганнардыр — хәтерләмим. Һәрхәлдә дүрт сыйныфка 100 укучы булгандыр.

Мәктәптән котылып, өйгә кайткач, бердәнбер файдалы эш (шул баянның каешын муенга асып) — «Әпипә» көен чыгарырга тырышу. Бу юаныч әнкәйнең: «Җәфалама абыеңны!», — дигән әмере белән туктала иде. (Абый түгел — мин җәфаланам).

Мал-туарыбыз булмагач, ничек көн итүебез, ничек яшәвебез турында төгәл генә яза алмыйм. Шунысы гына истә: гел ашыйсы килә иде.

Әнкәй, әткәй кәсебен дәвам итеп, авылдашларга үзләре биргән хакка (катык-сөт, он, утын, керәчин) киез итек (бездә аны «пима», диләр) баса башлады. 14 яшендәге апабыз мунчада йон тетә. Өйдә ярамый — «чертләгән» җәя тавышы, урамга ишетелеп, силсәвит кешеләре «сәвиткә каршы эш эшләп» ятуны фаш итәчәкләр. Шуңа күрә пима басу «җинаяте» кеше ятып беткәч, керәчин лампалары сүндерелеп, сукыр лампаларга күчкәч кенә эшләнә иде. Конспирация, янәсе!

Әйтеп узганымча, без 86 яшьлек авыру карчык җитәкчелегендә йонга «первичный обработка ясыйбыз», ягъни, тетүгә әзерләп, тигәнәкләрдән, пычранып каткан төеннәреннән аерабыз. (Чынында, картыйга комачаулап утырабыз.) Шушы шөгылебез «беренчел эшкәртү» дип атала. Ягъни «йон язу» була. Язылган йонның сыйфаты өчен сукыр картый җаваплы. Әйбәт чыкса — сүз юк. Әгәр инде төерләр калган булса — ачуланалар. Шул тавышка елый башлаган сеңлебез мин баян акырта башласам гына тына. Бу ярдәмем өчен картый хәергә бирелгән сап-сары шикәр кисәген түшәге астыннан алыр иде дә, чыра пычагы белән учында гына китеп, «нәм-нәм» каптырыр иде. Ничектер, ул чактагы шикәр татлырак булып, тәме «тел төбендә» әле дә саклана сыман. Әллә ачыдан да ачы тормыш фонында шулай тоелды гынамы икән?

Язылган йон кәрҗиненә капчыктагы язылмаган йонны өстәп, эшне тизрәк бетерү хәйләмне сизенсә, картыйның сары шикәре миңа тәтер идеме икән?

Тәтер иде дип уйлыйм. Чөнки, картый миңа ышана гына түгел, тиешсезгә ярата да, яклый да иде.

...Минем хәзерге аңлавымча, ул дөньялыкта үз өлешенә тигән газапларны ничектер курыкмыйча, рәнҗеми-сукранмыйча мәгърур кабул иткән, ахирәткә гөнаһларыннан арынып күчәм, дип инанган әүлия кортка иде. (Хатирәләрем дога булып ирешсен аңа.)

Шул рәвешле «яшәп», мин һаман «Шахта» көе белән «Әпипә»дән уза алмыйм. Әнкәй: «Абыең көен өйрән!» — дип, «Сагыну» белән «Кошлар кебек»не таләп иткәндә, аклану өчен мин баянның басмаган килеш кычкыручы телләрен гаеплим; хикмәтнең телләрдә түгел — кулларда булуын әлегә үзем дә белмим, белсәм дә сиздермәс идем.

Бу хәл әткәй трудармиядән котылып кайтканчы, ягъни 1944 елның язына кадәр сакланды. Әмма әткәй кайтуга, «Әпипә»сез дә биергә мәҗбүр иде: өй җимерек, ачлык өстенә илдә кан чире, утыртырга бәрәңге орлыгы юк. Булган байлык — абыйдан калган шул баян шәүләсе. Сатыйм дисәң — аны алучы табылуга өмет юк. Әткәй белән әнкәй ике сыер хакы түләп алган баянны бер бозауга алыштыру ихтималы турында гәпләшәләр. Әнкәй: «Мәрхүм улымның төсе», — дип каршы килсә, әткәй мине гаепли, баяннан ничек тә котылырга кирәклекне тәкрарлый:

— Өйрәнмәгәч, ник кирәге бар ул хәерче күрегенең?

— Өйрәнер әле!

— Өйрәнсә? Аннан ни файда?

— Файдадамы хикмәт?

— Хикмәт — икмәктә! Исән калырга кирәк!

...Йөри торгач, таба әткәй алучыларны. Җәй үтеп, ниһаять, карлар явып, күрше Кужбахты авылының Гата белән Вара атлы гармунчылары тана бозауны түбәсез абзарның баганасына китереп бәйләгәч, «теләгәндә барып уйнарга каршы килмәү шартында» әнкәйнең дә күңеле сына. Яшьсез-тавышсыз гына елый-елый котылабыз баяннан.

...Инде телдән дә калып, урыныннан тора алмаган картый бердәнбер көнне өйдәге шомлы тынлыкны боза:

— Әүдах кая китте соң? Нигә гармунын уйнамый? — ди, кинәт теле ачылып.

Өйдәгеләрнең һәммәсе аптырашып, бер-берләренә карый: саташамы, әллә мыскыл итәме? Картыйга җавап бирү миссиясе әткәйгә йөкләнә:

— Әүдахың үлгәнгә ел тула инде...

— Нигә аны миңа әйтми гөнаһлы булдыгыз?

Шулай ди дә картый ябынган тунын өстеннән шудырып төшерә һәм тынып кала.

— Нинди гөнаһ? — ди әнкәй, әткәйгә карап.

— Нинди гөнаһ? — дип кабатлый әткәй картыйга.

Ничә кабатланса да, картыебыз, «теге дөньяга» киткәнлектән, дәшми, селкенми. ...Өйдә озын-озакка сузылган тынлык урнаша...

...Картыйны җирләгәч, иркенәеп калгандай тоелган мәгарәбездә нәрсәгә тотынсаң, шул — йә картыйны, йә абыйны хәтерләтә. Елауны әнкәй башлый да үзе үк мәрхүмнәр рухына дога кылып тәмамлый. Аңа кушылып без дә, «әппәр» иткән булып, бит сыйпыйбыз...

...Баштагы мәлләрдә әнкәй баян торган урынга бүтән әйбер куйдырмыйча, аның «эзен» саклаcа, сонрак әткәй дә күрше Кужбахты авылына барып, баянның хәлен белеп, аны тыңлап кайтырга кысташтыра башлады. Янәсе, «буявы шул килеш саклангнмы, ремонтлатканмы, әллә бездән киткән көенчә җәфалыйлармы мескенне»?

Авылларыбыз арасы ерак түгел, зират кына аерып тора, яңа ел каникулларына чыккач киттем, ерактан гына булса да, баянымны күрергә, күрә алмасам, тавышын ишетергә.

Бәхетемә, Кужбахты авылы клубында «вечер» бара иде, минем баянда уйныйлар! Клуб эче тузан, тәмәке төтене һәм суык томан белән тулы. Шулай булуга карамастан, үкертә бозау хуҗасы баянымны: эченә төтен, тузан, суык тула дип саклау юк. Әллә нинди мин ишетмәгән «кәркәбияк» көенә котыралар кужбахтылылар. Баян төзәтелгән, буявы янартылган, ахры: ялтырап-ялтырап куя. Биючеләрнең йөзләрендә сагыш булса да, аяклары көйгә тәңгәл баса, хәрәкәтләре бердәм һәм нининдер мәгънә аңлаткан кебек. Аларны тылсымлангандай карап, тыңлап торганда, үземчә карар кылдым: мин дә шулай уйнатырга, шулай биетергә тиешмен! Әмма аның өчен баян кире кайтырга тиеш!

...Ничек кайтканымны хәтерләмим. Бөтен игътибарым баянны ничек җәфалауларын тәэсирлерәк тасвирлауга юнәлгән иде. Теләгемә ирештем бугай: үзем дә еладым, әнкәйне дә елаттым.

— Ир булсаң, иртәгә үк барып әйт: без ана мәрхүм улыбызны, мәрхүм улыбыз истәлеген мәсхәрә итсенгә бирмәдек! — диде әнкәй, күзләреннән очкын чәчеп.

— Кеше малында безнең ни эшебез бар? — дип каршы килеп маташса да, әткәйнең 180 градуска борылганлыгын сизеп була иде.

Нәтиҗәдә ике арада катлаулы сөйләшүләр башлана. Таң атуга, әткәй Кужбахтыга китеп, төш житкәндә генә кайта. Әлегә баянсыз кайтса да, барган саен «яктырыбрак» кайта. Апрель житеп, көтүләр чыгар алдыннан, бозауны баянга алыштыру шартнамәсе төзелә, силсәвит пичәте басыла, пүнәтәйләр алдында баян кире кайтарыла, бозау да үз анасы көтүенә озатыла.

Бу урында «эш башланды», дип язарга кирәктер. Чөнки, баянда уйнарга мин шушы бозау «операциясеннән» соң гына өйрәнә башладым.

Мал азыгы өчен тотылган тагын бер баян алырлык чыгымнар бәрабәренә кире кайтарылган иске баянны ничегрәк уйнасаң ,әткәй-әнкәйнең тынычлык

табу ихтималын сизенгәнмендер, ахры — «Сагыну» көен дә «Әпипә»не түзәрлек өйрәндем.

...Тик шунысын тану кирәктер: «кунак сыенда» кышлап, җәйгә чыккач бозаулаган тана сыерның хуҗасы Вара абзыйны (ничек кенә тырышсам да) уздыра алмадым. Кечкенәдән баянның каешын муенга асып өйрәнүдән минем уң кулым гына «эшли», сул кул көй чыгаруда катнашмый иде. Шуңа күрә көйләр гармониясез, мелодиядә генә яңгырый. Бу исә бию көйләрен бөтенләй юкка чыгара, темпо-ритмсыз бию көе була алмый бит. Мин бию көе уйнаганда, клубта кемнәрдер кул чабып торырга яки урындык төбенә суккалап утырырга тиеш булалар иде.

...Авылыбызда Наип исемле тумыштан сукыр яшьтәшемә әтисе каяндыр трофей аккордеон алып биргән. «Вечер»ларда икебезне бергә утыртып уйнату гадәткә кергән иде. Мин мелодияне түзәрлек уйнасам, Наип исә басны «такылдата».

Әгәр клубка мин килеп җиткәнче уйнарга кыстасалар, Наип әйтә икән: «Ашыкмагыз, Әхтәм килеп житсен, аннары күз күрер».

Сукыр Наип күрерлек, чукрак Мәсәй ишетерлек уйнагач, музыкабыз түзмәслек булмаган, күрәсең. Елаттык та, җырлатып биеттек тә авылны. «Башмагым» спектакле белән олимпиадаларда беренчелекне алдык хәтта.

...Күп еллардан соң театрда артист булып эшли башлагач, яшьлегемне сагынып, кулыма баян алганда, мәшһүр баянистыбыз Рәис абый Сафиуллин уйнавымны тыңлап-карап торыр иде дә: «Җәмәгать, күрегез, махсус өйрәтсәң дә телләргә шулай җәйсез һәм ялгыш басу мөмкин түгел. Ә ул баса һәм... көе дә, ни гаҗәп, чын көйгә охшый! Пальцовка түгел, фальшовка ич бу», — дия иде. Урыны оҗмахта булсын, ихлас сүзенә рәхмәт. Останың бу бәһасенә мин хурланмый да, үртәлми дә идем.

...16 яшендә өйләнеп, 18 яшендә һәлак булган абыемны күз алдыма китерергә тырышам: ул ни әйтер иде икән? Мөгаен, ул да канәгать булмас иде. Без шундыйрак буын булдык: телләргә үзебезчә басып, үзебезнең көйгә биеттек. Ә менә безнең оныклар нәрсә уйнарлар?! Ничек биетерләр? Бүген аерым бүлмәдә ике баяным утыра. Ник шуларның берсен оныкларның берәрсе тотып карасын! Телләренә ялгыш-җәйсез басып булса да дүрт оныкның берәрсе «Әпипә»не уйнаса, абыемның рухы тынычланыр иде кебек. Бар белгәннәре — компьютер, уен, интернет, кино. Соңгы вакытларда абый, ачуланып, ике тапкыр төшкә керде: имеш, мин немец баянында уйныйм, сукыр Наип барабан сугып утыра. Абыйның кулында мылтык, шуның белән дирижёрлык итә, имеш. Кинәт уендагы фальшны сизеп, уң кулының ике бармагын өскә күтәрә. Без, уйнаудан туктап, «икеле» куйдырырга аңа «зачётка»ны бирәбез, абый юкка чыга. Өскә күтәрелгән ике бармак нәрсәне аңлатуны Наиптән сорыйм, ике бармак латинча «V» хәрефен хәтерләтә бит, дим. Әллә, «җиңдегез», дип әйтүе булдымы, дим. Наип көлә, күрмәгәч, аңа ни күрсәтсәң дә барыбер бит! Икенче төнне кабат шул төш, шул ук җиңү тамгасы. Кемнең нәрсәне җиңүе? Әллә инде яшәү ул — җиңү тандемы дигәнне аңлатырга тырышуымы? Алай дисәң, яшәү — җиңү белән җиңелүләрдән генә тормый бит...

Җавап нинди генә булмасын, абый калдырган баян мине олы сәнгать юлына чыгарды. Озын юл ул. Шул баяннан башланган тормыш сабакларын тагын кайда һәм ничек алып булыр иде икән?!

Әткәй белән әнкәй яшьли гомере өзелгән улларына булган мәхәббәтне дә, ышаныч-өметләрен дә миңа багладылар, миңа булыштылар. Үзем аларга аз гына да ярдәм күрсәтергә өлгерә алмый калдым — мәрхүм булдылар...

...Хисләргә бирелеп, читкә китеп барам, ахры...

Баянны кире кайтару тарихында тукталган идек. Бу 1945 елның язы иде бит, Җиңү язы!..

...Җиңү көнен ничек уздыруны хәтерлим. Карлы-яңгырлы көн иде. Урамнардан узарлык түгел — пычрак. Шулай булуга карамастан, мәктәп җитәкчесе Салиха апа укучыларны демонстрациягә чыгуны оештыра. Флаглар тотып, барабаннар кагып.

Мине баян тоттырып бәләкәй арбага утырталар. 4-5 малай арба тартып алдан барырга тиеш, мин уйнарга, калганнар кушылып җырларга тиеш. Көен һәркем белә, сүзләре:

Алга, дибез, алга, дибез,
Алга таба барабыз.
Алга барырларга кушкан
Безгә Ленин бабабыз...

Бик таныш көй булса да, уйный гына алмыйм бит, каһәрең... Ахырда, баянның каешын арба төбенә эләктереп, үзебез генә җырлап йөрдек...

...Кич җитеп, халык клубка җыелгач, Салиха апа: «Демонстрациядә мәрхүм Әүдахның баяны катнашты», — дип сөйләде.

Әлбәттә, бу факт әнкәй белән әткәйгә еларга тагы бер сәбәп өстәде. Еларга гына түгел — мактанырга! Әйтерсең, баян да сугыштан җиңеп кайткан иде!..

Җиңү елы безгә күзгә күренерлек үзгәрешләр дә китерде. Өйне яңарту хәстәренә керештек. Үрчетергә дип бер сарык алдык. Иң әһәмиятлесе — әткәй кайтып эшкә керде. Акчалы эшкә. Хәзер ул Агыйдел пароходчылыгының Исмаил участогында 119 нчы бакен посты хезмәткәре — маякчы! Аена бер мәртәбә ярма, он, шикәр, керәчин бирәләр.

Идел буендагы бакен йортында кунып ятарга кирәк булса да, моңа бик шатландык. Бигрәк тә әнкәй шат. Хезмәт хакы алудан гына түгел, хуҗалык әсбаплары эшләп, кәсеп итәргә, балык тотарга була, дип сөйләнүләре хәтеремдә сакланган. Чынлап та, ул җәй балыкка кинәндек, тирә-як авылларны әткәй ясаган бәләкәй арба «басты».

...Бакенщик малае булгач, абыйлардан калган иске-москыдан үзгәртеп тегелгән кием белән йөрү килешмәс дип, минем өс-баш киемнәрен яңартырга булдылар.

...Авылның Тәгъзимә исемле бер апай Казанда яши иде. Пароход белән кайта да юл чыгымнарын капларга күкәй җыеп китә. Казанда сата икән. Кыйммәт, ди. Әнкәй мине дә Казанга җибәреп, кием яңартырга ниятләде...

...Күршеләрдән җыеп, 200 күкәйне фанер чемоданга тутырдык та Казанга пароходның кайчан буласын белергә апаны Әхияр пристанена җибәрдек. Ни өчен апаны, дигәндә, алар шул төбәк урманына балтырганга барырга килешкәннәр икән. Иртән иртүк иптәш кызлары белән шунда киттеләр. Кич белән кайткач, апаның әйткәне: «Казанга пароход көн аралаш була икән, билетны алдан сатмыйлар, пароход килгәч кенә саталар икән». Бүген булмаган. Димәк, иртәгә була! Чемоданны бәләкәй арбага салып, әнкәй үзе пристаньга илтеп куйды да, әткәй янына керергә ниятләп, мине калдырып та китте. Нишлисең, мин калдым. Черки болыты астында прахут (пароход) көтәм. Янымда башка кеше юк. Шкипер дигән абзый (аның исеме алай түгеллеген соныннан белдем): «Куда тебе?» — дип сорый. Шура апада укыган бит, русчаны беләм. «Казан», — дип җавап бирдем. Бер сүз белән. «Казань будет только ночью, жди в дебаркадере», — диде Шкипер абзый.

Дебаркадер дигәне ярга арканлап куелган, түбәсе ябык олы көймә икән.



«Тукай» фильмын (Ә.Фәйзи) төшерү вакытында. Сулдан уңга: Рабит Батулла, Камал III, Нәҗибә Ихсанова, Равил Шәрәфиев, Дамир Хәйруллин, Зариф Закиров, Иркә Сакаева, Хәмзә Бәдертдинов, Туфан Миңнуллин, Ринат Таҗетдинов. 1960 ел.

Ишеген ачып кердем дә почмактагы урынга барып утырдым. Чемоданны эскәмия астына этебрәк куйдым: кем кермәс тә, ни булмас?!

Иртүк торып килгәч, арыткан, йокы басты. Утырган килеш кенә «черем» итеп алырга булдым.

Хәер, йокы бит чакырганны көтми, үзе килә. Пароход тавышына гына уяндым. Касса янында 3-4 кеше чиратка баскан. Мин дә бастым. Кемдер «Молотов», ди, кемдер «Дербышка», ди. Чиратым житкәч, мин дә «Казань», дип акча суздым.

«Этот ещё не Казань, а «Генерал Жереховский», — дип, маржа апай акчаны кире бирде дә, — «Казань ночью», — дип өстәде.

Көтәргә булгач, көтәргә, кабат таныш бүлмәгә кердем. Шул арада «Генерал Жереховский» килеп, пассажирларын утыртты да юлын дәвам итте. Тагы ялгыз калдым.

Күпме утырылгандыр, озак йокланылганмы, чамалый алмыйм. Уянып китсәм, караңгыланган иде. Кемдер, шырпы сызып, фонарь кабызырга маташа, ике хатынның яше миңа карап: «Исереккә охшамаган ул», — ди. Йокым качып, күзләрем ачылып китте. «Исереккә охшамаган», дигән сүздән түгел, ә шул сүзне әйтүченең матурлыгыннан, чибәрлегеннән. Моңа кадәр андый матурларны очратканым булгандырмы, юкмы, әмма бу кызның гүзәллеге минем һушымны алды, күкрәкләренең күлмәге аша «чыгам-чыгам» дип селкенеп куюлары күзләремне камаштырды, телдән яздырды. Авылда да кызлар белән аралашабыз бит инде. Әйтик, су кергәндә, клуб янында туплы уйнаганда. Алар да ямьсез түгелләр, күкрәкләре дә бу кызныкыннан ким түгелдер. Әмма бу чибәр әгәр миннән: «Чемоданыңда ни бар?» — дип сораса, яшереп тормас идем, серемне әйтер идем. Алай гынамы — чемоданы белән бирер идем! Сорамады гына. Минем бәхеттән, аларга да «Казан» кирәк икән.

Ниһаять, пароход килә. ...Керүен керсәк тә, утырырга урыннар юк — басып кына бару мөмкин. Киттек. Урынсызларга өске палубада барырга рөхсәт иттеләр. Шунда күтәрелдек. Чемоданны рәшәткәгә сөяп куйдым да үзем теге чибәрне эзлим. Күренми. Алып чыгып качу ихтималы юк — чемоданымны калдырдым да гармун тавышы ишетелгән койрыкка киттем. Анда да булмады. Чемоданым янына кире әйләнеп килсәм — ул! Минем чемоданым өстендә утыра! Үзе! Күземә генә күренәдер дип, янына килмәк булдым. Ә ул... ул, урлашып тотылгандай куркып, торып басты да... апасына карады.

Ә апасы (мин шулайдыр дип уйладым): «Ну и что?» — диде дә, чемоданга утырып, чибәркәйне үз алдына утыртты. Бу минутларда миннән бәхетлерәк кеше бар идеме икән? Булмагандыр.

Тәүлек тулганда... Казанга килеп життек... Казанга? Тукта! Ә нигә «Өфе» дип язганнар дебаркадерларының маңгаена?

Кыскасы, мин «Казан» пароходына утырып Уфа шәһәренә килгәнмен икән... булып чыкты. Пароходның исеме «Казан» булу аркасында буталганлыгымны әнкәйгә гомере буе аңлата алмадым. «Ничек инде «аска» белән «өскә» дигәнне бутарга була? Син «аска» төшәсе урында, «өскә» менеп хаталангансың», — дип, җае чыккан саен, чыкмаса — чыгарып, шул күкәй сәүдәсен искә төшерер иде... Ә «сәүдә»нең ахыры бик матур куелган спектакль булганлыгын хәзер генә төшендем.

«Казан» пароходы Уфа пристанендә туктагач, чемодан тотып ялгыз басып торуымны вокзалдагы эскәмияләрне юеш чүпрәк белән сөрткәләп йөрүче бер апай искә төшерде: «Монда чемодан белән басып торырга ярамый. Әйберләреңне камера хранениягә тапшыр да... юлыңда бул!» — диде ул. Нәкъ безнеңчә. «Минем шушы күкәйдән тыш әйберем юк, мина базарга барырга кирәк!» — дидем җавабымда.

Апай җанланды, «үз» булып китте.

— Бу вакытта базар эшләми. Күкәй сатыр өчен базарга менәсе юк, әнә катык сатучылар янына барып бас та, ычкындыр... күкәйләреңне!..

Мин китә башладым...

— Тукта, ничә тәнкәдән сатасың?

— Белмим. Әнкәй: «Үзеңә күлмәк-ыштанлык булсын», — диде.

— Алайса катык базарына менеп йөрмә. Үзебезнең баракка алып барам, момент сатып бетерерсең.

«Барак» дигәннәре ерак түгел, алебастр заводын узгач, тимер юл күперен чыкканчы, уң як тау итәгенә салынган, безнең авыл клубы кебек агач йорт икән.

...Кайсы иләк, кайсы чиләк тоткан әби-чәби бик тиз җыелды. Һәммәсенә күкәй кирәк икән.

— Туктагыз, ашыктырмагыз баланы. Ачсын чемоданын, чыгарсын товарын...

— Товарым юк минем, шул күкәй генә анда, — бәйләгән-чорнаган җепләрен чишеп, ачып җибәрсәм, ни күзләрем белән күрим — чемодан ярты гына калган...

— Монда синең чынлап та товар түгел — күкәең дә юк! — шулай диде дә апаем, кәгазьләргә төргән күкәйләрне «сүтеп» бер кырыйга тезә башлады.

Аларның һәркайсы ватылган яисә чатнаган булып чыкты. Җыелган халыкның кайсы сүгенеп, кайсы көлеп таралышуы истә калган.

— Ярар, аптырама юкка, ватык булсалар да, тамактан узарлар, кар базыбыз бар — барысын да үземә алам, түлке чирек хакына, — диде апай, күңелемне күтәрергә теләп.

Мин чирек хакның ничә сум булуы турында баш ватканда, ул инде барактагы үз бүлмәсендә чемоданны... бушата иде...

— Мин сиңа акчалата бирә алмыйм. Үземә дип алган кайбер кием-салым нәрсәләрем бар. Шулардан өлеш чыгарырмын... Утыр, чәй эчәрсең дә килгән «Казан»ыңа утырып әллүк Уфадан. Ник дәшмисең? Башка керер кешең, адресың юктыр бит?..

— Юк...

— Билетны үзем алып озатырмын. Миннән булсын игелек!..

Тамаша тәмам.

Апаның «игелеген» гомергә онытасым юк. Ул мине сәүдә итү кәсебеннән коткаручым буларак хәтеремдә саклана. Өлеш чыгарган нәрсәләреннән «майка» дип биргәне хатын-кызлар өчен эчке күлмәк, «трусик» дигәне ретуз булып чыкты. Әнкәй көлә: «Баян уйнаганда үзең киярсең», — ди. Ник кими? Кидем! Баян уйнаганда түгел — кич белән уйнарга чыкканда да кидем.

...Безнең урамда, әти-әниләре үлгәч, җизнәләрендә тәрбияләнүче Зәйнә исемле бер ятим кыз бар иде. Барлык малай-шалай шул Зәйнәгә гашыйк, шул кунак кызының күңелен яуларга тырыша. Мин дә бер кичне яңа киемнәрдән Зәйнәне үземә каратырга өметләнеп чыктым... (Кесәм булмагач, ике прәннек кепкам эченә яшерелгән). Миңа таба карады кыз каравын... Тик, малайлар каршында мыскыл итеп: «Күрегез, күр, хатыннар ретузы киеп килгән, әртис булган»! — дип көлә башлады.

«Әртис» булыр өчен әле күп михнәтләр күрәсе барлыгын каян белсен инде ул?!

...Инде чынлап та «әртис» булып отпускларга кайткач, күчтәнәчкә йомырка (хәзер инде «күкәй» дип әйтү не культурно!) тотырганда, әнкәй: «Ватылса да, өстә берничәсе генә ватылыр, астагыларына берни булмас. Ватык дип ашыгып ташламагыз. Камырга салырга ярый ул», — дип әйтә торган иде. Ашыгабыз шул... ашыгу харап итә бәндәне. Аска төшәм дип, өскә менүләрдән әллә ни зур зыян күрмәсә дә, кеше гомере буена алдыйм дип үзе алдана; өскә менәм дип, һаман аска төшә, күтәреләм дип, гел түбәнлектә гомер кичерә.

Әйтеп узганымча, җиңү елы безнең гаиләнең дә җиңүләре елы булды. Без такта түбәле, почмаксыз буралган усак йортта яшибез! Яңа йортта! Онытткан кардәш-ыруг, туган тиешлеләр кабат безгә сукмакларын яңарттылар. Өй котлап, сөлге-тастымал кебек җиһаз китерүчеләр дә булды.

Иң әһәмиятлесе — торф чыгарырга яңа эшчеләр вербовать итү сылтавы белән Аяткадан олы абый кайтып төште. Үзе генә түгел — начальнигы белән. Янавыл станциясеннән ат яллап, бер авылдан икенчесенә күчә-күчә, дүрт көн дигәндә авылыбызда. Дугаларында кыңгырау, чана башында зур сөңге саплы олы флаг — әләм. (Җинел машинада безнең авыл белән Янавыл станциясе арасын хәзер 40 минутта узалар икән.)

Бу «флаг» дигән Кызыл байрак яхшы эшләгән өчен абыйның үзенә бүләккә бирелгән булган. (Шәхси милке булганлыктан, абый аны колхозга сатарга да маташкан иде — алмадылар. Ни өчен икәнен хәтерләмим.)

Абый белән бергә килгән вербовщик урыс та коры чемодан белән кайтмаган: бераз киелгән костюм-пиджаклар, чалбар, күлмәкләрне тараткач, өстәл, сәке өсләре тулды. Ул аларны акчага дип тормый, ярмага, бал-майга да алыштыра; каз түшкәләренә яңа костюм-чалбарларга кадәр ычкындыруы хәтердә. Фатирда торган өчен дипме, бүләк итепме, миңа да бик матур курткасы белән ике чалбар эләкте. Күчтәнәчкә бирелгән чәй-шикәр өстәлдән атна буе өзелмәве истә калган.

...Алар бер атнадан эшләрен уңышлы төгәлләп, Рәмүзә апабызны да ияртеп киттеләр. Әйе, алар китте. Безнең әткәйләр «баеп» калды. Чөнки зур абзый бүләккә дип алып кайткан чүпрәк-чапракка өстәп, өй эшләткәндә «баткан бурычыгыздан котылырсыз», дип акча да биреп калдырды. «Шактый» дип шактый вакыт абыйны мактап телгә алулары онытылмый. Аның бүләккә алган Кызыл байрагын Сталин премиясенә, «За трудовую доблесть» медален Орденга тиңләп, әткәйнең кергән бер кешегә отчёт биреп мактануларын мин отпускларга кайтканда, авылдашлар гел искә төшерәләр: «Синең һаман шундый булса да орденың юк мыни?» — дип көләләр. «Металл житми», — дип аклана идем.

«Абзаңнан калганын булса да тагып йөр!»

...Шулай олы абый китте... Абруе калды: вербовщик!

...Бер килгәч, килә бит ул: кышкы каникулларга чыгар алдыннан, абыйлардан посылка да килеп төште. 8 килолы! Посылка эчендә «бәбәй күчтәнәчләре» белән хат: кызлары туган! Роза дип исем кушканнар. «Шулай яраса, Коръән укытып, шул исемне беркетеп куйдырыгыз», — дигәннәр хатларында.

Коръәнне дә укыттылар, кергән бер кешегә хатны да күрсәттеләр. Дөнья түгәрәкләнде. Сарык бәрәнләгәнне генә көтәбез.

Тик... «чү... ашыкма», ди тормыш... Көннәрнең бер көнендә безгә ят кунак килеп керә дә әткәйгә гарәпчә язылган язу суза.

...Олы абзыйның хатыны Зәһинә жиңгәчәйнең әтисе Шакир кода оныктуу унае белән Ишкарга кунакка чакырган! «Жир астыннан юл булмас, шушы хатны тапшыручыдан калмый ияреп килегез», — дигән. Бу сүзләрне укыганда, әткәйнең күзләре яшьләнүе, әнкәйнең ишеттереп елаганы хәтердә.

...Алардан калышып булмый бит инде — мин дә мышкылдаган булдым, әртисләндем. Әткәй эшне тиз тотты. Үрчетергә дип алган буаз сарыкны суеп, «кемнеке» дигәндә, «аларныкы» диярлек күчтәнәч әзерләп, әнкәйдән «төш» (бездә чәкчәкне шулай дип йөртәләр) пешертеп, ике көн буена чакыру китергән кодачаны яна суелган сарык ите белән сыйлап, өченче көннең иртәсендә кунакка киттеләр. Күчтәнәч чанасы әткәйдә, сенелне утырткан каз оялы чана әнкәй белән «кодача»да. Миңа наряд шул: беркемне дә кертмәскә; кем какса да, ишекне ачмаска; ашарга — әнә — калган бәлеш тә, аш та житәрлек; «без бер-ике кичтән кайтырбыз»...

...Дүртәүләп юлга кузгалалар, тик алар китү белән, күз ачкысыз буран чыга. Минем курыкканым: кире генә кайтмасалар иде. Чөнки мин инде аулак өйгә кемнәрне чакыру, нәрсәләр пешерү мәсьәләсен чишкән идем. Төш житте. Димәк, кайтмадылар. Хуш! Болай булгач, урыс абый биргән «яңа» киемнәрне киям, Зәйнәне чакырам. Ул үзе генә кермәячәк... Шуна күрә аның иптәш кызларыннан авыл советы председателе — күршебез Мирзаханов кызы Ленаны, классташлардан Гөлсинә белән Фәрхиямалны, малайлардан 5 кешене — куначага!

«Аулак өебез» олыларныкыннан ким түгел — матур гына башланып китте. Коймак пешерәбез дип күп кенә тунмай яндырсак та, коймагыбыз ашарлык булмады. Аны посылкада килгән күчтәнәчләр алыштырды. Тора-бара калган ашлар да, бәлеш катылары да бетте. Посылка белән килгән шикәргә күченеп, чәйгә утырабыз дигәндә, кинәт капка шыгырдаганы ишетелде. Бераздан ишекне дә шакыдылар.

— Кем булыр? Нәрсә булыр?

...Сельсоветка илтеп түлисе бурычларны абый кайтканда түләделәр... Башка сәбәп белән чакырып, дежур килергә — соң... Аннары әткәй белән әнкәйнең кунакка китүен Мирзаханов абый да, аның хатыны да беләләр ич. Әнкәй аларга «күз-колак булырсыз», дип әйтеп калдыруын үзем ишеттем, «кодача» кем беләндер сөйләшергә дип телефонга чыгып киткән иде.

...Ишек шаку көчәюенә, шакучының ачулы тавышы өстәлү мине, куркудан, елау хәленә житкерде: бу «кодача» тавышы иде.

— Ишекне ачмасаң, бакча як тәрәзәнне ачып, посылка ящигындагы, анаң төйнәп куйган төенчекне бир, алар шуны алырга онытканнар. Ярты юлдан борып мине жибәрделәр. Тиз бул, алар көтәләр!

Шушы сүзләрдән соң дип әйтимме, шушы сүзләр белән бергәме — урам як тәрәзә форточкасын ачып, Лена кычкыра башлады: «Папа, коткарыгыз, үтерәләр! Мама!»

...Ленага Гөлсинә, Гөлсинәгә Фәрхиямал һәм башкалар кушылды...

Күрше йорт тәрәзәләрендә ут балкыды. Ә бераздан Лененың әнисенең тавышын таныдык.

— Кемне кем үтерә?

— Ишекне ачарга куша, посылка ящигындагы төенне сорый.

— Кем?

— Теге кем... кунакка чакырып килгән апай!.. Әнкәләр җибәрде, көтәләр, ди.

— Кая соң ул үзе?

Капканы ачып керсә, «кодача»ның ындыр артына таба киткән эзен генә күрә Ленаның әнисе... Ә үзе юк!

...Калганын дип әйтергәме, ана кадәргесенме, әнкәй сөйләде:

— ...Юлга чыгуга, буран купты. Кужбахтыга җиткәндә, юлны югалттык, чамалап кына бара башладык. Борылып кайтыйк, дим. Атаң: «Оят бит, ни сөйләмәсләр», — ди. Кайтмадык. Җитемәккә җиткәндә, Дания елый башлады, «әчем», ди. Астын алыштырырга күз ачкысыз буран. Нишлик? Ферма йортына кереп хәл алырга булдык. Кодача: «Сез шушында көтегез, мин колхоз кәнсәләренә барып, ат сөйләшәм. Җәяү атларлык рәт калмады, озак көттерсәм үзегез атлый торырсыз. Куып җитәрмен», — ди дә, китә бу. Без көтәбез. Караңгы төште. Юк теге. Каравылга килгән бабай әйтә: «Бу вакытта кәнсәләрдә кеше калмый, председатель өенә барып, үзегез сөйләшегез, риза булса — иртән ферма аты белән үзем илтеп куярмын», — ди. Атаң түзмәде — китте кәнсәләренә. Бәхетенә, кәнсә мичен утын тутырып маташучы әби анда икән. Шул әби күргән — икенде-ахшам вакытында бер ят хатын Кужбахты-Тәҗәй юлына таба «элдерткән», өстендәге сырмасы белән башындагы бүреге тегенекенә туры килә...

Председательдән рөхсәт язуы алып, иртән Ишкарга илттердек. Үзебезне генә инде...

Кодаларда кунак кайгысы түгел иде. Икесе дә түшәк өстендә авырып яталар. Алып килгән күчтәнәчләребез белән үзебез кайнатып чәй эчтек тә китергән атыбызга утырып кайттык. Хакны кыйммәт алмады алуын, шулай да атаң гаепле... Мин ышанмадым ул хатынга. Беренче күрүемнән шик басты... Атаң әйтә: «Күрәчәк», — ди. Сарыкның ике бәрәне чыкты, икесе дә саулык иде. Еларсың, дип сиңа әйтмәгән идем. Әйдә, ела рәхәтләнеп...

«Күрәчәк», имеш. Бусы «күрмәячәкме»? Гомергә ашыкты, гел алданды. Ә менә син миңа охшагансың, шикчелсең.

— Шикчел түгел — сакчыл, әнкәй, сагаям мин.

— Анысы да миннән! Ишекне ачмавың өчен атаңа дигән тун тышлыгыннан сиңа сырма сырдыртам!..

### «Балык суда бит ул...»

Яшьтәшем Фауканы искә алып, аның белән булган бер «хәл»не язып узыйм әле.

...Ватан сугышы корбаны — кече абый балыкка йөрергә әвәс булган... Бер баруында буш кайткач, әнкәйнең: «Көне буе йөреп, бер балык та тота алмадыңмы?» — дигәненә: «Балык суда бит ул», — дигән, имеш.

Кемгә дә булса абыйның тапкырлыгын, зирәклеген калкурак күрсәтергә кирәк булганда, әнкәй шушы мисалны китереп, соныннан аның нинди балыкларны күпме тотуы турында мактаныр иде.

— Кичә җәен турында сөйләгән идең, бүген «бер корбан», дисең... Кайсы дөрес, кайсына ышанырга соң бу әкиятнең? — дип әнкәйнең сүзендә ялгыш тапсак: «Бәлки бөтенләй ят балык булгандыр, аның ничек аталуындамы хикмәт, суда ни генә йөзмәс», — дияр иде.

Шунысы нык хәтердә: 1944 елның язын әнкәй яңа сөзгеч бәйләтеп каршыларга ниятли. (Абыйның шундый теләге булган, имеш.) «Иске сөзгечне ямап кына гамәлгә ярарлык итеп булмый», дигән нәтиҗәгә килеләр.

Ашыгыч рәвештә җитен сүсеннән җеп эрләп, аны тиешле сыйфатына

житкергәч, тәрәзә янагындагы кадакка элеп яки үзең белән «кул эше» итеп алып, корал бәйләү процессы башлана.

Кемнең кулы житә — сөзгечкә үз өлешен кертә.

Ничек итсә — ителде, сөзгеч бәйләнде, Мокыйм бабайны яллап, сап та куйдырылды. Корал әзер.

...Яз житте, елгалардан боз китте. Әмма сөзгечкә тигән кеше юк. Кемдер сорап керә икән, әнкәйнең жавап катгый: «Әйе шул, мәрхүм улымнан калган истәлекне ерттырырга бирдем, ди».

...Мин тугызынчыда укыган елның язына кадәр шулай — мунча түбәсенә сөялгән багор, пумала, янгын баскычлары белән бергә торды балык сөзгеч, жил-янгыр, кояш астында...

Каникуллар башланды. Классташым Фаука әйтә: «Тегермән буасы киткән, сөзгечләре булганнар балыкны умыралар гына... Иске сөзгечеңне биреп торсаң, мин дә бәхетемне сынап карар идем», — ди.

...Иске сөзгечне Фаукага биреп, үзем яңасын тотып, киттек балыкка. Аякта абыйдан калган итек, Фаукада — тишек ботинка.

...Базы елгасының тегермән буасы артындагы «ике базы арасы» дигән болынлыкта «Әйләмә күл» дигән зур күл бар. Шуның тамагының яртысыннан күлгә су тула да икенче яртысыннан агып та чыга. Бу могжизаны үз күзләрең белән күргәндә дә ышануы авыр. Кеше әйткәнне ишеткәч, көлгән генә булыр идек, йомычкалар ыргытып, тикшереп карагач ышандык: бер үк бугаздан керә дә су, агып чыга да. Могжиза дими, ни диярсең?!

— Синең аякта итек, сөзгечең дә зур, син бар — урап, тамакның теге ягына чык, уылдыкларын чәчеп, күлдән чыгучы балыкларны күпләп тот, миңа күп кирәкми, ничә баш керсә — шул житә, мин бу кырыйдан аларны сиңа озатып, куалап торырмын.

Фаука — күп балалы гаиләсендә генә түгел, классыбызда да иң ушлы малай, аның сүзен тыңламый булмый — киттем күл тамаганың теге ягына. Урнаштым. Сөзгечемне балык күп керерлек итеп тотып ярда торам. Үзем уйланам: савытның кечкенәсен алып ялгышканмын, абыйдан калган биштәрне аласы калган, күп эләксә, кая салып, ничек алып кайтырмын?

Мин уйланам, Фаука «чабыр-чобыр» килеп, сөзгеченнән чуртан чыгарып, кәрҗиненә сала, берәмләп кенә, җай гына сала. ...Берне, өчне, бишне... сала...

Мин «көтүе» белән керәчәк балыкны һаман көтәм. Тундырган да сыман, тирлим дә кебек. Утырырга мәҗбүр булдым. Юешкә утырганмын.

...Фаука һаман «чыпырдата».

Түземем житми: «Ничәү?» — дип кычкырам. «33», — ди Фаука, миңа карамый гына.

Кыскасы, миңа бер балык та эләкмәде. Фаука, кәрҗиненә сыймаганнарыннан, «сөзгеч ялына» дип, өч чуртан бирде.

Аның үзенә калганы әллә 86, әллә 96 баш чуртан иде. Кәрҗингә сыймаган балыкларын сөзгечкә салып, көч-хәл белән генә күтәреп кайтып життек авылга.

...Әнкәйгә өч чуртанны кайтарып биргәч, шатлануын тасвирларга сүзем житми. Азлыгына аклану өчен: «Өч балыкка шулай шатланасың, иртәгә утызөчне алып кайтырмын», — дигәч, әнкәй: «Чү, улым, алай димә, балык суда бит ул. Булганының кадерен белеп ашарга язсын, уылдыгы гына да бер пироклык!» — диде.

...Озак еллардан соң ялга кайткач, Фаука белән бер очраштык. Ул хәрби хезмәттәге кеше, полковник иде. Мин — артист. Г.Камал театрында эшләгән чак, акчасыз.

— Әйдә, Базы елгасы буена, — ди Фаука. — Яшьлекне искә төшереп, уха ашап кайтырбыз. Тамак чылатырга да бар!

— Ә балыгын каян алырбыз? Чуртаннар хәзер уылдыкларын чәчәргә Әйләмә күлгә кермиләр, — дидем мин элеккеләрне хәтерләтү өчен. — Базы елгасында хәзер буасы да, тегермәне дә, суы да, балыгы да юк бит, яшьти!

— Уханың консервланганын ашарбыз. Проблема шунда: мин бит теге чак сиңа бер балык та кермәсен белдем. Закиржан абзый миңа кайда, ничек басарга кирәген сер итеп кенә әйтеп, әлегә балыкның күлгә керүен, чыгуы атна-ун көннәрдән соң гына башлануын аңлаткан иде. Гөнаһлымын. Икеләтә. Хәтерлисеңме: бер атнадан соң тагын төштек. Син минем урынга, мин синең урынга бастык. Сиңа бер балык та эләкмәде, миңа тагы бер кәрҗин... корбан балыгы...

— Өчне миңа да бирдең...

— Нигә мин шулчак белгәнемне сиңа да белгертмәдем икән? Суда балык күп иде бит... Юкса... Көнчелекме бу? Комсызлыкмы? Саранлыкмы? Этлекме? Тозсызлыкмы?

— Кешелек бу, кешелек! Бары кеше генә шулай була ала, — дидем мин, үземне үземнән акыллырак күрсәтергә теләүдән җавапсыз калмас өчен генә.

— Ә мин гомер буе шул сорауларга җавап эзләдем — таба алмадым. Кичер мине — көчең җитсә.

...Яшьтәшем белән әлеге очрашуга күп вакыт узса да, аның суы корыган күл буенда гафу үтенеп утыруы бүгенгедәй хәтердә.

Хәзер аны отставкадагы генерал, диләр. Булса да булыр. Көчле кеше иде ул. Аның көчлелеге сер саклавында да, гафу үтенә белүендә дә чагыла.

...Төрле бәхәсләргә катнашмыйча, агымнарга кушылып акмыйча, үз рәхәтенә генә яшәүчене «яши белеп яшәүче», диләр. Андыйларның телләрен тешләп дәшмәскә көчләре җитсә дә, үз вакытында гаепләрен аңлап гафу үтенергә көчләре җитми.

Бәлки, көчсезлекнең бер төредер бу?

Без үзебез, шәхсән, күлләр корып, балык беткәч, аларның кайчан уылдык чәчеп, кайчан чыгуларын белсәк тә, бәхетнең кайсы ишектән кереп, каян чыгуын белә алмадык. Бик тырышсак та.

Фаука кебек алдан белүчеләр белән аралашып яшәсәк тә, алар мине үз төркемнәренә якын җибәрмәделәр, «балык тоту» серләрен чишмәделәр.

Бәлкем, минем бәхетем шундадыр?!

Мин, сизенгәнсездер, «Ничек артист булырга?» дигән сорауга һөнәр мәктәбенең иң-иң башлангыч сыйныфларында алган берничә сабагымнан мисаллар китердем. Алар бик күп һәм бер сабак икенчесенә охшаш түгел — төрлеләр. Шул сабаклар кешедән һөнәрче ясый, шәхес ясый. Яше үскән саен, «сабаклары» да катлаулана, арта бара кешенең. Бер көн килеп тормыш сабаклары гына җитми башлый. Ул сайлаган һөнәрне мәктәбендә белергә омтыла. Безне язмыш Щепкин исемендәге театр мәктәбендә укытты, татар академия театрында эшләтте. Гомернең бу чоры турында мин «Шомырт оны» дигән әсәр язмакчымын. Өлгерсәм, әлбәттә. Хатирәләрем җитәрлек. Әсәргә кадәр хезмәттәшләрем турында телевизион очерклар төшереп күрсәттем, иҗатлары турында мәкаләләр язып бастырдым. Инде менә шул мәкаләләрне, шул очеркларның эчтәлеген уйлап, үземә-үзем гаҗәпләнеп утырам: артык мактаганмын түгелме?

Кемгә ни бирә шул мактау дигән тылсым? Әллә сихерме ул?

Барысы да уен, театр, «әртисләнү», әлбәттә...



*«Тукай» фильмыннан (Ә.Фәйзи) күренеш. Сулдан уңга: Тукай – Дамир Хәйруллин, Г.Камал – Ринат Таҗетдинов. 1960 ел.*

## Сәхнә арты мәзәкләре

Йөз елдан арткан тарихлы Камал театрында иҗат камытын артистлар белән бергә тагын бик күп һөнәр ияләре кия. Рәссамнар, музыкантлар, костюмерлар, чәчтарашлар, бутафория цехы эшчеләре. Тамашачыга үзләре күренмәсә дә, театрның уңышында аларның роле бик зур. Шул хезмәт ияләре арасында гаять кызыклы шәхесләр була. Әхмәт абзый белән Солтан абзый дигәннәре аеруча истә калган. Мин бу язмаларымда 60-70 нче елларда шул кешеләрнең үз авызыннан ишеткәннәрне генә файдаланам.

Әхмәт Гыйззәтуллин — Казандагы Тегәрҗеп урамында туып-үскән чын татар. Театр техникумын тәмамлаганнан соң, артист булып та эшләп алган. Кайдадыр сынатып, холкындамы шунда, һөнәрен алыштырырга мәҗбүр булган.

Солтан абый исә опера театрында хорда солист булган, имеш. Икесе дә, сүз иярә сүз чыкканда, артист булуларын оныттырмыйлар иде. Янәсе, «бик нитмәгез, без дә сездән ким түгел!»

Бу «парчалар» бер «капустник» өчен театрның ул вакыттагы директоры Рәшидә Җиһаншина тәкъдиме белән язып алынган иде. «Капустник»ка дәрт булса да, дәрман житмәде, ахрысы. Ният тормышка ашмый калды. Язмада телгә алынганнар үзләрен «бывший», дисәләр дә, «настоящий» артистлар иде. Ялгышлар китсә, аларны белгән, хәтерләгән кешеләр төзәтеп укысыннар. Бу исә гаделсезлек корбаннарына дога булып ирешер. Дөресен әйтергә кирәк, гаделлек учагы булырга тиешле урында — театрда да гаделсезлеккә мисаллар очрый шул.

## Гәҗиттәге ит

Камал театрының хуҗалык цехлары бинаның подвалында урнашкан булып, такта яру һәм ышкылау станоклары эшләгәндә, тавышы сәхнәгә дә ишетелеп комачаулый.

Шуна күрә спектакль вакытларында ул цехларда станокларны эшләтү тыела. Эш сәгате чыккач, гараж ачкычын шоферга, котельная ачкычын слесарьга бирү гаеп саналмый.

Проходнойда элеккеге НКВДшник чукрак Хәлфиев дежур торган төн була бу. Бутафор аннан агач эшкәртү цехының ачкычын сорап ала. Бераздан спектакль башлана. Тавыш-тын юк. Барысы да тәртиптә шикелле тоела Хәлфиевкә. Черем итеп алырга була ул. Тик бераздан телефон шалтырый. Озак шалтырый. Нидер сизенеп, Хәлфиев трубканы ала:

— Проходная слушает.
— Кто там?
— Хәлфиев.
— Хәлфиев икәненне беләм. Анда кем шаулый?
— Берәү дә шауламый. Һәркем үз эшендә.
— Всех задержать! Никого не выпускать!

Хәлфиев колакка каты булганга күрә ишетмәгәнме, цехка керсә — Солтан ниндидер такта башын ышкылап ята. Хәлфиев тиз генә электрны өзеп, Солтанга чыгарга боера да постына китә.

Анда инде директор үзе басып тора икән. Ә бу кеше элек янгын сүндерү участогы башлыгы булган үтә дә сизгер «чекист».

— Кем анда?

— Бутафор.

— Фамилиясе шулаймы?

— Һөнәре.

— Кая ул?

— Үз цехына менеп китте. Хәзер үк чыгарга куштым.

Бераз көттереп, Солтан чыга. Култыгына, газетага төреп, нидер кыстырган. Директор тузына.

— Групповое расхищение госимущества! Ни ул анда синен?

— Сезнен дача өчен эшкәрткән тактадан калган нәрсәләр.

— Ниемә кирәк ул черек такта башлары?

— Ит турарга.

— Ите кая соң анын?

— Ите, әнә, гәжиттә, — ди Солтан, төргәген сүтә башлап.

— Сүтмә, — ди директор. — Иртәгә бер кубометр эшкәртелгән такта өчен дип, кассага акча түләрсен.

— Бергә инде, бергә. Групповой булгач, түләвен дә бергә кирәк.

Элегрәк театр ишегалдындагы каеннар ышыгында кин такта башы беркетелгән агач төбе бар иде. Тәмәке тартырга чыгып утырганны Әхмәт абый күрсә, гел әйтә иде: «Белегез: Солтаннын ит тактасында утырасыз».

Кемдер юри генә: «Ите кая сон анын?» — дип сораган була. Шунда ук кемдер җавабын да бирә: «Ите, әнә, гәжиттә», — ди.

Яши Солтан, телләрдә яши.

### Итек кыйссасы

Камал театрынын Опера һәм балет театры белән бер бинада «өйдәш» булып яшәгән чагы. Кайбер цехлар ике театрныкы бер бүлмәдә.

Опера һәм балет театрынын итекчесе Женя Камал театрынын бутафория цехы бүлмәсендә Әхмәт һәм Солтан белән бергә утыра икән.

Евгений Абрамович — сугыш вакытында эвакуацияләнеп, Львовтан килгән яһүд. Ул бик оста туннар, бүрекләр, итекләр тегүче икән. Заказларны теләсә кемнән кабул итми, ышанычлы кешеләр аша — «по-блату» гына.

Солтан кемгәдер итек тектереп бирергә ышандырган. Итек «итальянский», «офицерский», гомумән, хәтәр итек булырга тиеш икән. 43-45 нче үлчәмле!

— Кемгә сон ул? — дип сорый Женя.

— Үземә!

— Синен аягын 34ле бит?

— Киез итек белән киярмен.

— Калдыр!..

Шулай ята итек тегелмичә. Яһүд Евгенийны татар Солтан ышандыра алмый. Беркөнне эшкә яланаяк килгән бу. Имеш, кияренә юк. Тик барыбер ышандыра алмый үҗәт яһүдне.

Ниһаять, Солтанга жай чыга бит. Әлеге дә баягы, кибетләрдә кинәт аракы бетә. Евгений сукрана. Әрмән ягыннан кунаклары кайтасы икән. Табынга куярга бернәрсә юк, ди.



*Шул ук фильм. Сулдан уңга: Диндар – Зариф Закиров, Юныс бай – Камал III, Шәмче Гали – Әхтәм Зарипов. 1960 ел.*

Икенче көнне Солтан эшкә бер чүлли аракы кыстырып килмәсенме!

— Каян алдың, Султанчик?

— Горняктан. Анда минем дус грузчик булып эшли.

— Дус итсәң, миңа бер литр ак табып бир!

— Синең дуслыгыңа ышансаң, әнә, ята аунап.

— Бар эшемне ташлап, итегенә тотынам. Бар, алып бир, зинһар. Мә акчасын.

Солтан китә һәм өч сәгать узгач, буш кул белән кайтып керә.

— Булмадымыни?

— Итек ямау гына түгел бит ул. Караңгылангач килергә куштылар.

— Мә, итегенне ал да монда утырма. Төзәттем. Кулдан ычкындыруың бар, акны, дим.

— Дуслык хакына гына барам, барсам да.

Солтан, итеген сумкасына салып, дуслыгын хакларга китә. Шул китүдән өч көнсез килеп күренми. Гәүдә бәләкәй, буй кыска, ашау юк. Аяк ялына дигәне тамак юлыннан китеп, башына бәргән, ахры. Кызы килеп, атасының «больничныен» күрсәтеп китә. «Йөрәге» дип язылган була бюллетеньдә. Атна узгач кына Солтан үзе күренә.

— Кая аракың?

— Нинди аракы?

— Блат белән алганы, Горняктан...

— Хатын әйтмәдемени? Арестовать итте ич мине. Әйтергә тиеш иде.

— Ничек?

— Шулай: төнлә белән кайтып киләм. Каршыма хатыным килә. «Кая югалдың? Эзләмәгән морг калмады», — ди.

— Грузчик булып ялландым. Төне буе аракы бушаттык, — дим.

— Бушатканыңны күрәм. Китер монда калганын, — диде дә шешәләремне алды.

— Үземә түгел, кешегә, диярга иде.

— Әйттем. Ә ул: «Кем сине эш вакытында аракыга җибәрә? Фамилиясе кем?» — дип төпчене башлады.

— Әйттенме?

— Дуслык хакына йөргәнне белә ич ул. Дустым син генә.

— Ничек булып бетте?

— Кая бетсен! Башлана гына әле. Директор үз янына чакырткан. Шунда барам, дип калды.

— Султанчик, зинһар, минем исемне атамасын, әйт! Мә, сиңа тагын дарулык. Жайла-майла, миңа гына тимәсеннәр.

— Юк инде, дустым, без дуслыкны акчага алыштырмыйбыз! — ди Солтан һәм акчаны алмый.

— Чыннан да шундый хәл булдымы? — дип сорыйм Әхмәттән. — Булды,

— диде Әхмәт. — Женясы да Солтан кебек үк шук иде... Итегенә гуталин сылап, үкчәсенә резин гына сугып бирүе житмәгән, «даруга» дигән акчасы да бутафор гына булып чыккан.

— Үзе бутафор кеше шул ялганны сизмәдеме?

— Бездә дусларны «сату» гадәте юк. Сиздермәде. Элеккеге артист бит. Чиркәү хорында жырлап, тамагын ярган баритон.

— Солтан баритонмы?

— Жырлавын колакны томаламый тыңларлык түгел иде.

Бутафор Әхмәт ага Гыйззәтуллинның үзен тыңлаганда да күздән яшь чыкканчы көлә торган идек.

— Мине артистлар штатыннан бутафорлыкка күчергән әмергә «Режиссёр трактовкасын даими бозган өчен» дип язылган иде. Ярый әле күчергәннәр. Монда рәхәтләнеп трактуем.

Көлдерү өчен әйттеме, үпкә белдерүе идеме? Һаман аңлый алмыйм.

### Вобла

1956 ел, Казан, Камал театры. Кибеттә вобла саталар икән, дигән хәбәр тарала. Тик чираты бик зур, якын килерлек түгел. Артистлар тыз-быз киләләр, местком рәисен театр исеменнән вәкил итеп жибәрмәкче булалар.

Шул арада бутафор Әхмәт кием цехыннан үзбәк халаты, реквизитчы Сонядан кара күзлек сорап ала, кәкре башлы таяк тота. Үзе әйтмешли, «для пущей важности» противогаз сумкасы аса да, Солтаннан житәкләтеп, Карл Маркс урамындагы кибеткә китә. Артистлар үтенеч хаты язып, машинистка Жәннәттән бастырганчы, бер кап вобла алып кайтып та житә.

30 кг вобланы утызга бүлеп, сатуны да оештырып жибәрә. (Хикәянең бу урынына житкәндә: «Килосы 87 тиеннән», — дип кыстырып куя Әхмәт абый.) Вобла сатылып бетә, кемнәргәдер житми кала, үпкәләш-тавыш куба. Шуннан Әхмәт белән Солтан сәүдә сәфәрен кабатламак булып, тагын кибеткә китәләр. Тик, бу юлы чират алдына килеп бассалар, теге юлы чират ахырындагы маржаның чираты килеп житкән икән. Тавыш куба.

— Тагын килдегезме, артистлар? — ди ул, Солтанны да, Әхмәтне дә танып.

«Сукырлар» көч-хәл белән генә качып котыла. Әмма маржага үпкәләре юк. Ул аларны артистлар дип атады бит. Әхмәт абый бу вакыйганы бик тәмләп сөйли торган иде.

### Сәйдәш көне

...Элек театрларда репетиция башланганчы, ягъни 9дан 11гә кадәр политинформация дәресе була торган иде. Аларга йөрү мәжбүри булмаса да, керми калсаң, баштан сыйпамыйлар иде. Йә премия биргәндә, йә фатир чиратын барлаганда искә төшерәләр. Атнага бер мәртәбә бу дәрескә театрның башка цехларында эшләүчеләр дә чакырыла. Артистлар өчен бер кирәксез чара булып тоелган нәрсә башкаларга эштән аерылып, ял итеп алу мөмкинлеге иде.

Шундый көннәрнең берсе. Сәгать иртәнге тугызлар. Сәясәт серләрен төшенергә Татарстанның халык артисты Ибраһим Гафуров та килгән. Ана ничек тә килгәнлеген труппа мөдире Мәрьям Чанышевага күрсәтергә кирәк. Шуның өчен ул расписание укыган булып тора. Чынлыкта укымый, чөнки бүген дә, иртәгә дә эше юклыгын кичә килүендә үк күреп китте. Ана Мәрьям апасының күрүе мөһим. Ниһаять, труппа мөдиренең әмере белән кыңгырау шалтырый һәм Мәрьям Чанышева Ибраһим Гафуров янына килә.

— Син менмисеңмени, Ибраһим?
— Төштем генә, Мәрьям апа.
— Нигә төштең?
— Кан басымы уйный.
— Төштеме, күтәрелдеме?
— Икесе дә — ашкындыра да, йокы да килә.
— Алайса кайтып йокла. Шимбә көн «Кыз урлау».
— Шулай итми булмас, ахры.

Мәрьям Чанышева китә, Ибраһим янына Солтан килә. Бер кулында кабартма, икенчесендә чәчәк.

— Сәлам, халык артистына!
— Син нигә дәрескә менмисен, Солтан?
— Менә сине котларга дип төштем әле.
— Нәрсә белән?
— Исем алуың белән.
— Соң аңа биш былтыр бит инде.
— Сүз белән котлауны әйтмим. Теге чакны сыйлый алмый калган идем. Кәефең булса, буфетка керик...
— Андый уем юк иде дә. Сине үпкәләтмәс өчен, теләгең булса, мин каршы түгел.
— Алайса бу чәчәк белән закусканы тотып, буфетка бара тор. Сәйдәш бюсты янында көт.

Китәләр болар икесе ике якка — Ибраһим буфетка, Солтан үзен «билгеләтергә». Кайда, нәрсәгә, ник «билгеләтергә»? Моны ул чакта түгел, соңыннан да белә алмый Ибраһим ага. Ярты сәгать, бер сәгать көтә Солтанны. Теге юк. Буфет ачык. Кулында китап битенә төрелгән кабартма белән чәчәк. Ул вакытларда кара дәфтәргә фамилияңне язып, әҗәткә аракы бирәләр иде. Күңеленә корт керә бит абзыйның. Буфетчы маржа янына килеп баса.

— Что, Абрам Ильич, сухомятка горло дерёт?
— Угадали. Пиши 50 грамм.
— А за прошлые угощения когда рассчитаемся?
— За всё сразу с зарплаты.

Кабартмасын сындырып кабыйм дисә, җен ачулары чыга — катыргы кабартма икән. Солтанны эзләп, бутафория цехына төшеп китә бу.

Цех ишеге бикле. Күрше ишекләр дә бикле. Аптырагач-йөдәгәч, янкормага күтәрелә. Анда Солтан берни булмагандай «Экономия должна быть экономной» дигән доклад тыңлап утыра. Ишеккә аркасын куеп утырган. Бер ача ишекне Ибраһим, ике ача. Моны күреп, Мәрьям Чанышева чыга.

— Син кайтып йокларга тиеш иден бит, Ибраһим?!
— Кайтмый гына йокланды шул...
— Алайса кер. Әкият тыңла.
— Юк инде, әкияткә ышанып, шушы хәлгә калдым.
— Нинди хәлгә?
— Солтан миңа катыргы кабартма биргән. Шушы кәгазь чәчәкне тоттырган. Хурлык!

Озак та үтми лекция бетә. Иң ахырдан Солтан чыга.

— Нигә көтмәден? Көт дидем бит! — ди ул Ибраһим Гафуровка.
— Көтмәсәм, монда булыр идеммени? Доклад тыңлап утырдың лабаса!
— Бетмәгән доклад булмый. Ә аракыны бетерергә әллә нинди указлар чыгарсалар да, ул бетми, арта гына бара.

— Әйдә, алайса шул артканын 100 грамм салдыр да бәхиллим. Син — мине, мин сине күрмәдек.

— Юк инде, бу юлы синен чират бәхилләтергә.

— Көләсең, ә?

— Салгансың ич әнә, шунысы минем исәптән булыр.

— Салу гына түгел, ашадым да. Син биргән катыргы кабартманы!..

— Мин бит аны сиңа тотып торырга дип кенә калдырдым. Чәчәген Салих абый һәйкәленә куярга иден!

...Җаен табып, Солтан абыйның үзеннән сорыйсы иттем бу мәзәк хәл турында, шундый шаяру булдымы, дип...

— Шаяру түгел, үч алу иде ул, — диде Солтан абый. — Салих Сәйдәшев өчен. Аның туган көне иде. Ник берсе искә алсын! Фатирсыз тилмергән Ибраһим абыйга Салих Сәйдәшев үз өендә урын бирә. Ә ул аның хатынын урлый, дустына хыянәт итә. Салих абый Ибраһимга ничек рәнҗегәнен гел безгә кереп сөйли иде.

— Шул да булдымы үч?

— Минем өчен алар икесе дә кадерле иде. Миннән шул җиткән. Калганын ахирәттә үзләре карасыннар.

Бу хикәятләрдә сүз гел акча, аракы тирәсендә бара сыман. Ә бүген нәрсә турында сөйләшәбез соң? Сөйләшеп кенә калсак икән.

## Адашлар

1960 елның июнь башларында «щепкинчылар»ның татар студиясен диплом спектакле күрсәтергә Мәскәүдән Казанга кайтардылар.

Академия театры артистлары катнашында югары профессиональ әзерлегебезне Казан тамашачысына һәм язмышыбызны хәл итәчәк төрле оешма вәкилләренә күрсәтергә тиешбез икән, шунсыз артист булу ихтималы юк, имеш.

Кыскасы: тиешбез! Төп рольләрдә студентлар булса, «ярдәмче» рольләрдә театрның күренекле артистлары уйнау җаваплылык бермә-бер арту икәнне СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлилов шулай аңлатты: «Дүрт ел буе мин сезнең өчен көрәштем. Бу спектакль белән сез түгел, мин имтихан тотам. Сынатсагыз — сынып кына калмассыз — кисеп ташланырсыз»...

...Спектаклебез Әхмәт Фәйзинең «Тукай» драмасы буенча кыш буе Мәскәүдә әзерләнеп, Казанда аңа махсус яңа киемнәр тектерелде, декорацияләр эшләнде.

Инде менә Казан... И, Казан, моңлы Казан, дәртле Казан...

Безне — студентларны «Дом крестьян»га, элекке «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең гыйбадәт залы булган 100 кешелек бүлмәгә урнаштырдылар. Хатыным һәм 20 көнлек улым белән мин дә бер койкага кунакладым...

...Тәнен нинди дер сыткылар басудан, улым поездда ук авырый башлаган иде, «Дом крестьян»га урнашкач, кинәт температурасы да күтәрелде. Ашыгыч ярдәм чакырып, доктор кинәшләре алгач, шул ачыкланды: монда калу балага гына түгел, анасына да хәвефле икән...

Юыну, юындыру мөмкинлеге умывальниктагы Идел суы гына. Аерым номер алып, кунакханәгә күчү өчен дә, фатирга күчәргә дә акчабыз юк. Нишләргә? Киңәш сорап Хәлил абый Әбҗәлиловка мөрәҗәгать иттем. Аның җавабы: «Өйләнгәндә миннән сорап тормадың бит! Бала ясарга ашыкмаска иден... Замдиректорга әйтермен, көтегез, түзегез, шыншымагыз!..»

Мин түзәр идем — бала түзә алмый, ул елагач, бүлмәдәш 97 кеше, бимазаланып, холык күрсәтә.

...Репетицияләр көнгә ике мәртәбә: иртәнге уннан, кичкесе — өчтән. «Дом крестьян»да дежур торучы апай, безнең хәлне аңлап, кызганудан, үзендә яшәп торырга тәкъдим ясады. «Борисково» бистәсендә. Йөрергә ерак булса да, йортының иркенлеге безне күндерде бу вариантка.

...Кичке репетициядән соң такси яллап киттек. «Борисково»да яшәргә урнаштык.

...Йорт хуҗасының чын исеме Нәгыймә икән. «Дом крестьян»да аны «тётя Нина», дигәннәр иде.

— Әби, дисәгез дә үпкәләмәм, балагызны гына терелтегез...

«Күпме хак сорар икән», дип баш ватканны сизгән кебек, Нәгыймә апай үзе сүз кузгатты:

— Гомер буе тере артистлар белән аралашу хыялы белән яшәдем. Ниһаять...

— Без әле артист түгел, фәкыйрь студентлар гына, — дидем мин.

— Борчылмагыз, тарсынмагыз — өегездәге кебек үзегезне иркен тотыгыз...

— Шулаен шулай да... Ни бит... Тормыш авыр...

— Акча сорар, хак алыр дип хафаланмагыз, алсам да, театрдан гына алачакмын. Сабый хакына бушлай да ризамын. Театрыгыз түрәләренең гамьсезлегенә ачуым килгәнгә әйтүем. Әмма бер шартым бар: балагызга атап Коръән чыгарып, исем куштырасыз! Тәнендәге сыткы-кычулары исемсезлектән аның, догасызлыктан, пәри ялаганнан...

— Туу турында таныклыгы бар ич аның... Исеме — Айдар!

— Мулла кушкан исеме булырга тиеш баланың! Аның авырулары да, тәнендәге җәрәхәтләре дә... барысы да шайтан иярләшүдән. Тьфу-тьфу... тәүбә-тәүбә...

— Авылга кайткач, исем туе ясарбыз дип планлаштырган идек...

— Кайчан кайтасыз авылга?

— Августта. Июльдә минем солдат хезмәтем.

— Күрмисезмени, балагыз көчкә тын ала? Бүген-иртәгәдән калмый, өшкертмәсәгез... Тәүбә-тәүбә...

— Белгән-күргән таныш мулла булса икән...

— Мулланы мин сезгә үзем табам. Сездән ризалык кына кирәк.

— Күпме сорыйлар соң алар?

— Сорамый торганын табам.

— Сорамаса да, бирми булмас бит?

— Була. Ризамы?

— Ризамын дип мин нишләргә тиеш булам?

— Коръән аятьләре укыганда, «амин-амин» дип утырырсың. Мулла сорау бирсә — дөрес итеп җавап бирерсең.

— Кайчан оештырылыр бу мероприятие? Премьералардан соң безне озак тотмаслар... Җибәрерләр...

— Мероприятие түгел, ә мөселман өчен фарыз гамәл бу — дини йола. Кайчан сина унай — шул көндә ясарбыз.

— Премьерадан соң.

— Ярый.

— Әмма ләкин мин үзем исем кушу мәҗлесенә кайтып җитмәвем ихтимал. Премьерадан соң сөйләшүләр булыр... Тегесе-бусы... Хатыным Җәмиләгә барлык хокук-вәкаләтләрне калдыргач, минем катнашу мөһим дә булмастыр, бәлки?

— Коммунистмы?

— Комсомол...

— Сүздән куркасын?

— Сүздән кем курыкмый?

— Әнә шул мулла абзый курыкмый сүздән.

— Указлыдыр?

— Кайчандыр Коръәнне яттан белгән. Хәзергесен әйтә алмыйм... Син аны үзен дә беләсендер?

— Кем ул?

— Адашын: Зариф хәзрәт...

— Закировмы? Артист Зариф Закировны беләм.

— Язучы! Бәшири, диләр аны.

— Язучы башы белән Коръән укып йөриме?

— Кунак ул. Бик ерактан кайткан, безгә туган тиеш кеше. Без аны тегеләй дә, болай да чәйгә алырга тиешбез. Күптән кайтканы юк иде. Мәкаме бик моңлы, Коръән укытырбыз, эшләп ашасын...

...Икенче көнне иртәнге репетицияләргә кадәр радиокомитетка кермәк булдым. Акча эшләп алу мөмкинлеге юкмы, янәсе. Рокыя Юнусова атлы редакторга мөрәҗәгать итәргә куштылар; тапса — эшне ул таба, диделәр. Кердем. Күрдем.

...Рокыя апа калын гына гәүдәле, киләч йөзле, ачык күнелле, иҗат кешеләре белән ихлас кызыксынучан журналист икән. Тәржемәи хәлемне, гаилә мәшәкатьләре, уку-каникуллар турында җентекләп сорашты да, гозеремне әйткәнне дә көтмичә, тәкъдим ясады:

— Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына. Нәкъ син кирәк идең миңа бүген...

— Мин?

— Премьерагыз турында якшәмбе тапшыруына «страничка» кирәк. Бүген тотынсаң өлгерәсең...

— «Страничка» ни дигән нәрсә ул?

— Музыкаль тапшырулар редакциясендә Ләбиб Айтуганов атлы егет эшли. Шагыйрь дә, композитор да, үзе үк режиссёр да. Ул сиңа барысын да аңлатыр. Аңлатып кына калмас, чыганагыңны алып кайткач, монтажлауда да ярдәм итәр. Мин техника белән эш итә белмим; әзер булгач, текстны карап чыгармын. Ләбибтән соң текстка кул тыгасы калмаса да, Фәтхи Фазылҗановичка кадәр мин дә күз йөртергә тиешмен.

— Фәтхи Фазылҗановичка күрсәтү нигә кирәк?

— Радиотапшыруны күрсәтеп булмый. Ә тыңлатмыйча ярамый. ...Ф.Ф., тапшыруны эфирга кадәр тыңлап, барырлыкмы, түгелме икәнен хәл итә.

— Бер кеше генә хәл итә торган эшкә алына алмыйм мин, Рокыя апа, куркам.

— Нәрсәсеннән куркасың? Премьерага кадәр 3-4 тамашачыдан «Тукай» спектакленнән ни көтүләре турында сорыйсын да премьерадан соң шулардан ук канәгать калганнармы, юкмы сорауларына (мактатыбрак) җавап аласың. Тәнкыйтьтән качарга тырыш. Безнең театр тәнкыйтьне кабул итә алмый.

— Бу бит... безнең диплом спектакле, театрныкы түгел...

— Сәхнәдән күрсәткәч, тамашачы өчен һәрнәрсә театрныкы була. Отышлырак ике-өч эпизодны алдан ук яздырып куй. Сайлап алу мөмкинлегең булыр. Калганын Ләбиб аңлатыр...

— Акчасын кайчан бирәләр?

— Эфирда яңгырап, бер айлап вакыт узгач...

— Миңа хәзер үк кирәк иде шул... Гаиләне авылга озатасы бар, яшәп тору

өчен дә... Шулар өстенә фатир хуҗам Нәгыймә апа малайга исем туе уткәрүне уйлап чыгарды.

— Метрикасы юкмыни улыңның?

— Баланың авыруы мулла кушкан исеме булмаудан, ди.

— Гонорар алгач кайтарырсың. Менә сиңа пока яшәп торырлык акча... Санап ал. Хәергә түгел — әҗәткә. Мулла бушка исем кушмас.

— Нәгыймә апа акча «кирәкмәс», дигән иде. Муллага.

— Ай-һай, кайсы мулла бушка исем кушар икән?

— Ул ерактан кунакка кайткан язучы, диде. Зариф атлы. Миңа адаш була.

— Бәшириме әллә? Аны кайткан, дигәннәр иде... Әгәр ул булса — аны обязательно яздыр! Бу безнең олы табышыбыз булыр.

— Кем соң ул? «Нәфисә»нең авторы Бәшировмы? — дидем мин, татар әдәбиятыннан һәм язучыларыннан хәбәрдар булуымны күрсәтергә теләп.

— Мин аның «Нәфисә» дигән әсәрен белмим. «Әнисә»сен укыган идем.

— Анысын мин белмим.

— Сезнең буынга эләкмәгәндер шул. Чуваш кызы турында ул. Аның турында венгр галиме Мессораш заманында мактап язып чыккан иде. Нигәдер, күрмәгәнгә, ишетмәгәнгә сабыштылар, йомдылар. Хәер, безгә анысы кирәк түгел. Син аннан Тукай турында күбрәк сөйләтергә тырыш... Тукайны яхшы белә ул.

...Ләбиб Айтуганов мине күптәнге танышы кебек ачык йөз һәм... мөлдерәмә тулы «стакан» белән каршы алды. Мин репетициядә чакта Рокыя апа аңа минем турыда да, миннән нәрсә көтүе турында да сөйләгән булып чыкты.

— Мин синең белән теге кайтуыгызда ук танышкан идем. Хәтерләмисеңме? Син Минзәлә театрында эшләп киткән кеше, ә мин Минзәләдә укып, профессор булдым...

— Профессор?

— Профессор булмасаң, монда эшләп булмый.

...Шуннан соң ул миңа Бәширигә нинди сораулар бирергә, үземне ничегрәк тотарга кирәген — барысын-барысын остазларча аңлатты да уңыш теләп озатып калды.

Мин Борисковога кайткач, Зариф абыйга бирерсең дип, Нәгыймә апайга чакыру билетын калдырдым.

...Исем кушу мәҗлесен безнең спектакльне комиссиягә күрсәткән көнгә — сәгать кичке бишкә билгеләдек.

«Сдача» — имтиханны да, имтиханнан соңгы сөйләшүне дә зыянсыз гына уздырып, кичке сәгать алтылар тирәсенә Борисковага кайттым. Табигый, исем туе мәҗлесенә өлгермәдем. Нәгыймә апаның «туй»га чакырган кунаклары киткән, таралышкан, Зариф мулла гына мине көтеп калган иде.

«Бәшири», «Бәшири», дисәләр дә, минем өчен ул очраклы бер таныш кына бит. Миндә Батулла зирәклеге дә, Фәрваз Миңнуллиндай алдан күрүчәнлек сәләте дә юк — радио өчен кирәк, димәсәләр, бу карт белән сөйләшеп утыру ихтыяҗы да булмас иде. Түзәргә булдым. Сүз башлаганчы, магнитофонымны җайга салырга керештем. Җайладым, «запись» дигән кнопкасына бастым...

— ...Әллә ялланып та өлгердең?

— Кемгә?

— КГБга булмый кемгә булсын...

— Радиотапшыру өчен сездән интервью алырга ялландым. Радиога.

— Алар җаен таба белә... Әйдә, тапсыннар, яздыр.

— Ә сез җайсыз кешеме?

— Миндә тәкәбберлек юк.

— Анысы ни була?

— «Гордыня», ди урыслар.

— Сезнең кебек әдәбият аксакалыннан интервью алу белән горурланам икән — бу гордынямы?

— Алты яшьлек кунак килсә, алтмыш яшьлек кунак ит, — ди китап. Син килешкән, сөйләшкән вакытка кайтмадың. Бу китапча да түгел, заманча да түгел.

— Кайсы китапча түгел?

— Ә син кайсы китапларны беләсең?

— Үзем укыганнарны.

— Алар арасында Коръән бармы?

— Коръән безнең библиотекада юк шул.

— Күңелләрдә булырга тиеш китап ул.

— Безнең күңелләрдә әлегә дөнья гыйлеменә ирешү теләге... Имтиханнар, диплом спектакльләре... тамак, гаилә...

— Бер-берләренә комачауламый ич алар.

— Аларга комачаулау күп төрле.

— Ничегрәк җиңәсез соң?

— Тукайча инде: «Жырлап торам, торган җирем тар булса да. Курыкмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да; күкрәк киереп каршы торам, миңа милләт хәзерге көн мылтык — ук атар булса да»...

— Бүген Тукайга ук атучы юк. Кирәксә дә, кирәкмәсә дә мактау да, табыну гына. Тукай бүген яңа пәйгамбәр. Аңа табынмаучыны гаепләп, дошман ясау гадәти бер алым... Әйе... нишлисең, заманның яман чире.

— Аңа тиң шагыйрь юк бит.

— Берәүнең бугазына басып, икенчене күтәрүне күрсә, мәрхүм Габдулла үзе түзә алмас иде.

— Бу кемгә кагылышлы?

— Иҗат дөньясындагы һәркемгә. «Не сотвори себе кумира», дигән бер даһи. Чөнки — «иң яхшы» бәһасе — яхшылыкка омтылуның дошманы ул.

— Тукай дошманнарын бик тиз таный алган. Аларның күбесе дус кыяфәтендә булгач, тану авыр бит...

— Мәрхүм яза: «...юк изге эш ятканда да, торганда да; эш кушарга каршыма һәрдәмдә шайтаным килә. Нәрсә күрдем бу җиһанда? Ни бетердем? Уйласам: алдыма чын эз вә юлдан читкә тайганым килә. Жырлыймын, ләкин җырымнан файда бармы халкыма? Бер мәләктән яки шайтаннанмы илһамым килә?»

Шагыйрь хаклы: аның бер шигыре мәләктән булса, икенчесе — шайтаннан. Спектаклегезнең умыртка сөяге шушы каршылыкны исәпкә алып төзелергә тиеш иде. Ә сез аннан социалист ясарга тырышкансыз.

— Аның коммунистлар үз итәрлек шигырьләре дә күп.

— Юк! Габдулланың тормыш театрындагы уйнаган рольләрен яхшы беләм мин. Мәхдүмнән коммунист ясарга тырышу коммунистлар шөгыле генә.

— Ә ни җитми аңа коммунист булырга?

— «Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем, күр, ни рәвешле тулган иман берлә Коръән күкрәгемә», — ди Габдулла үзе турында үзе... Ягъни шигыренең берсендә. Шунысы игътибарга лаек: ничә шигырь язган булса, аларның һәркайсының үз Габдулласы.

— Мәсләксезлек түгелме бу?

— Мәсләкләр төрлелеге! Аларга ирешү өчен, бер шәхескә биш кеше гомере бирелсә дә җитмәс иде.

— Шагыйрь Габдулла Тукай белән гражданин Тукаев Габдулла «ике сынар бер кием»ме?

— Ул «сыя алмый андый шартлар, фани дөнья вакытына, башын бөксә — зур җинаятьләр олуг җан хаккына»...

— Ишеткәнем дә, укыганым да бар.

— Боларны сезгә кемнәр ишеттерә инде? Яһүдиләрме?

— Күбесе шулардан...

— Татар әртистләрен Мәскәү яһүдләре укытсын, диген, ә, вәт заманнар...

— Чын яһүди түгел алар...

— Яһүдилек куркыныч түгел, милләтен яшергәннән саклан, ди китап.

— Алар үзләре безне саклый.

— Чөнки сез аларга кирәк, алар сезгә түгел.

— Алар безне генә укытмый, безнең белән янәшә төрле милләт студияләре белем ала.

— Ничек өйрәтә инде алар сезне мөнбәр теленә?

— Сәхнә мөнбәр түгел.

— Ә менә Мөхтәр абзаң «сәхнә — мөнбәрнең энесе», ди торган иде.

— Мөхтәр? Кем ул?

— «Галия» шәкерте Мутин. Әмин Зөбәеров, Фәттах Латыйпов белән алар Өфедә башкорт театрын оештырдылар. Мәскәүдә укымасалар да, гаҗәп артистлар иде, гыйлем иияләре иде.

— «Үлгән сыер сөтле була»... Хәзерге театрда да мәсәлчә Шамуков кебек талантлар бар.

— Тагы кемнәрне атый аласың?

— Хәлил әкә Әбҗәлиловны. Гаҗәеп актёр диләр.

— Аларга ияреп, син дә шулай дисеңме?

— Мин генә түгел — барыбыз да әйтә.

— Аның гаҗәплеге нидә?

— «Король Лир»да Корольне уйный...

— Татар тамашачысына бүген «Король Лир» бик кирәк идеме?

— Аның «Хужа»сы, «Биктимер»е дә бар ич.

— Ит юкта гөмбәләр, дисәңче...

— Безнең «Тукай»да ул авыл крестьяны, күргәнсездер...

— Шәһәр крестьяны да буламыни?

— Ул якларын тикшермәдек без.

— Кай ягын тикшердегез?

— Дусларын, дошманнарын.

— Аның иң якын дусты — Фатих Әмирхан. Ул сезнең спектакльдә юк. Аның урынына Галиәсгар абзыйны кертәсез. Ялган бит! Ул чакта Галиәсгар абзый Казанда да юк иде. Габдулла башта миңа килде, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә. Шәһәрне белми. Адреслары буенча мин йөрттем аны. Күчтәнәчләр таратты.

— Күрәсең, авторга андый фактлар кирәк булмагандыр.

— Спектакльдәге бер күренеш тә чынбарлыкка таянмый. Барсы да автор хыялыннан. Хакимият заказы буенча.

— Пьесаның авторы Тукайның шигырьләренә таяна, шулардан импульс ала.

— Анасының кабер ташын йомшак диган Тукай солдатка каралу өчен авылга кайткач (Каенсарга): «Күз яшен дә кипмичә, егълап вафат булган әни! Гаиләсенә җиһанның ник китерден ят кеше?!» — дип язган Тукай, мөмкинлеге була торып, Соснага, анасының каберен зыярат кылырга бармый. Гаҗәп түгелме? Ул чакта әле Шакир хәзрәт исән. Мәмдүдә турында күп нәрсә сөйләгән булыр иде ул шагыйрьгә. Юк инде — шагыйрь үзе бер дөнья, тормыш бөтенләй башка шигырь. Тукай кебек талантлар турында язганда, ялгансыз да материал җитәрлек. Аның Камил Мотыйгый белән мөгамәләсе үзе генә дә бер драмалык.

— Камил Мотыйгый аның дошманымы?

— Кем шагыйрьнең дошманы, кем дусты булганны бездә обком хәл итә. Әгәр Камил аның дошманы икән — нигә спектакльдә ул юк соң? Билгесез Мәхмүдидән дошман ясап маташканчы, минем белән булган конфликтны кулланса да, отышлырак булыр иде. Кулланмый. Чөнки бәхәснең асылын белми. Белгәнен белдерергә курка.

— Спектакльдә бер җыелма шагыйрь образы булу житкән, дигәндер.

— Кем ул җыелма образ?

— Бикчәнтәй. Батуллин уйнады ул рольне.

— Андый шагыйрьне тарих белми.

— Галимжан Ибраһимовны күздә тотып язылган образ, диделәр.

— Галимжан — Габдулланың дусты. Дошманы дигән ялган хәбәрне дошманнары тарата!

— Ә Мәхмүди? Шәрәфләрнең берәрсеме?

— Бәлки Хөсәенов яисә Кәримовларның берәрседер? Сезгә аны Әхмәт Фәйзинең үзеннән сорасагыз да әйтә алмас иде. Чөнки Тукайга караш матбагачылар тарафыннан гел җылы булды.

— Сезнеңчә, Тукай әйбәт тормыш, мул тормыш кичергәннән, яшьли үлеп киткән булып чыга.

— Әйбәт тормышта яшәү ул — узганнарга һәм киләчәккә таянып, бүгенге тормышны төзү мөмкинлегендә. Тукайның андый мөмкинлеге бар идеме? Бар иде. Ләкин Габдулланың бөтен көче, таланты булганны җимерүгә юнәлгән иде. Кеше үзенең кайдалыгын һәм кая таба баруын белсен өчен, каян килүен дә яхшы белергә тиеш. Киләчәк узганнарсыз һәм хәзергесез була алмый. Тукайда киләчәк юк иде. Шигъриятендә аның бунт та, кире кагу, сүгү.

— Аның шигърияте белән рухланып, без киләчәкне төзибез.

— Ниндиен?

— Коммунизм дигәнен.

— Шәһәр карап йөргәндә, сабын фабрикасы янындагы ашханәгә кереп чәй эчмәкче идем. Гардеробта торган ханым клиентларның киемнәрен ала да, номер бирми генә, кая эләксә, шунда ташлый. Мин номер таләп иттем. Бирмәгәч, мөдирне чакырттым. Бу хәлнең шәхестән көлү, аны мәсхәрәләү икәнен аңлатмакчы идем. Мөдир әйтә: «Югалган стаканнар өчен кем түли?» — ди. Имеш, кесәләренә яшереп стакан урлыйлар икән! Көлке! ...Урамдагы мичкәдән сыра саталар. Чираты — бер тыкрыктан икенчесенә кадәр. Шулар белән коммунизм төзү турында сүз алып барудан ни мәгънә?

Тоталитар җәмгыятьнең череп таркалуы мисалы бу. Таркалсын! Үзенә күрә мәслихәт күренеш! Әмма дә ләкин сез сүтәргә тиеш җәмгыятьнең баганалары бик нык, бик тирән казып утыртылган. Ә үзегез төзи торганына нинди багана кирәген дә белмисез. Сезнең «Тукаегыз» «беләбез», дип сөйләнү генә ул, үпкәләшмик, улым.

— «Тукай» — тарихи әсәр.

— Тарихны сәхнәдән күрсәтеп булмый. Шул чорның әхлакый проблемаларын бәрелештереп, чын көрәшне күрсәтергә кирәк. Көрәштә генә холыклар ачыла.

— Һәр көрәштә җиңеп чыгучысы була. Җиңүчене «герой», диләр. Тукай җиңүче бит?

— Тукай герой түгел — шагыйрь, чын шагыйрь. Эчендәге — тышында.

— Аның геройлыгы шигырьләрендә.

— Ә пьеса авторының геройлыгы нәрсәдә?

— Вакыйгаларның чынбарлыкка тәңгәллегендәдер.

— Спектакльдә чынбарлыктан качылган шул.

— Персонажны тулырак ачар өчен, аннан ерагаерга кирәк, диләр бит.

— Ерагаю — аны бөтенләй югалту түгел... Театрның шигъри тамырлары корудан бу. Тычкан койрыгына тубал тагып, мәчене куркытырга маташудан. Шигъри җанлы сәхнә геройлары юк бүген театрларда.

— Сезнеңчә ничек: безнең спектакльгә тамашачы йөререме?

— Спектакльнең эчтәлеге аны караучыга бәйле. Сәясәттән чыккан эчтәлектә могҗиза булмый. Кеше тамашадан могҗиза көтә. ...Явызлык кулланып, игелек кылып булмый. Сәхнәдән халыкны бер кешенең икенчесен үтерүенә кул чабарга өйрәттеләр. Тукай авырып үлә, революция юк...

— Әйе, «Тукай»да революция юк, ә нинди көчле алкышлар яңгырады! Бу могҗиза түгелмени?

— Әгәр сезгә шундый могҗизалар кирәк икән — алар күп булсын, еш булсын, спектаклегез озак барсын! Миннән теләк шул.

— Безнең әле тагы бер ел укыйсы бар. Маяковскийның «Мунча»сын, Коләхмәтовның «Ике фикер»ен әзерлибез.

— Кем кушуы буенча?

— «Мунча»сын укытучылар сайласа, «Ике фикер»не Йосыпов абый.

— Анысы кем тагы?

— Режиссёр.

— Андый режиссёрны белмим. Габдулла Кариевны беләм...

— Йосыпов абый да Габдулла.

— Кариев Коръәнне яттан белә иде.

— Артистның төп эше шул ятлау инде.

— Ялгышасың. Һәр иҗат әһеленең максаты — иҗатында яңа сүз әйтү. Тутый кош булу түгел.

— Тутый кош кеше әйткәнне кабатлый, ә артист автор язганны үзенчә аңлата.

— Дүрт ел уку дәверендә күп ятладыңмы кеше язганны?

— Укырга кергәндә, Фатих Кәримне ятлап сөйләгән идем, инде менә Әхмәт Фәйзине...

— Фатих Кәримине яттан белүең бик мәслихәт. Аның исемен мәктәпләрдә телгә алалар идемени?

— Телгә алмасалар, кулга бирмәсләр иде. Аның «Разведчик язмалары»н укымаган малай калмагандыр авылда.

— «Салих бабайның өйләнүе», «Шәкерт белән студент» дигән әсәрләрен укымадыңмы?

— Шәкертләр тормышын каян белсен ул? Андый әсәргә ышанмыйм мин.

— Ник?

— Соң ул бит 15 яшеннән комсомол! Педагогия, җир төзелеше техникумнары студенты. «Азат хатын», «Атака» журналларынын җаваплы секретаре! 1933 елдан Татгосиздат редакторы, Язучылар союзы әгъзасы, 1941 елдан җиңү язына кадәр хәрәкәттәге Армиядә! Фронтовик шагыйрь!

— Фатих Кәримиме?

— Әйе!

— Синең Фатих Кәрим турында шулай тәфсилле белүең, аны яклавың мактауга лаек. Әмма аннан да олы шәхес Фатих Кәримине белмәвең булачак сәхнә әһелен бизәми, улым. Сине генә түгел — буыныгызны төссез итә. Фатих Кәрими Истанбул дарелфөнүнен татарлардан беренче булып бетереп кайтканда, Фатих Кәрим әле тумаган да. Фатих Кәрими — беренче татар матбагасын оештыручылардан ул. Аның редакциясендә «Вакыт» газетасы,

«Шура» журналлары чыга. Шул чордагы Оренбургның барлык милли газета-журналлары аның матбагасында басыла. Ә сезнең Фатихыгыз үз вакытының хакимият сандугачы булса, безнең Фатих — милләт хадиме.

— Тукай көлеп язган Кәримиме ул? «Чүкеч» редакторы Тимершаех Саллавийның бабасы?

— Тукайга ияреп, үзең белмәгәннән көлү — наданлык.

Хәер, сезне гаепләү гөнаһ булыр. Сез — мөстәкыйль фикерләү сәләтен югалткан, көтү булып яшәргә, көтүгезчә уйлап, көтүгезчә сөйләргә күндерелгән буын. Үзең өчен булмаса, нәселең өчен һәрнәрсәгә үз фикереңне, үз карашыңны әйтеп калдырырга тырыш.

Кемгәдер ияреп, башканы хурлама да, мактама да.

Тәнкыйтьлисең икән — ышандырырлык нигезлә. Көнчел сүзе диярлгә урын калдырма. Дөрес сүзгә дуслык терәк түгел, ә ялганга дуслык кирәк түгел.

Сез — гомум ялган чорында иҗат итәргә тиешле буын. Алла ярдәм бирсен үзегезгә.

— Дөреслек юл таба башлады ич. Хаксызга хөкем ителгәннәр котылып кайта, элек тыелган әсәрләр кабат басыла...

— Зуррак ялганга күзне томалап, халыктагы сизгерлекне зәгыйфьләтү өчен генә кылынган гамәлләр алар.

— Әгәр сезгә ышансаң, дөньяда яшәүдән ни рәхәт, ни файда?

— Ә син файда өчен дип яшәмә, дөреслек өчен яшә!

— Ничек?

— Тукайча! Тукай — дөреслек өчен гомерен биргән шагыйрь! Үз дөреслеге өчен.

— Минем дөреслек өчен гомер бирәсем килми. Дөреслек өчен яшисем, иҗат итәсем килә!

— Амин, шулай булсын!..

...Менә бу текст Зариф Бәшири белән булган әңгәмәнең магнитофон тасмасыннан кәгазьгә күчерелгән караламасы нигезендә язылды. Монтажлыйм дип күп нәрсәне җуйдыруым, югалтуым хәтеремдә.

Әдипкә 72 яшь, миңа 25 яшь булган. Хәзер миңа 79 яшь тулып килә. Ярты гасыр элек язылып, могҗиза белән генә сакланып калган текстны бүген редакцияләүнең дә, «менә» дип күтәреп чыгуның да әһәмияте юк. Бу — бер хатирә.

...Тапшыруның эфир вариантын бераз кыскартырга Ләбиб әфәндегә калдырдым да үзем хәрби бурычымны үтәргә киттем.

Китәр алдыннан Рокыя апа телефон аша: «Эфирга кайчан баруын Ләбибкә шалтыратып белерсең, спектакльне күкләргә чөйгән булсагыз да, Ф.Ф.гә ошады, заман идеологиясенә җавап бирә», — диде.

...Без — щепкинчы егетләр Вышний Волочек шәһәрендә бер айлык хәрби хезмәт узып ятабыз. Көн дә диярлек шалтырата торгач, тапшыруның кайчан барасын, ниһаять, беллем. Инде кайда, ничек тыңлау проблемасын гына чишәсе калды. Анысына командир-полковник Рябовал ярдәм итте. Хәрби шәһәрчектә яшәүче капитан Козловның радиоалгычы Казанны гына түгел — Лондонны да «тота», ди. Ниһаять, бәхет миңа да елмаячак: тапшыруым яңгыраячак!

Тапшыру барырга тиеш көннең тиешле сәгатендә, алдан сөйләшенгән офицер фатирына радио тыңларга киләм.

...Офицерның хатыны радио кабызды да тәрәзә пәрдәләрен алыштыра башлады. Өен бизи, янәсе!

...Алюминийдан ясалган баскычка басып, күтәрелә дә бу, тимер элмәкләрен баугa элэктерә. Еш кына йә элмәге кулыннан идәнгә төшеп китә, йә пәрдәсе.

Ханым шунда мина: «Помоги, пожалуйста», — ди. Мин баскычка таба карарга да тартынам. Чөнки ханымның өстендә халат кына, ә халаты каптырмаларына каптырылмаган — ачылып-ачылып китә дә, бөтен дөньясы ачыла...

...Мин, гөнаһлы хискә бирелүдән бигрәк, офицер абзый кайтып керүдән куркып, «шым» гына утырам. Ханым һаман нәрсәсендер кулыннан ычкындыра да һаман: «Пожалуйста, смелее», — ди. Шулай утыра торгач, тапшыру вакытының 7 минуты үткән булып чыкты... Ә эфирда безнең тапшыру вакытында Тукай монологы урынына Хрущёв сөйли иде. (Соңыннан ачыкланунча, бу — Никитаның совнаркомнар оештырырга кирәклеген мактаган 4 сәгатьлек нотыгы булган икән. Аны Советлар Союзының барлык радиостанцияләре буенча иртә-кич ике көн тапшырдылар. Шул чор программаларын архивтан табып тикшерергә була.)

...Никитаны мин шушы хәлдән соң гомерлеккә дошман күрдем. Беренчедән, ул минем «егетләнү» карьерама кара таракан булса, икенчедән, журналист буларак беренче эшемне эфирга «уздырмады».

...Бер айлык хәрби хезмәтемне уздыргач, Казанга кайттым. Гонорарымны да алырмын, тапшыруны да тынлармын дип өметләнгән идем.

«Бармаган тапшыруга гонорар бирелми!» — диделәр. Тапшыру яздырылган магнит тасмасы икенче бер тапшыру өчен җуйдырылган, Ләбиб ялга киткән, текстлар сакланмаган — ташланган булып чыкты.

Барысы өчен дә Хрущёв җаваплы, жалобаңны аңа язып җибәр! — дигән көлешүгә, үземә дә кушылырга туры килде. Хәерлегә булсын, диештек тә оныттык.

...Үтте еллар. Артист булып кайттык. Режиссёр булып радиода да, телевидениедә дә эшләдем. Минем өчен Тукай шәхесе һаман чишелеп бетмәгән объект булып кала бирде.

Телевидениедә Тукай турында 4 спектакль куйдым, күп серияле 2 фильм төшердем. Байтак чыганакларга таянырга туры килде. Арада Зариф Бәширинең «Замандашларым белән очрашулар» дигән китабы да бар. Ул аерым игътибарга лаек.

...Мин аны минем белән очрашуы турында язмаганмы дип комсызланып укыдым. Әлбәттә, язмаган иде.

...Теге чакта (1960 ел) «Тукай» спектакленә кагылышлы интервьюны яздырып, магнитофонны сумкасына салып бикләгәч, гөбәдия ашый-ашый сөйләшеп чәй эчтек. Шунда ул китабын бастырырга кайтуы турында әйтүе хәтердә. Ә мин — мәнсез бер студент — кызыксынмаганмын. Ә ул «бабай», ничектер, богаулардан ычкынган, нindидер тоткыннан котылган кешедәй тоелды. Сизәм: нәрсәдер әйтәсе килә, нигәдер кыенсына шикелле.

Шунда мин, кыюлыгымны җыеп, сорыйсы иттем:

— Зариф абый, шулай да Тукай белән дошманлашуыгызның сәбәбе нидә?

— Берничә сәбәбе бар инде аның. Ин элек ул Тукайның холкына бәйле. Кешене хакарәт итү, кимсетү аңа берни дә тормый иде. Шунда ук, онытылып, ул сине мактый да башлый иде. Бу төпле ата-ана тәрбиясе алмаудан булгандыр, дим. Ана «чү!» диюче юклыктан. Аннары безнең һәммәбезнең дә хезмәт иткән эш урыныбыз, хуҗабыз бар бит. Хуҗалар бер-берләре белән көндәшләр. Без Тукай белән үзара яхшы мөгамәләдә идек. Мин Фатих Кәриминең кияве Тимерша Саллавийга (Соловьёвка) эшкә күчкәч, килеп чыккан әдәби каршылыклар шәхес каршылыкларына әверелде. Бәйләнешләр киселде, дуслык өзелде, тәнкыйтьләшү башланды. Ләкин бу дошманлашуга сәбәп түгел иде. Нишлисең, без яшьләр, бер янакка сукканда, икенчесен куеп булмый, җиреләсе килми, каһәрен.

...«Шура» журналының әдәби бүлегендә эшләгәндә, мина Дәрдмәнд, үзе чакырып, «Вакыт» газетасын тоттырды. Анда: «Иң алдынгы шагыйрьләр кем?» — дигән сорауга Габдрахман Сәгъдинең җавабы басылган икән. Ул: «Тукай белән Бәшири», — дигән җавап биргән.

— Моңа ничек карыйсың? — ди Дәрдмәнд миңа.

— Сәгъдинең җавабынамы, куелган сораугамы? — дип сорауга каршы сорау белән җавап бирдем мин.

— Сорауга, — дигәч, мин аңа:

— Тукай белән Дәрдмәнд, — дидем.

Әмма мине Дәрдмәнднең җавап сүзе һаман уйландыра. Ул: «Сәгыйть Рәми», — диде. Тукай урынына куеп әйттеме ул Сәгыйтьне, үз урынынамы? Зариф урынынамы? Шуңа әлегә кадәр җавап таба алмыйм. Һәркемнең үзеннән зуррак булып күренергә теләвенә бер мисал гына булса да бу — беләсе килә, каһәрең, күңелне корт кимерә һаман...

...Мин шунда, акыллы булырга тырышып: «Дәрдмәнд, Зариф, Тукай» — димәкче идем, соңгы сүзне Зариф абый үзе әйтте: «Дәрдмәнднең Габдрахман Сәгъдигә каршы барасы килмәгәндер, мөгаен, һәр чәчәкнең үз исе, үз төсе булуын Габдрахман абзый ышандырырлык язган». Бу эпизод аның истәлекләр китабында да бар. Икенчерәк төрле язылса да — бар. Шуны Зариф Бәширинең үз авызыннан да ишетүем белән горурланам бүген.

...Бу очрашуларга инде ярты гасырдан артык гомер узган. Кулымда Бәширинең шул истәлекләр китабы. Анда ул кемнәр белән ничек очрашуы турында яза. Бик кирәкле, кадерле мәгълүматлардан тыш, берьяклылары да, субъектив карашлардан чыгып язылганнары да бардыр, әлбәттә. Әмма алар — тарих, алар булган, алар кирәк, алар кадерле.

Нинди кеше белән очрашып та, мин аңа кызыклы сораулар бирә белмәгәнмен! Надалык! Әгәр хәзер очратсам, «ни сөйләшер идек икән?» — дигәнгә җавабым: «Син хаклы, адаш абый», — дияр идем. Кая карама, кемне тыңлама — ялган мактау, мактану, макталу. Тукай дөреслекне «суга баткан», дисә, без исә, ул төшенчәнең хәзер су төбендә дә, куктә дә юклыгын күрәбез. Эшебез шул. Ышанасыңмы, Зариф абый, бүген «дөрес» дигән сүз кулланыла икән, ул «ялган»ны аңлата. Шулай булса да яшәү — яшәүдән әйбәтрәк. Артистлыкка уку дәвам итә. Бусы чын дөреслек, дияр идем.

...Милләтебезнең мәдәни тормышында нинди генә шәхесләр яшәп мәңгелеккә күчмәгән?! Алар турында без күп белмибез. Мәсәлән, Тукай сүгеп, көлеп язган Ишми ишан чынында нинди булган? Буби мәктәбенең укытучы-мөгаллимнәре аны нигә кунакка чакырып сыйлаганнар?

«Ишморатовлар чәе» дип аталырлык булгач, нинди чәй булган ул чәй? Ә үз замандашларыбыз турында ни беләбез? Мәсәлән, Рөстәм Яхин турында романслар авторы буларак кына беләбез түгелме? Ә бит ул — фаҗигале тормышта яшәп, фаҗигале үлемгә дучар булган шәхес.

Талантлы шәхесләребез бик күп. Һәр тарихи бинаның кирпече гади үзле балчыктан сугылып, мичтә кыздырыла. Шул кирпечләрдән шедевр биналар төзелә; киләчәк буыннарга үзле балчыкның каян алынуы да, кирпечне кемнәр сугып, нинди мичтә яндырылуы да, бинаны кемнәрнең ничек төзүе дә кызыклы.

Артист буласы килгән кеше өчен бер мәгълүмат та артык түгел. Ә сүзнең озынга китүе һәр һөнәр иясе өчен артык. Бигайбә.

## *«Казан утлары» архивыннан*



*СССР язучыларының I съезды делегатлары; беренче рәттә (сулдан уңга): Кави Нәҗми, Алексей Толстой, Максим Горький; икенче рәттә: Хәсән Туфан, Гомәр Толымбай, Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Нигъмәти. Август, 1934 ел.*



*Бауман урамында урнашкан атаклы Матбугат йорты. Үткән гасырның утызынчы еллар уртасыннан сиксәненче еллар уртасына кадәр бу бинада Татарстан Язучылар оешмасы урнашкан иде.*



*Ватан сугышында катнашкан язучылардан бер төркем. Беренче рәттә (сулдан уңга): Әдип Маликов, Сибгат Хәким, Мәхмүт Хөсәен; икенче рәттә: Шәйхи Маннур, Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Ерикәй, Вадим Земной; өченче рәттә: Мөнир Мазунов, Әхмәт Исхак, Шәрәф Мөдәррис. 1948 ел.*



*Бу фоторәсемгә нәкъ 50 ел. 1964 елның 27 мартында Язучылар оешмасы тарихында беренче тапкыр әдәби ел йомгаклары дип аталган зур җыелыш үтте. Ике көн дәвамында барган шул тарихи җыеннан соң төшерелгән фотосурәт. Беренче рәттә (сулдан уңга): Роберт Бикмөхәммәтов, Ләбибә Ихсанова, Афзал Шамов, Мансур Хәсәнов, Гомәр Бәширов, Хәй Хисмәтуллин, Нәкый Исәнбәт, Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Мирсәй Әмир, Гариф Гобәй, Ибраһим Гази; икенче рәттә: Баян Гыйззәт, Габдрахман Әпсәләмов, Мария Елизарова, Әнәс Камал, Зәки Нури, Әминә Бикчәнтәева, Нәби Дәүли, Әдип Маликов, Әхмәт Юныс, Нури Арслан, Газиз Иделле, Фатих Хөсни, Габдрахман Минский, Әмирхан Еники; өченче һәм арттагы рәтләрдә: Зәет Мәҗитов, Хәй Вахит, Рафаил Төхфәтуллин, Идрис Туктар, Гариф Галиев, Гали Хуҗи, Госман Бакир, Илдар Юзеев, Самат Шакир, Нил Юзиев, Шәүкәт Галиев, Барлас Камалов, Газиз Мөхәмммәтшин, Анатолий Мелузников, Нур Гыйззәтуллин, Рафаэль Мостафин. Кызганыч, татар әдәбиятының күәтен билгеләгән бу зур көчле төркемнең (фотода алар кырык ике әдип) бер генә вәкиле дә бүген безнең арада юк инде...*

# ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕН ТӨЗҮ ЮЛЫНДА

Зур максатлар, якты өметләр белән төзелгән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, профессор Нил Юзиев житәкчелегендәге вакытлы иҗат төркеме Тукай энциклопедиясе төзүгә 1993 елның ахырында керешкән иде. Шуны хәтердә яңартсак, бу фундаменталь фәнни хезмәтне гамәлгә кую юлында беренче адымнар ясалудан соң шактый күп сулар агуы — егерме ел гомер узганы күренер. Димәк, эшнең барышыннан хәбәрдар булмаган затлар аның әле һаман да дөнья күрмәвенә бүген инде ризасызлык та белдерә ала. Кайберәүләр хәтта ки уникаль Лермонтов энциклопедиясен булдыру өчен нибары 18 ел гына сарыф ителүенә төртеп тә күрсәтер...

Күпләргә мәгълүм, Петербургтагы Рус әдәбияты институтында (Пушкин йортында) әзерләнгән һәм 1981 елда басылып чыккан Лермонтов энциклопедиясе бүгенгәчә бу типтагы хезмәтләр арасында иң камиле, иң уңышлысы булып кала (1999 елда кабатлап бастырылды). Билгеле ки, рус әдәбият белемендәге хәл-әхвәлләрне яхшы белгән Нил Юзиевнең Тукай иҗатын өйрәнүчеләрнең сафы лермонтовчы галимнәрнеке белән чагыштырганда күпкә кимлеген, татар галимнәрендә энциклопедияләргә урнаштырырлык мәкаләләр язу тәҗрибәсе дә әлләни зур булмавын белә торып та, Татарстанның үз Фәннәр академиясенең координацион үзәк сыйфатында эш йөртәчәгенә дә өмет баглап, Тукай энциклопедиясе өчен үрнәккә Лермонтов энциклопедиясен сайлап алуы аклана иде. Бөек рус шагыйренең шәхесе һәм иҗаты ни рәвешле, ничек мондый уникаль хезмәттә гәүдәләнешен өйрәнү нәтиҗәсендә, ул күләме 100 табаклы Тукай энциклопедиясендә иңләп алынырга тиешле төп сигез тематик юнәлешне билгеләп чыкты һәм моның өчен 2800 ләп мәкалә һәм белешмә (якынча 2400 бит) язу кирәклегенә төшенде. Башлыча Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләре катнашында энциклопедиянең лөгатьлеге («словникы») әзерләнеп беткәндә, Н.Юзиевнең кинәт вафат булуы (1996) аркасында, ул лөгатьлек бары тик 1998 елда гына кулъязма хокукында күбәйтелеп таратылды; бераздан, Фәннәр академиясенең ул чорда Мансур Хәсәнов житәкләгән әдәбият белеме буенча фәнни советында фәнни җәмәгатьчелек һәм язучылар хозурында тикшерүгә куелып, бу эшне башларга фатиха да бирелде.

Күрәбез, шуннан бирле дә 16 ел чамасы гомер узган... Алайса инде...

Энциклопедияләр төзү тарихын ачыкларга омтылучылар XVIII гасыр фәненең җимеше булган Чемберс (Англия) һәм Дидро һәм Д'Аламбер (Франция) хезмәтләрен эчтәлек һәм структурасы ягыннан бүгенге көндәге энциклопедияләргә бик якын торуын әйтәләр. Ике-өч гасыр эчендә инде аларның нинди генә төрләре барлыкка килмәгән. Бүгенгебезгә кайтсак, без моны бигрәк тә ачык күрербез. Узган гасыр ахырларында суверенитет алуга ирешкән Татарстаныбызда энциклопедияләр төзү мәсьәләсе бик житди бурыч сыйфатында алга килеп баскан иде. Фәннәр академиясе житәкчелеге дә, җәһәтлек күрсәтеп, махсус фәнни структура — Татар энциклопедия институты булдырды. Бүген ул универсаль характерда булган татар һәм рус телләрендәге алты томлы «Татар энциклопедиясе» төзүне тәмамлау алдында

тора. Соңгы елларда Татарстанда төбәк (районнар), тармак энциклопедияләре төзүгә дә омтылыш көчәйде...

Энциклопедияләр арасында аеруча мөһим бер юнәлешне исә персональ энциклопедияләр тәшкил итә. 1914 елда андыйларны күренекле галимебез, үзе дә энциклопедиягә тартым хезмәтләр авторы Риза Фәхретдин хосусый энциклопедияләр дип атаган иде. Россиядә, СНГ илләрендә башлыча әдәбиятчылар тарафыннан Шукшин, Шолохов, Пушкин, Бунин, Островский, Нәвои, Абай, Салават Юлаев һ.б. персональ энциклопедияләре тудырылган инде. Башкортстанда Мәҗит Гафуриныкы да әзерләнә дип беләбез.

Искәртүебезчә, Тукай энциклопедиясен төзүгә Н.Юзиев җитәкләгән төркем исә нәкъ менә Лермонтов энциклопедиясендә чагылган уңышлы якларны искә алып кереште. Шагыйрь 1908 елларда ук үзен бик хаклы рәвештә Пушкин, Лермонтовлар янәшәсендәге йолдыз итеп хис иткән иде (шигырь 1926 елда гына басыла). Татар милләте яшәгәндә, әдәбиятыбызның чыннан да беренче зурлыктагы йолдызы булып һәрчак балкып торачак Тукайның хосусый энциклопедиясен төзергә алыну һәм мона кадәр «Татар әдәбияты тарихы»ның алты томлыгын язуда җитәкчелек итеп, зур тәҗрибә туплаган Н.Юзиев инициативасы галим-голяма тарафыннан хуплап каршы алынды. Дөрес, моның кебек зур эшләрне фәнни учреждениеләрнең тикшеренү планнарына кертмичә генә башкару уңайлы юл түгел иде. Әнә, махсус институтыбыз бар ич, диючеләр дә булгандыр. Ләкин 1939 елда татар халкының әдәби һәм сөйләм телен, җиде-сигез гасырлык әдәбият тарихын, халык авыз иҗатын, тарих-этнографиясен тикшерү максатында төзелгән институтның әдәбиятчылары һәм текстологлары ул елларда XX гасыр татар әдәбияты тарихын язу һәм дә җитди текстологик эш — Гаяз Исхакыйның унбиш томлы «Әсәрләр»ен төзүгә алынганлыктан, әлеге институт Тукай энциклопедиясен төзүне үз өстенә ала алмады. Хасил булган ситуациядән чыгуның бердәнбер юлы — төрле-төрле фәнни учреждениеләрдә, югары уку йортларында эшләүче аерым галим һәм белгечләрнең иҗади мөмкинлекләрен эшкә җигүдә гәүдәләнде. Татарстан Фәннәр академиясе җитәкчелеге, аерым алганда, Мансур Хәсәнов һәм Мирфатыйх Зәкиевнең кулларыннан килгәнчә иҗат төркеменә ярдәм итеп торуларын да басым ясап әйтергә кирәк. Бу аеруча 2006 елгача сизелде — Татарстан дәүләтенең Фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык эшләре фондыннан Татарстан Фәннәр академиясенә бүлеп бирелә торган матди чыганаклардан Тукай энциклопедиясен төзүгә дә елның-елында (әлләни зур булмаса да) өлеш чыгарылды. Соңрак «Мирас» программасы буенча да мөмкинлекләр тудырылды... Әлеге чаралар олы максатка ирешү өчен җитәрлек булмаса да (2008 елда ярдәм сорап Татарстан Республикасы Президентына да мөрәҗәгать ителгән иде), бүген инде Тукай энциклопедиясенең «гәүдәсе» — реаль сурәте шәйләнә...

Сүз башында барлык материалның (төрле зурлыктагы мәкалә һәм белешмәләр) энциклопедиядә башлыча сигез тематик юнәлештә тупланачагы искәртелгән иде. Аларның һәрберсе бик мөһим, барысы да Тукай феноменын, Тукай дөньясын ачуга хезмәт итәсе. Алай да иң әһәмиятлесе, иң җитдие — Тукайның һәр әсәренә дә шәрех язу (фәнни-нәзари ноктадан анализлау). Гомуми саны 770 чамасындагы текстларның һәркайсы диярлек бүген шул рәвешле тикшерелеп чыгылган инде. Бу урында мондый төр мәкаләләр авторлары Тукай шигырьләрен, мәкаләләрен бүгенге заман күзлегеннән тикшерергә күп көч куйганлыкларын әйтеп китәргә тиешмен. Хәер, Институт текстологлары, Тукайның тулы академик басмасын әзерләү вакытында, XX гасыр татар вакытлы матбугатын җентекләп тикшереп, публицистик эшчәнлегенә караган ике дистәдән артык «яңа» әсәрләрен табып алдылар. Алары турында да фәнни фикер әйтелер.

Тукай иҗатын әдәбият белеме, татар иҗтимагый фикере һ.б. тарафлардан якын килеп тәфтишләү ахыр чиктә яңа татар әдәбиятының XX гасырда һәм хәзерге вакытта үсеше-үзгәреше турысында дәлилләрәк сүз йөртергә мөмкинлек бирә. Ачыграк әйткәндә, Тукайның дөньяга карашларын, сәнгатьчә фикерләү хасиятләрен аның лирикасы, сатирасы, иҗат ысулы һәм алымнары, дини-

әхлакый, халыкчанлык, миллилек кебек мәсьәләләргә нисбәттә дә ачарга кирәк. Билгеле ки, моңа тик тоталитар режим вакытларында алга сөрелгән идеологик таләпләрдән арынып, соңгы вакытларда шактый дәрәҗәдә катлауланып киткән әдәбият нәзариясенә нигезләнеп, фәлсәфи-эстетик карашлар белән коралланып кына ирешергә мөмкин булачак.

Өченче тематик юнәлештәге мәкаләләр хәтта ки гади укучының мәнфәгатьләренә дә туры килә торган мәгълүматларны үзендә туплар. Ни өчен аларны язу планлаштырылды? Чөнки без әле бүген дә Тукайның туганнары, якын дуслары, замандашлары белән ике яклы (вакыт-вакыт катлаулы да) мөнәсәбәтләренә караган истәлекләрне, төрле хәбәрләрне бер тирәдә туплап бирә алганыбыз юк. Нәкъ менә хосусый энциклопедия жанры бу турыда объективрак сүз алып барырга мөмкинлек бирәчәк дип уйлыйбыз. Бер гасыр элек булып узган вакыйгаларга таянганда, аларны бүген инде бөтен нечкәлекләре белән тасвирлау кулдан да килмәс. Һәрхәлдә Тукайны гаепләргә дә, акларга да кирәкми. Төрле имеш-мимешләрне, гайбәтләрне читкә куеп, бары тик басма чыганакларда чагылганны гына искә алып язылсын иде ул мәкаләләр.

Фәнни әдәбиятта хосусый энциклопедияләр теге яки бу тарихи шәхес (персонаж) турында моңа кадәр булган эзләнү-тикшеренүләрнең гомумиләштерелгән йомгагы булып тора дигән фикер өстенлек итә. Бу дөрестер дә. Әмма, чынлыкта, эш барышында яңа фактлар чыгып тора, чыганаклар табыла. Мәкалә язарга алынгансың икән, элегрәк әйтелгән фикерләрне тәнкыйть аша уздырырга тиеш буласың.

Тукай кайбер язмаларында әлгәреге заман шагыйрьләре бакчасына таш ыргыткаласа да, аның бөек шигърияте — күп гасыр дәвамында татар әдәбиятында һәм бөтендөнья сүз сәнгатендә җыйналып, тупланып килгән потенциаль егәрне теге яки бу дәрәҗәдә иҗади үзләштерү нәтиҗәсе дә. Һәм бу шигъриятнең бәрәкәтле тәэсирен әдипнең үзеннән соңгы әдәбият мәйданына килгән, аның үсешенә хәл кадәри өлеш керткән татар язучылары һәрчак тоеп яшәделәр, аның шәхесенә, әсәрләренә мөнәсәбәтләрен белдерделәр. Тукай тудырган образ-сурәтләргә нигезләнеп, күпсанлы шигырь, поэма, хикәя, повесть, драмалар иҗат ителде. Шунлыктан энциклопедиядә «Тукай һәм татар әдәбияты» дигән олуг теманың чагылышы да бик урынлы. Әдипнең татар вакытлы матбугаты, «Фикер», «Уклар», «Әлгасрелҗәдид», «Яшен», «Ялт-йолт», шулай ук «Чүкеч», «Бәянел-хак», «Дин вә мәгыйшәт», «Шура», «Вакыт» кебек газета һәм журналлар белән бәйләнешен дә игътибар илә өйрәнеп язу сорала.

Жуковский, Пушкин, Лермонтовлар кебек, Тукай да башка әдәбиятлар хәзинәсеннән файдаланган, әсәрләренә ияреп язган, иҗади тәрҗемәләрен бастырган. Хәтта Касыйм Уралец дигән берәү гаять тенденциоз мәкаләсендә аны тәрҗемәче генә дип кимсетеп тә караган. З.Бәшири дә «Мөтәрҗим шагыйрь» исемле шигырь бастырып үчләшкән. «Эт кеби һаулап яманым, күз йомалар яхшыма», дигән иде шагыйрь бервакыт. Юк, татар халкы аның яхшысына күз йоммады, кайнар уй-хисләрен кемгә караганда да күңеленә урнашырлык рәвештә өйрәтеп биргән чын лирик шагыйрь итеп таныды. Әсәрләре дә күп телләргә тәрҗемә ителде. Билгеле ки, төрле вакытларда, төрле алымнар белән, төрле дәрәҗәдәге сәнгати эшләнештә. Йөздән артык шагыйрь-тәрҗемәче бу гаять үзенчәлекле иҗат өлкәсендә үзләренең сәләтләрен чарладылар.

Тукай әсәрләре белән генә түгел, сәнгатьтә дә яши. Аның образы, иҗат җимешләре театрда, сынлы сәнгатьтә, музыкада һич саекмас илһам чыганагы булып хезмәт итә. Шушы зур байлыкны шагыйрь энциклопедиясендә дә чагылдырырга иде бит. Шөкер, сәнгать белгечләре моны аңлыйлар, эзләнәләр.

Хезмәттә Тукай тормышы һәм дә иҗаты белән бәйле урыннар, аларның Тукай әсәрләрендә чагылышы, шулай ук Тукай кулланган псевдонимнар (аларның саны 65 чамасында) турында да сүз булачак.

Тукай вафатыннан соң узган йөз ел гомер эчендә шагыйрь хакында, шигъри, һәҗүви (сатирик), публицистик мирасы турында бик күп хезмәтләр язылды, әсәрләрен шәрехләгәндә, каршылыклы фикерләр дә әйтелде, бәхәсләр дә булды.

Чынында, без — татарларда Тукай фәне бар. Аны яшәтүгә, үстерүгә өлеш керткән галимнәр (күпләре инде вафат) хакын да хакларга, ягъни аларның фәнни ачыш дип саналырлык хезмәтләренә объектив бәя бирергә иде.

Сүзне озынга сузмыйча гына әйткәндә... Югарыда китерелгән мәгълүматлар укучыга Тукай энциклопедиясенең эчтәлеген, структурасын, шулай ук эшнең барышын күзаллауга җитә яза дип уйлыйм. Кыскасы, әлеге 2800 мәкаләнең 2100е редакцияләүгә әзер. Озакка сузмыйча, калганнарын да язып чыгасы иде.

2016 елда Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулачак. Бу вакытларга әсәрләренең алты томлы академик басмасы инде укучылар кулына барып ирешкән булыр. Олы юбилейга, моннан егерме еллар әүвәлдә уйланылган рәвешен алып, Тукай энциклопедиясе дә басылып чыкса икән. Әмма күптән көтелгән бу 100 табаклы саллы хезмәтне дөньяга чыгарганчы башкарасы эшләр әле бик күп...

2013 елның көзеннән башлап фәнни мөхәррирләр Тукай әсәрләренә язылган мәкаләләрне редакцияләү белән шөгыльләнә. Әмма алар әлегә гомуми күләмнең 20-25 процентын гына тәшкил итә. Иң элек тагын 700 ләп мәкаләне язардай авторлар табасы һәм яздырасы бар. Һәм барысын да редакцияләү, энциклопедиягә кертерлек рәвешкә китерү бурычы тора.

Мона кадәр язылган мәкаләләргә объектив бәяне аларны редакцияләүгә алынган мөхәррирләр бирер. Хәер, хөрмәтле галим-авторларыбыз язганнары белән канәгатьләнеп тормаслар, кайчак үзләре үк яңадан кулларына алып, аларны тулыландырырга, камилләштерергә теләрләр шикелле. Бер өлеше мәкаләләр шактый күптән, хәтта ки узган гасыр ахырында ук язылып, безләргә тапшырылган иде бит. Яшерен-батырын түгел, бу юлларның авторы үзен энциклопедик хезмәтләр тудыруга бик актив катнашкан, бай тәҗрибә туплаган затлардан санамый. Шуна да карамастан, мин авторларның кайчакларда факт-мәгълүматларны урынсыз куллануларын әйтми кала алмыйм. Энциклопедиядә барлык төр мәгълүмат, уй-фикер, бәя, аңлатма-шәрехләмәләр бары тик Тукай шәхесенә, иҗатына бәйлелектә генә бирелергә хаклы. Әйтик, сүз берәр кеше турында бара икән, нигә инде аның кайда туганлыгы, нинди җирләрдә яшәгәнлеге, нинди уку йортларында белем алганлыгы, ә инде орден-медальләре, мактаулы исемнәре турында язып китү бөтенләй урынсыз (Тукай бүләге иясе булуы гына әйтелә). Кайбер мәкаләләр библиографик күрсәткечләр рәвешен ала, гомумиләштереп анализлау җитми. Дөресен генә әйткәндә, һәр мәкалә алынган темага караган барлык төр чыганакларны җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә генә туарга тиеш.

Заһир Бигиев турында «...Милләт яшәдекчә яшәр / Милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар», дип язган Тукай заманында. Бу сүзләр аның үзенә аеруча туры килә. Энциклопедиясе төзелеп басылу исә моны тагын да ныграк исбатлар. Уртак көчебез белән аны бөек шагыйребезнең тууына 130 ел тулу вакытына өлгертсәк иде!

**Зөфәр РӘМИЕВ,**
*Вакытлы иҗат коллективы җитәкчесе,*
*филология фәннәре докторы, профессор*

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ТӨРЕК МОТИВЛАРЫ

Татар халкының ерак гасырларга барып тоташкан сүз сәнгате — бик тә бай, катлаулы һәм каршылыклы күренеш. Ул үзенең тарихи барышында төрле цивилизацияләр, мәдәниятләр, диннәр белән мөнәсәбәткә кергән, алардан төрледән-төрле идеологик, фәлсәфи-эстетик, этик карашларны, әдәби традицияләрне үзләштергән. Урта гасырларда, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы кебек дәүләтләребез булган чорларда ул үзенең югары үсеш — Ренессанс дәверен кичергән. Бу заманнарның Яңарыш символы булып безнең көннәргә архитектура сәнгатендә Сөембикә манарасы килеп житкән. Дәүләтчелегебезне югалтып, шактый гасырлар торгынлык кичергәч тә, XX гасырның икенче яртысында милли тәрәккыят байрагын күтәргән, аны дәүләти төшенчә дәрәҗәсендә күзаллаган мәгърифәтчеләр эшчәнлеге башланып китә, татар халкының Яңа замандагы икенче Яңарыш хәрәкәтенең беренче адымнары пәйда була. Аурупа һәм Россиянең мәдәният, тарих вәкилләре кебек, Каюм Насыйрилар, Шиһабетдин Мәрҗанилар башлап жибәргән бу үзгәрү-алгарышка омтылыш Шәрекъ һәм Гареб мәдәнияте казанышларын ижади синтезлап, монарчы күрелмәгән үсеш баскычына — икенче Ренессанс дәверенә жирлек әзерли. Чагыштыру һәм тарихилык принцибына корылган, татар халкының ижтимагый-рухи яшәешен гәүдәләндерүне максат итеп куйган бу XX гасыр башы Яңарыш хәрәкәтенең нигез ташларын салуга Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, М.Гафури, Дәрдмәнд, С.Рәмиев, Г.Камал һәм башка бик күпләр белән бергә татар шигъриятенең даһие Габдулла Тукай да үзеннән зур өлеш кертә.

Габдулла Тукай (1886-1913) — татар халкының горурлыгы, вөждане, ижтимагый гаделлек идеалларын жырлаучы. Ул — халыкчы һәм милли шагыйрь. Жамал Вәлидичә пафос белән әйтсәк: «Тукаев — татар тарихында мәңге онытылмас исем!», «Татарча сүзләр сөйләүче шагыйрь». Дөрестән дә, Тукай шигърияте, фарсы-азәрбайжан әдәбиятларының бөек шагыйре Низами Гянжәви «Серләр хәзинәсе» поэмасында тасвирлаганча, күкләрнең тугызынчы катында, Аллаһы Тәгаләнең тәхете янында сакланучы «Илаһи кәлям»нән — күзләрне камаштырырлык нур дингезе булган изге Коръәни Кәримнән татар халкына ингән изге сүз сәнгате балкышы иде. Моның шулай икәнлегенә инану өчен туган телебезгә, рухи кыйммәтләребезгә, кылган догаларыбызга мәдхия укыган «Туган тел» шигырен искә төшерү дә житә. Гаяз Исхакый язганча, шагыйрьнең *«И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле // Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы»* дигән сүзләре халкыбызның милли аның, милли хисләрен тәрбияләүче «һимнә», ягъни гимн... Татар әдәбиятының икенче Ренессансы дәверендә халкыбызга Тукай бүләк иткән бу гимн Татарстанда, Россиядә, чит мәмләкәтләрдә гомер сөрүче һәр татар кешесе өчен «изге символ» (Надир Дәүләт) булып тора.

Мәкалә авторы үзе дә моңа шаһит. 1967 елның августы. СССР дигән империянең тимер кысаларында яшәп яткан чак... Көтелмәгән вакыйга: Татарстан хөкүмәте безне — профессорлар Хатыйп Госман белән Мөхәммәт Гайнуллинны һәм дә мине — яшь тукайчыны — Финляндиягә командировкага жибәрде. «Күлләр иле»ндә яшәүче мөһажир милләттәшләребезгә «Тукай жәмгыяте» төзүдә, аның булачак житәкчесе, хокук белгече Гомәр Даһерга (Таһировка) фәнни ярдәм күрсәтү, лекцияләр белән чыгыш ясау, китапханәләрдә булу төп максат итеп билгеләнде. Мәскәү-Хельсинки

поезды Суоми жиренә — вокзалга аяк басу белән, безне кыр казлары кебек тезелеп сафка баскан милләттәшләребез Тукаебызның «Туган тел»ен җырлап, шатлыклы авазлар белән каршы алды. Мәхәллә йортында Финляндиянең төрле шәһәрләреннән, якындагы Аурупа илләреннән, хәтта Төркиядән килгән мөһаҗир милләттәшләребез катнашында Казаннан килеп чыккан кунаклар хөрмәтенә 400 кешелек табын корылды, нотыклар, шигырьләр сөйләнде, татар милләтенең ачы язмышын сурәтләгән Дәрдмәнднең «Кораб» шигырен укыгач та, зал тын калды, тирән сагышка батты, башымны күтәребрәк карасам, тетрәндергеч күренеш: күп кенә ир-атларның күзләрендә яшь. Ниһаять, мәҗлес тәмамланды. Унҗиденче елгы октябрь инкыйлабыннан бирле ярты гасыр дәвамында ватандашлары белән аралашудан мәхрүм булган, мөһаҗирлектә яшәгән милләттәшләребез безне кабат Тукаебызның мөкатдәс «Туган тел»ен җырлап озатып калдылар. Бу сәяхәтемнән соң да Тукай юбилейлары унае белән ирем Зөфәр Рәмиев белән бергәләп Әнкарәдә (1996), Истанбулда (2011) үткәрелгән тантаналарда катнашырга туры килде, һәркайда татар кешесе үткән тарихта дәүләтле халык улы һәм кызы булганлыкны онытмаска чакырган, шагыйребезнең милли гимн, символ, код, пароль вазифасын үтәгән үлемсез «Туган тел»е яңгырады.

***

Советлар дәверендә Тукайның иҗат биографиясе беренче рус революциясен хәзерләү, үткәрү, аның җинелү, реакция, яңа инкыйлабый күтәрелеш кебек иҗтимагый-сәяси баскычларга бәйле рәвештә яктыртылды. Бүген галимнәр шагыйрьнең тормыш юлын, иҗат сәхифәләрен Җаек (1895-1907) һәм Казан чорына (1907-1913) бәйле рәвештә өйрәнәләр. Әдәбиятчыларның барысы да диярлек Тукайның талантлы шагыйрь булып әдәбият мәйданына килүендә төрек әдәбиятының да йогынтысы көчле булуны билгеләп үтәләр. Әле Җаек каласында Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә укыган елларда ул гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә һәм бу уку йортына килгән төрек газеталары һәм журналлары белән даими рәвештә танышып бара. Яшь Апушның әдәби иҗатка тартылуында, солтан Габделхәмид золымыннан качып, Җаек каласына килеп чыккан хөр фикерле төрек мөһаҗире шагыйрь Габделвәли Әмрулланың да тәэсире зур булган. 1902-1903 елларның җәен һәм кышын алар Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә үткәрәләр, табигатькә чыгалар, бергәләп төрек һәм татар җырларын җырлап моңланалар. Габделвәлинең кайбер шигырьләрен Тукай булачак күренекле артист, дусты Габдулла Кариевка да укып күрсәтә. Габделвәли Тукайны һәм мәдрәсәнең башка шәкертләрен төрек әдәбиятының классик дәвере һәм яңа заман шагыйрьләре белән таныштыра; Габделхак Хәмид, Нәмекъ Кәмалларның әсәрләрен укый, төннәр буенча французчадан төрекчәгә тәрҗемә ителгән романнарның эчтәлеген сөйли.

Тукайның 1905-1906 елларда язылган мәдхия, газәл, касыйдәләренең яртысы диярлек төрек авторларына тәкълидләр, нәзыйрәләр булып тора. Шагыйрьнең прозасы һәм публицистикасы да госманлы теленә бик якын. Шуна күрә дә татар, төрек һәм рус галимнәре Җ.Вәлиди, Г.Ибраһимов, Г.Сәгъди, Ф.Көпрелезадә, В.Бартольд Тукайның башлангыч чор әсәрләрен төрек диван әдәбиятына, аеруча Мөхәммәд Языҗы углы Чәләбинең «Мөхәммәдия» һәм аның энесе Әхмәт Биҗанның «Әнвәрелгашыйкын» («Гашыйклар нуры») кебек дини-мистик әсәрләренә ияреп иҗат итү чоры дип тә атыйлар. Күренекле тәнкыйтьче Җамал Вәлиди язуына караганда, Җаекта яшәгәндә Тукай һәрвакыт диярлек «Мөхәммәдия» китабындагы аерым шигырьләрне көйләп йөрүдән тәм тапкан. Кайчагында ул төннәр буе «Мөхәммәдия» көенә җырлап утыра торган булган. Дөрестән дә, аның «Нур», «Фикер», «Әлгасрелҗәдид» газета-журналларында дөнья күргән «Голүмен бакчасында», «Чөнанча бездә Камил әл-Мотыйгый», «Шигырь», «Бу көнди бер сарай ачты әһали», «Алла гыйшкына», «Хәзерге хәлемезә даир», «И каләм!», «Ифтирак соңында», «Гыйшык бу йа!», «Пушкинә», «Дәрдмәнд дәгелмием», «Гәзитә мөрәттибләренә», «Мөхәррирга», «Мәхү идәрмәсән», «Бөраләрән нәсыйхәт», «Милләтә», «Мөхарәбә вә Государственная Дума», «Заманыбызның әдип вә мөхәррирләренә гаид» мәкаләсенә гаид» һәм



*Сулдан уңга: Г.Тукай, С.Рәмиев, Ш.Гайфи.*
*Әстерхан, 1911 ел*

башка байтак әсәрләрендә госманлы шивәсе өстенлек итә. Галимҗан Ибраһимов та үзенең «Татар шагыйрьләре» исемле хезмәтендә Тукаевның госманлы язуларын тудырган заманны «Мөхәммәдия» дәвере» дип атау бер дә хаксыз булмас иде», ди. Әдип фикеренчә, Тукай шигырьләрендәге мәгънәне шәрехләү, гыйбарәләр, сүз тезмәләрен сайлау, стиль, ритмика үзенчәлекләре генә түгел, мәхәббәт лирикасы белән тәнкыйди-һөҗүви рухта язылган әсәрләрдә дә «Мөхәммәдия» китабының йогынтысы ачык сизелә. «Аның вәзеннәренең байтагы, — ди ул, — «Мөхәммәдия»дәгечә улдыгы кебек, ифадә вә тәркибләрдә, өслүбтә, тәгъбиратның бик күбендә, хәтта гыйшык вә шикаять хакында булган шигырьләренең мәгънә вә мәфһүмнәрендә дә җәнабе Кәлибүли хәзрәтләренең күләгәсе бик ачык төшеп тормактадыр».

Билгеле, Тукай төрек суфыйчылык әдәбиятының күренекле вәкилләре Мөхәммәд Чәләби, Әхмәт Бижан һәм башка авторларның әсәрләренә иҗади якын килә, аларны яна заман өчен хас мәгърифәтчелек идеалларын раслауга юнәлтә, мөселман өммәтенең дә, үз милләтенең дә тәрәккыятен кайнар яклый. Мәсәлән, «Алла гыйшкына» (1906) шигырендәге суфыйчылык тәгълиматы һәм әдәбияты өчен хас Аллага гыйшык тоту мотивы милләт төшенчәсе белән тыгыз мөнәсәбәткә кертелә; Алланың Берлеген, барлыгын хис-тойгы, калеб-күңел, йөрәк белән тану фәлсәфәсе торгынлык кичергән татар тормышын Акыл культы ярдәмендә үзгәртеп кору кирәклеген яклауга юнәлтелә. Лирик геройның үз милләтен шөһрәтле милләтләр арасында күрәсе, аңа мәдхия укыйсы килә. Милләтне алгарышка илтү теләге анда шул кадәр көчле ки, аның өчен милләт файдасына бил буып тырышу, аңа хезмәт итү Аллаһы Тәгаләне яратуга һәм аның рәсүле Мөхәммәд пәйгамбәр сөннәтләрен үтәүгә тиң. Кыскасы, шигырь тулысынча Коръән белән бик тә аваздаш булган, акыл культын өстен күргән төрки кавемнәр өчен хас булган суфичылык рухында иҗат ителгән.

Тукайның «Гыйшык бу, йа» (1906) газәле дә төрек суфичылык әдәбиятының икенче бер канаты — пантеистик карашлар йогынтысын татыган. Газәлнең өченче бәетендәге «Бән дә хәүләндә сәнең дәүранаем, дәүранәем» («мин дә синең тирәндә әйләнәм, әйләнәм») дигән шигъри юл үзе үк әсәрнең «әйләнүче, биюче суфилар» — мәүләна тарикате, аның рухи житәкчесе Җәлалетдин Руми газәлләре йогынтысында язылган дип фаразларга мөмкинлек бирә. Суфиларның мәҗлесләре вакытында Руми үзе котыб буларак үзәктә басып торган, көйләп шигырь әйткән, аның тирәсендәге мөритләр, түгәрәк ясап, Аллаһыга якын булабаз дип, кәманчада уйналган көйгә җырлап, биеп йөргәннәр. Тукайның бу тәкълид нәзыйрәсе пантеистик суфичылык фәлсәфәсе өчен хас үзенең беренчел мәгънәсен дә югалтмаган. Аның Аллага гашыйклыктан авыруга сабышкан, җуләрләнү дәрәҗәсенә житкән, кансыз, җансыз сурәткә әйләнгән лирик герое шәраб эчеп исергән, җирдә, тузанда аунап яткан, экстаз халәтенә кергән мәгъшук суфины хәтерләтә. Икенчедән, бу газәлнең эчтәлеген, шәрекъ әдәбиятлары эстетикасындагыча, шагыйрьнең музасы — иҗатына илһам бирүче гүзәл хатын-кызга мәхәббәт дип тә аңларга мөмкин.

Шунысы да игътибарга лаек: рус шигъриятенең горурлыгы булган Пушкин турында язганда да («Пушкинә») Тукай, бер яктан, төрек диван шагыйрьләре стиленә, икенчедән, фарсы суфичылык эстетикасы һәм этикасы өчен хас булган бакча, чәчәклек (гөлзар), гандәлибән (сандугачлар), шәмс һәм башка яктылык

сурәтләре белән бәйле чагыштыру, метафора, символ, гиперболаларга мөрәҗәгать итә. Пушкин шигърияте белән бөеклеген жиһанга нур сибүче якты кояшка — шәмскә тиңли. Илаһи гүзәллеккә тиң Пушкинның сәнгатьчә фикерләү осталыгыннан татар шагыйре Аллаһы Тәгалә фәрманы белән үзенә дә өлеш чыгар дип өмет итә. Тукайның Пушкин шәхесенә һәм ижатына ихтирамы һәм мәхәббәте ихтыярсыз төрек, бер үк вакытта фарсы суфичылык поэзиясенең патшасы Җәләлетдин Руминың рухи җитәкчесе, укытучысы Шәмсетдин Тәбризигә мистик мәхәббәт тарихын да искә төшерә. Мәүләна үткәргән «сәма»ларга — дәрвишләрнең зыр-зыр килеп әйләнүләрен, Аллаһыга мәхәббәтнең югары баскычы дип саналган җыр-бию мәҗлесләренә ишарә «Пушкинә» шигырендә дә бар. Татар шагыйре хыялында Пушкин шигърияте аһәңнәреннән агачлар, ташлар да җанлана, дәрвишләрнең сәмаларындагыча, үз-үзләрен белештермичә бии *(«сәнең әшгаренә, бәнчә, агач, таш билә рәкъсандыр»)*. Гүзәл шигърият, музыкаль авазлар, бию хәрәкәтләре тәэсирендә табигатьнең экстаз халәтенә җиткерелүе — пантеистик юнәлештәге суфичылык поэзиясендә еш очрый торган традицион гилозоизм алымы.

Кыскасы, «Мөхәммәдия» дәверендә, ягъни төрек тәсаувыф әдәбиятына тәкълидләр язганда, Тукай ижади эш итә, аның дини-мистик эчтәлеген алып ташлый, яңа заманга ярашлы дөньяви мотивлар белән сугара; мөселман һәм татар дөньясын торгынлыкка дучар иткән кадимче голямаларга каршы чыга, иҗтимагый тәрәккыят һәм рухи яңарыш идеяләрен яклый.

Заманында бу хакта үз фикерен Җамал Вәлиди дә әйткән иде. Ул да Тукайның «Бакырган», «Мөхәммәдия» кебек төрек классик әдәбиятының өслүбе һәм аһәңе тәэсирендә язылган шигырьләренең бөтенләй «башка типта» булуына басым ясады. Аныңча, төрек шагыйрьләрендәге «суфизмга каршы Тукаевта инде бөтенләй бер антисуфизм бар. Ул тегеләрнең *«Төнлә торган бәндәләр солтан икәндер — белмәдем»ләренә каршы «Вә ишанлар милләтә дошман икәндер — белмәдем»* нәзыйрәләрен китерә».

Казанга күчеп килгәч тә, Габдулла Тукай төрек әдәбияты белән кызыксынуын дәвам итә. Мәсәлән, ул Мөхәммәдия мәдрәсәсе мөгаллиме Шәһәретдин Шәрәфтән төрек әдәбиятының байтак китапларын алып укый. «Госманлы әдәбияты нәмүнәләре» исемле җыентык белән танышкач, «бу китапта миңа ярарлык нәрсәләр дә бар икән», — ди. Шул ук вакытта ул ижатының «Мөхәммәдия» дәвере белән дә алыш-бирешен өзми. Мөхәммәд Чәләби Язынҗы углының образ-сурәтләрен, сюжет элементларын, көйләү ысулын, үлчәм-ритмикасын сатирик әсәрләр тудыру максатында файдалана. Шундый әсәрләрнең берсе — «Шүрәле» имзасы белән басылган, 38 бәеттән торган «Ысуле кадимче» поэмасы. Әсәр «Мөхәммәдия» китабының ничек итеп язылу тарихына нәзыйрә булып тора. Көннәрнең берендә Мөхәммәд Чәләби үзенең чиләханәсендә утырганда, аның янына, Мөхәммәд пәйгамбәр турында әсәр язуны үтенеп, дуслары — дәрвишләр килә. Шушы мөрәҗәгатьне нигез итеп алып, шагыйрь татар кадимчеләренең түбән әхлагыннан көлеп, өр-яңа сатирик эчтәлекле поэма ижат итә. Аның әсәрендә Чәләбинең кырык көн дәвамында Аллаһыга сыгынып яшәгән чиләханәсе Тукайда — пивнойга, дәрвишләр — трактир гашыйкларына әверелә. Ахыр чиктә пивнойда кәеф-сафа корган, дошманнары — җәдитчеләрне сүккән, эчеп-исереп йокыга талган, төшендә хур кызлары кочкан, акчасын урлаткан «каһарман» полиция участогына эләгә.

«Мөхәммәдия»дән» (1908) дип аталган икенче бер сатирик нәзыйрәсендә Тукай, Чәләби китабының Адәм галәйһиссәламгә багышланган юлларыннан файдаланып, Камил Мотыйгыйның «Бәянелхак» газетасы мөхәррире Әхмәтҗан Сәйдәшев белән мөнәсәбәтләренең эзлексез һәм мәсләксез булуына игътибар итә.

Габдулла Тукай талантлы лирик шагыйрь булу белән бергә көчле сатирик та иде. Аның атаклы һәҗү, юмор остасы булып танылуында рус, төрек, азәрбайҗан сатирик журналистикасының да әһәмияте зур иде. Замандашларының язуына караганда, ул Истанбулда чыга торган «Карагөз» («Кара күз»), Тифлистә басылган «Мулла Насретдин» көлке журналының бер санын да калдырмыйча укып барган, төрек һәм аңа бик тә якын торган азәрбайҗан һәҗүе һәм юморы үрнәкләре белән танышкан. XX гасыр башы татар тормышындагы артталыктан каһкаһә белән көлгән

атаклы «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасының каһарманы Кисекбаш образының да тамырлары, академик В.Гордлевский тикшеренүләренә караганда, төрек фольклорына һәм риваятьләренә барып тоташа. Тукай нәзыйрә язган «Иске Кисекбаш»ның авторы кем һәм кайдан — Болгарданмы, Урта Азиядәнме, Төркиядәнме — бу хакта да бәхәсләрнең әлегә кадәр тынганы юк. Мәсәлән, Фәрит Яхин «Кисекбаш» китабының авторы Шәмс Тәбризи тәхәллүсе белән чыгыш ясаган Җәләлетдин Руми дип фаразлый.

Габдулла Тукай Урта гасыр һәм Яңа заман төрек әдәбиятының барышы, аның классик дәвере, диван һәм сарай әдәбияты, Тәнзимат (ислахчылык), золым чоры әдәбияты турында да фикерләрен әйтеп калдырган; байтак кына авторларның әсәрләреннән, әйткәнебезчә, аеруча «Мөхәммәдия» китабыннан иҗади файдаланган, төрле типтагы нәзыйрә, пародия, иярүләр язган, аның тел, стиль, шигъри үзенчәлекләрен дә кабул иткән. Тел җәһәтеннән шагыйрь иҗатының икегә — госманлы теленә нигезләнгән «Мөхәммәдия» чорына (1905-1906), ә «Кечкенә азан» шигыреннән башлап саф татар теленә күчә башлавы (Г.Ибраһимов) шул хакта сөйләсә кирәк.

Габдулла Тукай яңа заман төрек әдәбиятының классиклары Ибраһим Шинаси, Зыя паша, Нәмекъ Кәмал, Әхмәд Мидхәд, Халид Зыя Ушаклыгөл, Габдулла Җәүдәт, Тәүфикъ Фикрәт, Мәхмүд Әкрәм, Әмин бәк һәм башкаларның иҗатыннан хәбәрдар булган. Тәнзимат чоры әдәбиятының танылган җәмәгать эшлеклесе, Аурупа мәдәнияте һәм әдәбиятларын яхшы белгән, әдәби-публицистик эшчәнлеге белән төрки дөньяда да ихтирам яулаган, «Шагыйрьнең өйләнүе» дигән беренче төрек комедиясе авторы, «Тасвире әфкяр» журналы мөхәррире, киң колачлы гыйлем иясе Ибраһим Шинаси (1826-1871) шәхесе алдында баш игән. Аның төскыяфәте белән үткен акылы арасында ассоциация үткәреп, түбәндәге фәлсәфи юлларны язган: *«И төрек, иң әүвәл ук әйтим сиңа: борның кылыч; // Гыйльмилә хикмәт базарында синең урның кылыч»*. Каюм Мостакаевның язуына караганда, шагыйрь «эче пошкан вакытларда күбрәк Мәхмүд Әкрәмнең «Яд ит!», Габдулла Җәүдәтнең «Юлында бең хакыйкать бу шанлы дөньядан...» шигырьләреннән өзекләр укырга» яраткан.

Тукай, Габдулла Җәүдәтнең «Бер кыйтга» исемле шигырендәге «мөкәүкәб»тәй — йолдыздай нур чәчү мотивына таянып, тирән лиризм һәм психологизм белән сугарылган «Күңел йолдызы» (1909) исемле нәзыйрәсен язган һәм аннан аерата «күңеленә ошаган» түбәндәге ике сәтырны (юлларны) эпиграф итеп китергән: *«Тәнәфферләр, тәхаттырлар, тәрәххемләрлә дөньядан / Гөзарым зәхемдар васле бер һиҗра мөкәүкәбдер» («Нәфрәтләнүләр, үткәннәрне искә төшерүләр, җан әрнүләре белән дөньяны кичәрмен; / Күңелдә яра калдырган аерылышу гына йолдыздай нур чәчәр»).* Төрек шагыйренең җемелдәп торган йолдызга әйләнгән, кабул ителмәгән мәхәббәте, аның һәрдаим сыкранучы, сызланучы лирик героен Тукай да кабул итә, әмма ул аны иҗтимагый, милли мотивлар, өр-яңа эстетик карашлар белән баета. Ул шәхес азатлыгын буучы явыз җәмгыять белән дә, иҗатына кизәнүче мәлгунь кара көчләр белән дә конфликтка керә, изүче дөньядан курыкмый, «елар җирдә көлә»; гомере караңгы төн булса да, аның йолдызлы булачагына өметен өзми, бөтен вөҗүде, рухы белән адашкан җир кешеләренә ярдәм кулы сузарга тырыша *(«...йолдызлары һаман нурлы / Гаҗәпме, юлга салса, ичмасам, бер генә юлсызны?»)* Күктәге йолдызлар кебек, Тукайның да лирик герое «Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Раб гүзәл эзне» дигән идеал утларында яна, әдәби иҗаты белән җир кешеләре каршында шагыйрьлек вазифасын үтәү максаты илә яши. Шуңа күрә җир тормышы никадәр авыр булмасын, аның күңеле «мөкәүкәб»ле, ягъни төрледән-төрле хисләр бәйләме тудырган, җем-җем нурлар сирпеп торган йолдызлы:

*Минем күңлем мөкәүкәбтер өмид, хәсрәт, тәәссерлә,*
*Зарар юк, барча кодсиятебез дә айлы, йолдызлы!*

Күренә ки, Габдулла Тукай үзе дә, аның лирик герое да милләтенең кодсиятенә,

рухи омтылышларының илаһилыгына һәм аларның тормышка ашачагына ихлас ышана.

Нәтиҗә ясап, кабатлап, шуны әйтергә мөмкин: Габдулла Җәүдәтнең дә, Габдулла Тукайның да төп игътибары яшәү фәлсәфәсе мәсьәләләрен чагылдыруга юнәлтелгән. Төрек шагыйре иҗатында яралы, әмма йолдызлы мәхәббәт тарихы шәрекъ әдәбиятлары өчен хас традицион рухта яктыртыла. Тукай исә экзистенциаль мәсьәләләрне заманга яраклы рәвештә иҗтимагый эчтәлек белән баета, Аурупа-рус шагыйрьләре кебек, замандашлары алдындагы рухи-әхлакый вазифасы турында уйлана, әлегә кара төн булса да, халкының киләчәге кодсиятле, айлы, йолдызлы булачагына өметен өзми.

Габдулла Тукай төрек Тәнзимат әдәбиятының атаклы язучысы Нәмекъ Кәмалның әдәби таланты алдында баш игән, аның әсәрләрен яратып укыган, төрек-рус сугышы вакыйгаларын чагылдырган «Ватан, яки Силистра» трагедиясен татарчалаштыру уе белән дә яшәгән. Тәнзимат чорының икенче бер талантлы вәкиле Габделхак Хәмид әсәрләре белән дә Тукай яхшы таныш булган. Аның «Нәстәрин» пьесасын укыгач та: «Шундаен куәтле мәхәббәт берлә куәтле дошманлыкның бер күнелгә җыелуына минем башым җитми, Габделхак Хәмиднең тасвирларын башыма сыйдыра алмыйм», — дия торган булган. Замандашларының истәлекләрендә Тукайның Г.Хәмиднең «Һинд кызы» пьесасын яратып укуы турында да фикерләр әйтелә.

Ибраһим Шинаси, Нәмекъ Кәмал, Габделхак Хәмид — Тәнзимат дип аталган Яңа заман төрек әдәбиятының нигез ташларын салучылар, аны аурупалаштыручылар, әдәби барышка күп яңалыклар алып килүчеләр, зур ачышлар ясаучылар. Тәнзимат чоры әдәбияты Тукайга зур йогынты ясаган, киләчәктә бу юнәлештә махсус эзләнүләр, өйрәнүләр алып барылырга тиеш.

Габдулла Тукай Төркиянең иҗтимагый-сәяси тормышы, Габделхәмид солтан идарәсе золымы, яшь төрекләр фиркасенең тотрыксыз эшчәнлеге, Италия-Төркия, Балкан сугышлары, Англия, Франция, Алмания, Австрия, Россия кебек империалистик державаларның Төркиягә карата икейөзле сәясәте турында «Борадарәнә нәсихәт» (1906), «Китмибез!» (1907), «Ахыр көрешүләр» (1909), «Габделхәмид» (1909), «Өч баш» (1911), «Тәмсил» (1911), «Һазихи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа» (1912), «Былтырның хисабы» (1912), «Балканда» (1912), «Балкан көйләре» (1912) кебек байтак кына шигырь, фельетон, памфлет, мәкаләләрен яза. Бу әсәрләрнең күбесе Р.К.Ганиеваның «Сатирическое творчество Г.Тукая» исемле монографиясендә (1964) анализланган.

Госманлы империясен Аурупа дәүләтләренең ярым колониясенә әверелдергән, Төркиянең шәһәрләрен, биләмәләрен талауга юл ачкан, илдә утыз елдан артык (1876-1908) рәхимсез золым, цензура, шымчылык урнаштырган Габделхәмид солтан идарәсен тәнкыйтьләүгә Тукай зур игътибар бирә. Мөселман дөньясына нур сибеп, магнит кебек үзенә тартып торган, хәлифәлек вазифасын үтәгән Төркиянең дәүләти бәйсезлеген югалту куркынычы алдында торуын ул бик авыр кичерә. Аталар балаларыннан, ирләр хатыннарыннан куркып яшәгән Габделхәмид хакимиятен фаш итүдә татар шагыйре сатирасы аеруча үткен була. «Китмибез!» памфлеты — менә ачык мисал. Шагыйрь анда солтан җирен тәмугның да иң кайнарына — сәкарьгә тиңли, аны халыкны изүче, хәзинәне талаучы коррупционерлар һәм шпионнар иле дип тамгалый:

*Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен:*
*Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион.*
*Анда бит бардыр хәзинәне талаучылар, шөкер;*
*Ач мужиктан соң кисәкне тарткалаучы бар, шөкер!*
*Без җүләрме, үзебезне утка илтеп ник терик?*
*Бу кызу җирдән чыгып, тагын сәкарьгә ник керик?*

Шуңа күрә дә Тукай Россиядәге тәртипләр ошамаса, татарлар Төркиягә күчеп китсеннәр дип шаулаган Дәүләт Думасының карагруһ депутатларына: *«Если лучше*

*вам, / Туда сами пожалте, господа!»* — Үзегез анда күчегез, безнең тарихыбыз, шәһәрләребез үз Ватаныбызда, ягъни «Китмибез!» дип җавап бирә.

Татар шагыйре солтанның тәхеттән төшерелүен дә мыскыллы көлү, гарәпләрчә әйтсәк, ачы һиҗа, грекларча — сардоник көлү алымына корылган «Габделхәмид» дигән эпиграмма белән каршы ала:

*Утыз ел хөр фикерләләрне үлтерт,*
*Төрекләрдә азатлык тамырын корт,*
*Ватан яктыртучы шәмнәрне сүндерт,*
*Мөселманнан бөтен читләрне көлдерт, –*
*Утыз ел казыган баз бик тирән шул:*
*Менә инде Хәмитең шунда*
*ГӨМБЕРРРТ!*

Вакыты-вакыты белән сәяси сизгерлекне җуеп, Габделхәмид золымын аклаган, аның белән хезмәттәшлек иткән «яшь төрекләр» фиркасен дә, солтанның «Йолдыз» сараен, хәрәмендәге җарияләрен мактаган сарай шагыйрьләрен дә Тукай һәрдаим тәнкыйть итеп килә: «Ушбулар язган шигырьнең бик кызык шигърияте: / *«Һа! Имеш, солтан тәти, «Йолдыз» тәти, кызлар тәти!»* («Мәтдаһе Истанбул шагыйрьләре»).

Моннан йөз ел элек тә Аурупа илләренең рәсми пропагандасы, безнең заманның Самюэл Хантингтон ише фәлсәфәче һәм сәясәтчеләре кебек, Төркиянең 1912-1913 елларда Италия, Балкан дәүләтләре белән алып барган кан коюлы сугышларын диннәр, мәдәниятләр арасындагы зарури бер бәрелеш итеп аңлатырга тырышты. Тукай исә киресен — аларның яңа җирләр яулап алу, «алтын алмалар өзеп», капитал туплау өчен алып барылган талау, суеш-үтереш кебек иҗтимагый-сәяси афәтләр икәнлеген аңлата:

*Ушбуны, «изге, кирәк бер кан», диләр,*
*Сугыша Инҗил белән Коръән, диләр,*
*Алдый алмаслар халыкны юк белән,*
*Мондый хәзрәтләр сугышмый поп белән.*

Англия, Франция, Алмания, Россия коткысы белән алып барылган бу сугышларда Тукай ихлас күңелдән Төркиянең җиңеп чыгуын тели. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр татар шагыйре өчен «Төркия күктә очкан бөркет» булып кала («Тәмсил», 1912).

Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Тукай төрек халкының иҗтимагый-сәяси яшәеше, мәдәни-әдәби хәрәкәте, аерым язучылар иҗаты белән кызыксынып тора. Бу хактагы уй-фикерләрен һәм кичерешләрен үзенең шигырьләрендә һәм публицистик чыгышларында да гәүдәләндерә. Үзенең дусты шагыйрь Сәгыйть Рәмиев белән бергә ул Әстерхан аша Төркиягә барып чыгу турында да хыяллана. Әмма авыру һәм рәхимсез үлем — 27 яшендә гүр иясе булу — шагыйрьнең Төркияне күреп кайту турындагы хыялын тормышка ашырырга мөмкинлек бирми.

**Резеда ГАНИЕВА,**
*филология фәннәре докторы, профессор*

# «ТАМЫРЛЫ ТУКАЙ»

## ФЛЁРА ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА ИЖАТЫНДА ТУКАЙ

Татарның һәр шагыйре яз саен Тукай турында яна бер шигырен яза, яз килүгә, шагыйрь һәйкәле каршына Шигырь бәйрәменә җыела. Шигырь бәйрәмен һәр шагыйрь Тукайның үзе янына килү итеп күрә. Монда елның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булучылар исеме игълан ителә. Бәйрәмдә рус, чуваш, башкорт, казакъ, удмурт, мари һәм башка халык шагыйрьләре дә чыгыш ясый. Мондый шигырьләрдә татар шагыйре Тукай белән сөйләшә, Тукайдан үзенә сыену эзли, киңәш сорый, кыскасы, бу шигырьләрдә Тукай исәннәрдән исән итеп күрсәтелә. Беришә шигырьләр, мәдхия характерында язылып, Тукайның шигъри осталыгына соклану белдерсә, икенчеләре Тукай язмышын татар тарихы, татар язмышы, туган тел белән бәйләнештә карый — Тукай белән горурлана, өченчеләрендә Тукай уйлап чыгарган геройларны янадан тергезү омтылышы булса, дүртенчеләре шагыйрьне бала чагына, Кырлайга «кайтара», ягъни шагыйрь биографиясендәге теге яки бу чорны бүгенге шагыйрь күнеле аша үткәрүгә юнәлдерелә. Аерым әсәрләр шагыйрьнең әнисе образын сурәтләүгә багышлана.

Әлеге язмада, мәртәбәле премиягә тәкъдим ителеп тә, һаман читтә калып килгән, «шигъри йөкләрен төяргә эшелоннар көтеп яшәгән» шагыйрә Флёра Гыйззәтуллина иҗатында Тукай образы чагылышы үзенчәлекләрен ачыклау максат булып тора[1]. Тукай исеме шагыйрәнең уннан артык әсәрендә телгә алына: шигырьләр — «Үлемсезлек маршы», «Арча гимны», «Җыр-моңнар Ватаны син, Арча!», «Гасыр арасы», «Елмаюлар булып», «Кушлавычта шаулый кушкаеннар», «Хаж кылу төбәге син, Кырлай!», «Айда — Зөһрә, Җирдә — бөек Тукай» һәм поэма-трилогия — «Яңу дәверләрендә».

«Үлемсезлек маршы» шигырендә төп мотив — Казан шәһәренең Ирек мәйданында ел саен уздырыла торган шигырь бәйрәме. Шигырь *«Тамырланып, Тукай басып торган / Шигырь мәйданында, / Казан урамнары чәчәк ата / Апрель айларында»* дип башланып китә. Гап-гади сүзләр, фикер дә яңа түгел, әмма беренче сүз сискәндереп җибәрә: «Тамырланып, Тукай басып торган». Татар әдәбияты классик язучыбыз Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ын белә. Тирән тамырларның мәгърур имән образы аша ассоциацияләнүенә ияләшеп беттек. Язучының имәне дә гади бер агач кына түгел иде, ул имән безнең еракларга киткән тарихыбыз булды. Менә Г.Ибраһимовтан соң икенче бер «яңа тамыр» табылды. Ул — Тукай. Бер шагыйрь тарафыннан да монарчы әйтелмәгән үзгә образ табылган. Тукайның Шигырь мәйданында «тамырланып басып торуы» шигырьнең тәэсирен көчәйтеп җибәрә, онытылмый торган итә, башкалардан аерып, күңелдә уелып кала. Шигырьдән көчле горурлык хисе бәреп тора. Горурланырлык сәбәп тә бар: Пушкин, Җәлил, Горький һәйкәлләре тере кебек тора, яз килүгә, халык аларны чәчәккә күмә, барча күңелләрне бәйрәм хисе били, Тукай биргән «пар ат»та, кояш күзенә туры карап, халык Шигырь бәйрәменә агыла. Шагыйрә әлеге бәйрәм халәтен Үлемсезлек маршына тиңли. Шигырь 1980 елда язылып, «Күз нурларым» исемле җыентыкта урын алган.

Тукай исеме шагыйрәнең «Арча гимны»на да килеп керә. Бу шигырьдә Тукайдан тыш М.Мәһдиев, Ш.Мәрҗани, Г.Курсави исемнәре дә атала. Риф Гатауллин көй язган әлеге җыр тексты, 2000 елда ук язылып, Арча төбәген данлауга юнәлдерелгән.

[1] Әдибәнең иҗаты турында кара: Хәсәнова Ф. Флёра Гыйззәтуллинаның шигъри дөньясы // Казан утлары. — 2012. — №4. — Б.132-137.

Тукай исеме Арча төбәгеннән чыккан башка зыялы шәхесләр рәтеннән аталып кителгән.

«Жыр-моңнар Ватаны син, Арча!» әсәре дүрт бүлектән гыйбарәт булган бер шигъри циклны хәтерләтә. Бу әсәрнең пролог өлеше дә бар. Шагыйрә үзенең иҗатында Арча ягына багышланган өлешнең шактый бай булуын әйтә, сәбәпләрен күрсәтә, Азнакайдан сузган юлның Арчаларга барып тоташуын таный, С.Хәким, Тукай, Х.Туфаннарны санап китә. Шагыйрә үзенең авыр язмышын Тукай ятимлеге янына куеп карый: *«Шып-шыр ятимлегем ягыннан — / Мин дә тиңдәше бит бу айның. / Чорлар буе үксим кочаклап / «Апуш» кына чагын Тукайның»*.

«Гасыр арасы» шигыре зур булмаган лирик поэманы хәтерләтә. Вакыйга XX һәм XXI гасырлар чигендә бара. Шагыйрә кичен, ак тюльпаннар төялгән кара машинага утырып, кемнеңдер иҗат кичәсенә бара. Теләп бармый, кирәк булганга бара, шагыйранә әйткәндә, болай килеп чыга: *«Минем моң-сагышым саркып карый / Тукай күзләреннән»*. Кичәдә, кирәк булгач, Тукай теле дә телдән төшми. Шагыйрәне кылган гамәлләре ашап-эчүдән узмаган ялган «йолдызлар»ның мәртәбәле исемнәр алуы борчый. Аларга ул *«чәчәк кадере белән шигырь кадере / калды иң түбәндә»* бәясен бирә. Әсәрнең төп идеясе Тукай бәеклеген ваклау белән килешә алмауга кайтып кала.

«Елмаюлар булып» шигыре бер күзәтү мизгелен чагылдыра[2]. Тукай моңын чор моңына кушып, бер яшь ана бишек тирбәтә. Бишек җыры сабыйны да, Ананы да, шагыйрәне дә елмайта. «Тукай туган җирдә...» шигыре, Тукай турындагы циклны башлап җибәреп, Кушлавычка мәдхия рухында язылган, авылның табигатенә, кешеләренә соклану хисе белән тулы. Кушлавычлыларны шагыйрә «төп тамырлы Тукайлылар» дип атый. «Кушлавычта шаулый куш каеннар» — Луиза Батыр-Болгари тарафыннан көй язылган җыр тексты алдагы шигырьнең эчтәлеген дәвам итә. Биредә шагыйрә Кушлавычны үз итеп өлгергән. «Җырлап сулган ятим шагыйреңне мәңге сагынырсың, Кушлавыч!» — дип кинәш бирергә дә үзен хаклы саный. «Хаҗ кылу төбәге син, Кырлай» — Луиза Батыр-Болгари көен язган җыр тексты Арча циклын тәмамлый. Бу юлы мәдхия Кырлай авылына, Кырлай музей-комплексына яңгырый. Тукайның авыл табигатенә, урман-кырларына багышлап язылган әсәрләренә басым ясала. «Айда — Зөһрә, Җирдә — бөек Тукай» шигыре 90 нчы еллар рухында язылып, халыкның иманга кайтуын сурәтли[3]. Шигырьдә Янарышның җилел генә булмаячагын сизенү бар. *«Имансыздан, нурсыз, язмышсыздан / Шуны раслап Тукай көләдер... — / Эчләрендә нинди ут янганын / Ләкин үзе генә беләдер»*, — дип, шагыйрә шигырен тәмамлый.

Ф.Гыйззәтуллина «Яңу дәверләрендә» әсәре жанрын «поэма-трилогия» дип билгеләгән[4]. Әдәбият теориясендә поэма төшенчәсенә күптән аңлатма бирелгән. Жанр буларак барлык билгеләре ачыкланган, шулай ук «трилогия» төшенчәсе дә татар әдәбияты өчен ят түгел. Язучыларыбыз роман-трилогия жанрында язарга остарып бетте. Фоат Садриевның «Бәхетсезләр бәхете», Тәлгат Галиуллинның «Сәет Сакманов», Факил Сафинның «Саташып аткан таң», Айдар Хәлимнең «Хунвейбин» әсәрләре соңгы елларда дөнья күрде. Әйтелгәнчә, бу әсәрләр роман жанрына карый, чәчмә белән язылган. Ә менә «поэма-трилогия» дигән жанрдагы әсәрне укырга туры килмәгән иде. Дөрес, татар шигъриятендә шигырь-триптихлар бар. Газинур Моратта күп алар. Поэма-триптих өчләтелгән поэма булырга тиештер инде. Поэма үзе дә күләмле жанр, аны өчләтү кирәк микән дигән сорау тууы да табигый. Бер сюжет өч мөстәкыйль тармакка аерылып, бер идеяне чагылдыручы, бер максатка хезмәт итә торган, бер нәтиҗә чыгарлык итеп язылган бербөтен әсәр туарга тиеш булып чыга.

Әсәрдә Тукай исеме 53 урында телгә алына. Әдәбият теориясе кануннары буенча әсәр шигырьнең катлаулы формаларының берсе саналган полиструктур композиция (ПК) таләпләренә җавап бирә. Әсәр һәрберсе исемләнгән зур өч бүлектән гыйбарәт. Һәрбер бүлектә аерым лирик цикллар урнашкан. Барысы

[2] Гыйззәтуллина Ф.С. Йөрәгемдә шаулый карурман. — Казан: Рухият, 2001. — Б.245.
[3] Гыйззәтуллина Ф.С. Башкаемда дөнья исәпләре: шигырьләр, поэмалар, балладалар. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2007. — Б.10.
[4] Гыйззәтуллина Ф.С. Яңу дәверләрендә: поэма-трилогия. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. — 320 б.

96 цикл. Алар эпиграф итеп бирелгән һәм шагыйрәнең үзе тарафыннан язылган кечкенә шигырьләре белән башлана. Әсәр бер милли идеягә буйсындырылган, эчтәлеге буенча татар тарихын чагылдыра. Халыкның үз тарихын ничек саклавы, бөек шәхесләрен данлавы бүгенге көн таләпләреннән чыгып карала. Һәр мәсьәлә автор позициясеннән чыгып билгеләнә, бәяләнә. Вакыйгаларга Тукай күзлегеннән бәя биргәнлектән, язучы үзенең хаклы булуына шикләнми. Әсәрдә татар халкының бик күп язучы, тарихчы, сәясәтче, галимнәре исемнәре атала. Текст язучының әдәби табышлары, өр-яңа детальләре күплеге белән аерылып тора: «кара карчыгаларның Тукайның «Су анасы»н тотып чукуы», «котып җилләренә изү ачып, юл чатында басып торган Тукай», «Мине Тукай күршесенә күмегез, дип язмаган Рәш.Әхмәтҗан», «Мокамай»дан туеп, «Су анасы» белән «Шүрәле»не үзгәртеп язарга кушкан заман», «хәрәмне хәләлгә санап ялгышкан буын», «Тукайның мәшһүр «Шүрәле»сен ярык бүрәнәгә басып сөйләү», «Шүрәленең, бөтен нәсел-нәсәбен туплап, универсаль бию хәзерләве» һ.б.

Шагыйрә Тукайны «татар монсары» дип атый. Дөрес, «монсар» атамасы үзе яңа төшенчә түгел. Композитор С.Садыйковага «ябышып калган» символик исем ул. Уйлап карасаң, Тукай да «монсар» икән бит. Аерма тик шунда гына: берсе көйдә булса, икенчесе — сүздә. Тукайның мәшһүр «Шүрәле»сенә музыка язып та, үзенең иҗат җимешен күрә алмыйча яу кырында ятып калган Ф.Яруллин да «монсар» буларак тәкъдим ителә.

Әсәр исемендәге «яңу» сүзе шагыйрәнең җинел булмаган («сугыш чорының ятим кәккүге»), «ком буран»лы, «тимер юллы», «эшелонлы», «Себерләрне урап кайткан» озын тормыш юлын чагылдырган символик мәгънәгә ия. Шагыйрә үзе дә: «Әнкәй үлгәч, мин дә Тукай кебек үксезлектә дөрли-дөрли яндым», — дип белдерә, ана аш савытындагы борчаклар да Тукайның күз яше кебек эре булып күренә. Әдибә үз тормышының һәр мизгелен Тукай үлчәме белән үлчи булса кирәк. Шагыйрьнең әнисе Мәмдүдә булса, Ф.Гыйззәтуллинаныкы — «рифмалашкан Мәүгыйдәләр» (чыннан да шулай икән бит!). Әсәрне укыган саен, анда язылган язмышлар тарихы җанлана бара, сурәтләнгән һәр вакыйга авторның үзе тарафыннан кичерелгән ачы язмыш елъязмасына әверелә. Шагыйрә үзе, Тукай яшен өч тапкырга үтеп китеп яшәсә дә, кылган гамәлләрен аның күзлегеннән кичерә, аның сүзләре белән бәяли бара, кыскасы, Тукай Ф.Гыйззәтуллина өчен тайпылмый торган бер ориентирга әйләнә.

Поэмада татар халкының күпсанлы язучылары исемнәре атала, кайберләренең эш-гамәлләренә бәя бирелә. Әсәрнең берничә урынында Тукай премиясенә нисбәтле эпизодлар чагылып китә. Аларның берсе Рәшит Әхмәтҗанов исеме белән бәйле. Шагыйрь каләме белән генә түгел, бәлки бәдәне һәм гамәле белән Тукай бүләгенә лаек булып та, «исемсез» китте дип борчыла шагыйрә. «Татар шагыйрьләре тыйнак артыгына. Тукай бүләгенә лаекларның да бәхетләре инде ярым-йорты гына», — дип яза ул, үзенең дә «мәңгеләшер чагы җиткән»леген тоеп. Әсәрдә «шигърияттә тибрәр бишек үргән» Кол Гали, тарихның өлкән ханы Нурихан, җыр өлгесе калдырган Җәлил, Әлфия (Авзалова), Гамил (Афзал), үз халкына хезмәт итү үрнәге булган Минтимер (Шәймиев), язучылар Мөхәммәт (Мирза), Вахит (Имамов), Әгъләм (Мөдәррис), Кадыйр (Сибгатуллин), Сәгыйрь (Гакыйль), Шаһинур (Мостафин) һ.б. күренекле шәхесләр исемнәре чагылып китә. Әсәрдә шагыйрьлек хезмәтенә бик зур бәя бирелә: «Без язабыз җырның һәр иҗеген тәмуг мәхшәреннән табып алып», — ди ул. Шагыйрә гаделсезлекне авыр кичерә: «Җыен алкышына дәгъва кыла яңа Тукай, яңа Мусалар», дигән юлларны олы кешенең рәнҗеше итеп кабул итик. Заман үзгәрә, идеаллар гына түгел, әдәбиятның эстетик юнәлешләре дә борылыш ала. Шул рәвешле, әсәргә «Мокамай»дан туеп, «Су анасы» белән «Шүрәле»не үзгәртергә кушкан эпизодлар килеп керә.

«Тукай моны аша» дип исемләнгән өлештә «милли хыянәт» турында сүз бара. Бу сүз-образ артында иҗатташы, яшьлек дусты булган Мәрвәр карчыкның, Тукай һәйкәленә арт сөяп, кочак-кочак Библия сатып торуы, Сөембикә атлы кызның, сәхнәгә ярым ялангач чыгып, төрле телдә җырлавына алкышлар алуы, аны күреп, Тукайның гына йөрәк турын тотып көрсенүе турында сөйләнелә. Чыгыштан соң банкет оештырыла. Затлы шешәләр бушатыла. Ятимнәр чүплек башыннан буш

шешәләрне жыя һәм соныннан яшүсмерләр аларны сатып эчә. Шул эчүчеләрне туендыру максатыннан, картлар каравылга чыга.

«Кайтавазлар» исемле бүлектә 20 кайтаваз бар. Тугызынчы кайтавазда Тукай сүзләре урын ала. «Кайсы хан сон шагыйрь булмаган?» дигән сакраменталь сорау куела. Жавап өлешендә шигъри биштәре акчасызлык, ачлык белән тулы булса да, шагыйрь хәер эстәргә чыкмый, дигән фикер үткәрелә. Унберенче кайтавазда шагыйрьләр сүз ала. Аларның *«Чак-чак килми калган азатлыкка / Без чыгардык бары бәет кенә — / Язмышларнын канлы тастымалын / Итәк өсләренә жәеп кенә / Кер чайкадык канлы Казансуда»*, — дигән юллары 90 нчы еллар сәясәтен искә төшерә.

Алда әйтеп үтелгәнчә, бу әсәр катлаулы композициягә нигезләнгән. Әдәбият теориясендә мондый формалы әсәрләрне матрёшка тибында төзелгән дип карау кабул ителгән (Ю.М.Лотман). Димәк, әсәр эчендә күләме кечерәк икенчесе, аннан өченчесе, дүртенчесе килеп чыгарга мөмкин. Шул сәбәпле, полиструктур композициядә бердәм сюжет жебен тотып алу кыенлаша. Шагыйрә укучы өчен тагын бер кыенлык «әзерләп куйган» — ул да булса тарихи эчтәлекне эпик планда түгел, бәлки лирик планда сурәтләү. Татар әдәбияты лирик поэмаларга артык бай түгел. М.Жәлил, Ф.Кәрим, И.Юзеевларны гына искә алу да житә. Ә менә эпик планлы тарихи поэмалар соңгы елларда күпләп языла башлады. Ә.Рәшит, Р.Харис һ.б. иҗатында татар тарихының «шигырьләнмәгән» этабы калмагандыр да.

«Яңу дәверләре» әсәрендә «Үчле жилләр, хәтәр жилләр» исемле бүлек бар. Ул үзе 3 бүлекчәдән тора. Сюжет эчтәлеге болай: Хәтер көне житте исә, гасыр капкаларын Вакыт шакый башлый:

*— Уяулармы, аек, исәннәрме?*
*Ил эченә сыйдырамы иләт*
*Иләмсезне, гамьсез, ушаннәрне?*
*Илдә базар ачып баеганнар,*
*Алданганнар, таланганнар нишли?..*
*Сакчы рапорт бирә:*

*— Байгуралар,*
*Айга менеп, айгыр булып кешни!*
*Бай кайгырта фани дөнья эшен,*
*Хәерчеләр, коллар эшләсен, дип, —*
*Океан артларына олактырган*
*Долларларның хакы төшмәсен, дип.*

Язучы Вакытка үзенең символик бәясен бирә: «Һәр тарафка ашыгыч ярдәм кирәк булган икейөзле азгын дөнья», — ди. Ә яшәүчеләре — «шәжәрәсез ирдән бала тапкан», «хәрәмен хәләлгә санап ялгышкан буын»нан гыйбарәт. Әсәр «Жиңү рухы» исемле бүлекчә белән тәмамлана. Янадан Агыйделдәге Ак пароход образы алга чыга. Язмыш Иделендәге ак караб халыкның өметен чагылдыра...

Ел да үткәрелеп килә торган Шигырь бәйрәме шагыйрьләрнең күңелләрен жылытып жибәрә, өметләрен уята, аларга Тукайның күңел кошлары әйләнеп кайткан кебек тоела башлый. Соңгы елларда хатын-кыз шагыйрьләр арасыннан Тукай премиясен ала алган Л.Шагыйрьжан Шигырь бәйрәмен Шигырь мәйданына тиңләгән иде. Шигырь бәйрәме ул — Сабан туе да, марш атлап узар парад та, бу мәйданга таш яуса да, жил-давыллап яңгыр койса да киленә, бары тик бу мәйданда гына шагыйрьләр күңеле тигезләнә, дип саный шагыйрә. — «Һәркем килә монда хет бер тапкыр / Утырып булмасмы дип пар атка...» Л.Шагыйрьжан шигырьләрендә Тукай безнең арада «яши», безнең кебек үк «рәнжетелә», «кимсетелә». Бу образга гомумиләштерелгән татар шагыйре дә сыя, «милли киртәләр» дә керә.

Менә шушы «пар ат»ка «эшелоннарга тәярлек» иҗаты булган тагын бер шагыйрәне — Флёра Гыйззәтуллинаны утыртасы иде. Лаек ул бу олы бүләккә. Шагыйрәнең Тукае да «тамырлы», үз иҗаты да татар әдәбияты тарихында тамырларын тирәнгә жибәргән.

**Фәридә ХӘСӘНОВА,**
*Г.Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Әдәбият белеме бүлеге җитәкчесе*

# XX ГАСЫР ТАТАР ПОЭЗИЯСЕНДӘ ТУКАЙ ОБРАЗЫ

XX гасырны әдәбият тарихынын буеннан-буена Тукай турында әсәрләр язылу, сүз сәнгатен, иҗади югарылыкны, татар дөньясы алга куйган идеалны аның белән үлчәп карау дәвере дип атарга мөмкин булыр иде. Тукай турындагы әдәбият XX гасыр башыннан юл ала, аны образ буларак сурәтләүнең теоретик нигезләре дә шушы чорда эшләнә.

Билгеле булганча, XX гасыр башы әдәби-эстетик фикер үсешендә һәм иҗтимагый-мәдәни тормышта кискен үзгәрешләр чоры, бер үсеш баскычыннан башка этапка күчү дәвере, чиктәш ситуациягә аяк басу вакыты буларак билгеләнә. Сүз сәнгате, бер яктан, үткән гасырлар сынавын кичкән классик традицияләргә нигезләнүен дәвам итсә, икенче яктан, шул традицияләрне «үтеп китеп», аларны янарту, трансформацияләү омтылышын алга куя. Милли янарыш һәм үсеш идеяләре әдәбият, мәдәният, мәгариф өлкәләрендә үзгәреш, янача сулыш кирәклеген аңлау белән бергә үрелә. Билгеле бер кануннар нигезендә формалашып, аң-белемгә өндәгән, шул юлда халыкны бәхетле итәргә омтылган мәгърифәтчелеккә алмашка иҗтимагый-сәяси тормыш белән тыгыз бәйләнгән, милли идея белән сугарылган әдәбият килә. Д.Заһидуллина билгеләгәнчә, идеаль тормыш моделен төзеп, идеаль герой-тип тудырып, шушы максатка ирешеп була дип санала. Шулай татар әдәбияты тамырдан үзгәргән: Шәрыктан Гаребкә, дини-мәгърифәтчел рухтан дөньяви реалистик һәм романтик, традицион халык мәдәниятеннән югары культурага борылган вакытта әдәбиятта яңа идеал — шагыйрь, замандаш милләт хадиме образы пәйда була. Әдәби мәйданга ул, урта гасыр мөселман һәм XIX гасыр традицияләрен дәвам иткән, рус, көнбатыш фәлсәфәсенең эстетик фикерләре белән баетылган, чорга аваздаш яңа дөньяви милли идеал булып килә. Халыкка игелек, милләткә хезмәт итү, милләт бәхете өчен көрәшү кебек сыйфатлар милли идеалның эчтәлеген билгеләсә, әдәби гәүдәләнештә дини-суфичыл «камил инсан» концепциясе һәм рус, аның аша Европа әдәбиятыннан кергән «камил кеше» теорияләре кисешә.

Билгеле булганча, иҗтимагый фикер, сәяси шартлар үзгәрү белән яңа җәмгыятьнең мәдәни нигезен, идеологиясен эзләү башлана. Урта гасыр иҗтимагый-әдәби фикеренең бер үзенчәлеге булып илаһи сүзнең зур кыйммәткә ия булуы санала. Дини идеология башкарак планга күчеп, илаһи сүз дөньяви фикер белән алышына торган чорда аның урынын иҗади сүз ала һәм дөньяви идеология, әдәби-эстетик, фәлсәфи фикернең төп таянычына әйләнә. Бу фикерләрне дәлилләп, Г.Ибраһимов «Альбом мөнәсәбәте илә» мәкаләсендә: «Сәнгать — яңа заманның дине, бөек сәнгатькярләр ул диннең пәйгамбәрләредер», — дип яза.

Агымдагы чорда көнчыгыш суфичылык әдәбиятыннан кереп, урта гасыр татар сүз сәнгатендә иркен файдаланылган «камил инсан» өйрәтүе үзләштерелүен дәвам итә, аның фәлсәфи нигезләре, функцияләре, образ-үзенчәлекләре дөньяви идеалны сурәтләүгә күчерелә. Шул рәвешле, Мөхәммәд пәйгамбәргә хас әхлакый кыйммәтләр, гуманистик сыйфатлар, мөселман дөньясын туплау кебек иҗтимагый бурычлар шагыйрь шәхесенең эчке дөньясын, милли юлбашчылык сыйфатларын ачуга юнәлә.

Икенчедән, сүз сәнгатендә милли идеалның сурәтләнешенә, фәлсәфи һәм әдәби гәүдәләнешенә шушы чорда рус әдәбиятына Европа әдәбиятыннан үтеп кергән һәм билгеле күләмдә татар дөньясында да яңгыраш тапкан Ф.Ницшенын «гадәттән тыш кеше» өйрәтүе дә тәэсир ясый. Ницше иҗади башлангычны әһәмиятле саный, кешенең рухи кыйммәте, яшәү мәгънәсе турында уйлана, «өстен кеше»нең җәмгыять кануннарына буйсынып яшәүдән бигрәк, башкалар өчен азат шәхес үрнәге булырга тиешлеген билгели. Шул чордагы татар әдәби фикеренең ихтыяҗларына җавап

биргән әлеге фәлсәфи тәгълимат милләт азатлыгына омтылган, шул нигездә яңа яшәеш моделен, җәмгыятен төзергә теләгән татар зыялылары өчен мөһим тоела һәм милли эчтәлеккә утыртылып сүз сәнгатенә «күчерелә». Бу сыйфатлар милли идеалның гражданлык характерында билгеле урын ала.

Г.Тукай XX гасыр башы татар поэзиясендә нәкъ менә шундый таләпләргә җавап бирүче дөньяви милли идеал буларак күтәрелә. Агымдагы дәвер татар шигъриятендә ана милли күзлектән, чорның идея-эстетик үсеш ноктасыннан бәя бирелә, шушы җирлектә милләтне үстерүгә керткән мәдәни, иҗтимагый эшчәнлеге төп бизмән итеп куела. Гомумән, 1910 еллар татар поэзиясендә шагыйрь һәм шагыйрьлек темасына бәйләнештә пәйгамбәр-шагыйрь образы алга чыга. Шуңа мөнәсәбәттә, унынчы еллардан Тукайны пәйгамбәр образы белән бәйләнештә сурәтләү тенденциясе урнаша һәм «камил инсан» өйрәтүен юлдаш итеп ала.

Мәсәлән, С.Сүнчәләйнең «Азан», «Шагыйрьгә», Н.Габидовның «Нигә бу шәмнәр сүнә» шигырьләрендә Тукай — ак, чиста күңелле, рухи саф, әхлакый бөтенлеккә ия, сабыр, акыллы шагыйрь-пәйгамбәр дәрәҗәсендә сурәтләнә. С.Сүнчәләй үзенең «Азан» шигырендә «Тукайның һәр сүзен изге сүз дип», бөтен иҗатын «татар халкын — баен, ярлы гавамын, мулласын» йокыдан уятучы, «таң атуын хәбәр итүче» азан белән тиңләштереп, шагыйрьне Аллаһ югарылыгына күтәрә, шуңа мөнәсәбәттә шигырь структурасында Алла — кеше, кеше — Алла кебек суфичылык мотивы үзәккә алына:

*Бер гаҗәпләнсен кояш, таң, җен, фәрештә, җир, адәм,*
*Бар да торсын мактасын тәңрен, яраткан Алласын!*

Х.Габидовның фәлсәфи рухта язылган «Нигә бу шәмнәр сүнә» шигырендә Тукай образы суфичылык әдәбиятында еш кулланылган шәм символы аша ачыла. Суфичыл образлар системасы, диңгез шаулавы, бөтен дөньяның тӧтенгә күмелүе, куркыныч өннәр чыгарып, ил карабының ыңгырашуы кебек романтик детальләр ярдәмендә шагыйрь татар милләтенең тормышын бәяли, шагыйрь һәм милләт язмышын илаһи бердәмлектә сурәтләргә омтыла. Суфи әдәбиятта Аллаһ сурәтендә кулланылган шәм, традицион эчтәлеген үзгәртеп, Тукайның даһилыгын, бөеклеген ачуга юнәлтелә, суфичыл образлар төп идеяне тәгалләштерә: татар милләтен даһилары яшәтә, аларның үлеме милләтнең якты киләчәген томанлый.

Ш.Бабичның «Габдулла әфәнде Тукаев», «Тукай үлгәч» кебек мәдхия-мәрсияләре Тукайны пәйгамбәр, «камил инсан» дәрәҗәсенә куя. Шул рәвешле шагыйрь образын пәйгамбәр баскычына кую әдәбиятның иҗтимагый дәрәҗәсен күтәрә, шагыйрьлекне милләт өчен иң әһәмиятле, файдалы эшчәнлек төренең берсе буларак аңлата башлый.

Шуның белән янәшәдә Тукай иҗатының бөеклеге, даһилыгы турында уйланулар алга чыга. С.Сүнчәләйнең «Инеш» шигыре — шушы юнәлештәге әсәрләрдән. Кояш образы, аның «якты нурлар, оҗмах төсләре сибүе» лирик герой күңелендә соклану хисе уята. Ләкин кинәт кенә кояшның сүнүе сәбәпле, шатлык хәсрәт белән алмашына. Кояшның халәте, хәрәкәте, үсеш-үзгәреше аркылы автор Тукай шәхесенә, тормышына һәм, гомумиләштереп, татар халкының шагыйрен югалтканнан соңгы халәтенә бәя бирә. Шушы ук мотив Ш.Фидаиның «Тукай» шигырендә тагын кабатлана. Ш.Бабичның «Габдулла әфәнде Тукаев» шигырендә Тукай ай образы, К.Курмашевның «Әдәбият былбылы олугъ шагыйремез Габдулла Тукаевка» әсәрендә Чулпан, якты кояш образлары аша бәяләнә. Тәңречелек тәгълиматы буенча, Җир дөньясы — Күк дөньясының чагылышы. Шуңа бәйләнештә Кояш, Ай, Чулпан йолдыз образ-символлары белән Тукайның берлеге, бөеклеге, поэзиясенең зурлыгы, олылыгы һәм аны югалткан халык фаҗигасе арасында параллельләр үткәрелә, шигырь экзистенциаль мотивлар белән баетыла. Бу төр шигырьләрдә Тукайга соклану, ана булган чиксез мәхәббәт, шагыйрь иҗатының бөеклеген исбатлау төп эчтәлекне тәшкил итә. Лирик герой өчен Тукай остаз, чиксез бөеклек, шагыйранә талант үрнәге булып күтәрелә.

1913 елда Тукай иҗаты тирәсендә башланган әдәби бәхәсләр тәэсирендә аның шагыйрьлегенә бәя тагын да калкулана: ул татар реалистик поэзиясен нигезләүче шагыйрь, остаз, тел остасы үрнәге итеп куела. Бу юнәлештә С.Сүнчәләй беренчеләрдән

була. Аның 1913 елда язылган «Бер газетага» шигыре төп мәгънәсе белән шул чорда Тукайга каршы юнәлтелгән урынсыз карашларга, шагыйрь һәм халык мәсьәләсе тирәсендә барган бәхәсләргә җавап рәвешен ала. Ж.Юмаевның «Шагыйрь үлде», Г.Сөнгатинең «Милләтебезнең сандугачы китте», Я.Мамишевнең «Ядкяр өчен», К.Патииның «Тукайга» шигырьләрендә дә Тукайның шагыйранә бөеклеген ачу тенденциясе күзәтелә. Р.Ибраһимова, К.Патии, Я.Кизләви, Гайнуллин-Чокалый шигырьләрендә исә Тукай халыкчы буларак гәүдәләнеш таба.

Бер төркем әсәрләрдә Тукайга бәйле каршылыклы фикерләрне кире кагу иҗатының миллилеген, лирик нәфислеген исбатлау аша башкарыла. Г.Сөнгатинең «Милләтебезнең сандугачы китте», М.Фәйзинең «Габдулла әфәнде» шигырьләре – шушы юнәлештәге әсәрләрдән. Шулай Тукай иҗатын бәяләү юлында суфичылык әдәбиятыннан ук яратып кулланылган бакча һәм сандугач символик образлары ярдәмгә килә. Шагыйрь образын сандугач символы аша чагылдыру тенденциясе көнчыгыш әдәбиятында ук киң кулланыла, «үз эченә бикләнгән, шау-шулы халык дөньясыннан яшеренгән» шагыйрьне гәүдәләндерә. Ләкин Г.Сөнгати, М.Фәйзи әсәрләрендә аның башка мәгънәви бөтенлеге күзәтелә: сандугач символы Тукай поэзиясенең камиллеген, серлелеген, милләткә мәхәббәтен ачуга юнәлтелә, Тукай – милләт сандугачы янәшәлеге барлыкка килә.

Гомумән, тикшерелә торган чор лирикасында шагыйрьне объектив сурәтләүдән бигрәк, субъектив башлангычка зур урын бирелә, Тукай үлеме белән бәйле төстә халыкның эчке дөньясын, җанындагы сызлануларын, рухи кичерешләрен чагылдыру өстен куела һәм романтик сурәтлелек, экзистенциаль мотивлар алга чыга. Романтик буяулар шагыйрьнең бөеклеген, халыкның аңа чиксез мәхәббәтен һәм хөрмәтен күрсәтү, Тукайның татар дөньясына багышлаган гомерен, хезмәтләрен бәяләүгә, экзистенциаль мотивлар милләтнең аны югалтканнан соңгы халәтен ачуга хезмәт итә.

XX йөз башы татар поэзиясендәге сан һәм сыйфат җәһәтеннән күтәрелүдән соң, 1920-1950 еллар арасындагы Тукайга багышланган әдәбиятта сан һәм сыйфат ягыннан чигенеш күзәтелә. Бу еллар – Тукай шәхесен үзәккә алган шигъри әсәрләрнең чагыштырмача аз язылган чоры. Шушы вакыт аралыгында бер-бер артлы килгән Октябрь инкыйлабы, гражданнар, Бөек Ватан сугышлары кебек вакыйгалар Тукай турындагы әдәбиятка да сизелерлек йогынты ясый. Сыйнфый көрәш, сугыш, батырлык, каһарманлык поэзиядә әйдәп баручы мотивларга әйләнә, шулай да Тукай шәхесенә, образына игътибар тулысынча кимеми. Мәсәлән, 1923 елда «Тукайның үлүенә ун ел тулу хатирәсенә багышлап», Ф.Бурнаш «Көрәш җырлары» исемендә бер җыентык бастыра. Ләкин ул мәҗмугада Тукайга яд ителгән шигырьләр урын алмый, Ш.Бабич, Н.Исәнбәт, К.Әмири, З.Бәширова, Һ.Такташ, К.Нәҗми, М.Җәлил кебек замандашлары яки яшь шагыйрьләрнең «көрәш очкыннары» белән тулы шигырьләреннән үрнәкләр бирелә. Шагыйрьнең үлеменә егерме, утыз ел тулган көннәр дә чагыштырмача тыныч үтеп китә.

Татар поэзиясендә егерменче еллар уртасыннан, мәгълүм сәбәпләр нәтиҗәсендә, социологик юнәлеш өстенлек ала, Тукай шәхесе иҗтимагый планда ачыла, аның шигърияте дә шул яссылыкта бәяләнә. Бу төркем шигырьләрдә хәзерге тормышны үткән аша чагылдыру принцибы алга чыга. Вакыт бүленеше идея-эчтәлекне ачуда әһәмиятле өлешкә әверелә, вакыт аралыгы, ике чор каршылыгы иҗтимагый эчтәлеккә төреп тәкъдим ителә. Үткән тормыш катып калган, схоластик, әрбөтен, хәтта канлы, дәһшәтле булып, шул чордагы алсу, матур көнитешкә каршы куела, ягъни «үткән – бүгенге» антиномиясе тудырыла. Шушы җирлектә Тукай шәхесе «азат» яшәешкә алып чыгучы образ буларак күтәрелә һәм мондый каршылык Тукай образын социаль бәяләүдә төп сәнгати алымга әверелә.

Г.Хуҗиның «Габдулла Тукай истәлегенә», Ә.Юнысның «Тукайга», Ш.Маннурның «Җир мәңгелек» кебек шигырьләрендә Тукай образы ярлылар өчен көрәшү, азатлык яулау, байларны җиңү мотивлары белән янәшә тасвирлана, шагыйрь – халыкны яңа тормышка алып баручы янәшәлеге алга чыга. М.Җәлилнең «Тукай каберендә», К.Хәмзинның «Милләтсезләр иле» шигырьләрендә исә шагыйрь образы башка яссылыкта бәяләнә башлый: милли кысу, гаделсезлек шартларында милләтне рухи һәм иҗтимагый саклап калучы милли идеал булып күтәрелә.

С.Хәкимнең «Пар ат», «Шагыйрьнең балачагы», Г.Шәрәфнең «Шүрәле белән очрашу» кебек әсәрләре иҗтимагый якның эстетик калып белән алышынуын хәбәр итә. Мондый әсәрләрдә каләм иясе матурлык тудыручы оста, эстетик камил әсәрләр иҗат итүче шагыйрь кебек бәяләнә. Бу тенденция әдәбиятта иҗтимагый якның яктыртылышын гына таләп иткән идеология, җәмгыятькә тискәре мөнәсәбәтне белдерү чарасына да әверелеп китә, әкренләп сәнгатьнең вазифалары, сафлыгы, эстетикасы турындагы сүзгә бару да тоемлана. Нәкъ шушы сыйфатлар XX гасырның икенче яртысында Тукай турындагы поэзиядә булачак үсеш-үзгәрешне нигезли.

Тукай турындагы поэзиядә янарыш, иҗтимагый яшәештәге үзгәрешләр тәэсирендә, 1960 елларның икенче яртысыннан башлана, татар әдәбиятының киңәю-тармаклану вакытында яңа сыйфат үзгәрешләре белән байый, тулылана. Аның, алдагы чорлар белән чагыштырганда, башкарак юнәлештә үсеп китүе фәлсәфи һәм әдәби фикердәге яңалыклар, әдәбиятның иҗтимагый кануннарны алга куйган идеологик кысалардан чыгуга омтылышы, дөньяны, яшәешне сәнгатьчә кабул итүнең яңа яклары ачылу белән аңлатыла. Шушы чордан Тукай образының сурәтләнеше катлаулы һәм катнаш төс ала: бер әсәр чигендә Тукай образына мөнәсәбәттә шагыйрь һәм шигъриятнең хәле, шагыйрь — галәм, реалистик, романтик, мифологик традицияләрнең һәм дини фәлсәфәнең бергә кушылуы күзәтелә, менә исә төрле сәнгати алымнар аша ирешелә.

Тукай турындагы шигърияттә реалистик традицияләр шагыйрьнең биографиясеннән мизгелләр, шәхси тормыш һәм характер сыйфатлары кебек якларның әсәр тукымасына кереп, беренче катлам бәяне бирүдә катнашуы, шулар ярдәмендә аның яңа сыйфатларын ачарга омтылыш белән тоташып китә. Бигрәк тә поэмаларда отышлы файдаланылган бу катлам шигъри әсәрләрне гадәти яшәештән ераклаштыра һәм шул ук вакытта глобаль реальлеккә якынайта, Тукай тормышын кабат җанландыра, аны тышкы дөнья, галәм язмышы белән бер үремтәдә бирә.

Нигез-өлге белән параллель үстерелүче романтик сызык, беренчедән, шагыйрьнең эчке дөньясын, рухи омтылышларын, киләчәккә өмет-хыялларын чагылдыруда күренсә, икенчедән, шигырьләрнең лирик аһәнен көчәйтә, тар, күнегелгән бożрадан алып чыга.

Романтик сызыкка яшәешнең дини ышанулар, җан кыючы яки яшәүгә көч бирүче затлар белән бәйле өченче буыны — мифологик фикерләр өстәлә. Бу сызык Тукай турындагы поэзияне әдәбиятның иң ерак катламнарына — халык авыз иҗатына, ырымнарга, мифологиягә тоташтыра. XX гасырның 90 нчы елларында әлеге катламга игътибар аеруча көчәя. Боларга 1960-1980 еллар поэзиясендә Тукайга бәя бирүнең төп хасиятләреннән берсенә әйләнгән әдәби, мәдәни үремтәләр бәйләнә. Бәя ике яклы төс ала: бердән, аның шагыйрьлегенә, татар әдәбиятын әйдәп баручы кебек иҗади хасиятләренә мөрәҗәгать ителсә, икенчедән, идеологик кысаларга кертелеп, иҗтимагый-сәяси идеяләр белән генә яшәгән әдәбият үзе тәнкыйтьләнә башлый. Шушы нигездә шагыйрьләр әдәбият-сәнгатьнең бурыч-максатлары, үзәк сыйфатлары, әхлаклылыгы мәсьәләләрен күтәрәләр, Тукай шәхесенең һәм иҗатының яңа буын шагыйрьләргә йогынтысы, каләмгә тотынган кешенең намусы, әдәбиятның хакыйкатьне әйтеп бирү көче хакында тулы бер сөйләшү башларга мөмкинлек туа. Милли үсешкә югары мәдәният аша ирешеп булуы ассызыкланып, Тукай иҗаты ярдәмче үрнәк модельгә әверелә.

Агымдагы чорда Тукайга багышланган поэзиядәге янарышны «Һаман шулай», «Халык төсе», «Без һаман бергә», «Язгы авазлар», «Чәчәкләр китерегез Тукайга», «Кулын канга батырса да» кебек әсәрләре белән Х.Туфан хәбәр итә. Аның шигырьләрендә яңа бер күренеш: Тукайны сурәтләүдәге социологик юнәлешне кире кагып, иҗтимагый-әдәби эчтәлекне берләштерү сыйфаты күзәтелә. Мәсәлән, «Без һаман бергә» шигырендә ул, шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесен чагыштырып, беренчесенең чын юлбашчы икәнлеген раслау, шуның ярдәмендә әдәбиятның тормыш-яшәештәге урынын хакимият баскычыннан да югары күтәрү максатын куя. Хакимнәрдән өстен Тукай образын бизәүдә сакральләштерү, изгеләштерү тенденциясе тоемлана.

С.Хәким иҗатында («Тукай дәфтәреннән» шигырьләр циклы, «Бер татарда ничә йөзләп шагыйрь» һ.б.) Тукайны сурәтләүнең тагын бер сукмагы — шагыйрьне татар әдәбиятында остаз, әдәбиятны әйдәп баручы итеп сурәтләү үзенчәлеге шәйләнә:

*Килде Тукай... Әйтте халык: Үзе...*
*Ияр аңа, инан, туры бар.*
*Бу сынатмас, бу беркайчан сатмас,*
*Йөзендә нур, иман нуры бар.*

Туфан-Хәкимнәрдән соң килгән буын — Г.Афзал, Р.Фәйзуллин, Р.Мингалим, К.Сибгатуллин, М.Шабаев һ.б. шигырьләрендә иҗтимагый-әдәби катламның әдәбилек ягы калкулана: Тукай образы әдәбиятның сыйфатын билгеләүче бизмән, Шагыйрь дигән бөек исемне йөртергә лаеклылыкны аңлатучы чисталык, аклык-сафлык, намуслылык үрнәге кебек сурәтләнә. Әкренләп иҗтимагый бәя-фикер әдәбиятның халык тормышындагы ролен күрсәтүдә кала. Шагыйрьләр идеалына хас сыйфатлар берлеге итеп караудан Тукайны милли көрәшче кебек тасвирлауга борылыш күзәтелә. Мәсәлән, Р.Фәйзуллинның «Яздан аерып булмый Тукайны!» шигырендәге строфадан строфага алмашына барган символлар аша чагылган идея, фикер Тукайны һәм аның турындагы поэзияне яңа сыйфатлар белән баета. Яз образының алышына барган мәгънәсе шагыйрьнең төрле сыйфатларын ачарга мөмкинлек бирә.

*Яздан аерып булмый Тукайны!*
*Язда килгән, язда ул янган.*
*Язы киләчәге барлар ничек китсен,*
*Ничек югалалсын дөньядан?!*

Галәм киңлегендә барган мәңгелек табигый алмашыну — язның кабатлануын үзәккә алып, шагыйрьнең мәңгелеген символлаштыручы фәлсәфи һәм киләчәккә өметне гәүдәләндерүче романтик чылбыр рухи яшәешкә тоташа. Тукай күңелендәге өмет, хыял, гүзәл гамьнәрне туплаган яз символы күңел аклыгын, сафлыгын яктырту (яз белән кара елларның янәшәлеге аны үзгә дәрәҗәгә күтәрә) белән бергә Тукайның яшьлегенә, изгелегенә, мәңгелегенә дә ишарә ясый.

К.Сибгатуллинның җан фәлсәфәсенә нигезләнгән «Яшь белән дә, җан һәм тән белән дә...» шигыре дә Тукайның үзенә һәм чорга бәя бирүгә юнәлтә, Тукайга субъектив бәя өстенлек ала. Заман шаукымында керләнгән күңел / Тукай җанының аклыгы каршылыгы соңгысының намус, әхлак, вөҗдан дәрәҗәсен ачарга мөмкинлек бирә. Шул рәвешле, шагыйрь үз чорына һәм халкына бәя бирә, шуның аша автор милләт хәленнән ризасызлыкны белдерүче сәяси фикер-карашларын да җиткерә. Тукай кешелекнең җанын сафландыручы, рухын саклаучы үзәгенә күтәрелеп, намусы кешелеккә бизмән, әхлакый бәянең иң югары ноктасы, пәйгамбәрләргә хас әхлакый камиллек һәм халыкка хезмәт үрнәге итеп куела. Ш.Галиевнең «Туры Тукай» шигырендә дә шагыйрь әхлакый камиллек, намус һәм туры сүз символы булып күтәрелә, рухи камиллек фәлсәфәсе аша чагылдырыла.

Мифологик, дини-космогоник образлар системасы Л.Зөлкәрнәев, Г.Морат кебек шагыйрьләр иҗатында Тукайны милли герой, Аллаһы Тәгалә тарафыннан татар милләтенә төшерелгән илче кебек тасвирларга ярдәм итә. Мәсәлән, «Тукай» шигырендә Г.Морат символлар ярдәмендә ачылган мәгънә аша шагыйрьгә берничә яклы бәя бирүгә ирешә. Тукай поэзиянең генә түгел, кешелекнең күкләр белән бәйле кагъбәсенә, табыну үзәгенә күтәрелә. Мифологик төсмер-сурәтләр авторга Тукайның намус чисталыгын, күңел аклыгын ачарга мөмкинлек бирә. Бу сурәт Р.Гаташта да җанландырыла. Аның «Шигърият!..» әсәрендә «кеше — Алла», «Алла — кеше» кебек суфичылык мотивы тудырылып, шагыйрьнең бөеклеген раслаучы фәлсәфә белән үрелә. Шигъриятнең бүгенгесеннән риза булмаган, сүз сәнгатенең дәрәҗәсе төшүе, әхлагын югалтуы өчен борчылган лирик герой төрле дәрәҗәләргә үрелгән, вөҗданы какшаган шигърият һәм каләм әһелләренә Тукайны намус, аклык символы итеп күрсәтә. Шул рәвешле, Р.Гаташ сәнгатьнең сафлыгы, әдәбият әһеленең намуслылыгы турындагы традицияләрне яңарта.

Х.Туфанның «Чәчәкләр китерегез Тукайга», Х.Әюповның «Туры сүзгә», «Иман яңарту», Илдар Юзеевнең «Син яшьтәш тә, замандаш та...» һ.б. шигырьләрендә милләтнең Тукайга мөнәсәбәте, шуның аша татар халкының бүгенгесе һәм киләчәге

хакында уйлану, кайбер әсәрләрдә җәмгыять хәле белән бәйле сәяси тәнкыйть урын ала.

*Без чәчәкләр аша тапшырырга*
*Тиеш тә бит сиңа сәламне.*
*Ел буена тик бер генә тапкыр*
*Күрәсең син, Тукай, аларны.*

(Х.Туфан. «Чәчәкләр китерегез Тукайга»).

Тукайга хөрмәт, игътибар милләтнең рухи үсешен, мәдәни дәрәҗәсен күрсәтү бизмәненә әйләнә. Сүз сәнгатенең югары дәрәҗәсе Тукай иҗаты белән билгеләнә, әдәбият-сәнгатьнең үсеш дәрәҗәсен танып-белүнең «Тукай иҗаты» дип аталган биеклеге бәяләү бизмәне буларак алына. Шул рәвешле Х.Туфан «йокыга талган», «көнлекчеләр» тормышы белән яшәүче милләтен уятырга омтылып, илнең бишьеллык планнарны, гигант төзелешләрне генә мәдхия, максат иткән сәясәтенә үз карашын да житкерә. Бу әдәби катламның сәяси юнәлеш алуын күрсәтә.

Ш.Галиевнның «Тукайга», Зөлфәтнең «Ялгызлык», Р.Әхмәтҗановның «Тукайның соңгы рәсеме», Р.Харисның Тукайдан алган «Китмибез без, безгә анда...» эпиграфы белән башланган «Китмибез!», М.Әгъләмовның «Әйтте Тукай», Р.Зәйдулланың «Йокысызлык» һ.б. шигырьләрдә исә, гомумән, милләт язмышы, актуаль мәсьәлә кебек куелып, Тукай шәхесе, аңа мөнәсәбәт милли бәйсезлеккә чакыру мотивлары белән байый. Мәсәлән, Зөлфәтнең «Ялгызлык» шигырендә җил, боз образлары чор вазгыятен күз алдына бастыра, идеологик кануннарны танырга ярдәм иткән мистик кара шәүлә образы милләт тормышын җимерүче көчләрне символлаштыра. Яшәү һәм мәхәббәтне символлаштырган шәм уты образы авторга Тукайның халкы өчен яшәвен, көрәшүен, иҗади эшчәнлеген дә шул юнәлештә алып баруын күрсәтергә ярдәм итә. Гомере, мәхәббәте белән халкын «җылыткан» шагыйрь үлем алдында ялгызы кала. Зөлфәт даһилар кадерен белмәүнең татарда өзлексез дәвам итүенә ачына, Тукайны югалту кебек тарихның ачы сабагын күрсәтү аша Тукайга мөнәсәбәтне милләткә бәя бирү чарасы итеп куя.

Тукайга багышланган поэмалар шагыйрь образын сурәтләүне эпик әсәр мөмкинлекләрен файдаланып тирәнәйтә. С.Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә», М.Әгъләмовның «Тукайдан хатлар» поэмаларында биографик-реалистик, сатирик-тәнкыйди янгыраш, иҗтимагый фикерләр: милләт, аның язмышы, үткәне, бүгенгесе, киләчәге; фәлсәфи уйланулар: кеше һәм яшәеш, яшәү мәгънәсе һәм кешелек алдындагы бурыч; әдәби мәсьәләләр: әдәбият һәм аның кеше, милләт тормышындагы роле, әдәбиятның шагыйрьгә йөкләтелгән олы вазифасы, шагыйрь шәхесе; сәяси ачыну: марксистик идеология һәм система китергән фаҗигаләр хакында сөйләү белән үрелеп бара. Шулай милли идеал булып күтәрелгән Тукай шәхесе, образы тормыш-яшәешнең гомумән татар әдәбиятын борчыган, кызыксындырган барлык өлкәләрен үз янына җыя.

Әнә шулай гасыр башында дөньяви милли идеал булып мәйданга чыккан Тукай образын татар поэзиясе 1960-1980 елларда сәяси-реалистик, дини-мифологик, иҗтимагый, әдәби-аксиологик, хыялый-романтик аспектларда баета һәм 1990 елларда, татар милли күтәрелеше күзәтелгән бер вакытта, кабат милли көрәшче дәрәҗәсендә укучыга тәкъдим итә. Гомумән, Тукай турындагы шигърият XX гасыр әдәби-эстетик фикерендә барган үзгәреш-янарышларны тагын бер кат шәрехли, әдәби традицияләрнең дәвам ителешен, үстерелешен, мәгънәви баетылышын дәлилли һәм сүз сәнгатенең милли нигезләрне, кыйммәтләрне югалтмавы хакында сөйли.

**Нурфия ЮСУПОВА,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

# МИЛЛӘТКӘ ХЕЗМӘТ ИТӘБЕЗ



Татарстан Язучылар берлеге төзелүгә быел 80 ел тула. Кеше гомере белән исәпләгәндә, бер гомер дип саналырлык сан. Бу еллар эчендә язучыларның дүрт буыны алышынган: утызынчы-кырыгынчы еллар, илленче-алтмышынчы еллар, житмешенче-сиксәненче һәм жәмгыять яңа формациягә күчкәннән соң яшәүче бүгенге заман язучылары. Алар арасында соңгы өч буын эчендә яшәп көн күргән өлкән яшьтәге язучыларыбыз да байтак. Жәмгыять үзгәрү белән, Язучылар берлегенә караш, мөнәсәбәт тә үзгәреш кичерде. Аңа карата төрле фикерләр барлыкка килде. Бүген ижат берлекләренә гап-гади ижтимагый оешма итеп кенә карау тенденциясе күзәтелә. Шул ук вакытта 80 ел эчендә Язучылар берлегенең илебез, халкыбыз тормышында үз урыны, жәмгыять үсешенә керткән үз өлеше барлыгын да билгеләп үтәргә кирәктер.

Ижат берлекләре — совет системасы балалары — шул система тудырган, аңа хезмәт иткән оешмалар. Система үзгәрде, ә ижат берлекләре сакланып калды. Жәмгыятьтә ижат берлекләре дә бетәргә тиеш дигән фикерләрне еш ишетергә туры килә.

Язучы ул — жәмгыятьнең барометры; тормышта булган барлык әһәмиятле вакыйгалар, үзгәрешләр һәм яңалыклар һәрчак язучы ижатында чагылыш таба, әсәрләрдә тасвирланып, мәңгелек гәүдәләнеш ала. Әдәби әсәрләр аша кешенең, халыкларның үткәне мәңгеләштерелә, тарих битләрендә язылып кала. Язучы сүзе ул гаять көчле корал, рупор да. Язучы һәрчак тормышның үзәгендә кайный. Халык һәрвакыт иң гадел, иң кирәкле сүзне язучылардан көтә. XIX гасыр ахыры — XX йөз башында жәмгыятьтәге революцион үзгәрешләрнең үзәгендә кайнап, ижтимагый хәрәкәтне әйдәп баручылар да нәкъ менә әдипләр булган. Язучыларны һәрчак күз уңында тоту, аларның эшчәнлегенә, ижатына тиешле юнәлеш бирү максатында коммунистлар тарафыннан бер берлеккә тупланган каләм әһелләре, ижтимагый хәрәкәткә йогынтылары зур булганлыктан, узган гасырның утызынчы елларында иң күп зыян күргән затлар булгандыр да. Бәхетле тормыш кору турында хыялланып, өметләренең акланмавыннан гайрәте чиккән, шул хакта үз фикерләрен белгертергә жөрьәт иткән язучылар партия тарафыннан рәхимсез рәвештә эзәрлекләүгә дучар ителә. Бер уйлап караганда, Язучылар берлеген оештыру әнә шулай халыкны күзгата алган көчкә ия каләм әһелләрен бәйдә тоту өчен кирәк булган. Совет системасы жимерелеп төшкәннән соң, ижат берлекләре Россиядә ижтимагый оешма дип игълан ителделәр. Яңа ижтимагый формация дингезендә үз көнен үзе күрергә тиешле караб хәленә төшерелделәр. Шуңа күрә дә Мәскәүдә бүген язучыларның биш-алты ижат берлеге яшәп килә. Алар дәүләт бюджетыннан финансланмый. Хәер, совет чорында тупланган байлыкларын законлы-законсыз рәвештә бүгәләп, үзләштереп бетергәннән соң, шуны кире кайтару өчен үзара ызгышып-талашып яшәп ятучы берлекләргә карата хакимият тарафыннан башкача караш, мөнәсәбәт булуы мөмкин дә түгелдер. Ләкин ижат берлеге ул мал бүлешеп, үзара ызгышып, талашып ятар өчен оештырылмый. Аның төп максаты — бердән, ижат әһелләренең югары сәнгать әсәрләре ижат итүенә, аларны бастырып чыгаруда һәм дөньяга таратуда ярдәм итү булса, икенчедән, язучыларның ижади, гражданлык, сәяси, икътисади һәм социаль хокукларын яклау белән шөгыльләнү. Берлек эшчәнлегенең барлык юнәлешләре дә бары тик аның менә шушы максатларны тормышка ашыру омтылышыннан гына булырга мөмкин һәм тиеш. Ә вак-төяк интригалар, ызгыш-талашлар әлеге

максатларга ирешүдә һич тә ярдәмче була алмый. Киресенчә, аларның җәмгыять тарафыннан иҗат берлегенә карата тискәре мөнәсәбәт урнашуга китерүе мөмкин. Россиядә иҗат кешеләренә карата мөнәсәбәтнең бик үк уңай булмавы нәкъ менә шуның нәтиҗәсе дә инде. Ләкин хөкүмәт, хакимият акыллырак булырга, андый түбәнлекләрдән өстен торырга, иҗат әһелләрен яклый һәм аларның иҗатын стимуллаштыра торган законнар кабул итәргә тиеш дигән фикердә торам мин.

Иҗат берлекләре дигәндә, иң элек иҗат дигән төшенчәнең әһәмияте турында сүз алып барырга кирәктер. Кызганычка каршы, дөньяда иҗади эшчәнлекнең бәһасен аңлап бетермәү яшәп килә. Әдәби әсәр, музыка, рәсем иҗат итүгә генә түгел, фәнни-техник иҗатка да ничектер хобби итеп кенә карау тенденциясе бар. Соңгы елларда Россиядә Фәннәр академиясен дә иҗат берлекләре дәрәҗәсенә куюу омтылышы булып алды.

Кешене яшәткән, алга илткән көч — ул аның әйбер, продукция җитештерүе генә түгел, бәлки нәкъ менә иҗади сәләткә ия булуы, сәнгатьчә матур итеп сөйли, яза белүе, җыр, көй тудыруы, рәсем төшерүе һәм шул сәнгать әсәрләренә карап соклана алуы. Хайван гына үзенең ничек яшәгәнен, ничек дөньяга яралуын, бер көн килеп үзенең кемдер тарафыннан юк ителәсен аңламыйча, тарихи язмышын белмичә, бары тик азык табу максаты белән яши. Ә кеше, әйткәнемчә, төрле сәләтләргә ия һәм үзенең тормышын, күргән-белгәннәрен тасвирлый, хис-кичерешләрен шигъри сүзгә, көй-моңнарга төреп бирә, рәсем итеп төшерә. Тау куышларында сакланып калган рәсемнәрдән без моннан дистәләрчә мең еллар элек яшәгән кешеләрнең тормышын, яшәешен күзаллыйбыз. Борынгы заман язучыларының әсәрләреннән укып, кешелекнең тарихын, үсеш эволюциясен, нинди юл үтүен беләбез.

Иҗади эшчәнлекнең менә шундый әһәмияткә ия икәнен аңлаганда гына, без иҗат әһелләренең эшчәнлеген оештыруга хезмәт итү өчен төзелгән берлекләребезнең нәтиҗәле эшләвенә ирешә алачакбыз.

Безнең республикада иҗат берлекләре Министрлар Кабинетының резерв фондыннан финанслана. Моннан тыш бюджет хисабыннан Татарстан китап нәшриятында китапларыбызны бастырып чыгару мөмкинлегебез бар. Нәшриятта ел саен йөзгә якын язучыбызның китаплары басылып тора. «Татмедиа» агентлыгы газета-журналларында яна әсәрләребезне халыкка җиткерә алабыз. Әле шуларга өстәп республика җитәкчеләренең — Президентыбызның, хөкүмәт башлыкларының хәерхаһлы мөнәсәбәтен һәрдаим тоеп яшибез. Татарстанның халык язучысы, халык шагыйре исемен йөрткән барлык әдипләребез дә, ә аларның саны — 26, үз вакытында әсәрләренең күптомлыкларын һәм тулы басмаларын чыгару бәхетенә ирешә. Алардан тыш та язучыларыбыз әйбәт, халык яратып укый торган әсәрләренең күптомлыкларын әледән-әле дөньяга чыгарып тора. Безнең берлектә бүген 330 язучы исәптә. Шуларның 210ы пенсия яшендә. Президентыбыз мәрхәмәте белән барысына да менә икенче ел инде ай саен бер мең сум күләмендә пенсияләренә өстәмә акча түләнә. Халык язучысы исемен йөрткән эшләмәүче аксакалларыбыз шуна өстәп ай саен ун мең сум күләмендә акча ала. Мондый ярдәмне мин бары тик кыргыз һәм казакъ язучылары гына ала дип беләм. Татарстан Язучылар берлеге 1986 елдан бирле Казаныбызның күрке булган, тарихи архитектура, мәдәният ядкәре дип исәпләнгән затлы бинада эшләп килә. Ике ел элек ул бик яхшы сыйфатлы итеп, зур чыгымнар түгеп төзекләндерелде. Берлекнең Чаллы һәм Әлмәт бүлекләре дә бөтен уңайлыклары булган биналарда урын били. Болар барысы да республикабыз җитәкчелегенең, бигрәк тә Президентыбызның язучыларга карата җылы мөнәсәбәтен сөйләп тора. Шуна күрә без беркөнне тотарлар да Язучылар берлеген «асраудан» туктарлар дигән уйдан ерак торабыз. Дөрес, заман бик катлаулы, иҗат берлекләре — бүгенге заман өчен артык кашык ул, кебек фикер берсенең башына килмәсме дигән уй да күңелдә яши. Ләкин, алда әйткәнемчә, иҗат кешесенең тормыштагы урынын, ролен күрә белгәндә, мондый хәл булмаска тиеш.

Дөрес, Татарстан Язучылар берлеге моннан 80 ел элеккеге, беренче оешкан чордагы вазифасын башкарудан ерак тора. Иҗат әһелләрен берлекләргә туплау — ул аларның эшчәнлеген цивилизацияле юл белән оештыруның бер билгесе. Узган гасырда коммунистлар шуны аңлаганнар һәм иҗади эшчәнлекне үз идеологияләренә хезмәт иттерүнең иң ышанычлы юлын шунда күргәннәр. Бүген идеология юк. Дөресрәге, ул бар, ләкин аның барлыгын күрсәтмәскә тырышалар, чөнки ул — байлык, мал туплау

идеологиясе. Ләкин бу берәүләрнең фәкыйрьләнә баруы хисабына туплана. Ә сәнгать, әдәбият, мәдәният, зыялылык мондый идеологиянең дошманы. Иҗат әһелләре һәрвакытта да бәхетле матур тормышта яшәү өчен көрәшне идеаллаштырганнар, шуның өчен көрәшүчеләр язмышын чагылдырган әсәрләр тудыруны үз бурычлары итеп күргәннәр һәм шуңа омтылганнар. Бу бит начар түгел. Безнең җитәкчеләребез дә, гомумән, дәүләт үзе дә — кеше өчен, хезмәт кешесе өчен, аны яклауны кайгырту өчен тудырылган гарант бит ул. Ә язучы ана шушы вазифасын башкаруда иң ышанычлы ярдәмче булырга тиеш һәм ул үзенең иҗаты аша шуңа хезмәт итүче зат. Дөрес, язучылар алар кешелекнең иң нечкә күңелле, хисчән вәкилләре һәм шуның аркасында салкын акыл белән эш итүгә караганда, эмоцияләргә бирелеп, хөкүмәт сәясәтенә каршы чыгышлар ясарга да бик маһир халык. Россия, аның төп халкы булган урыс милләте вәкилләренең мәнфәгатьләрен кайгыртуны алга сөргән Мәскәү кул астында яшәүче башка вак халыкларның республикалары җитәкчелегенең хәлен дә аңларга кирәк. Урыслар ачыктан-ачык православие диненә өстенлек бирергә, урыс телен генә үстерүгә юнәлтелгән, башка милләт балалары туган телләрен предмет буларак кына өйрәнергә тиеш дигән сәясәт алып барганда, республикабыз башлыкларына җитәкчелек итү гаять авыр һәм катлаулы. Безнең «милләтпәрвәр» дигән даны чыккан кайбер каләм ияләребез ни өчендер менә шуны аңларга теләмиләр һәм кайда туры килсә шунда җитәкчеләребезне тәнкыйть утына тотарга торалар. Имеш, алар гына милләт турында кайгырта да, алар гына хаклы. Мондый каләм ияләрен мин һичшиксез иҗат берлекләренең киләчәктә яшәп калуына куркыныч тудыручылар дип саныйм. Шунысы гыйбрәтле: алар республика җитәкчелегенең Язучылар берлегенә күрсәткән барлык игелекләреннән дә бернинди вөҗдан газаплары кичермичә файдалануны мәкуль күрә. Безгә бүген үзебезгә карата шундый хәерхаһлы мөнәсәбәтне бары тик яхшы әсәрләр белән генә акларга мөмкин.

Соңгы вакытта җәмәгатьчелектә Ә.Еники, Г.Бәширов, М.Мәһдиев, А.Гыйләҗев, Н.Фәттах, Г.Ахунов кебек көчле язучылар калмады, күләмле әсәрләр язылмый, дигәнрәк фикерләр ишетергә туры килә. Ләкин бу дөреслеккә туры килми, дияр идем. Безнең оешмада талантлы каләм ияләре байтак. Күләмле әсәрләр дә языла. Мондый фикерләр яңгырауның төп сәбәбе, минемчә — халыкның китап укымавында. Бигрәк тә эре-леваклы түрәләребез, китап укымыйча гына, шулай сөйләнә башлады. Китап кына түгел, вакытлы матбугат та укымыйлар. Түрәләребезнең күбесе республиканың төп басмаларын да укымый. Совет чорындагы кебек, үзәк матбугатта чыккан тәнкыйть язмаларына реакция ясау да бетте. Әдәби китап урынына күп җитәкчеләр үзләре турында, үзләре җитәкләгән предприятиеләр, оешмалар турында гел мактаудан гына торган, төсле иллюстрацияләр белән бизәлеп, затлы кәгазьдә басылган, үзкыйммәте әдәби китапларга караганда өч-дүрт мәртәбә югарырак, ләкин әдәбилеге бик түбән, тел зәгыйфь китаплар бастырып чыгаруны хуп күрә. Үзләре ул китапны укымасалар да, килгән кунакларына шул китапларны бүләк итеп җибәрергә гадәтләнеп киттеләр. Килгән кунакка шул китап бик кирәк дип беләләр инде. Акчаны әдәби әсәрләр яздырып, шуларның китапларын чыгаруга, язучыларга гонорар түләүгә сарыф иткәндә, ул җитәкчеләр турында әдәбиятта Гомәр Бәшировның «Туган ягым яшел бишек», «Җидегән чишмә», Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә», Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән», «Балта кем кулында», Гариф Ахуновның «Хуҗалар», «Хәзинә» кебек әсәрләре дөньяга туар иде. Андый әсәрләрне тудырырдай язучылар арабызда, шөкер, бар. Язганнары өчен тиешле гонорар һәм, әйтергә кирәк, аванс белән алдан түләнсә, иң ышанычлысы — әсәрләр заказ белән язылса, һичшиксез, замандашларыбыз образларын тудырган күләмле әсәрләр дөнья күрер иде. Элек бит ничек иде: язучы китабын чыгарса, бер ел буена беркая да эшләмичә язып кына ятып, яңа әсәр иҗат итәрлек гонорар ала, күләмлерәк китап бастырып чыгарса, аның гонорарына әле хәтта җиңел машина сатып алырлык та мөмкинлеге була торган иде.

Бүген, күләмле әсәрләр иҗат итәрдәй язучылар да юк дигән имеш-мимешләргә сүз калдырмас өчен, язучыларның иҗади эшчәнлеген оештыру Язучылар берлеге, аның идарәсе алдындагы төп бурычларның берсе булып тора. Ул аның уставында шулай билгеләнгән. Берлек идарәсе бүген дә бу документка тугры. Соңгы елларда илдә грантлар алу гамәлгә керде. Без дә шуның бер төре булган әдәби конкурслар

игълан итүдән файдалана башладык. 2012-2013 елда Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә бүгенге авыл тормышын чагылдырган проза әсәрләре иҗат итү буенча әдәби конкурс үткәрдек. Моның нәтиҗәсе булып 8 роман, 27 повесть һәм 34 хикәя иҗат ителде.

Быел мин Мәдәният министрлыгы һәм республикабыз җитәкчелеге алдына язучыларыбызга күләмле әсәрләр иҗат итү өчен дәүләт заказы алу турында идея белән чыктым. Элек бит шулай булган: әле XVIII гасырларда ук әдипләр төрле журналлардан, нәшриятлардан әсәрләр иҗат итүгә заказлар алган. Урысның XIX гасырда яшәгән барлык күренекле язучылары да заказ буенча, аванс белән гонорар алып үз шедеврларын тудырганнар. Чит илләрнең бөек язучылары да шулай язган. Советлар Союзында да заказ системасы яшәп килде. Әсәре басылып чыкканчы ук, язучы гонорарының бер өлешен аванс белән ала иде. Бу язучыга бары тик иҗат белән генә шөгыльләнергә мөмкинлек тудыра. Югыйсә безнең хәзерге язучыларыбыз нинди дә булса газит-журнал редакциясендә түбән хезмәт хакына эшләп йөрергә, аның мең төрле вак мәшәкатеннән арып-талып кич өйгә кайткач, китап итеп басылып чыгуына бернинди дә гарантия булмаган иҗат белән шөгыльләнергә, берәр оешма яки хәллерәк заказчыдан эш алып, тәрҗемә яисә халтура язу белән маташырга мәҗбүр. Ә болай таралу ул беркайчан да күләмле һәм талантлы әсәр иҗат итәргә ярдәм итми, киресенчә, язучының иҗат потенциалын киметә. Быел, әйткәнемчә, биш кенә бөртек булса да язучыбызга күренекле татар шәхесләре турында күләмле проза әсәрләре язар өчен дәүләт заказы алуга ирештек. Һәм әдипләребезнең бу эшне зур җаваплылык белән, унышлы башкарып чыгасына иманым камил. Мондый эш ел саен дәвам итәр, яна әсәрләр тудыруга киләсе елларда да дәүләт заказлары алуга ирешербез дип өметләнәм.

«Әдәбият» дигән сүзнең тамырында «әдәп» ята. Димәк, әдәбият ул әдәплелек, тәрбия дигән мәгънәләргә ия. Әдәби китап укыган кеше — әдәпле кеше, әдәбият укып үскән бала гуманлы, кешелекле була. Бу — борын-борыннан килә торган фикер. Язучы хезмәте ул гуманлы, әдәпле кеше тәрбияләү белән бер.

Дөрестән дә, әдәбият фәне мәктәп тәрбиясе системасының нигезен тәшкил иткән. Борынгы заманнардан ук баланы мәктәптә тәрбияләү эшендә китап укыту төп дәрес булган. Дөрес, элек ул дини китап, дини әдәбиятны укытуны күз алдында тоткан. Дөньяви фәннәр укытуга күчә барган саен, әдәби әсәрләр укыту алгы планга чыккан. Әдәбият укыту бүгенге белем бирү системасында да төп урыннарны алып тора. Әдәбият, туган тел дәресләре балага үз туган телен өйрәнеп, белеп үсәргә ярдәм итә, китап укырга, тормыш, дөнья белән танышып үсәргә булыша. Балаларга туган телгә, әдәбиятка мәхәббәт тәрбиясе бирүдә язучыларның катнашы гаять зур әһәмияткә ия. Безнең язучылар шулай ук балаларның иҗади сәләтләрен ачуда һәм үстерүдә актив катнашып киләләр. Мәктәпләргә очрашуларга йөриләр, чыгышлар ясыйлар, үз иҗатлары белән таныштыралар, әдәби мирасыбызны укучыларга җиткерүдә зур эш башкаралар. Язучыларның районнарга чыгып, мәктәпләрдә татар әдәбияты көннәре үткәрүе — күптәннән килгән традиция. Менә берничә ел инде республика Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә балаларның иҗади сәләтләрен ачыклау һәм үстерү максатыннан, республика конкурслары үткәрелә. Бу безгә язучылар сафын тулыландыру, яшь алмаш тәрбияләү өчен зур мөмкинлек. Соңгы елларда Россиядә мәктәп, укыту системасында урыслаштыру сәясәте көчәйгән бер заманда, бердәм дәүләт имтиханнарын бары тик урыс телендә генә тапшыру алга куелганда, милли республикаларда туган телдә укыту бары тик предмет буларак кына барганда, балаларны татар әдәбияты, язучы, аларның иҗаты белән таныштыруының әһәмияте аеруча зур.

Яшь алмаш тәрбияләү дигәннән, яшьләребез турында да кыскача гына тукталып үтәргә кирәктер. Бүген Берлегебездә 35 яшькә кадәр егерме егет һәм кыз әгъза булып тора. Тагын нәшриятларда беренче китапларын чыгарган шуның кадәр яшь һәм башлап язучылар бар. Бу кечкенә саннар түгел. Әлеге яшьләр — узган гасырның соңгы ун елында мәктәпләрдә белем алган, милли укыту системасының уңдырышлы туфрагында бөреләнгән җимешләребез. Ләкин соңгы елларда милли мәгариф системасында кискен үзгәрешләр барлыкка килде. Туган телдә сөйләшү даирәсе кысылды. Туган телендә сөйләшмәгән бала, иҗатка сәләте булса да, туган телендә фикерли алмый башларга мөмкин. Нинди телдә фикерләсә, шул телдә язачак та. Дөрес, әлегә мәктәпләребездә



*ТР Язучылар берлеге бинасы*

туган телләрендә шигырь язучы балалар белән аларның сәләтләрен ачу һәм үстерү буенча зур эш алып барыла. Республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгы да бу эшкә зур игътибар бирә башлады. Быел министрлык каршында милли мәгариф буенча махсус идарә ачылды. Бу идарә белән безнең Берлек арасында үзара хезмәттәшлек буенча килешү төзелде. Без, язучылар, уку елы дәвамында төркем-төркем булып районнарга, мәктәпләргә очрашуларга чыгабыз. Туган тел һәм әдәбият көннәре үткәрәбез. Төрле төбәкләрдә туган язучылар иҗатына багышланган фәнни укуларда, «түгәрәк өстәл» сөйләшүләрендә катнашабыз. Иҗатка сәләтле балалар арасында республика конкурслары үткәрелә. Болар барысы да, бердән, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү буенча игелекле эш булса, икенчедән, яшь әдәби алмаш хәзерләү чарасы да.

Яшьләребезнең иҗаты матбугатта киң яктыртыла. «Сабантуй», «Ялкын», «Идел» журналлары бу җәһәттән яшьләргә киң мәйдан бирә. Бер генә нәрсә күнелдә төер булып калды: «Сабантуй» газета булудан туктап, журнал форматында чыга башлады. Газета чагында аның балалар иҗатын яктыртуга, балалар өчен язган әдипләребезнең иҗатына зур урын бирелә иде. Газета белән журнал арасында вакытлы матбугат басмасы буларак зур аерма бар. Бу хакта сөйләп торуның хаҗәте юктыр дип уйлыйм.

Яшьләребезнең күбесе газета-журнал редакцияләрендә эшли, гомерләрен һәм эшчәнлекләрен матбугат, әдәбият белән бәйләгәннәр. Араларында укытучылар, тәрбиячеләр дә байтак.

Яшь алмаш тәрбияләүче төп үзәкләр — ул әдәби берләшмәләр. Һәр район газетасы редакциясе каршында шул төбәктә яшәүче, әдәбият белән кызыксынучыларны, каләм тибрәтүчеләрне үз тирәсенә туплаган әдәби берләшмәләр эшләп килә. Казанда М.Горький музее каршында — М.Зарецкий исемендәге, Казан федераль университеты каршында — «АРС», «Әллүки», медицина университетында «Белая ворона» берләшмәләре эшләсә, Әлмәттә — «Белая ворона»ның филиалы, «Кызыл каурыйлар», Сарманда — «Сарман таннары», Азнакайда — «Гөлстан», Бөгелмәдә — «Монсар», Җәлилдә — «Җәлил чаткылары», Мөслимдә — «Зөлфәт» клубы, Түбән Камада — «Кама таннары», Лениногорскида — «Чишмә», Яшел Үзәндә — «Фирүзә» кебек дистәләрчә әдәби берләшмә безнең әдәби резервыбыз ролен башкара.

80 ел ул шактый зур вакыт, алда әйткәнебезчә, бер кеше гомеренә бәрабәр. Берлек бу вакыт эчендә зур эшләр башкарды. «Язучы» сүзенең нинди зур көчкә ия икәнен аңлап, коммунистик идеологиянең байракчысы ролен башкару өчен төзелгән Язучылар берлеге беренче көннәреннән үк ил-дөнья вакыйгаларының үзәгендә булды, тормыш казанында кайнады. Һәрнәрсәгә үз карашы булган, тайпылышларны да дөрес күрә белеп, үз фикерен белдергән язучыларның байтагы узган гасырның утызынчы елларында сәяси репрессияләр корбаны да булды. Язучылар берлеген оештыруда актив катнашучы Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Толымбай, Шамил Усманов, Гомәр Галиләр хәтта халык дошманы дип игълан ителеп, физик юк ителүгә дучар булды. Кави Нәҗми, Мирсәй Әмир, Сәрвәр Әдһәмова, Хәсән Туфан, Фатих Кәримнәр төрмә, сөрген җәфаларын күрергә дучар ителде. Әле илленче елларга хәтле, Сталин үлгәнче сузылган репрессияләр 43 татар язучысының язмышын талкыды.

Бик күп язучыларыбыз Бөек Ватан сугышында ил азатлыгы өчен кулына корал алып сугышты, алгы сызыкта фронт газеталары хәбәрчеләре булып, ут эченә керде. Мәскәү, Ленинград язучылары, эвакуацияләнеп, Казанга, Чистайга, Алабугага

кайтып, тормышларын саклап ятканда, безнең 104 язучыбыз фашистларга каршы ут эченә керде. Аларның 31е яу кырында мәңгегә ятып калды. Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыгы аеруча гыйбрәтле һәм тиңдәшсез. Мирсәй Әмир, Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Гариф Гобәй, Афзал Шамов, Фатих Хөсни кебек әдипләр совет халкының тылдагы батырлыгын тасвирлаган күләмле әсәрләр иҗат иттеләр.

Сугыштан соң Германиягә кадәр җиңүле авыр юл узып кайткан язучыларыбыз — Габдрахман Әпсәләмов, Сибгат Хәким, Ибраһим Гази, Зәки Нури, Шәрәф Мөдәррис, Әнвәр Давыдов, Риза Ишморат, Габдулла Шәрәфи, Әхмәт Исхаклар, коралларын каләмгә алыштырып, яңа бер дәрт, теләк белән иҗат эшенә кереште, колачлы, масштаблы романнар, хикәя-повестьлар, шигырь-поэмалар иҗат итте. Совет халкының сугыштагы һәм тыныч тормыштагы тиңдәшсез хезмәт батырлыгын үз әсәрләрендә җырга салды.

Сталинның шәхес культы фаш ителгәч, әдәбият мәйданына Хәсән Туфан, Ибраһим Салахов, Аяз Гыйләҗев, Нәби Дәүли, Гурий Тавлин, Гәрәфи Хәсәнов, Сөббух Рафиков, Мин Шабай, Адлер Тимергалиннар кайтты. Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Шамил Усманов, Галимҗан Ибраһимов һәм башкаларның гаепсез икәнлеге мәгълүм булды, әсәрләре мәктәп дәреслекләрендә, китапханә киштәләрендә кабат урын алды.

Илленче елларда Әлмәт республикабызның нефть башкаласына әверелде. Гариф Ахунов, Гамил Афзал, Рафаил Төхфәтуллин, Саҗидә Сөләйманова белән Әдип Маликовлар бирегә килеп, бу төбәктәге талантлы каләм ияләрен бергә туплап, Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеген оештырдылар. Алар белән бер сафта Шамил Бикчурин, Мәхмүт Хәсәнов, Альберт Хәсәнов кебек яшьрәк буын әдипләре нефтьчеләребезнең данлы хезмәтенә багышланган әсәрләр иҗат иттеләр, Әлмәт каһарманнары данын дөньяга таныттылар. Аларның эшен бүген Фоат Садриев, Нур Әхмәдиев, Илдус Гыйләҗев, Клара Булатова, Дамир Гарифуллин, Рәмзия Габделхакова кебек каләм осталары дәвам итә.

Җитмешенче елларда Татарстанда тагын бер гигант төзелеш колач җәйде — Чаллы автомобиль заводы һәм Чаллы шәһәре корыла башлады. Ул СССРның төрле төбәкләреннән яшь егет һәм кызларны үзенә җыйды. Әлбәттә, биредә кулында каләм уйнаткан яшьләр дә күп иде. Эдуард Касыймов, Мәхмүт Газизов, Кадыйр Сибгатуллин, Хәниф Хөснуллин кебек язучылар, берләшеп, Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеген оештырдылар. Мөдәррис Әгъләмов, Газиз Кашшаф-Үзиле, Шәүкәт Гаделша кебек талантлы әдипләребезнең дә иҗат чишмәләре Чаллы төзелешләрендә баш ала. Бүген биредә талантлы прозаик Вахит Имамов җитәкчелегендә Рәшит Бәшәр, Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Факил Сафин, Айгөл Әхмәтгалиева кебек утыздан артык язучыны берләштергән бүлек эшчәнлеген дәвам иттерә.

80 ел ул зур вакыт. Бу еллар эчендә Татарстан Язучылар берлеге илдә барган вакыйгаларның үзәгендә кайнады. Берлекнең 17 корылтае булып узды. Берлек белән төрле елларда Кави Нәҗми, Мирсәй Әмир, Муса Җәлил, Әхмәт Ерикәй, Гариф Гобәй, Гомәр Бәширов, Афзал Шамов, Ибраһим Гази, Зәки Нури, Гариф Ахунов, Туфан Миңнуллин, Ринат Мөхәммәдиев, Фоат Галимуллин һәм Илфак Ибраһимов кебек күренекле язучылар җитәкчелек итте.

Әдипләребезнең әсәрләре 2012 елның маенда 90 еллыгын билгеләп үткән «Казан утлары», узган ел беренче саны чыгуга 100 ел тулган «Сөембикә», быел үзенең 25 яшьлеген билгеләп үтүче «Идел» («Идель»), Чаллыда нәшер ителә торган «Мәйдан» кебек журналларда, «Мәдәни җомга» газетасында һәм башка вакытлы матбугатта дөнья күрә. Быел шулай ук төзелүенә 95 ел тулучы Татарстан китап нәшрияты язучыларыбызның әсәрләрен дөньяга чыгаруда гаять зур эш башкара. Нәшрият һәрвакытта да Татарстан Язучылар берлеге белән иҗади хезмәттәшлек итеп килә. Биредә басыла торган китаплар, бигрәк тә әдәби басмалар Язучылар берлеге белән үзара килешү-киңәшләшү нәтиҗәсендә дөнья күрә. Биредә ел саен йөзләп кенә язучының әсәрләре китап булып басылып чыкмыйдыр. Дәүләтебез җитәкчелеге республика икътисади авырлык кичергәндә дә нәшриятны саклап калды һәм ул милли республикалар арасында китап бастырып чыгару буенча иң нәтиҗәле эшләүче нәшриятларның берсе булып тора. Менә 15 елдан артык инде нәшрият белән тәҗрибәле нашир, китап басу эшенең бөтен нечкәлекләрен сизгер тоемлаучы белгеч Дамир Шакиров җитәкчелек итә.

Язучыларыбыз Татарстан белән генә чикләнеп калмый, Мәскәү, Санкт-Петербург, Башкортстан, Удмуртия, Мордовиядә, Ульян, Төмән, Чиләбе өлкәләрендә, Кырымда, Казакъстан, Төркия, Англия, Германия, Америка кебек чит илләрдә дә яши һәм иҗат итә.

Язучыларыбыз Татарстан белән генә чикләнмәгән кебек, аларның әсәрләрен дөньяга таныту да безнен алда торган бурычларның берсе. Моның берләнбер туры юлы — тәрҗемә. Бүген без күбрәк татарчаны урысчага һәм төрек теленә күчерүгә игътибар бирәбез. Урыс теле элекке Советлар иле составында булган халыкларга, шулай ук кардәш казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән, азәрбайҗан һәм башка төрки кардәшләребезгә дә яхшы аңлашыла. 2007 һәм 2008 елларда Татарстан китап нәшриятында бер-бер артлы татар әдипләренең урыс теленә тәрҗемә ителгән әсәрләрен туплаган «Современная татарская проза» һәм «Современная татарская поэзия» дигән китаплары басылып чыкты. 2010 елда «Гасырдан гасырга» (Из века в век) дигән баш астында («Кириллица әлифбасы халыклары шигърияте» дигән сериядән) Дәрдмәндтән бүгенге көнгәчә булган татар шагыйрьләренең әсәрләре татар һәм рус телләрендә аерым том булып дөнья күрде. Бу — энциклопедик басмалар. Болардан тыш та аерым язучыларның тәрҗемә китаплары басылып тора.

Төп игътибарны әсәрләребезне төрек теленә тәрҗемә итүгә юнәлтергә уйлыйбыз. Бу безгә иң элек башка төрки телле милләттәшләребезгә барып җитүне җиңеләйтсә, шулай ук төрек теле аша инглиз, алман телләренә күчерү мөмкинлеге ачыла. Берлегебездә төрек милләтеннән булган язучы барлыкка килү дә офыкларны киңәйтеп җибәрде. Төркиядән Алабуга педагогия институтына укырга килеп, укуын тәмамлап, бетергәч Казанда яшәп калган Фатих Кутлу исемле егетебез татар әдипләренең әсәрләрен бик теләп төрекчәгә тәрҗемә итә башлады. 2013 елда аның тәрҗемәсендә Төркиянең «Мәңгү» нәшриятында биш китап дөнья күрде.

Соңгы елларда ТӨРЕКСОЙ Халыкара төрки мәдәниятләр оешмасы актив эшли. Төркиядә әдәби очрашулар, шигырь ахшамнары, конгресслар еш үткәрелә. Бу төрки кардәшләребез белән аралашу, алмашу мөмкинлеген бирә. Моннан, һичшиксез, нәтиҗәле файдалану сорала. Үзебезгә дә төрки кардәшләребезне ешрак чакырырга кирәк. Быел Казан төрки дөнья мәдәнияте башкаласы дип игълан ителде. 26 апрельдә шул уңайдан Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия балет һәм опера театрында зур тантана булачак. Форсаттан файдаланып, без үзебезнең юбилейны шушы көнгә туры китерергә булдык. Аны 23-27 апрельдә Төрки әдәбиятлар фестивале итеп үткәрергә карар кылдык. Ниятебезне Мәдәният министрлыгы да, хөкүмәт җитәкчеләре дә хупладылар. Туган көн бәйрәмебез, Алла боерса, бөтен төрки дөнья әдәбиятлары һәм мәдәнияте тантанасы рәвешендә үтәчәк.

Башкортстанда миллионнан артык милләттәшебез яши. Заманында, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллиннар исән чакта, татар-башкорт мөнәсәбәтләре бик җылы булган. Казанлылар — Уфага, уфалылар Казанга үз өйләренә кайткан кебек йөрешкәннәр. Тамырлары Башкортстан белән бәйләнгән дисталәгән әдип — Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Саҗидә Сөләйманова, Нил һәм Илдар Юзеевлар, Хәсән Сарьян, Әхсән Баян, Рәдиф Гаташ, Ризван Хәмид, Роберт Миңнуллин, Госман Садә, Фәиз һәм Ләис Зөлкарнәйләр, Галимҗан Гыйльманов, Марат Кәбиров, Зәки Зәйнуллин, Резеда Вәлиевалар татар әдәбиятының әйдәп баручы каләм ияләре булдылар. Нажар Нәҗми, Әнгам Атнабаев, Рафаэль Сафин, Марат Кәримов кебек шагыйрьләрне әдәбият һәм шигырь сөючеләр һәрчак үз әдипләре итеп санап йөрттеләр. Башкортстан Язучылар берлеге җитәкчесе итеп Риф Тойгын сайлангач, аралар тагын җылына башлаган кебек булган иде. Башкортстанда әдәби очрашулар, яшь язучыларны Татарстан Язучылар берлегенә тәкъдим итү буенча утырышлар, Татарстанда татар-башкорт яшь язучыларының иҗатларын тикшерү буенча уртак семинар, Чаллыда татар-башкорт әдәбияты көннәре үткәрелде. 2014 елда Башкортстанда да шундый семинар үткәрергә дип ниятләп тора идек. Башкортстан Язучылар берлегенең яңа җитәкчелеге Р.Тойгын башлаган изге эшне дәвам иттерер дип өметләнәбез.

Безне шулай ук Мәскәү белән элемтәләрнең шактый тотрыксыз һәм киеренке булуы бик борчый. Моның сәбәбе — Мәскәүнең үзендә тотрыклылык булмау. Анда хәзер 5-6 берлек: Россия Язучылар берлеге, Россия Язучылары берлеге, Мәскәү Язучылар берлеге, Мәскәү өлкәсе язучылар берлеге, Халыкара Язучылар берлекләре берләшмәсе... Барысы

да үзара таркалашып ята, үзләрен элеккеге СССР Язучылар берлегенең варисы дип игълан итә. Кайсы хаклыдыр, белгән юк. СССР таркалгач, без үзебезне мөстәкыйль дип игълан итеп, бер берлеккә дә әгъза булып кермәгән идек. Фоат Галимуллин рәис булып торганда Халыкара Язучылар берлекләре берләшмәсе составына кабул ителгәнбез. Элекке рәисебез Илфак Ибраһимов бу берләшмәнең башкарма комитеты составында булды.

Халыкара Язучылар берлекләре берләшмәсе, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Лаеш муниципаль районы арасында ел саен Татарстан һәм Россия язучыларына Г.Державин исемендәге премия бирү турында килешү төзелгән. 2000 елдан бирле бу премиягә 21 язучы лаек булды.

Премияләр турында сүз чыккач, язучы хезмәтен бәяләүнең бу төре турында да берничә сүз белән тукталып үтү мәслихәттер. Дөньяда язучыларга бик күп төрле премияләр бирелеп тора. Иң зуры — Нобель премиясе. Ә бездә, Татарстанда, 1958 елдан бирле әдәбият, сәнгать өлкәсендәге олы казанышлар өчен Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелеп килә. Бу вакыт эчендә әлеге олы бүләккә 59 язучы лаек булган. 1968 елда республикада яшь язучыларга Муса Җәлил исемендәге яшьләр премиясе бирелә башлады. Бүген язучыларыбыздан 21 кеше — шушы премия лауреаты. Болардан тыш Мәдәният министрлыгы белән Язучылар берлегенең 1991 елдан — Гаяз Исхакый, 1996 елдан — Абдулла Алиш, Фатих Хөсни, Җамал Вәлиди (2001), Һади Такташ (2005) премияләре бирелеп килә. 2006 елда «Татнефть» берләшмәсенең «Рухият» фонды күренекле шагыйрә Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия булдырды. Бүген әлеге премия белән 24 язучыбыз бүләкләнде, тагын 24 язучыбызга кызыксындыру премиясе бирелде. Өч шагыйребез — Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллин һәм Рафаэль Газизов Г.Х.-Андерсен исемендәге Халыкара мактаулы дипломга лаек булды.

Язучылар берлегенең мактанычы, күптәнге бренды — ул аның Тукай клубы. Берара ул йокымсыраган хәлдә иде. Бүген Берлекне клуб эшчәнлегеннән башка күз алдына да китереп булмый, дисәк, хаталанмабыз...

Дөресен генә әйткәндә, Язучылар берлеге Бауман урамындагы бинада урнашкан чакта Казан әдәбият сөючеләренең яраткан мәдәният учагы булган Тукай клубы 1986 елдан, Берлек Мөштәри урамына күчкәч, рәтле-башлы эшләде дип әйтеп тә булмый торгандыр. Чөнки биредә кичәләр искә төшкәндә бер, очраклы рәвештә генә оештырыла килде. Берлек бинасы 2012 елда тәмамланган капиталь ремонттан соң, Тукай клубы әдәбият сөючеләр өчен, янадан тугандай, ишекләрен киң ачты — биредә атна саен җомга көннәрендә әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелә башлады. Татар әдәбиятында матур эз калдырган күренекле язучыларны искә алу кичәләре, юбилейлар, китап тәкъдир итүләр, кызыклы очрашулар, әдәби салоннар, фестивальләр, концертлар... Клуб Казан халкының яраткан мәдәният учагына әверелеп бара. Казанда әдәбият, мәдәният сөючеләрне шулай рәхәтләнеп ял иттергән, үзара аралашу, күңел ачу урынына әверелгән тагын бер шундый клуб бар микән?! Әлеге сүзләрне безгә тамашачылар үзләре әйтә, кичәләр үткәргән өчен ихлас рәхмәтләрен укыйлар. Бу — безнең халыкка әдәбиятыбызны пропагандалау буенча, туган телебезне, сәнгатебезне саклап калу һәм үстерү җәһәтеннән җәмәгатьчелеккә күрсәткән игелекле хезмәтебез.

Без, әлбәттә, туган халкыбызга хезмәт күрсәтү өчен, шундый шартлар тудырган, язарга, иҗат итәргә, сәләтләребезне тормышка ашырырга ярдәм иткән республика җитәкчелегенә зур рәхмәтле.

**Рафис КОРБАН,**
*Татарстан Язучылар берлеге рәисе,*
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

**Редакциядән:**

*Язучыларны олы юбилейлары белән котлыйбыз! Каләмнәре тутыкмасын, әдәбият сөючеләрне «Казан утлары» журналы аша әдипләребезнең яңадан-яңа талантлы әсәрләре белән шатландырып торырга язсын.*

# МОҢСУ БЕР ТАРИХ

## Хаҗиморат Казаковның тууына 100 ел

Кеше гомере язгы ташкын кебек — бик тиз агып китә. Татарстанның мәшһүр рәссамы Хаҗиморат абый белән танышканга да кырык биш ел үткән икән инде.

Тәтеш районы газетасында эшләгән чак. Газетабызның илле еллык юбилеена әзерләнәбез. Кулыбызда 1919 ел башында чыккан тәүге саны да юк хәтта. Беренче редакторы егерменче гасыр башында Тәтештәге татар мәктәбе директоры булып эшли башлаган, соңыннан республикабызның күренекле дәүләт эшлеклесе булып танылган Исхак Мостафа улы Казаков икәнен белә идек белүен.

Эзләнә торгач, Казанда беренче мөхәрриребезнең бердәнбер улы яшәвен ачыкладык. Рәссамнар берлегенә кереп, адресын алып чыктым да, өен эзләп табып, фатирының ишеген шакыдым.

Үземнең Тәтеш районы газетасы редакторы икәнемне әйткәч, хуҗа бик җанланып китеп:

— Узыгыз, утырыгыз, минем дә балачагым Тәтештә үтте. Киләсе 1969 елда сезнең газетаның юбилее бит, — дип, стена буендагы зур сандыкны ачып (ул әтисенең архивы белән дыңгычлап тутырылган иде), гарәп шрифты белән 1919 елның 1 февралендә басылган дүрт битле «Тәтеш хакыйкате» газетасын мина сузды.

Чәйләп алган арада кунакчыл хуҗа мина күп кенә кызыклы нәрсәләр сөйләп өлгерде. Үз нәселләренең Казаков фамилиясе тарихын да, әтисе белән бертуган Өммегөлсем апасының улы Мулланур Вахитовның яшьлек елларын, аның Петроградта психоневрология институтында белем алуын, революцион эшчәнлеген дә, кыскача гына булса да яктыртып алды. Аның туганнан туган мәшһүр абыйсы белән чиксез горурлануы әллә каян күренеп тора иде. Шул арада бер папка ачып, абыйсының төрле портретлары, барельефларының фотокүчермәләрен дә күрсәтте. М.Вахитовның халкыбыз алдындагы онытылмас революцион эшчәнлеге белән бергә төс-кыяфәте, йөзе дә тау бөркетедәй горур, чибәр булганлыгы игътибарны җәлеп итте. ...Пугачёв гаскәрләре 1774 елда Казан тирәсендә фельдмаршал Михельсон армиясе тарафыннан тар-мар ителгәч, татарча да сөйләшә белгән бер Дон казагы, Хаҗиморат абыйның ерак бабасы ягъни, губернаның төньягындагы татар авылларының берсендә тимерче булып урнаша алган. Ислам динен кабул итеп, татар кызына өйләнгән. Исемен алыштырса да, фамилиясе Казаков булып калган. Бер караганда, бу атаманың безнеңчә «Качак» сүзеннән килеп чыгуын аңлау өчен филолог булу да кирәкмидер. Тарихчылар язуынча, Рәсәй патшаларының золым-җәберенә чыдый алмыйча, көньяк Дон тирәләренә килеп яши башлаган татар качаклары янына соңыннан башка халык вәкилләре дә, шул исәптән урыслар да килеп тупланган. Шуннан соң аларның барысын бергә казаклар дип йөртә башлаганнар.

Ә теге татар авылына килеп урнашкан мөселман-татар Казаков нәселе, соңыннан Казанга күчеп, тернәкләнеп, зур-зур сәүдәгәрләре белән дан алган. Шуларның берсе, урыслыгыбыз бетсен дип, Яңа Бистәдә кирпеч мәчет салдырган. Соңыннан аны бөтен Казан халкы Казаков мәчете дип йөрткән. Хаҗиморат абый, бервакыт мине шунда алып барып, совет власте елларында җимерелгән әлеге мәчетнең нигезен дә күрсәтте.

Хаҗиморат Казаков ул чагында ук үзенең бөек Тукаебыз иҗатына багышланган дисталәгән әсәрләре белән республика халкына танылган иде. Безнең газетаның

юбилеенда катнашып, әтисе турындагы гаҗәеп кызыклы истәлекләрен сөйләде. Шуннан башланган дуслык 17 ел буена, аның вафатына (1984 ел) хәтле дәвам итте.

Х.Казаковның кешелек сыйфатларына, гаҗәеп эрудициясенә, Ходай мул итеп биргән күпкырлы талантына, тирән профессиональ белеменә, күпсанлы сәнгать әсәрләренең, бигрәк тә Тукаебызга багышланганнарының, гаҗәеп камил эшләнүләренә сокланмый мөмкин түгел. Уйлап кына карагыз: яшь-яшь егет чагында — 1934-1938 елларда — Ленинград сынлы сәнгать һәм архитектура институтында, 1939-1941 елларда Киев сынлы сәнгать институтында укый. Бөек Ватан сугышында катнашып, Берлинга хәтле юл үтеп, япон самурайларына каршы көрәшергә дә өлгереп, 1946 елда Казанга кайткач, ике ел буе сынлы сәнгать училищесында укытканнан соң, 1948-1949 елларда Ригада Латвия дәүләт сынлы сәнгать академиясендә белем ала. Өч югары белем! Шуна күрә ул чорда Татарстанда гына түгел, СССРда да анардан һөнәри әзерлеклерәк, эрудициялерәк рәссам булмагандыр.

Иҗатының чәчәк аткан чорында Хаҗиморат абый кечкенәдән үк яраткан шагыйре Тукай иҗатына мөрәҗәгать итә. Ул аның Печән базарына баруын да, Идел буйлап пароходта Әстерханга сәфәр кылуын да, Казан урамнарында йөрүен, култык астына папкасын кыстырып, Болак күперенннән чыгып килүен дә тасвирлый. Ә шүрәлеләрен: картларын да, бала-чагаларын да урманның нинди генә урынында, нинди генә кыяфәттә сурәтләми! Һаман уйлана торгач, әле бала чагында, мәктәпкә йөргәндә үк шагыйрьнең «Исемдә калганнар»ын укып, Габдуллаҗанны кызганып елавын хәтерли һәм илленче еллар ахырында (1958) «Үксез бала» яки «Бәләкәй Тукай» дип тә халыкка танылган мәшһүр әсәрен иҗат итә.

Сәгъди абзыйлар өендә сәкедә утыручы бәләкәй Тукай сурәтләнгән картинаны күргәч, хәйран каласың. «Балачактан ук калебебезгә кереп урнашкан сабый Тукайның гүзәл образы бит бу!» — дисең. Әйе, авылдагы һәр өйдәге кебек, яран гөл чәчәк атып утырган тәрәзәдән сибелгән кояш нурлары түр почмактагы бик пөхтә итеп җыеп куелган урын-җирне, сәке уртасына утырган баланың кечкенә гәүдәсен, зурларча җитди йөзен, безгә төбәлгән сагыш тулы моңлы, акыл ияләренә генә хас карашын, зур кара күзләрен, кулларына инде аның ничәнче «әнисе» тоттырган ипи телеме белән агач кашыгын, тәлинкәсендәге буы күтәрелеп торган кайнар бәрәңгесен һәм кәтүкләрдән ясалган уенчык атын яктыртып тора. Менә ул милли рәссамның халык күңеленә хуш килгән милли сәнгать әсәре нинди була! Безгә таныш интерьерда, иртәнге чык тамчысындагы кебек, бер фокуска тупланган кечкенә генә мәйданда, нихәтле тирән эчтәлек, матурлык, хозурлык! Ходай сәләтне, талантны җәлләмичә биргән рәссамның бөтен әсәрләре арасында әлеге шедевр, йөзек кашындагы бриллиант кебек ин уңышлысы, дияр идем. Казандагы һәм Кырлайдагы Тукай музейларына барып кергәч, беренче чиратта, нәкъ менә шушы гүзәл әсәрнең, бөтен игътибарыбызны җәлеп итеп, магнит сыман үзенә тартуы бер дә очраклы түгелдер.

Хаҗиморат абый Матбугат йортына еш кереп, күп кенә язучылар, журналистлар белән күрешеп, сөйләшеп йөри, төрле газета-журналларда үзенең мәкаләләрен, сәнгать әсәрләрен бастыра. Шулай бервакыт ул фойеда Гариф Ахунов белән Сибгат Хәкимне очрата. Аларның Тукай якташлары икәнлеген яхшы белгәнгә күрә: «Мин сезгә бер сюрприз әзерләдем, фатирыма кереп карамассыз микән?» — дип сүз башлый.

Биш минуттан алар инде урамның каршы ягындагы рәссам фатирына килеп керәләр. Хуҗа кеше «Бәләкәй Тукай»ны матур кысага тарттырып, тәрәзәдән яктылык мул төшә торган урынга элеп, өстен ак ситсы белән каплап куйган була.

— Күзегезне йомыгыз, мин әйткәч ачарсыз, — дип, җәһәт кенә урындыкка менеп, япманы алып төшә дә:

— Ачыгыз! — дип боера.

Кунаклар, күзләрен ачып, игътибарлы карашларын алтын кысадагы картинага юнәлтәләр һәм ун минут чамасы бер сүз дәшмичә селкенми дә басып торалар.

— Егет тә икәнсең, Хаҗиморат дус. Безне мондый «сюрприз»ың белән сөендергәнең өчен сиңа нинди генә рәхмәтләр укысак та, аз булыр. Мин кечкенә Тукайны нәкъ менә шундый итеп күз алдыма китерә идем. Беләсеңме килсә, син шушы бер әсәрең белән генә дә халкыбызның сынлы сәнгать тарихына алтын хәрефләр

белән язып куелырга лаеклы рәссам, — дип, Гариф Ахунов аның кулын кыса. Сибгат Хәким дә ана кушыла.

Хажиморат абый гамәлләрендә-гадәтләрендә әлегә хәтле күзем күрмәгән, колагым ишетмәгән кызыклы-гыйбрәтле нәрсәләргә тап булып хәйран калган чакларым күп. Бервакыт безнен Тәтеш районынын Вахитов исемендәге колхоз рәисе Мәсхүт Әхтәмов заказы белән идарә диварына урнаштыру өчен ясалган Мулланур Вахитовнын зур гына портретын алып килгәч, гадәтенчә, кунарга безгә керде.

Чәйләп-мәйләп алганнан сон, папкасыннан стандарт ике кәгазь битен чыгарып, алдыма салды. Мәктәп укучылары улым Илдар һәм кызым Гөлназнын туш һәм төсле кара белән ясалган портретлары иде аларда.

— Һич анламыйм, Хажиморат абый. Синен балаларыма карап рәсем ясап утырганынны хәтерләмим. Ничек булып чыга сон инде бу?

— Аларнын портретларын көнелемдәге кыяфәтләрен күз алдыма китереп, хәтеремнән ясадым.



*«Бәләкәй Тукай».*
*Рәссамы — Х.Казаков*

Гажәп хәл. Йөзләренен һәр детале: күз формалары, хәтта аларнын төсләре, борын, колак, иякләре, чәчләре — барысы да нәкъ үзләренчә. Үзем дә кечкенәдән рәсем ясарга яратам. Әмма кешенен рәсем-портретын хәтердән, күз алдына китереп кенә шулкадәр дә төгәл ясап буладыр дип уйлаганым юк иде әле. Чынлап та, кайбер рәссамнарда мондый сәләт бар икән.

Хажиморат абый аны гомер буе камилләштереп торган. Гомумән, анардагы феноменаль хәтергә гажәпләнми мөмкин түгел иде. Бервакыт сөйләшеп, әнгәмә корып утырганда, бер бит кәгазь алып, егермеләп тарихи шәхеснен исем-фамилияләрен язып чыкты да аларнын туган һәм вафат булган елларын, көннәрен язып куярга кушты. Мондый нәрсә белән махсус шөгыльләнмәгәнгә, үзем, карчыгым һәм балалар да берничә датадан башканы хәтерли алмадык. Житмәсә, хәтерләгәннәре дә төгәл түгел иде. Безнен ялгышларны төзәткәч, ул калган шәхесләр турындагы мәгълүматларны теркәп куйды. Сонынннан мин аларны энциклопедиядән карап чыктым. Рәссамнын бер генә ялгыш та жибәрмәгәнен күрдем.

Шулай жәйнен матур бер көнендә Тәтеш пристаненда «Метеор»га утырып Казанга киттек. Алдыбыздагы рәттә утырган ике ир кеше сөйләшеп бара: «Ул Екатерина IIне әйтер идем инде... Бөтен жир асты алтын белән тулган Аляскаdebug Америкага юк бәягә сатып жибәргән бит», — дип көрсенеп куйды берсе. Шунда колагы бик шәп ишетә торган Хажиморат абый: «Ялгышасын, иптәш. Екатерина II, үзебезчә-татарча әйткәндә, безнен милләткә дә кайбер яхшылыклар эшләгән Әби патша, ул ярымутрауны беркемгә дә сатмаган. Алясканы Америкага анын оныгы Александр II фәлән елда, фәлән сумга сатып жибәргән», — дип әйтеп куйды. Ә бит әле бүген дә кайберәүләр бу факт турында теге «Метеор»дагы ир кебек уйлый. Талантлы рәссамыбыз күрәләтә ялгыш жибәрүчеләргә, нахакка башкаларны рәнжетүчеләргә бервакытта да битараф калмады.

Тынгы белмәс яшь рәссам күпне күрергә, күп белергә, «язарына азык эзләп», күп жирләрдә булырга өлгергән. Андагы бай тормышны күпсанлы әсәрләрендә чагылдырган. Ул 1950-1952 елларда Кыргызстаннын Фрунзе шәһәрендә, 1952-1954 елларда Баулы, Бөгелмә, Әлмәт кебек нефть районнарында яшәп, бай тормыш тәжрибәсе туплый. Әгәренки гомер буена жыелган ижат жимешләреннән күргәзмә оештыра башласан, алар зур залга да сыеп бетмәс иде. Быел, бер гасырлык юбилей

елында, сайланма әсәрләреннән генә булса да саллы күргәзмә оештырасы иде. Моны, әлбәттә, Мәдәният министрлыгы Татарстан Рәссамнар берлеге белән бергәләп башкара алыр иде. Шундый олуг сәнгать әһелен зурлап халкыбыз хозурына чыгарырга бик вакыт.

Бервакыт ул 3кә 1,5 метр күләмендәге полотнода коммунист түрәләрнең, чама чиген югалтып, үз юлбашчыларын зур кодрәт иясенә тиңләп, шәхес культы әвәләүләрен гротеск формада чагылдырган аллегорик әсәр иҗат итте. Анда берничә чакрым биеклектәге гранит токымнардан торган текә таудан 100 метр биеклектәге дәһшәтле сфинксны хәтерләткән Ленин бюстын эшләү күренеше сурәтләнгән иде. Меңләгән кеше кырмыска кучедәй мәш килә, тау итәгенә спираль формасында салынган әйләнмә юллардан йөзләгән КамАЗлар вак таш, җирне башка урыннарга ташый. Дистәләгән гигант экскаваторлар каты тау токымнарын кимерә, зур-зур бульдозерлар артык җирне читкә этә. Ә әчтәрәк, уртада ак гранитны төрле кораллар белән чокып, кисеп, шомартып коелган, биниһая гигант сфинкс-балбалга охшап, Ленин бюсты калка. Борынгы Мисырда чираттагы фиргавенгә болытларга ашкан пирамида төзиләр, диярсең. Хаҗиморат абый бу полотноны фатирының бер диварына беркетеп күрсәткән иде. Әгәр дә мәгәр рәссам бу әсәрен Мәскәү Кремлендәге берәр зур түрәгә күрсәтсә, бәлки, аның әлеге аллегорик идеясен тормышка ашырырга да күп сорап тормаслар иде. Хаҗиморат абыйга, Ленин идеяләренә шул хәтле бирелгән сәнгать әһеле дип, аның премиясен дә бирерләр иде. Әмма ул торба формасында төрелгән киндер, караңгы чолан киштәсеннән читкә китмичә, еллар буе ята бирде. Гомумән, Хаҗиморат абыйның йөзләгән әсәрләре бүген нинди запасникларда тузан җыеп ята икән? Алар бит, бер уйлаганда, халык мөлкәте. Шул рәвешчә, үзе юкның күзе юк, дип ваемсыз йөри бирикме инде? Халык байлыгын подвалда яткырырга түгел, үзенә кайтарырга, үзенә күрсәтергә вакыт, җәмәгать!

Ходай Хаҗиморат абыйга төрле талант-сәләтләрне бер дә кызганмый, колачлап биргән икән. Анардагы дистәләгән патент-сертификат алырлык дәрәҗәдә инженер, галим белемен күреп соклануларым аз булмады. Бервакыт ул зал уртасына раскладушка китереп куйды да аңа ятып, түшәмгә карарга кушты. Шунда ниндидер сихри матур көй яңгырап китүгә, үзе ясаган калейдоскоптан түшәмнең зур мәйданында әлегә чаклы гомеремдә күрмәгән гөлләр-чәчкәләр алмашынып тора башлады. Могҗизага балаларның ничек куанганын күрсәгез иде! «Мин бу калейдоскопны кызым йөри торган балалар бакчасына илтәм әле», — дип куйды ул соңыннан. Бер бүлмәле коммуналь фатирының дүрт метр биеклектәге өч диварын үзе такта-рейкалардан җайлап ясаган стеллаж-китап киштәләре биләп торганы хәтердә. Аларда әтисеннән калган, гомере буе үзе җыйган әдәби, тарихи, гыйльми, сәнгатьнең күп өлкәләренә караган меңләгән том интеллектуаль-мәдәни байлык тупланган иде. Шуннан кыргыз халкының «Манас», үзебезнең «Идегәй» дастаннарын, дөньяның бөек рәссамнары Леонардо да Винчи, Рафаэль Санти, Рембрандт ван Рейн, Эжен Делакруа, тарихчылардан Геродот, Плутарх, Николай Карамзин, Михаил Худяков, Шиһабетдин Мәрҗани, Газиз Гобәйдуллин, Һади Атласи, борынгы философлардан Аристотель, Платон, Сократ әсәрләрен һәм алар турындагы китаплар алып укуым исемдә калган. Минем күз алдымда университет профессоры Рафикъ Измайлович Нәфигов, мәшһүр рәссамнардан Бакый Урманче, Тавил Хаҗиәхмәтов, Хаҗиморат абый белән байтак сөйләшеп, фикер алышып утырганнан соң, аның китапханәсеннән укып торырга төрле китаплар, альбомнар алып китте. Әнә шулай дөнья мәдәни мирасын даими өйрәнеп, туплаган энциклопедик гыйлемен һәм китапларын үзендә бикләп яткырмый, дус-ишләре белән дә юмарт уртаклаша-бүлешә иде ул.

Тукай әйткәнчә, бу дөньяда бер кеше дә буш булмый төрле көнчедән, куштаннан һәм дошманнан. Бервакыт Хаҗиморат абый да күршесеннән зарланып алды:

— Караватым безнең уртак стена янында. Кычкырып сөйләшкән бер-беребезгә яхшы ишетелә. Салырга яратучы күрше адәм, тавышын бар көченә куеп, төнге сәгать берләргә кадәр телевизор карый. Берничә тапкыр яхшылап аңлатып, кисәтеп тә карадым. Файдасыз. Туктале, мәйтәм, мин бит физикадан хәбәрдар, электрониканы, электротехниканы да азмы-күпме өйрәнгән кеше. Бу тупас сәрхушкә берәр төрле адекват чара эзләп карыйм әле. Һәм таптым да. Теге телевизорын

кабызуга, кулымдагы реле-җайланма кнопкасына басам да күрше бүлмәдә тулы тынлык урнаша. Теге ни уйларга да белми, аптырап кала. Аннары өенә чакырылган телемастер мона эшнең нәрсәдә икәнен аңлатып биргән. Шуннан соң гына күрше телевизорын нормаль тавышка куеп карый башлады...

Күп нәрсәләр белән кызыксынучы, киң мәнфәгатьләр белән яшәүче, гаҗәеп тирән белемле, кешелек ирешкән мәдәни-рухи байлыкларны тирәнтен өйрәнергә тырышучы олы иҗади шәхес иде ул.

Бу җәһәттән Хаҗиморат абыйның астрономия белән фанатларча мавыгуын әйтмәсәм, язмам тулы булмас. Казандагы мәшһүр астрономнар арасында да дуслары бар иде. Алар белән аралашып, даими фикер алышып тора. Ул чагында СССРның кайсы гына урынында Ай, Кояш тотылудан берничә көн элек бу вакыйга иң әйбәт күзәтеләчәк Самаркандка, Бакуга, Новосибирскига һ.б. шәһәрләргә поезд яки самолёт белән барып житә иде. Аннан кайткач, күзәтүләре турында мавыгып, дәртләнеп бөтен бер лекция сөйли. Үзенең кызына Афелия дип исем кушуы да очраклы түгел. Кояш тирәсендә әйләнеп торучы планеталар орбиталарының иң ерактагы ноктасы дигән сүз икән ул. Кайчак кайбер таныш-белешләре сәерсенеп:

— Сез кызыгызга ялгыш кына Афелия дип дәшәсезме соң? Әдәбиятта, сәнгатьтә Офелия дигән исем генә мәгълүм ләбаса, — дигәч, ул аларга эшнең нәрсәдә икәнлеген тәфсилләп, бик кызык итеп аңлатып бирә иде.

Халкыбызның 50-60 нчы еллардагы шахмат һәм шашка буенча бөтен илгә танылган мәшһүр остасы Рәшит Нәҗметдинов белән дә дустанә аралашып, лекцияләрен тыңлап, сеансларында катнашып тора Хаҗиморат Исхак улы. Үзем спортның бу төре буенча мастерлыкка кандидат булсам да, аны оту бер дә җинел түгел иде.

Гомумән, без Архимед кебек борынгы заман яки Леонардо да Винчи кебек урта гасырның күпкырлы талант ияләре — галимнәре, инженерлары, даһи сәнгать әһелләре турында язарга, авыз суларыбызны корытып сөйләргә яратабыз. Ә бит андый асыл затлар безнең халыкта да булган һәм бүген дә бар. Әмма, Тукай әйткәнчә, үлеп аңлатмый торып, кадерләрен генә белмибез шул.

Инде вафатыннан соң утыз ел үтеп китсә дә, олуг дустымның якты образы һаман күз алдымда. Нык ихтыяры, максатына ирешү өчен бөтен көчен, сәләтен жигә белүе, һәрнәрсәгә үз карашы, фикере булу белән сокландыра иде ул. Шәхес иреге, какшамас иманы аның өчен гел беренче урында булды. Шуңа күрә күпме генә кыстасалар да, коммунистлар партиясенә керми. Аның бөек кешеләргә хас янә бер күркәм гадәте бар иде: үзе инанган хакыйкатьне теләсә кем алдында Джордано Бруно кебек, гомерен куркыныч астына куеп булса да яклап чыга. Өлкә комитеты секретаремы, министрмы, эшендәге берәр түрәме, таныш профессормы, дусты яки хезмәттәшеме — барыбер, күзләренә туры карап, аларның эш-гамәле, ялгышлары турында үз фикерен ярып салыр иде. Туры әйткән — туганына ярамаган, дигәндәй, ул әлеге гадәте белән үзенә дуслар арттырмый иде, билгеле.

Бер гыйбрәтле очракны искә алып үтәсем килә. Бервакыт ул, Рәссамнар берлеге рәисе Харис Якупов кабинетына кергәч, аның күзенә туры карап: «Харис Абдрахманович, сезнең сюжетлы жанр картиналарыгызда күп хатын-кыз образларының йөзе хатыныгыз йөзенә охшаган, һәр кешенең үзенә генә хас буй-сыны, йөз-кыяфәте була бит инде. Сез моны махсус эшлисезме соң? Һич аңламыйм!» — дигән соравына каршы кабинет хуҗасы бик усал карап кую белән генә чикләнә.

Бу чорда бөек Тукаебызга багышланган дистәләгән әсәрләр циклы һәм аеруча «Ятим бала» яки «Бәләкәй Тукай» дип атала торган гүзәл иҗади казанышы белән киң җәмәгатьчелеккә, гомумән, халкыбызга танылган рәссам төрле авылларга, колхозларга йөреп, идарәләр, мәдәният йортларын бизәп — «шабашка эшләп» көн күрү хәлендә кала.

Бөтен иҗаты турында тулаем әйтеп тормастан, газиз шагыйребезнең ятим бала чагын сурәтләгән энҗе-мәрҗәннәргә тиң әсәре өчен генә дә ул Тукай бүләгенә лаек иде дә бит?..

Немец фашистларына, Япон самурайларына каршы көрәштә чыныккан, күкрәге

орден-медальләр белән тулган талантлы иҗат әһеле барыбер горур кеше, оптимист булып калды, соңгы сулышына кадәр газиз халкына хезмәт итте.

Ана бүләкләр дә, ялтыравык титуллар да, «атка атландырылган» исемнәр дә бирүче булмады. Әйе, горур, беркем алдында баш имәс талант ияләренә яшәү җинел түгел шул.

Кайчак Хаҗиморат абыйдан әлегә хәтле беркайда укымаган, беркемнән ишетмәгән мәгълүматлар белеп гаҗәпкә кала идем. Мәсәлән, Мирсәет Солтангалиевнен егет чагында, 1913-1917 елларда кызлар гимназиясендә укытканда, Бакуда революцион яшьләр белән аралашып торган елларда ук, төрле оешмалар, байларны талап һәм банклар басып йөргән банда башлыгы Иосиф Джугашвили белән танышлыгы турында башкача каян белер идем. Һәркемнең үз юлы, мәсләге дип, Мирсәет хәтта анын белән дустанә мөнәсәбәттә булган чорда бер төркем азәриләрнең Иосифны эләктереп, нефть сосып ала торган бик тирән кое янына сөйрәп алып килүләрен күреп, алар катына ашыга, һәм банда башлыгын, аяк-кулларыннан эләктереп, коега ташларга җыенганда көчле тавышы белән азәрбайҗан телендә:

— Туктагыз әле, егетләр, ул бит сезгә дә, безгә дә зарар итүче түгел, ул бит буржуй-байларны гына талый, банклар баса. Кирәк икән, ул сезгә акча белән дә булыша ала! — дигәч, тегеләр туктап кала. Шулай үзен котылгысыз үлемнән саклап калган Мирсәеткә Джугашвили «друг Мирсай», ә татар егете тегенә «Юси» дип эндәшә торган булган. Баш әйләнгеч метаморфозалар кичереп, төрле куркыныч тау сукмакларын исән-аман үтеп, 1917 елгы революциядән соң язмыш дигән бөек, серле көч бу ике «дусны» Мәскәү Кремлендә очраштыра һәм көрәштәшләр-хезмәттәшләр шәкелендә эшкә җигә. Мулланур Вахитов фаҗигасеннән сон, 1918 елда, Хаҗиморатнын әтисен Үзәк мөселман комиссариатынын баш коллегиясе әгъзасы итеп куялар. Исхак Казаковка милләтләр эше буенча халык комиссары Сталин һәм Хөкүмәт җитәкчесе Ленин белән дә даими очрашып торырга туры килә. Бергә, бер Казанда кайнап мәш килүче Галимҗан Ибраһимов, Мирсәет Солтангалиев белән дә тыгыз аралашалар. Солтангалиев аңа революциягә хәтле Бакудагы вакыйгалар, сер итеп кенә, банда башлыгы Джугашвилине котылгысыз үлемнән алып калуы турында да сөйли. Ленинның вафатына хәтле барысы да, үзара талашмыйча, зур конфликтларга керми генә, дустанә эшлиләр. Ә 1924 елдан соң партиядә һәм хөкүмәттә дилбегәне үз кулларына алган Сталинга зур мөмкинлекләр ачыла. Хәзер инде анын өчен дус та, иптәш тә юк, бары тик һәр өлкәдә үзенә берсүзсез буйсынган чиновниклар, зур дәүләт машинасынын «винтик»лары гына, Англия империализмына хас булганча, олы интерес-мәнфәгатьләр генә бар. Милләтләрнен үзбилгеләнүе, татар халкына да союздаш республика хокукы зарурлыгы турында анын белән аяк терәп бәхәсләшүче, үзен бәйсез, горур тотучы «Мирсай» корыч куллы диктаторга ошамый. Ул аны, «милләтче, троцкийчы» һ.б. шунын ише тузга язмаган гаепләр тагып, кулга алдыра, атарга хөкем иттерә. Чынлап та, «Фәлән-фәлән гаепләре өчен Мирсәет Солтангалиев сонынан атып үтерелде», дип игълан ителә. Әмма шунысы кызык: кайчандыр кеше талап, банклар басып йөргән банда башлыгы күнелендә үзен үлемнән коткарган «дустына» карата «мәрхәмәт» хисе уяна, күрәсен. Ул, яшерен рәвештә, бөтен куркынычсызлык хезмәтләре сер итеп саклау шарты белән, аны атып үтертмичә, зур сак астында төрмәдә тотарга боера. Фашистлар Германиясе белән сугыш башланудан берничә ай элек, 1941 елда, Сталин үзенен «дусты Мирсай»ны исенә төшерә. Махсус машинада аны Сталин янына Кремльгә китерәләр. Һәрвакыттагыча ыспай киенгән, хром итекләре көзге кебек ялтырап торган кабинет хуҗасы чәче житен кебек агарган, әмма әле гәүдәсен һаман төз, горур тотучы «дустына» байтак карап торганнан сон, утырырга куша. Берничә сәгатькә сузылган әңгәмә барышында Солтангалиев, совет диктаторына әйләнгән адәмнән берниндн мәрхәмәт көтмичә, анын үзе оештырган халыкларнын коммуналь квартирасы — совет империясе булуы, бирелә яшәүчеләрнен күнелсез киләчәге турындагы уйларын ачык итеп әйтеп бирә. Шунда «халыклар атасы», урыныннан торып:

— Прощай, Мирсай, это твой выбор! — ди.

Исхак абзый күп нәрсәләр турында улына сөйләп калдыра. Әмма ул үзе дә

халык дошманы дип кулга алынып, 1939 елда атып үтерелгәнгә, Солтангалиевнең 1941 елга хәтле яшәвен белә алмаган. Бу турыда Хажиморатка әтисенең бергә зур урыннарда эшләгән дуслары, көрәштәшләре һәм бик күп нәрсәләрдән хәбәрдар профессор Рафикъ Нәфигов әйтә.

«Казан утлары»нда *(2006 ел, №3)* журналның баш мөхәррире Р.Фәйзуллинның ул чордагы Президентыбыз М.Шәймиев белән бай эчтәлекле әңгәмәсе басылган иде. Минтимер әфәнде анда болай ди: «Иҗат кешеләре, чыннан да, Аллаһы кешеләре. Аллаһы Тәгалә безне яхшы якка үзгәртер өчен, игелеклерәк, камилрәк итәр өчен, аларны җибәрә... Ә вөҗданлыларга, бигрәк тә нечкә күңеллеләргә, беркайчан да җиңел булмаган. Төптәнрәк уйлап карасаң, халыкның вөҗданы инде алар. Халыкка киң танылу бәяләнүгә кирәкме? Әлбәттә, төп бәяләүче — халык үзе». Ошбу сүзләр чын талант иясе Хажиморат абыйга да турыдан-туры кагыла. Шуңа күрә ул — төрле түрәләрнең аны әйләнеп үтүләренә, нинди генә кыен шартларда яшәвенә карамастан, халкы тарафыннан танылуы, югары бәяләнүе белән бәхетле сәнгать әһеле. Үзебезнең Фәннәр академиясе әзерләп чыгарган энциклопедик сүзлектә (1999 ел) Хажиморат абый республикабызның танылган дәүләт эшлеклесе Исхак Казаков белән янәшә куелган. Алма агачыннан ерак төшми ул.

**Фарук НӘФИЕВ**

---

## Кайтаваз

*«Казан утлары»ның март санында Ренат Харисның «Каш ясыйм дип... (Рашат Низамига ике хат)» дигән язмаларын тетрәнеп укыдым. Чын әдәбиятны гайбәттән, чын иҗатчыны көнлекчедән аерган һәр татар кешесе өчен кадерле нәрсәләр күтәрелгән биредә. Әйе, Ренат кордашым бу искиткеч нечкә, күңелләребезне ничәмә дистә еллар буена өшетеп килгән Сәйдәш-Җиһанов, Яруллин-Җиһанов мөнәсәбәтләрен объектив яктырту мәсьәләләрен күтәреп, дөрес һәм, әйтергә кирәк, гражданлык батырлыгы эшләгән. Моның өчен аңа зур рәхмәт. Бөек шәхесләребезнең тормыш юлын сурәтләүдә гайбәтне әйбәттән аерып, катлаулы чынбарлык коллизияләрен «кыргый Печән базары мөнәсәбәтләреннән» тазартып һәм, идеал чыганакларыбызны, түбән мәнфәгатьләрдән чыгып, мәгънәсез пычратудан туктатыр вакыт җитте. Мин үзем дә моннан берничә ел элек Рашат Низаминың шушы язмаларын укып, Җиһановтан төшкән яктылыкны тишек палас белән капларга тырышучыларга каршы чыгарга талпынып караган идем. Әмма ул талпыныш куюдан ары узмады. Аннан минем бу катлаулы мәсьәләне бар тирәнлеге белән ачып салуда бер теләк кенә җитмәгәнлеге, Ренат Харистагы фактик материаллар кул астымда булмавы да тоткарлагандыр, күрәсең. Сәнгатьтә өч баскыч бар: талантлылык, даһилык һәм титанлык. Чынбарлык һәр сәнгать иясен һәр баскычта үзенчә газаплый. Бу «гүзәл газап» конкрет сәнгать кешесендәге шәхеслек, холык-характер микъдарыннан чыгып, үз өлешен өсти. Язучы боларны исеннән чыгармаска тиеш. Нәҗип абзый Җиһанов тоткан җиреннән өзә торган каты куллы, бөек йөрәкле, арыслан ябалдашлы Ир Заты иде. Ул Титан иде. Әмма аны безнең кайбер гайбәтчеләребез, имеш, башка талант-титаннарыбызны «агулар өчен» агу кайната торган чәйнүк-титанга, Сальерига әвереләдерделәр. Мондый түбәнлек, мондый хөсетлек безгә, дәүләтсез килеш бөек цивилизация тудырган халыкка, авыр җан сыкранулары алып килгән иде. Ренат Харисның бу «Ике хаты» иманыбызның шушы гайбәтчелек кризисыннан чыга башлау тантанасы булса ярар иде, амин!..*

*Кайнар вә чын рәхмәтләр илә*
**Айдар ХӘЛИМ**



Казанда Габдулла Тукай музее ачылу күренеше. 1986 ел.




«Казан утлары» журналы (элеккеге «Совет әдәбияты») 70 елдан артык Татарстан Язучылар союзы органы булып саналды. Ул хәзер дә язучыларыбызның төп журналы булуын дәвам итә.



Муса Җәлилнең туууына 80 ел тулуга багышланган тантанадан бер күренеш. Мәскәү. Колонналы зал. 1986 ел.



*Киңәйтелгән идарә утырышыннан соң төшерелгән рәсем. Сулдан уңга (утырганнар): Рөстәм Мингалим, Аяз Гыйләҗев, Рабит Батулла, Владимир Корчагин, Әхсән Баян, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Мәдинә Маликова, Зиннур Мансуров; басканнар: Мансур Шиһапов, Газинур Морат, Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин, Азат Әхмәдуллин, Рәфкат Кәрами, Рахмай Хисмәтуллин, Ләис Зөлкарнәй, Гариф Ахунов, Җәүдәт Дәрзаман, Ринат Мөхәммәдиев, Ренат Харис, Илдар Юзеев. 1994 ел.*

*Күп вакыйгаларның, очрашу-кичәләрнең шаһите булган Язучылар клубы. 1941 елда эвакуацияләнгән йөзләрчә язучыларның вакытлыча торак-штабы булып та хезмәт иткән. Бауман урамы, 19 йорт.*





*Татарстан язучыларының X съездында (май, 1984 ел) катнашкан язучылардан бер төркем. Сулдан уңга: Илдар Юзеев, Рафаэль Мостафин, Диас Вәлиев, Туфан Миңнуллин, Марс Шабаев, Аяз Гыйләҗев, Фәнил Мансуров, Нил Юзиев, Әбрар Кәримуллин.*

## ИКЕ ХАЛЫКНЫҢ БЫЛБЫЛЫ

«Бөтендөнья тарихына бер караш» китабында Һиндстанның күренекле җәмәгать эшлеклесе, булачак ил башлыгы Җәваһарлал Неру татарларга да зур бәя бирә. Алар элек бөтен дөнья күләмендә зур-зур мәмләкәтләр тотучылар иде, соңрак та күп кенә ил-мәмләкәтләрнең эшлекле вазифа башкаручылары буларак танылдылар, дип яза ул өч томлы тарихи хезмәтендә. Әлбәттә инде, бу очракта галим Неру хәзерге тар мәгънәдәге татар төшенчәсен күз уңында тотып язмый, борынгы төрки-татарлар оештырган зур дәүләтләр дәверен искә төшерә. Шулай да күңелнең татлы бер кылына чиртеп ала. Ж.Неруның татарларга карата әйткән мактау сүзе өлешчә генә булса да безгә дә кагыла лабаса.

Бүгенге көндә дә татарлар, кайда гына яшәсәләр дә, гыйлемгә, дәрәҗәле вазифалар башкаруга омтылучы затлар. Хезмәт юлында дан казанган милләттәшләребез байтак ул. Мондый шөһрәткә алар үзләре сайлаган эшне башкаруда талантлырак, остарак булулары нәтиҗәсендә ирешкәннәр. Әйтик, чордашларыбыздан Кытай кебек зур бер илдә югары дәрәҗәләргә ирешкән Буа ягы татары Борһан Шәһидине, дөнья күләмендә мактаулы исемнәр яулаган галимнәрдән Роальд Сәгъдиевне, Һарун Таҗиевны, Рәшит Сүнәевне, балет осталары Рудольф Нуриев белән Ирек Мөхәммәдевне алыйк. Яки Кытай илендә башлангыч белем үзләштергән тарихчы, әдәбиятчы академигыбыз Миркасыйм Госманов, Алматыга чиктәш бер бистәдән чыккан сәнгать академигы Фуат Мансуров, Үзбәкстанда туган бертуган Акчуриннар һәм архитектор Мидхәт Булатов, Ерак Көнчыгышта туып-үскән җырчы Гали Ильясов, ата-бабасының яшәгән төбәге казакъ иле белән чиктәш Орск каласыннан булган, заманында А.Карповтан кала дөньяның иң көчле шахматчысы Гата Камский һ.б. бик күп замандашларыбызны хәтергә төшерик. Алар белән горурланмаслыкмы соң?

* * *

Казакъ иле, казакъ халкы белән безнең бабаларыбыз аеруча якын мөнәсәбәттә булганнар. Чөнки кардәш төрки телләр арасында аларның сөйләм теле безгә иң якыны. Алардан да якынрагы, мөгаен, башкорт белән каракалпак телләре генәдер. Зур биләмәләргә таралмаган кумык, карачай телләрен исәпкә алмаган очракта, әлбәттә. Казакъ халкы безне күбесенчә нугай дип атап йөртә. Чөнки кайчандыр алар иленә чиктәш татар мәмләкәте нугай атамасы белән йөргән.

Казакъ халкының башлыча күчмә тормыш алып баруы, авыл, калалар төзеп яшәмәве сәбәпле, аларда даими эшләп килүче мәктәп-мәдрәсәләр сирәк булган. Шуна күрә белемгә омтылучы казакъ яшьләренең зур бер өлеше Оренбург, Троицк, Омск кебек дала чикләрендә урнашкан татар мәдрәсәләрендә белем алганнар. Шул рәвешле ике халыкның булачак зыялы катламы яшүсмер елларыннан ук үзара аралашып яшәгән. Мисалга берничә исемне атап китү дә килешер. Казакъ халкының мәшһүр шәхесләреннән Абай (мулла кушкан исеме Ибраһим) үз төбәгенең солтаны булган Конанбай улы, Семипалатинск шәһәрендәге Әхмәт Риза мәдрәсәсендә укыган. Шунда аның әдәби сәләте ачыла — беренче әсәрләре языла. Мәдрәсәдә укыганда, ул шәрекъ әдәби вә иҗтимагый фикер ияләре хезмәтләре белән таныша башлый. Соңрак аның Шиһабетдин Мәрҗани китапларына әһәмият биргәнлеген дә билгеләп үтәләр. Татар милләте вәкилләре белән гомере буена аралашып яшәгән. Гаилә бәйләнешләре дә шуңа мисал була ала: уртанчы улы Әбиш (Абдерахман)

безнең милләт кызы Мәгърифәгә өйләнә, кече кызы Кинҗә Конанбайлар ыруы мулласы оныгы Сәлимгазыйга кияүгә бирелә. Абай вафатыннан соң нәшер ителгән беренче китапларының да татар басмаханәләрендә чыгуын әйтеп китү кирәктер: «Ибраһим Конанбаев өлеңнәре» китабы 1909 елда С.-Петербургта Кырым татары Ильяс Бораганский тарафыннан, «Абай тирмәсе» җыентыгы 1916 елда Оренбургта бертуган Рәмиевләр тарафыннан нәшер ителгәннәр.

Икенче бер солтан улы Чокан Вәлиханов язмышы да гыйбрәтле. Башлангыч белемне ул Омскидагы татар мәдрәсәсендә үзләштерә. Шуннан соң аны шул ук шәһәрдәге хәрби мәктәпкә бирәләр. Анда ул Оренбург төбәге морзасы нәселеннән булган Шаһимәрдән Ибраһимов белән бергә укый. Ә Шаһимәрдән 1870 елда Ташкентта казакъ һәм үзбәк телләрендә атналык «Төркестан вилаяте гәжите»н чыгара башлагач, беренчеләрдән булып Чокан Вәлиханов язмаларына урын бирә. Кабат искә төшереп үтәсем килә: бу газета патша Россиясендә беренче төрки телле басма була. Димәк, тәүге басма казакъ теле кулланышы да шул дәвердән бирле килә дип раслый алабыз. Төрки телдәге икенче-өченче газеталар берничә елдан соң Баку һәм Тифлис калаларында «Кавказ татарлары» телендә, ягъни азәрбайҗан телендә чыга башлый. Ә казакъ телендәге икенче газета — Акмола шәһәрендә нәшер ителгән «Дала вилаяте гәжите» 1888 елдан басыла башлаган. Бер хезмәттә күрсәтелгәнчә, 1890 елларда аның тиражы 1300 данә булган. Бу газета эшчәнлегендә дә якташларыбыз актив катнашкан, анда татарчадан тәрҗемә итеп басылган язмалар да даими рәвештә күренгәләп торган. Бу газетада Абай кебек шул чор акыннарының шигырьләреннән тыш, тәүге басма хикәяләр дә дөнья күрә. Ул хикәяләрнең авторы Ибрай Алтынсарин Оренбург шәһәрендәге рус-казакъ мәктәбе мөгаллиме була...

Казакъ кардәшләребез илендә туган яисә шул илдә аякка басып, киң мәйданга чыккан милләттәшләребез исемлеге дә зур. Тукаебызның башлангыч чор иҗаты турында сүз чыкканда да, кайбер галимнәребез: «Җаек Гольфстримына эләкмәсә, мөгаен, ул да зур дәрәҗәгә ирешә алмас иде», — дип әйткәлиләр әлек. Күренекле дирижёр, музыка сәнгате академигы, Россия Федерациясенең халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Фуат Мансуров — Алматы шәһәре янәшәсендәге бистәдә туган, шул шәһәрнең музыка мәктәпләрендә башлангыч белем алган шәхес. Булачак мәшһүр композиторыбыз Заһид Хәбибуллинның да скрипкачы буларак тәүге иҗат юлы шул илдәге Актүбә каласыннан башланган. Әгерҗе төбәгендә туган Сабир Шәрипов уналты яшеннән якын кардәшләребез мохитендә яши, шунда язучы буларак та, җәмәгать эшлеклесе буларак та таныла. Сонрак, утызынчы елларда, Эмба елгасы тамагында, Каспий буйларында ачылган зур нефть чыганагын үзләштерүгә җитәкчелек итә. 30 нчы еллар ахырында ул инде Иранда СССР белән уртак нефть компаниясе җитәкчеләренең берсе итеп билгеләнә. Казакъ илендә туып, «Абай» исемендәге Казакъ опера һәм балет театрында арияләрне оста башкарып, зур дәрәҗәләргә ирешкән, СССРның халык артисты исеменә дә лаек булган ике бертуган милләттәшебез Мөслим белән Ришат Абдуллиннарны да танып беләбез. Элегрәк алар радиодан еш кына үз милли көйләребезне дә бик оста башкаралар иде... Саналган шәхесләр хәтер капчыгының иң өске өлешендә ятканнары гына бит әле. Ике кардәш халыкның уртак уллары һәм кызлары бик-бик күп.

Бүген мин шундый данлы шәхесләребезнең берсе турында тәфсилләбрәк язмакчы булам. Әйе, татар һәм казакъ дөньясында танылган күренекле композитор Латыйф Хәмиди дә шундый затларыбызның берсе.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

*Ахыры киләсе санда*

# БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫНДА АЛМАНИЯДӘ МӨСЕЛМАН ӘСИРЛӘРЕ

## 3. Хәрби әсирләрнең дини тормышы. Вюнсдорф мәчете

Алдагы мәкаләләремдә мин инде Алманиянең ислам диненә карата мөнәсәбәте, госманлы солтаны тарафыннан изге сугыш — «җиһад» игълан ителүе хакында сөйләгән идем. Беренче бөтендөнья сугышында мөселманнарны киң масштабта үз ягына җәлеп итү алманнарның төп сәяси-идеологик максатларыннан булуы аңлашыла. Кайзерның үзен госманлы солтанының һәм 300 миллион мөселманның «дусты» дип игълан итүе дә бу фикерне раслый. Димәк, аның кулына төшкән мөселман хәрби әсирләре язмышын хәл иткәндә, Алмания дини факторны, әсирләрнең дини мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү мәсьәләсен, һичшиксез, беренче нәүбәттә исәпкә алырга тиеш иде. «Пропагандистик» лагерьлар оешкан вакытта төзелгән документлардан күренә ки, бу очракта хәрби һәм сәяси түрәләр тышкы эффектка аерата зур әһәмият биргәннәр. Документларда, мәсәлән, мәчет төзү һәм әзерлекле имам билгеләү бурычы бернигә тапкыр искә алынган. Һичшиксез, мәчет төзелеше, аның даими эшләп килгән гыйбадәтханә булып торуы — алман ягы өчен әһәмиятле бер символик эшкә әверелгән.

Шунысы кызык: алман җирендә беренче мәчетләр XVIII йөздә пәйда булганнар. Мәсәлән, 1744 елда ук инде Байройт шәһәре янында Санпарей бакчасында, 1779-1791 елларда Шветцинген, 1791, 1841-1843 елларда Потсдам шәһәрләрендә мәчетләр булганлыгы билгеле. Гадәттә алар матур бакча урталарында төзелгән, биредә барлыкка килгән архитектура ансамбльләрен бизәп торганнар. Ләкин ул вакыттагы мәчетләр бары тик экзотик күренеш булып калган — XVIII йөздә, гомумән, күп кенә Европа илләрендә татар сугышчыларын (бигрәк тә Польша, Литва яки Кырым якларыннан) хәрби хезмәткә чакыру модага кергән. Бу очракларда алар өчен мәчетләр дә төзелгән. Ләкин мәчетләр сугышчыларның үзләре кебек үк бары тик «интерьер» өлеше булып торган. Мәчетләр чын мәгънәдә гыйбадәтханә булмаган. Шуна күрә Беренче бөтендөнья сугышы вакытында төзелгән Вюнсдорф мәчетен без алман җирендә, ә бәлки тулысы белән Үзәк Европа территориясендә беренче реаль мөселман гыйбадәтханәсе итеп карарга хаклы.

Беренче булып әсирләр өчен мәчет төзү тәкъдимен инде безгә таныш Макс фон Оппенһайм 1914 елның октябрендә ясый — ул кечкенә генә булса да агач мәчет төзелешен зарур дип таба. Булачак мәчеткә хәтта имам кандидатурасын да атый — төрек илчелегенең имамы Шөкри бәй. Госманлы империясеннән шәйхелисламның теләктәшлек фикере бары тик декабрь аенда гына яңгырый. Ниһаять, 1914 ел ахырында тәкъдимне Алмания югары җитәкчелеге дә хуплый — Тышкы эшләр министрлыгы һәм Генераль штаб үз ризалыкларын белдерәләр. Генераль штаб вәкиле Рудольф Надольный хәтта мәчетнең киләчәге турында да уйланып куя: «Төзеләчәк мәчет сугыш беткәч шул урында каламы, юкмы; үзенең функциясен үтиме, юкмы, анысы мөһим түгел — ул һәрхәлдә бу сугышның һәйкәле буларак үзенең кыйммәтен саклап калачак», — дип язган ул документларның берсендә.

Шул мәлдә Макс фон Оппенһайм төрле ил вәкилләре өчен аерым бернигә мәчет

---

*Дәвамы. Башы 2, 3 нче саннарда.*

төзү дөрес булыр дип фикерләрен янартып карасa да, 1915 елның башында бер мәчет төзү турында карар кабул ителгән була. Рәсми рөхсәт 3 февральдә бирелә. Ләкин бюрократик яраштыру тагын берничә айга сузыла, ул бигрәк тә төзелешне финанслау чыганакларын эзләү белән бәйле була: бары тик 18 мартта гына Хәрби министрлык 45 мең рейхсмарка суммасында туктый.

Төзелеш проектын рәсми хөкүмәт архитекторы Эрих Рихтер башкара, аңа сонрак Хәрби министрлык вәкиле А.Шульце ярдәм итә. А.Шульце мәчетнең тышкы күренешен түбәндәгечә тасвирлый: «Кергәч тә ишегалды уртасында агым сулы бассейн урнашкан. Гыйбадәт кыла торган бина эчке диаметры 12 метрлы гөмбәзле залдан һәм 3 метр киңлектәге керү юлыннан гыйбарәт. Гөмбәз нигезендә – тигез уналты почмак, якты югарыда базилика тәртибендә урнашкан кечкенә генә тәрәзәләр аша керә. Гөмбәз залында догалар уку өчен уем һәм мөнбәр урнашкан... Мөселман төзелеш традициясенә нигезләнеп, манара гөмбәзле залга мөмкин кадәр якын төзелгән — аның биеклеге 25 метр. (...) Куәтле фундаментка утыртылган бу бина, шул исәптән манара да, агачтан башкарылган һәм бар яктан да такта белән тышланган. Залның идәне тигез салынган һәм келәмнәр белән капланган Ратенов ташыннан эшләнгән. Гөмбәз тәрәзәләренә төрле төсләрдәге гади пыяла куелган. Эчке һәм тышкы бизәлеш өчен майлы буяулар кулланылган — монысы өчен Потсдам сарай рәссамы Андре җаваплы булган. Гөмбәзнең күтәрелеп барган тышкы өслеге фил сөяге төсенә буялган, өслекнең башка өлешләре кызыл һәм соры төсләргә сырланган. Гөмбәзнең эчке өслеге шулай ук фил сөяге төсендә буялган, аны сары сырлар һәм яшел сызыклар бизәгән».

Мәчет төзелеше чагыштырмача тиз арада тәмамланган — «Штибиц һәм Кёпхен» төзелеш фирмасы бу эшне биш атна эчендә башкарып чыга. Ашыгуның төп сәбәбе — алман түрәләре мәчетнең рамазан ае башында ачылуын теләгән, 1915 елда мөселманнар уразага 13 июльдә кергән.

Бу көнгә хәтта ачылу сценарие дә булдырылган. Сценарий буенча тантана түбәндәгечә уздырылырга тиеш булган. Бәйрәм сәгать 12дә, өйлә намазына бер сәгать кала башлана. Барлык тантанада катнашырга чакырылган кунаклар, мөселманнар һәм христианнар мәчетнең керү урынында уң һәм сул якта тезелешәләр. Керү урынына каршы исә төп «геройлар», хәрби әсирләр урнаша — алар арасында күпчелекне Африка халыклары вәкилләре тәшкил итәргә тиеш булган. «Татар лагерен»нан (ягъни күрше Вайнберг лагереннан) делегация дә ачылу тантанасына чакырылган — димәк, татарлар «төп геройлар» сафына әлегә кертелмәгән булып чыга. Алар сонра лагерьларына кире кайтып, калган иптәшләренә мәчет ачылу турында сөйләрләр дип уйланылган.

Бәйрәмне Алмания хөкүмәте вәкиле ачып җибәрә, кыска гына нотык сөйләгәннән соң, ул билгеләнгән имам кулына мәчет ачкычын тоттыра. Имам кандидатурасы ул вакытка инде расланган була. Бу — Тунис рухание Мөхәммәт әл-Хидр Хөсәен. Ачкыч алган вакытта имамга шулай ук мөселман руханилары киеме — җөббә белән кулъязма Коръән дә тапшырыла. Коръәнне махсус телеграмма сугып, Мюнхеннан антиквар кибетеннән эзләтәләр. Башта бу кулъязманы алу өчен 200 марка акча планлаштырылган булса, тора-бара Коръән, җөббә һәм имам таягына бары тик 150 марка тотарга рөхсәт ителгән.

Госманлы дәүләте исеменнән илче ясаган чыгыштан соң, сүз әсирләрнең берсенә бирелергә, аннан соң шул ук әсир мәчет каршында корбан чалырга тиеш булган.

Ураза башлану сәбәпле, христиан кунаклары өчен аш уздыру каралган, ләкин мәҗлес мөселманнар күрмәслек урында алман кунаклары өчен генә уздырылган.

Тантана шушы сценарий буенча барган да. Бәйрәмгә зур кунаклар чакырылган, алар арасында Алманиядәге төрек илчесе Мәхмүд Мохтар паша, Алманиянең Генераль штабы офицерлары, Хәрби һәм Тышкы эшләр министрлыклары вәкилләре, әсирләр лагерьлары өчен җаваплы түрәләр, Алманиядә белем алучы мөселман студентлары булган. Күрше Вайнберг лагереннан күп санлы татар делегациясе дә килгән.

Мәчетне ачу типик пропагандистик чарага әверелгән. Сонра алман вакытлы матбугатында бу зур вакыйга турында күп кенә мәкаләләр дөнья күргән, сөйләнгән


*Вюнсдорф мәчете*

нотыкларның текстлары пропагандистик листовкалар өчен нигез итеп алынган. Аларның төп мотивы — Алманиянең ислам диненә мөнәсәбәте барлык башка Европа илләренекеннән аерылып тора, кайбер пропагандистлар тарафыннан ике «махсус» лагерьда жыелган мөселманнар инде әсир дә түгел, ә кайзерның «кунаклары» булып каралырга тиеш, дигән тәкъдим дә яңгыраган. Шундый фикерне, мәсәлән, үзенең ачылу вакытындагы чыгышында яна мәчетнең имамы Мөхәммәт әл-Хидр Хөсәен дә уздырган. «Алмания дәүләте мөселман дөньясына ихлас дуслык хисләре белән карый, бу хисләр аның мөселманнарның матди тәрәккыяте һәм рухи яктан камилләшүләре хакында кайгыртуында, ислам дини тормышына ихтирамлы карашында чагылыш таба. Соңгы сүзләрнең төп дәлиле — биредә төзелгән мәчет. Моның өчен без Алманиягә мең рәхмәт укыйбыз», — дип ассызыклаган имам.

Берничә ел дәвамында Вюнсдорф мәчете әсирләр өчен генә түгел, ә Алманиянең үзәгендә яшәүче мөселманнар тормышында да чын бер үзәк булып торган. Ул тәүлек буена ачык булган һәм әсирләр теләсә кайсы вакытта мәчеткә килә алган. Жомга намазларына бирегә әсирләр жыеп китерелгән, мәчеттә иң зур мөселман бәйрәмнәре дә оештырылган, дин дәресләре бирелгән, женазалар уздырылган.

Вюнсдорф мәчете бары тик 400 кешене генә сыйдыра алган. Әсирләр саны, инде әйтелгәнчә, бу саннан зуррак булганга, 1915 елның сентябреннән жомга намазлары мәчет каршындагы мәйданда уздырыла башлаган.

Татар әсирләре тупланган Вайнберг лагереннан да мөселманнар бу мәчеткә килә башлаганнар, ләкин, башка лагерьда булу сәбәпле, бирегә алар оештырылган рәвештә атнасына өч тапкыр гына — 13.00дән 17.00гә кадәр килә алган. Бу, әлбәттә, ризасызлык та тудырган, өстәмә мәшәкать белән дә бәйле булган, шуна күрә Вайнберг лагеренда татарлар өчен 1915 елның августында аерым манара торгызылган. Комендант мәгълүматлары буенча Вайнберг лагеренда гыйбадәт кылуларда 3-4 мең әсир катнашкан, шуна күрә биредә дә аерым гыйбадәт залы ачу зарурлыгы туган. 1915 елның октябрендә биредә 3 мең кеше сыйдыра алган ике чатыр куелган һәм әсирләр 20 октябрьдә Корбан бәйрәмен инде үз лагерьларында бәйрәм итә алганнар.

Бу вакытта Вайнберг лагеренын да үз имамы булган. Бу — Төркиядән килгән, инде өлкән яшьтәге күренекле татар галиме Габдерәшит Ибраһим (1854-1944). Беренче тапкыр ул вәгазе белән 1915 елның 5 июнендә чыгыш ясаган һәм шул көннән имам вазифаларын башкарган. Ләкин алман пропагандасы өчен күп көч сарыф иткән Г.Ибраһим Алманиядә озак тормый — инде шул ук елның октябрендә ул кире Истанбулга әйләнеп кайта. Аннан соң имам итеп Төркиядән килгән тагын бер мәшһүр шәхес, Кырым татарларыннан Госман Кади билгеләнгән. Ә 1916 елның мартыннан бу урынга Галимжан Идриси куелган. Бу үзенчәлекле, бик каршылыклы гомер кичергән, соң дәрәжәдә авантюрист булган кеше турында, бигрәк тә аның Беренче бөтендөнья сугышы вакытындагы эшчәнлеге турында бераз жентекләбрәк әйтәсем килә.

Галимжан Жәгъфәр улы Идриси 1887 елда Кызылъяр (хәзерге — Петропавловск) шәһәрендә туган. Әтисе чыгышы белән Казан якларыннан, әнисе — Буадан. 1907 елда Бохарада белем алганнан соң, ул 5 ел Истанбул университетында фәлсәфә һәм дин фәннәрен өйрәнгән. 1912 елда кире Русиягә кайтып, бераз

вакыт атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсендә шәкертләргә дәрес биргән. Бу шәхеснең «күпкырлылыгы» инде шул чорда ук күренә башлаган — мәсәләнең, татар вакытлы матбугатында аның каләме астыннан чыккан күпсанлы мәкаләләрендә ул нинди генә мәсьәләләргә алынмаган. Дин, мәдәният, сәясәт темалары гына кызыксындырмаган аны, ул хәтта авыл хуҗалыгы яки машиналар төзү турында да мәкаләләр авторы була яки «Шура» журналы битләрендә «Без ни өчен уңагай» яки «Наполеон мөселман булганмы?» дигән мәкаләләр дә бастыра.



*Вюнсдорф мәчетенең эчке күренеше. Мөнбәрдә – Галимҗан Идриси*

1913-1914 елларда, бер ел чамасы Г.Идриси Швейцария һәм Бельгия университетларында телләр өйрәнү һәм фәлсәфә өлкәсендә белемен тирәнәйтә һәм Европадан юлын туры Истанбулга тота — биредә ул 1915 елның сентябренә кадәр Йосыф Акчура житәкләгән «Төрек йорты» журналында икенче мөхәррир вазифаларын үти. Телләр дигәч, Г.Идриси бу өлкәдә гаҗәеп дәрәҗәдә сәләтле булган: ул татар һәм рус телләреннән тыш төрек, фарсы, казакъ, үзбәк, француз һәм алман телләрен камил белгән.

Ниһаять, 1915 ел көзендә язмыш Галимҗан Идрисине Алманиягә китерә — амбицияләре бик куәтле бу яшь кешегә (ана бу вакытта әле 27 яшь кенә) Беренче бөтендөнья сугышы тиз күтәрелеп китәргә шанс биргән булып тоелган, ахрысы. Алман Хәрби министрлыгы белән тыгыз элемтәгә кереп, ул башта Вайнберг лагеренда татар хәрби әсирләре арасында пропаганда алып барган, милләттәшләренә «җиһад»ның максатларын аңлаткан. Бу эшне ул бирелеп һәм тырышып башкарган, күрәсең, шуна күрә 1916 елның мартында имамлыкка иң кулай кандидатура булып табылган.

Сугыш елларында бу урында Галимҗан Идриси бик зур эшләр башкара. Һәм тора-бара Русия мөселман әсирләренең идеологик башлыгына әйләнеп китә. Ул — барлык мөселман бәйрәмнәрен оештыручы, армый-талмый әсирләрнең матди һәм рухи мәнфәгатьләрен кайгыртучы, актив журналист (татар телендә әсирләр өчен чыккан «Әл-җиһад», «Татар иле», «Яңа тормыш» газеталарында хезмәттәшлек иткән автор). Әсирләр белән эшчәнлеге өчен Идриси соңра Алмания президенты Фридрих Эбертның рәхмәт хатына да лаек булган. Житәкче, оештыручы булу, күрәсең, аны бик мавыктырган — 1918 ел башында, сугыш әле барган вакытта Идриси Алманиядә беренче (һәм соңгы) татар хәйрия җәмгыятен оештырып җибәрә — ул «Русия мөселман шәкертләренең ярдәмләшү җәмгыяте» дип аталган һәм 1924 елга кадәр эшләп килгән. Татар хәйриячелеген чит ил шартларында дәвам иткән бу җәмгыять Алманиядә белем алган татар студентлары, 20нче еллар башында, дәүләтара килешү нигезендә, Алманиягә Совет Русиясеннән берничә йөз мөселман студенты укырга килгән) һәм хәрби әсирләр арасында арадашчы да, аларга матди һәм рухи терәк тә булган, мөселманнарны бер-берсе белән бәйләгән.

Әсирләрне студентлар белән якынайткан (бик үзенчәлекле бәйләнеш!) бер документ текстын китерәсем килә (аны үзгән ел Берлин китапханәсеннән тапкан идем). Студентлар җәмгыяте барлыкка килгәч, Г.Идриси Берлин басмаханәсендә әсирләр өчен ике телдә (алманча һәм татарча) васыятьнамә формулярын бастырта. Аның эчтәлеге:

«Авыру булсам да, бик авыраеп китмәс борын, гакылым башымда вакытта түбәндәге васыятемне ике шаһит хозурында яздырып кулымны куям.



*Галимҗан Идриси. 1920 ел*

Халис милкем булган ... марк вә ... сум акчамнан

... марк вә ... сумы «Русияле ислам шәкертләренә ярдәм җәмгыяте»нә бирелсен.

... марк вә ... сумы үземнең рухыма вә әткәм-әнкәмнең рухларына Коръән хәтем итүчегә бирелсен.

... марк вә ... сумы мине юып кәфенләүче вә зиратка алып барып күмүчеләргә бирелсен.

... марк вә ... сумы өемдәге хатын, балачагама, әткәм белән әнкәмә җибәрелсен.

Ошбу васыятемне Вюнсдорф лагерендагы хәзрәтебез Галимҗан Идриси әфәнде җиренә житкерсен.

Гакылым камил хәлдә васыять итүче:

Мәрхүмнең васыяте гакылы дөрест вакытта әйткәнлегенә гуаһлык итүче шаһидлар» (текстны бераз хәзерге тел нормаларына якынайтып бирәм).

Әсирнең нинди милке булсын инде? Шулай да, тексттан күренгәнчә, вафаты турында уйлаганда, ул әти-әнисен, балачагасын түгел, ә беренче чиратта Г.Идриси тарафыннан оештырылган җәмгыять турында уйланырга тиеш булган...

Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Галимҗан Идриси Алманиянең Хәрби министрлыгы белән генә түгел, ә Тышкы эшләр министрлыгы белән дә тыгыз элемтәдә булган. Аның соңрак язылган автобиографиясендә искә алынганча, ул, 1921 елның 21 июненә кадәр Тышкы эшләр министрлыгының рәсми хезмәткәре вазифасын үтәп, «төрле оешмалар һәм Алманиядә әсирлектә булган мөселманнар арасында элемтәләр урнаштырып, аларның ышанычлы вәкиле» булган.

Сугыш беткәннән соң, Г.Идрисинең тормышында әр-яна этап башланып киткән. Нәрсә белән генә шөгыльләнмәгән ул 1920-1940 елларда: Русиядән Алманиягә укырга яшьләр китерткән, Бохара совет республикасының Алманиядәге вәкиле булган, Берлинда тагын бер мөселман оешмасын башлап җибәргән, Берлин университетында укып алган, нацистлар чорында Тышкы эшләр һәм Пропаганда министрлыкларында хезмәттәшлек иткән (соңгысында ул гарәп һәм төрек редакцияләрен җитәкләгән), Гитлерның «Майн кампф» китабын фарсы теленә тәрҗемә иткән, 1940 елда алман ватандашлыгын алган, Икенче бөтендөнья сугышы башлангач, алман түрәләренә донослар язып, барлык төрки халыклардан булган күренекле сәяси эмигрантларны пычракка батырып бетергән... Сугыштан соң ул башта Швейцариягә, аннан соң Мисырга һәм, ниһаять, Согуд Гарәбстанына барып урнаша һәм 1959 елда вафат була. Соңра атасының җәсәден улы Илдар Алманиягә, Мюнхен шәһәренә кайтарта...

Гаҗәеп каршылыклы, катлаулы һәм, һичшиксез, фаҗигале язмыш... Галимҗан Идрисинең тормышы, минемчә, аерым китапка һәм киносценарийга лаек...

Ә без исә бу шәхестән кире Вюнсдорф мәчете тарихына әйләнеп кайтыйк.

Димәк, сугыш вакытында бу гыйбадәтханәнең үзенең төп функциясен үтәп торганлыгы аңлашыла. Сугыш беткәннән соң, ул сакланып калган микән, дигән сорау куярга мөмкин. Чыннан да, ул пропаганда максатларыннан бары тик хәрби әсирләр өчен генә төзелгән булган бит. Сугыш беткәч, әсирләрнең абсолют күпчелеге кире туган илләренә кайтып киткән (соңгы татар әсирләре 1921 елда репатриацияләнгән). Ләкин йөзгә якын татар, күпчелек Г.Идриси тарафыннан төзелгән шәкертләр җәмгыяте әгъзалары, кумәкләшеп, элекке лагерь территориясендә мәчеткә терәлеп торган ике баракта яши биргән.

Димәк, мәчет яшәгән әле. Аны саклап калу зарурлыгы турында хәтта кайбер



*Мөселман әсирләре Корбан гаетен бәйрәм итә. 1915 ел, 20 октябрь*

алман газеталары да язып чыккан — 1920 елда «Дойче алльгемайне цайтунг», мәсәлән, түбәндәге фикерне китергән: «Коръән күрсәтмәләре буенча беркем дә мәчетне җимерергә хаклы түгел. Алманиядә яшәүче татарлар һәм мөселманнар өчен ул изге урын булып кала, һәм Алмания аны шулай кабул итәргә тиеш. Алман хөкүмәтенең әхлакый бурычы — барлык кызыксынган татарларга үз дини мәнфәгатьләрен канәгатьләндерергә мөмкинлек бирү».

1921-1924 елларда Вюнсдорф мәчетендә иң зур мөселман бәйрәмнәре уздырылганы билгеле. 1922 елда Ураза бәйрәме вакытында (29 май көнне) шәкертләр җәмгыяте җитәкчесе Кәмалетдин Бәдри алман җитәкчеләренә рәхмәтләр укыган — әсирләр лагере рәсми бетерелсә дә, алманнар ярдәме белән татарларга биредә бер сыеныр урын калдырганнары өчен. Аның сүзләренчә, мәчет Алманиядә мөселман колониясе үзәге булып кала.

Ләкин Алмания 20нче еллар башыннан кискен икътисади кризис кичерә, «экзотик» мөселманнарга игътибар гел кимүгә таба бара... 1924 елның 13 июлендә мөселманнар Вюнсдорф мәчетендә соңгы тапкыр Корбан бәйрәмен уздыра. Бу вакытта инде мөселманнар үзләре дә шактый кыен хәлдә кала. Татар студентларын берләштергән җәмгыять матди кыенлыклар аркасында 1924 елда таркала. Берлинда эшчәнлек алып барган ике төрле мөселман җәмгыяте мәчет өчен бәхәсләшә башлый. Низаг озакка сузыла, алман җитәкче оешмалары өчен бу мәчетне «вакытлыча» ябып торырга шәп сылтау була. Мәчет янындагы баракларда яшәгән татарларның күбесе 1924 ел ахырына Берлинга яки башка шәһәрләргә күченеп китә.

Мәчеттә кем хуҗа булырга тиеш — ике мөселман җәмгыяте арасындагы сөйләшүләрдә Тышкы эшләр министрлыгы арадашчы ролендә була, ләкин бәхәсләшүчеләр уртак фикергә килә алмый.

1925 елда Берлинда тантаналы рәвештә Бринерштрассе урамында мәһабәт таш мәчет ачыла (ул мәчет бүген дә бар). Бу факт бәхәсле агач Вюнсдорф мәчетенә игътибарны тагын да киметә. Берничә елга сузылган буш сөйләшүләрдән соң, 1929 ел ахырында Тышкы эшләр һәм Оборона министрлыклары (элекке Вюнсдорф лагере территориясе ул вакытта Оборона министрлыгы карамагына күчкән була) уртак карарга киләләр — инде шактый тузып беткән Вюнсдорф мәчете бинасын сүтәргә, аннан калган материалларны арзан бәягә булса да сатарга.

Шуның белән татар әсирләре, студентлары, сәяси эмигрантлары язмышында зур роль уйнаган, алман җирендә беренче мөселман гыйбадәтханәсе — Вюнсдорф мәчете тарихы тәмам. Кайчандыр аның биредә булуын бүген Цоссен шәһәрендә бары тик Мәчет урамы дип исемләнгән урам гына хәтерләтә...

*Дәвамы киләсе саннарда*

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ,**
*тарих фәннәре докторы, профессор*

# ХӘЗИНӘДӘ ӘЗ ДИМӘ...

**Габдулла ТУКАЙ**

## Өзекләр

Борынгылар әйткәннәр: «Картлар сүзен капчыкка сал», — дип, әмма кайда ташларга? Ансын әйтмәгәннәр.

***

Динле булып күренү бик яхшы бер кәсеп ул.

***

Ахун бу Коръән аятьләрен шул кадәр сындыра, шул кадәр изә иде ки, бөтенләй урмандагы куе корган агачлар арасыннан аю йөргән төсле иде яки Коръән — ярма, хәзрәтнен тешләре тегермән ташлары кеби иде.

Минем шул вакытта вөжданым: «Һай, бу хәзрәтне болай мәҗлескә китереп сөйләткәнче, Тимерчегә алып барып авызын чүкечләтеп, бераз Коръән укырга, татарча сүз сөйли белергә өйрәтсән, нинди яхшы булыр иде», — дип тора иде.

***

Без инде моннан элекке өч Думаның өчесендә дә гакыллы кешеләр җибәреп карадык. Барыбер безнең файдага әллә ни эш чыкмады. 4 нче Думага исә без һич тә игътибар итмибез, шунар күрә без анда, өмидсезлегебезнең ачы бер көлкесе булсын дип, җүри җүләрне, җүри болванны сайладык. Үземезчә: 4 нче Дума үз дәрәҗәсен, үз мәгънәсезлеген сизсен, дидек.

[...] Европа парламентларында йозрык вә алтатар белән депутатлар бер-беренә золым итсәләр дә, безнең Думада, әлхәмделилла, андый кызулык булганы юк. Марков Икенче җәнабләре берәүнең борынына сукса да вә ул берәү анын күзенә сугып җавап кайтарса да, бу хәлләр (сөммә әлхәмделилла) Дума эчендә түгел, бәлки әллә кайда, әллә кемдә булган исерек мәҗлестә генә!

Пуришкевич исә, Дуров вә Бим-Бомнар кадәр үк булдыра алмаса да, Думада клоунлык кына итә. Ул һичкемгә золым итми. Хәтта бер-ике Думадан бирле тамак шеше белән сүздән калган сул депутатларны каһкаһәгә житкәнче көлдереп, кайчакта шешләрнен тишелүенә вә мәзкүрләрнен сөйләүләренә генә сәбәп була.

Русларда да эш шундый гына булганда, безнең татар депутатларына золым итү кая да, ни кая?

Туфан МИҢНУЛЛИН

## Робагыйлар

Сөешүләр чиста иде — ак каенлы,
Оят иде кочу, үбү җанкаеңны.
Ни кызганыч, ни аяныч, ядрәнәмәйт,
Бозык заман килгәч кенә картаелды.

***

Ачуыма чыдый алмый кара янып,
Әтәчкә мин ыргыттым бер таяк алып...
Ничек инде ыргытмыйча түзәсен, ди —
Заразаның берүзенә ничә тавык.

БАТУЛЛА

## Партия — савым сыеры

Драматург Шәриф Хөсәен СССР Язучылар союзы әгъзасы булгач, баштагы мәлләрдә партия җыелышына ара-тирә булса да йөргәләгән. Тора-бара ул бөтенләй йөрмәс була. Тиешле взнос акчасын почта аша гына җибәрә икән.

Партоешма секретаре Туфан Миңнуллин бер көнне Шәриф Хөсәенне очраткач:

— Шәриф абый, партия җыелышларына йөрмисез бит! — ди.

— ...тем партиягезне! — дигән драматург. — Мин фатир алдым инде!

Марсель ГАЛИЕВ

## Эреләр...

Сак булыгыз, мәгърур Гулливерлар!
Лилипутлар килә шигырьгә! —

дип язган иде заманында өлкән шагыйребез Шәйхи Маннур. Кыска буйлыларны — Пушкин, Лермонтов, Есенин кебекләрне, үзебезнең Мөдәррис Әгъләмнәрне күздә тоткан булса кирәк.

Равил Фәйзуллин да, киләчәген кайгыртып, сызланып уйланганнан соң, язып куйган әнә:

Ваклар эреләнеп калыр —
без киткәч...

Аңа җавап рәвешендә, шул ук Әгъләмнәр буйлыгыннан, Илдус Гыйләҗев болай дип кистереп әйткән:

Вак дигәнең бездер инде...
Язып та куйгансың, вәйт.
...Эре буласы килә бит,
Күпме көтик, шуны әйт!..

### И, бу ваклык

Чаллының «Аргамак» журналы редакциясендә бер төркем язучы гәпләшеп утыра икән. Шулвакыт Айдар Хәлим килеп керә. Йөзе шат. Чираттагы кирпеч калынлыгы китабы чыккан көннәре. Фаяз Дунай, чыраен сытып, аңа төбәлә:

— Син, Айдар туган, бик яман эш кылгансың бит. Китабыңда мине адәм рисвае итеп чыккансың. Имеш, мин сәрхушләнеп, мәҗлес табынын бозганмын, өстәлгә менеп сикергәнмен, савыт-сабаларны челпәрәмә китереп биегәнмен, имеш... Тагын, тагын әллә ниләр. Кешене бу кадәрле дә пычратырга синең ни хакың бар!

Айдар Хәлим башын чайкап тыңлап торган да Фаяз Дунайга бик рәнҗеп:

— И-и, бу татарның ваклыгы-ы.. Язган, беткән бит инде, югыйсә, — дигән.

### Куанычтан

Чаллы мәйданнарында митинг кайный. Ул чактагы шәһәр мэры Алтынбаев исеме өскә чөелгән йодрыклар арасыннан каһәрләнеп яңгырый. Бер кырыйда калфак кигән матур гына татар әбисе баш очына «Долой Алтынбаева!» дигән плакат күтәреп тора. Рус корреспонденты килеп әбигә дәшә:

— Чем он не угодил вам? Этот Алтынбаев плохой человек, да, бабушка?

Әби елмаеп җавап бирә:

— Харуши наш Алтынбаев. Уч-чин харуши чилавик.

Учына акча төрткәч, зиһене таралган әби үзе күтәрәсе плакатка күз дә салмаган икән шул...

### Халык күрмәсә...

Миргазиян Юныс, «Биектә калу» дигән әсәрен тәгаллләгәч, караламасын тәртипкә китереп, төннәр буе каютасында акка күчереп чыга. Материкка кайту белән редакциягә юллыйсы нөсхәне — бер папкага, караламаны икенче папкага таслап куйгач, эшеннән канәгать булып, палубага менә. Эре йолдызлар астында төнге Һинд океаны ухылдап ята. Күңелдә — канәгатьлек. Миргазиян ага нишләп артык кәгазьләр (таможнядагы «бүреләрне» шикләндереп) җыеп ятам әле, дип, каударланып, каютасыннан каралама кәгазьләр тупланган папканы алып чыга да Һинд океанына ыргыта. Кәгазьләр, чәчелеп, дулкын өстендә тирбәлә башлый. Бераздан «Зиләйлүк» көенә сызгырынып, шәп кәеф белән каютасына керә, яна тәгалләнгән әсәрен тагын бер сыйпап карарга дип, папканы ачса... йөрәге убылып китә. Ялгыш... акка күчерелгән папканы суга ыргыткан лабаса! Йөгереп, ул янадан палубага чыга. Аста — ваемсыз-бөек дәрья — татар романын йоткан Һинд океаны җәйрәп ята. Өстә — урак ае белән елмайган күк гөмбәзе. Еламас өчен, үкенечле мизгелне йомшартып, Миргазиян ага үз-үзеннән көлеп куя: гади халыкта «халикъ» дигән сүзен алмаштырып кулланыла торган әйтем нәкъ менә шушындый очракка туры киләдер шәт: «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык күрмәсә, балык күрер...»

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

## Татар эстрадасына хөкүмәт ярдәме кирәк!

*Журналның 1нче санында чыккан «Җыр өмәсе үткәрик әле!» дигән мәкаләне укыгач туды бу фикерләр.*

*Бүгенге «татар эстрадасының якты йолдызлары» рәтендә булган «мәшһүр» җырчыларыбыз катнашындагы тамашаларга күптәннән йөрмим инде. Оялам. Берәр танышым күрер дә: «Моның да музыкаль зәвыгы шул чама гына икән», — дип уйлар кебек. Мин җыр-моң яратам, үзем дә җырлаштыргалыйм. Әмма бүген иҗат ителә торган җырлар һәм шул җырларны башкаручылар күңелдә ризасызлык хисләре генә уятырга сәләтле. Безгә башка төрле эстрада кирәк. Соңгы ике дистә елда бу турыда күп сөйлибез, файдасы гына юк әлегә.*

*Миңа калса, эстрада сәнгате дә, опера, балет, симфоник музыка, театр һәм башка сәнгать төрләре кебек үк, халыкка, беренче чиратта, яшь буынга эстетик тәрбия бирү чарасы ул. Шулай икән, бу эш үз агымына куелмыйча, дәүләт контролендә алынырга тиештер, минемчә. Хөкүмәтебез бит театрларга, симфоник оркестрыбызга, филармониябезгә финанс ярдәме күрсәтә. Нишләп эстраданы читкә кагабыз әле, югыйсә бит халыкның күпчелеге опера-балетны, симфонияне түгел (кызганыч, әлбәттә!), нәкъ менә эстраданы — тәрбияви потенциалы гаҗәеп бай булган сәнгатьне үз итә. Менә дигән талантларыбыз бар, тик аларның бик азы гына үз көче, гадел юл белән югары сәхнәгә күтәрелә ала. Сәхнәбезне акчалы, ләкин талантлары чамалы булган әрсез яшьләр басып ала. Иң аянычы шул: алар югары сәнгатьнең бөтен таләпләренә җавап бирә торган чын җырның нәрсә икәнен дә белмиләр. Сөйләм телебездә «өч ноталы җыр» дигән тәгъбир юктан гына килеп чыкмады ул. Ни юньле эчтәлеге, ни истә калырлык көе булмаган шундый җырлардан хисләнеп, тамаша залында оеп-изрәп утыручылар һаман күбәя бит.*

*Мәкалә авторы Рәфикъ Юнысның һәм шагыйрь Роберт Миңнуллинның республика күләмендә яңа төр җыр бәйгесе үткәрергә кирәк, бу олы бәйгенең игътибар үзәгендә җырчы түгел, ә җыр, аның текстын һәм көен иҗат итүчеләр торырга тиеш дигән фикерләре белән тулысынча килешәм. Аңлашыла ки, әлеге бәйгене хөкүмәт, аерым алганда, Мәдәният министрлыгы ярдәме белән генә оештырырга мөмкин.*

*Ярый, хуш, үткәрдек тә ди шундый бәйгене, шәп җырлар да барлыкка килде ди. Шагыйрьләрне, композиторларны да гонорарлар белән ризалаттык ди. Җырлармы соң ул җырларны безнең бүгенге йолдызлар? Радио-телевидение ничек кабул итәр аларны? Бушка пропагандаларлар дисезме шул шәп җырларны? Үтте инде андый заманнар. Димәк, бу өлкәдә дә хөкүмәт ярдәме кирәк булачак.*

*Өметсез шайтан ди: хөкүмәттә дә җыр сөюче татарлар утыра ич. Миллиардлар кирәк түгел, миллионнар да җитә — сорый белеп сорасаң, бүлешерләр дип уйлыйм. Башлап йөрүчене табу гына проблема булырга мөмкин. Бар микән ул безнең эстрадада андыйлар?*

**Фаяз ХУҖИН,**
*тарих фәннәре докторы,*
*профессор*

**Редакциядән:**

*Мондый җыр конкурсы үткәрү идеясен Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе шагыйрь Разил Вәлиев, Татарстан Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин, җырчыларыбыз Ильһам Шакиров белән Салават та хупладылар. Конкурс кайчан һәм ни рәвешле үткәрелергә тиеш — бу хакта укучыларыбыздан, бигрәк тә җыр сәнгате музыка әһелләреннән, тиз арада фикерләр һәм тәгаен тәкъдимнәр көтәбез.*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнең сәхифә!

Факил
Сафин

# ТУЛГАН АЙ

БӘЯН

## VI

Тулганай — чын дус ул. Күзгә карап, ни әйтергә теләгәнне аңлый бит. Кәлимулла абзый иренми, этне өйрәтү алымнарын күрсәтеп кенә тора, ул әйткәнчә тырышып, бу серләрне Тулганайга өйрәтәм. Сез шундый хикмәткә ничек карыйсыз: Сарбай, өй кыегына сөялгән озын баскычның аралаларына басып өскә менеп китә, аннан кире борылмыйча, шыңшымый-нитми бер ян-ягыннан шуып диярлек кире төшә.

— Мондый этләр сирәк була, — ди Кәлимулла агай. — Чын акыллылары гына эшли ала аны. Оста дигәннәре дә өскә менеп җиткәч, башта кирегә борылмакчы булып мәшәләнәләр, интегә торгач, кире борылып, сакланып кына аратадан аратага күчеп, түбән төшәләр. Бу вакытны сарыф итү дигән сүз. Тулганай исә башка юл сайлады. Күренеп тора, акыл казаны буш түгел моның.

Укулар башланыр алдыннан авылга бәла килде: имеш, күрше башкорт якларында хайван авыруы — ящур башланган икән. Кешегә дә йога, ди. Хайваннар да, кешеләр дә кырылып бетәргә мөмкин дип көннәрдән бер көнне сыер-сарыкларны көтүдән өйгә кайтармый башладылар. Беренче көнне авыл башында милиция сакта торды, көтүне авылдан читтә туплап куйдылар. Халык эшнең уен-муен түгел икәненә тиз төшенде. Иртүк, таң сызылу белән хатын-кызлар чиләк тотып иртәнге савымга баралар. Көтү зират белән Калмыя елгасы арасындагы бер урынга кайтып туплангач, кичке савымга җыелалар. Алай күңел төшенкелеге сизелми, мәзәк сөйләшәләр, көлешәләр, шулай да ара-тирә генә ризасыз тавышлар ишетелгәли:

— Урып-җыю чорында халыкны шулай тинтерәтәләрмени? Башкорт ягында ящурның эзе дә юк. Ничек булса, шулай яши бирәләр — иртән көтү куалар, кич каршы алалар. Безнең түрәләр халык бер минут эштән соңга калып чыкмасын, бер минут алдан китмәсен дип кыланган булалар. Көн күрмәгән көн күрсә, көндез чыра яндырыр. Техника, техника дип шаулыйлар, эш башласалар, ни техникасы, ни акыллы оештыручысы юк.

Андый зарланучыларга кушылучылар сирәк. Бу сүзләр сөт исе сеңгән һавага асылынып кала.

*Ахыры. Башы узган саннарда.*

Авыл халкы һәр төнне чиратлашып көтү сакларга чыга. Август ахырларында чират безгә дә җитте. Көтү саклау күбрәк малай-шалай эше, үз чиратыбызда әткәй әйтте:

— Иртән мин Завод урманына агач кисәргә китәм, көтү сакларга син барырсың инде, улым. Ярдәмчең дә бар — Тулганайны үзең белән алырсың.

Сөенеп риза булдым. Этемнең бөтен осталыкларын күрсәтеп, күпләрне телсез калдырам, болай булгач. Тулганайны бәйсез йөртергә өйрәтә башлаган идем. Бәйдән башка ул минем белән рәттән генә барырга тиеш, алга — ике-өч адым чыга ала, артка шулкадәр калса — ярый, ди Кәлимулла абзый. Эт хуҗасы белән бер аяктан атлап барырга омтылырга тиеш икән. Бусын үзем аңлап җитмәсәм дә, Тулганай белән рәттән барганда сизәм — ул минем белән бер көйгә барырга тырышып теркелди.

— Акыллы эт моны үзе аңлап эш итә, — диде беркөнне Кәлимулла агай, минем Тулганай белән матавыкланганны карап торгач. — Күрәсең, ничек синең җайга барырга тырыша ул. — Аннан өйрәтү эшенә үзе дә кушылып китте. — Шәп, шәп, менә шулай, сабыр гына атларга өйрәт. Безнең авыл этләре тыйнак бит алар, — диде ул, кесәсеннән мөштеген чыгарып. — Күптәннән чамалап йөрим, башкорт ягыннан килгән этләр туктаусыз өрергә яраталар, бәлачел, әрсез булалар. Ник шулайдыр, әйтә алмыйм. Безнең авыл этләре бөтенләй башка шул. Кешеләр бер-берсен аңлап җиткермәгән заманда этләр белән аңлашу җиңелрәк.

Әткәй каршы төшәсе итте.

— Анда да безнең яктан киткән кешеләр бит инде. Этләре дә шул. Егерменче елларда кара урман уртасына күчереп утырттылар безнең яктан халыкны. Хәллерәк көн күрүчеләрне кудылар, күчмәсәгез, Себергә олактырабыз дип куркыттылар. Яңа җирләр үзләштерү дигән нәрсә башланган ие бит. Тирә-якта урман, авылларны өстенә килеп чыкмыйча тапмалы түгел, ерткыч җанвар тулы, вәт этләрнең тоташ куркып яшәүдән холыклары үзгәргән...

— Гаҗәп шул, — дип килеште Кәлимулла абзый. — Татарлар яшәгән җирләрдә кырганнар гына урманнарны. Бүре-фәлән килеп чыкканны, ачуым килмәгәе, дистә чакрымнан сизеп алалар безнең этләр, шуңа да тыныч холыклырак булганнардыр инде. Авылларның да коты калмаган шул, шыр яланда яшәп ятыш...

...Тулганай белән көтү каршыларга киттек. Авыл көтүе Язсаз дип аталган болынлыкта иде. Иртә яздан җәй уртасына кадәр кереп булмый торган сазлык анда, шуңа Язсаз дип атала. Без Калмыя аша салынган озын, тар күпер янына килеп җиткәндә, тузан болыты кубарып кайтучы көтү дә күренде. Тулганай белән минем бурыч — көтүне күпергә якын җибәрмичә, сулга куып, Калмыя белән зират арасына — туплауга бору. Өйләреннән иртәрәк кузгалган өлкәннәр дә булышканга, бу эш кыен булмады, алдан ашкынып, чабып кайтучы ике-өч сыер күпер ягына каера башлаганнар иде, таяклар болгап каршы чыгучы кешеләрне күреп, адымнарын әкренәйттеләр, аннан бөтенләй туктап калдылар, башларын селкеп, ризасызлык белдереп «му-уу»лап, мөгрәп, теләмичә генә олы юлдан туплауга төшеп киттеләр.

Мин бераз кәефсезләндем дә әле. Тулганайга ни кешеләр, ни сыерлар игътибар да итмәделәр ичмасам. Югыйсә этнең муенында өч медаль бар, юкка гына түгел бит инде!

Соңга калып килгән апалар сыерларын савып бетергәндә, кичке эңгер төште. Көтү сакларга чыкканнар җыелышып, эш бүлешү булды. Без — Кәлимулла абзый, мин, Тулганай — уң кулда торып, сыерларны олы юлга җибәрмәскә тиешбез, сул кулда торучылар исә малларны басу ягына таралып китүдән саклыйлар. Бер яктан зират коймалары, икенче яктан Калмыяның тирән яры көтүне таратмый, качырмый тотарга булыша безгә. Тулганай эш серенә тиз

төшенде. Бер-ике мәртәбә «чик сызыгын» үтеп, качарга маташкан берничә сыерны кире туплау эченә куып кертергә миңа булышкан иде, андый хәл кабатлангач, инде минем фәрманнан башка гына бу вазифаны әйбәтләп үтәп чыкты. «Чик сызыгын» бозарга маташсын гына бераэр сөтбикә, хәзер аның алдында җир астыннан калкып чыккан Тулганай пәйда була, «һау-һау»лап теге мәхлукның каршысына төшә. Сыер халкындагы кирелекне җиңеп кара! Кайберсе күзләрен акайтып, башын чайкый-чайкый, ал аяклары белән комлы җирне гөрс тырнап, эткә табан килә башлыйлар. Тулганай әле бер читкә, әле икенче читкә сикерә, «һау»лап каршысына чөелә, теге бичара аптырап кала, куәте шиңгән сыман була, мескен мөгрәп, кире туплауга борыла. Кәлимулла абзый ярдәмгә иң соңгы чиктә генә килергә киңәш бирде. Шул киңәшне тотам. Шушы хикмәтләрне карап йөреп, сизми дә калганмын, төнге каравылга мал табибы Шәүкәт абый да чыккан икән. Соңга калып килде. Олы юл ягын бергәләп сакларга тиеш булып чыктык.

Шәүкәт абый базык, юантык гәүдәле, кызыл йөзле, саргылт чәчле, утыз яшьләр тирәсендәге кеше иде. Ерак яклардан килеп чыккан безгә. Өйләнгән, ике баласы бар. Авылга алар язгы пычраклар башлангач килеп төштеләр. Хуҗалары читкә киткән ташландык диярлек бер йортка урнаштырдылар. Какча гәүдәле хатыны кәнсә тирәсендә эшләп йөри бугай. Бусы мөһим түгел, Шәүкәт абый, Кәлимулла абзый әйтмешли, аракы белән шаярырга ярата иде. Эчсә, авыл халкы арасында йөрмәс, әмма өйдә хатынын кыйный, җәберли икән, балаларын дөмбәсли, ниндидер кыргыйга әверелә, ди. Андый хәбәр тиз тарала авылда. Шуңа күрә аңа шикләнебрәк карый идем, ярый әле янда Кәлимулла абзый бар.

Әле кичә генә Кәлимулла абзыйның эткәйгә сөйләгәне колакка кереп калды.

— Үткән атнада сыер чирләп торган сыман булгач, алып киттем мал духтырына. Шәүкәтнең йорты каршысында гына — ветлечебница йорты, кирәк тапса, даруын да алып кына чыгар, дим. Кичкырын барып кердем, Шәүкәтнең эштән кайткан чагы гына. Сизенәм, моның башы авырта. Эшне аңлатмакчы булган идем. Тыңлап та тормый, баш чатный, төзәлмичә булмый, дип күзгә карап тора. Дөнья булгач, булыр инде. Буш йөри торган гадәтем юк. Бер чүллине өстәленә чыгарып утырттым. Менә, абзый, ышансаң ышан, андыйны күргән юк иде. Карап торуга спакуйный егет, бер рюмка салып эчеп тә куйды, хатынына әшәке сүзләр әйтеп бәйләнә дә башлады. Әле рюмкасын өстәлгә куярга өлгермәгән үзе, сугышырга маташа. Хатынын яклап сүз әйтмәкче идем, пычак алып өскә килә. Чыгып тайдым. Хатыны минем арттан йөгереп чыкты. Ә айнык чакта йомыш белән килсәң, елмаеп кына тора, чебен дә үтермәс бәндә кебек.

Менә шушы Шәүкәт абый инде бу. Шөкер, салмыш түгел, ахры. Кәлимулла абзый белән җылы итеп, дустанә күреште. Күңеленә Тулганай да хуш килде, ахры, ни кыланса, шуңа елмаеп, рәхәт чигеп, күзәтеп тора.

— Мондый помощник булганда, артык мәшәкать күренми безгә, — диде ул, елмаюын яшермичә. — Минем кызлар да эт алыйк дип теңкәгә тияләр. Алмак булам да кире уйлыйм. Безгә нигә инде эт? Аналары эттән яман, талый башласа, керер тишек тапмыйм. Кәлимулла абзый, беләсең бит, эчкәч ычкынам, брат. Шуның өчен сүгә инде ул... — дип, хатынын шундук аклап та куйды. — Сүз көрәштерергә яратам мин салгач, шул харап итә мине.

Калмыя ярыннан төшеп, таллыктан коры-сары җыеп алып мендем. Учак тергезми булмас, каршы яктан тымызык җил кузга салынган бәрәңге исе алып килә әнә, авыздан сулар китерә.

Үләнгә кичке чык төште. Аяк асты юеш, тәнгә суык үрмәли. Берзаман авыл өстендә түп-түгәрәк ай калыкты. Тулган ай авызын бераз кыйшайтып, үртәп

көлгән сыман безгә туп-туры карап тора. Тирәсендә йолдызлар сибелгән. Мин Калмыя ярына ук килеп басып, шушы серле манзараны күзәтәм. Аста Калмыяның җылы сулышын тоям, аннан сыек аксыл томан күтәрелә, таллыктан төн кошы пырхылдап куя, суда нәрсәдер йөзгән кебек, яр читен ара-тирә сак кына дулкын үбеп ала. Тулганай адашы тулган айга озак-озак карап торды да улый башлады. Эчкә шом йөгерде.

— Тулган ай җан ияләрен куркуга сала, — Шәүкәт абыйның тавышын ишетеп сискәнеп киттем. — Ай туды исә, терлек халкы ашаудан кала, кизү ала аларны. Эт тә куркып калды, өрә дә алмый, улый гына. — Инде ул безнең янга килгән Кәлимулла абзыйга борылды. — Борынгыда тулган ай вакытында яуга чапмаганнар. Атлары кизүдән кырылудан шикләнгәннәр. Менә ни өчен шулай ул? Тулган ай шулкадәр серле булып күренгән борынгы кешеләргә, хәтта ыруны саклау өчен дип, бер яшь егетнең башын чабып, казыкка утыртып куя торган булганнар. Кеше башын тулган айга тиң күргәннәр. Менә шундый заманнар булган... Гаҗәп бит. Мин үзем ай тулган төннәрдә йоклый алмыйм. Уйлыйм, уйлыйм, уйларның очына чыга алмыйм. — Шәүкәт абый тешләрен шыкырдатып алды. — Их, брат, бу яклар безнең яктан нык кайтыш, кайтыш. Каян килеп чыктым монда, үзем дә аңламыйм. — Аннан аракы исе аңкып китте. — Менә әйт әле, Калмыя синең өчен нәрсә? — Ул инде миңа эндәшә иде.

— Калмыя нәрсә булсын инде. Елга инде, су керәбез, балык тотабыз. Кыш көне бәкедән су алып кайтабыз мунча ягарга.

— Мунча!.. — Шәүкәт абыйның сүзе мыскыллы яңгырады. — Мунчага, брат, суны табарга була ул, җанны юып, шуның ачысын басып кара син. Мин үзем Кама буенда туып үскән кеше. Синең елганы күргәнең юк! Калмыя нәрсә инде ул?.. Әйт әле, Кәлимулла абзый, кайсы якка йөзү яхшы?

Шәүкәт абый ярсый иде. Кәлимулла абзый шикләнә төшеп җавап кайтарды. Үзеңә пычак белән ташланган кешене онытып буламы соң?

— Суы булса, кайсы якка йөзсәң дә ярый. Калмыяның чума торган урыннары да ике-өч кенә бит аның.

— Менә шул инде, брат. Тирәнлек җитми, сай йөзү дип атала ул. Бу якта халык йомыкый. Зур су буенда яшәгән халык белән сөйләштерергә иде сезне. Вәт, сайрап торалар алар. Телләренә шайтан төкергән. Суга каршы йөзү бернәрсә бирми, Кәлимулла абзый! Агым уңаена йөзеп тә мәгънә чыкмый. Аркылы йөзәргә кирәк, коры җиргә тизрәк аяк басарсың. Кеше нык басып торырга тиеш аягында. Уңайга йөз, каршы йөз — барыбер бер мәлне коры җиргә чыгарга кирәк. — Ул, башын учлап тотып, тын торды. — Мин ярны югалттым, брат, йөзеп чыгар ярым юк. — Чүгәләп, Калмыяга карап тора башлады.

Тулганай миңа сыенып тора, дер-дер калтырый. Кәлимулла абзый да эндәшми.

— Нәрсә эзләп килдем соң монда мин? — Шәүкәт абый инде җавап көтеп тормый, үз-үзе белән сөйләшә иде. — Югалткан нәрсәм ни дә тапкан нәрсәм ни? Аңлый гына алмыйм бит, шайтан алгыры. Зур суны ташлап, шушы тез тиңентен, сыер тизәге бөтерелеп аккан инеш буена килеп утыр инде. Югалтып табарга өйрәнгән кавем без. — Ул кисәк кенә борылып, минем аякка сырышкан Тулганайның борынына сугып алды. — Юеш борын, ни кылмак син монда? — Тулганай чинап бер читкә сикерде. — Этне кызганырга ярамый, брат. Безнең эштә җан иясен кызгану булырга тиеш түгел. Кызганган кеше беркайчан да табиб булмый ул. Бичара адәмнәр, эт-песиләр... Кызганган кеше гомер буе башкалар өчен чирләп йөри. Үзе өчен чирләргә вакыты калмый. Аңладыңмы? Табибларга ышанмагыз, алар эт йөрәген үтерәләр... учларына кысып... — Бу сүзләрне кемгә төбәп әйткәндер, Кәлимулла абзый белән икебез дә эндәшергә кирәк тапмадык. Дөресен әйткәндә, мин мондый сөйләшүләргә әзер түгел

идем. Кәлимулла абзыйның исә кәефе кырылган иде, бу сөйләшү аңа бөтенләй хаҗәт түгел иде.

Шәукәт абый, карашын югарыга төбәп, тулган айны күзәтеп торды. Тагын сүзен дәвам итте.

— Айга карап торам, ком белән ялтыраткан борынгы җиз табакка охшаган. Кемнәрдер ул табактан кайнар шулпа чөмергәндер, елкы ите ашаганнардыр. Беләкләреннән буй-буй май сызылып төшкәндер... Безгә исә өлеш калмаган, башны югары күтәреп, муен талганчы карап торасы гына... Шулкадәр эт булып улыйсым килә. Ни өчен өрәсе түгел, ә нәкъ менә улыйсы килә? Сәер... Этләр безне кеше итте. Уйлыйм да шаклар катам: эт өрә, бүре улый, чучка мыркылдый, һәркайсы үзенчә аңлашу җаен таба. Ә кеше, бер карасаң, чучка урынына мыркылдый, бер карасаң эттән битәр өрә, икенче карыйсың — бөтен дөньясы чәлпәрәмә килгән дә улап йөри... Кеше үзен тапмаган әле ул, хайванлыктан ары китмәгән ул. Мин ничек табиб булдым дисең, Кәлимулла абзый? Күпме эт суйдым студент чагында. У-у, кулдан күп үтте Сарбайлар, Актүшләр, Дүрткүзләр... — Кәлимулла абзый кыбырсып алды. Шәукәт абый аның иңсәсенә кулын куйды. — Кызганмадым. Ярамый! Күкрәк читлеген ватып, йөрәген тартып аласың. Теп-тере йөрәк, учка кысасың, җылы, бирешәсе килмичә тартыша, учтан суырылып чыгасы килә. Аның саен кысасың. Суына башлый... Җан йөрәктә түгел, диләр, кайда соң ул алай булгач җан дигәннәре...

Әлеге сөйләшү куркытты мине. Тулганайны бу тирәдән алып китү теләге белән:

— Әрәмәдән утын җыеп килəм, — дип, ярдан аска төшә башладым.

— Мәшәкатьләнмә! Тал чыбыгы ягып ятарга кем дип белдең мине? Мин — зур су буенда үскән егет, өскә нарат урманы авып тора иде! Сезнең кебек сыер тизәге ягып көн асрамаган. Әйдә, минем арттан калма! — Ул кырт борылып, зиратка табан китте.

Ирексездән Кәлимулла абзыйга күтәрелеп карадым. Ул сүзсез калган иде. Башын селкеп алды, белмим, Шәукәт абый артыннан бар диюе идеме, башка бер сүз әйтмәкче идеме... Шәукәт абыйга иярдем. Нигәдер бу кешене кызгана башладым. «Кызганмагыз! Кызганмагыз!» — дигән саен, бу хис көчәя генә иде сыман.

Шәукәт абый туп-туры зиратка табан китте. Мин куып җиткәндә, ул инде коймаларны каерып эчкә үткән иде. Сихерләнгән сыман аңа иярдем. Тулган ай караңгылык белән тартышта җиңеп бара — әйләнә-тирә яп-якты. Авыл картлары ике атна чамасы гына элек зират печәнен чабып алганнар иде, каберләрнең койма белән әйләндереп алынганнары гына түгел, калкулык хәлендә калганнары да уч төбендәге кебек.

Күңел борлыга. Шәукәт абый барган шәпкә каршыда калыккан искерәк кабер коймасына китереп типте. Чери башлаган җепсә урталай сынып, койма такталары шапылдап җиргә коелдылар. Шәукәт абый җан-фәрман селтәнеп, кабернең такталарын ботарлап ташлады, дүрт почмакта дүрт багана утырып калды. Көч белән баганага китереп типте, багана аумады. Сүгенә-сүгенә аны каера башлаган иде, искә килеп:

— Нишлисең, Шәукәт абый?! — дип кычкырып, аның беләгенә ябыштым. — Каберлеккә кагылырга ярамый, тукта!

Ул, кулын селтәп, мине читкә этәрде.

— Син нәстә беләсең, малакасус! Утын шулай була ул, брат. Тал чыбыгы, имеш... Төне буе шуның ачы төтенен иснәп чыкмакчы буласыңмы? Багана ягабыз. Дөрләп яна ул!

Кабер ботарлауга аптырашта калган Тулганай, ачу белән мине читкә кагып җибәрүен өнәмичә, кисәк Шәукәт абыйга ташланды. Арт ягын умырып

тешләп алды да нык бәдәнле Шәүкәт абыйны каберлектән читкә тәгәрәтте. Теге һушына килгәнче, сыерларны кугандагы кебек, әле бер якка, әле икенче якка сикергәли, аны абалап, каберлектән куа башлады.

— Үтерәм, эт тәресе, йөрәгеңне тартып чыгарам, — дип җикеренсә дә, Тулганайга якын килә алмады ул. Аягы астында аунап яткан баганага иелүе булды, Тулганай янә аңа ташланды, чалбар умырылган тавыш чыкты. Тулганайны тыймакчы булам. Ул исә минем кычкыруыма колак салмый, ярсып, һаман-һаман Шәүкәт абыйга һөҗүм итә.

Башка шаулап кан йөгерде. Колак төбендә Кәлимулла абзыйның тавышы ишетелмәсә, белмим, йөрәгем күкрәк читлеген ватып чыгар иде.

— Ни кыланасың, Шәүкәт? — дип җикереп кычкырды ул, килә-килешкә хәлне чамалап. — Ничек намусың җитеп каберлек туздырасың? Монда бит кемнеңдер әтисе йә әнисе, йә бер туганы ята. Хәзер үк чыгып олак моннан!

Кәлимулла абзыйның җан ачысы белән әйткән сүзләреннән Шәүкәт абый айнып китте. Күтәреп ала башлаган баганасын бер читкә орып бәрде дә елак тавыш белән:

— Кешеләр, коткарыгыз, үтерәләр! — дип котсыз кычкыра-кычкыра, эре адымнар белән зираттан чыгып чапты. Аның артыннан өрә-өрә Тулганай томырыла, алардан калышмаска тырышып мин йөгерәм. Тулганайның өрүендә җиңү тантанасы бар иде. Шәүкәт абый туплауга каермады, туры өенә йөгерде. Бер атналап өендә дәваланып яткан, диделәр. Үзен Тулганай талады, дисә, аңа беркем дә ышанмас иде. Кәлимулла абзый да, мин дә сөйләнеп йөрмәдек. Барысы да күз алдымда, мин сөйләгәнчә булды, анысын кулны күкрәгемә куеп раслыйм. Тулганайга тагын бер медаль тагып куйдым.

## VII

Мәктәптән кайтып киләм. Ялыктыргыч дәресләр, эчпошыргыч көннәр. Бу укуны кем уйлап тапкандыр! Белсәм, туйганчы сүгәр идем үзен! Мондый көнне тузанлы һава сулап, парта арасында утыралар димени!

Сентябрь урталары. Дөньяны рәхәт оетып, күктә кояш йөзә. Пәрәвезләр оча, иреннәргә, маңгайга килеп сыланалар. Агач яфраклары җәй көннәрендәге кебек җилләр белән дәртле шаярмыйлар, ничектер салмак, коры һаваны ерткалап кыштыр-кыштыр киләләр. Бар буйларына сары йөгергән. Миләш яфраклары гына җимешләреннән уздырып кызарганнар. Бакчадагы шул сары, кызыл төсле яфракларны ябынып алгач, җирдә икенче төрле тормыш башланган кебек. Күз белән җиргә моңсулык иңә. Кояш күпме генә туры карарга тырышмасын, әйләнеше көннән-көн офыкка якыная бара. Көннән-көн шулай — көн кыскара, кояш чүгә.

Капкага кагылуга, Тулганай шатлыгыннан нишләргә белми әрле-бирле чабып өерергә тотынды. Чылбырыннан ычкына калса — туп-туры мәктәпкә очып килеп җитә, дәресләр беткәнне көтеп тора. Камил абый җиденчегә күчте инде, аның эт белән уйнап йөрергә вакыты юк, моны сизенгән Тулганай гел минем тирәдә бөтерелә, быел җәй бигрәк тә нык дуслаштык инде. Ул минем уйлап чыгарган бөтен хикмәтләремә түзә. Бүген исәп — Кыркүле тирәләреннән әйләнеп кайту. Басулардан игеннәрне җыеп алдылар, йөри торгач, берәр куян килеп чыкмасмы, кыр үрдәген әләктереп булмасмы? Эт асрап бер куян да тотмагач! Кыр үрдәге әләктерсәң дә начар булмас. Алар җылы якка китәргә әзерләнәләр, өсләренә килеп чыксаң, тиз генә очып китә алмый маташа торган булырлар — симергәннәрдер инде ерак юлга хәлсезләнеп кузгалмый торганнардыр.

Уй-ниятләрне Тулганайга аңлатып тормадым, аңа нидер әйтеп, кул изәдем дә өйгә кереп сеңдем. Тизрәк өс киемнәрен алыштырырга да, чәй эчеп, Кыркүленә ычкынырга. Кыр үрдәкләре көн саен безне көтеп ятмаслар.

Уйларында җылы яклар гына инде аларның. Бүген укытучы апа шул хакта сөйләде безгә. Көз китәләр, яз көне бәбкәләр чыгарырга кайталар икән. Нигә алай йөри торганнардыр, анысын әле аңлап җитмәдем. Кич әткәйдән сорармын.

Өйдә әнкәй көтеп торган икән мине. Бераз сабыр да итмәде, балкып торган кәефне җибәрде дә куйды.

— Киемнәреңне алыштыр, ашап ал да (анысын үзем дә беләм) Тулганайны ветлечебницага алып барып кайт, — ди.

— Нигә? — дидем аптырап. Корган ниятне күрәләтә бозу бит бу. Карышып карарга кирәк. — Ветлечебницага сыерларны гына алып баралар, кан алырга, — дим ризасыз тавыш белән. — Без Тулганай белән Кыркүленә үрдәк тотарга барабыз.

Әнкәй көлеп җибәрде.

— Абзар артына барырсыз. Тоттыра ди сезгә үрдәк. Алар Ык буендагы зур күлләргә күчеп киттеләр инде. Шунда җыелышалар, аннан бергәләп җылы якларга китәләр.

Кәеф тәмам бозылды.

— Барыбер Кыркүленә барабыз, — дим көйсезләнә төшеп.

— Ярый соң, барырсыз, тик башта ветлечебницага барып кайт.

Күз алдыма Шәүкәт абыйның кызгылт йөзе килеп басты.

— Бармасаң ярыймы? Шәүкәт абый Тулганайны күрсә... — Теге төнге вакыйганы сер итеп кенә әнкәйгә чишкән идем. Түзеп буламыни?! Эт муенында медальләр арткан саен, ни өчен бирелгәнлеген аңлатырга кирәк бит.

— Шәүкәт абыең гына түгел анда. Районнан килгәннәр. Авылдагы барлык песи, эт җәнлегенә укол кадыйлар. Бик тә йогышлы авыру чыккан, ди. Кешеләргә йокса — үлеп кенә китәләр икән. Песи, этләр тарата ди ул авыруны.

— Нигә песине алып бармыйбыз? — дидем аптырый төшеп. — Сыер саугач, парланып торган сөтне иң беренче Акколакка бирәсез, укол кадарга булса, беренче — Тулганай.

— Авыл советы исемлегенә Акколакны кертмәдек, анысына баш җитте. Өй борынча йөреп, язып чыктылар кичә. Бүген исемлек буенча чакырталар, — дип сөйләнә башлаган иде әнкәй, ярты сүздә бүленеп калды. Бераз тын торгач:

— Тулганайны илтми булмый, аны Фәсхи абзыең иң беренче теркәп куйган инде, — диде. Киреләнмәслек итеп өстәде. — Тулганайны бавыннан ычкындыра күрмә, эт халкы сизгер була ул, качып китүе бар. Бер югалса, эзләп тә таба алмассың.

Ветлечебницага барганда, ул яктан кайтып килүче ике апаны очраттым. Берсе кызып-кызып кемнедер әрли:

— Адәм гыйбрәте! Бер елны сыерларны өйдән мәҗбүриләп алып чыгып киттеләр бит. Имеш, колхозда сыерлар җитәрлек, җан башыннан сөт биреп барачак, диделәр. Тот капчыгыңны, бирделәр, ди, балалар сөт төсе күрмичә җәфаландылар. Хәзер песи, этләрнең башларына җиттеләр. Имеш, агу куйсаң, бернинди дә песи кирәкми, күсе-тычканнар кырылып кына бетәргә тиеш икән. Бөтен җиргә агу куеп бетереп буламыни?

Әллә кире борыласы инде. Тулганай да никтер гел читкә сөйри. Ишегалдыннан чыкканда да еламсырап алды, хәзер дә моңаеп, минем күземә карап-карап ала менә... «Илтмә мине анда, уколдан куркам», — ди бугай. Уколдан мин дә куркам инде анысы, мәктәпкә килеп кадап китәләр аны. Укытучы апа: «Кызларга үрнәк күрсәтегез», — дип, иң беренче безгә кадата. Чыгып качмасыннар дип ишек төбендә сакта тора әле. Уколдан котылып булмый, Тулганай. Иң яхшысы — тиз генә кадатыйк та Кыркүленә элдерик. Чалбар кесәсенә зур гына ипи телеме салып куйдым, әзерлек йөз процент! Кәлимулла абзый шулай дип әйтергә ярата.

Ветлечебница янында бер кеше дә юк. Башыма уй йөгерде. Кем белә инде — эткә укол кадаганнармы, юкмы, кем кемгә хисап бирә. Тизрәк таярга кирәк моннан. Өйдә белеп, орыша башласалар: «Бардым, анда беркем дә юк иде», — диярмен. Чыннан да шулай бит инде. Ветлечебница ишегендә ат хәтле йозак, түрдәрәк бер трактор арбасы тора, шуның белән вәссәлам. Шулай уйлап бетермәдем, каршы яктагы өйләреннән Шәүкәт абый килеп чыкты. Шаулый-шаулый килә:

— Килдеңме, брат. Килми калып булмый шул. Гамәл дәфтәренә ни язылган, шуны үтәргә кирәк, дигән борынгылар, иеме, брат. — Ул ян кесәсеннән бер дәфтәр тартып чыгарды. — Тәк, тәк, фамилиягез ничек әле сезнең?

— Сафиуллин.

— Әйтәм бит, иң беренче язып куелган, эт, дигән, мәче халкы юк, значит.

Чүттән: «Акколак бар!» — дип ычкындырмадым. Тыелып калдым. Аны да бик яратам шул мин. Ул, билгеле, күбрәк әнкәй аяк астында урала, аңа ялагайлана. Бигрәк куштан инде. Тычкан халкына көн күрсәтми, шуңа әнкәй бер дә ачуланмый аны.

Шәүкәт абый җиңен сызгана төшеп, ветлечебница баскычы астыннан бәләк буе тимер торба тартып чыгарды. Ашыкмыйча гына баскычка чүмәште дә:

— Бир этеңне монда! — диде.

Эндәшмим. Зират вакыйгасыннан соң аның белән очрашмаска тырышып йөри идем, менә каршысында басып тор инде. Янга бер апа килеп басты. Песиен күтәргән. Кыюланып киттем: кеше булганда әллә нәрсә кылана алмас әле.

Тулганайның бавын кыскартып, Шәүкәт абыйга якынайтырга тырышам. Тулганай шыңшый-шыңшый кире чигенмәкче була.

— Сизә... Гөрзинең кем кулында икәнен белеп алды бу! — дип, Шәүкәт абый бауны минем кулдан тартып алды да, этне озын йонлы гәүдәсеннән эләктереп, баскыч алдындагы зур ак ташка дык иттереп китереп сылады. Тулганай чинап, сикереп тормакчы иде, Шәүкәт абый миңа җикерде:

— Нәрсә катып торасың, нәрсәгә исең китеп бактың? Тот этеңне, укол кадыйм. — Үзе олы итеге белән этнең өстенә басып тора.

Чүгәләп, Тулганайның җылы, саргылт башыннан сыйпыйм. Тынычландырырга тырышам. Үземнең йөрәк урынымнан купты. Шәүкәт абый янындагы тартмадан шприц алып, аңа ниндидер сыеклык тутырды, аннан эһ итәргә өлгермәдем, Тулганайның күкрәгенә укол энәсен батырды. Эт тартышып куйды. Күзеннән яшь атылып чыкты, миңа рәнҗеп, тутырып карап алды. Инде Шәүкәт абый уколын тартып алуга, этне торгызыйм дип кузгалган идем, сизми дә калдым, Шәүкәт абый янындагы торба кисәген алып, җан көченә Тулганайның башына китереп сукты. Эт чинап җибәрде дә тынды. Күз алларым караңгыланды. Шәүкәт абыйның башын кочаклап алдым:

— Тимә инде, Шәүкәт абый, суга күрмә инде Тулганайга. Акыллы эт бит ул.

Мал табибын теге апа да ачулана башлады.

— Син нәмә, җүнсезләнеп, сабый каршында явызлык кыласың. Тукта хәзер үк!

Шәүкәт абый бу сүзләрне ишетмәгәндәй, янә селтәнеп, Тулганайның башына сукты. Аннан тартышып яткан эт гәүдәсен читкә алып атты.

— Бар, әнә, арбага илтеп ыргыт этеңне, — диде. Тавышында кыргый куаныч бар иде аның. Янындагы хатынга җикеренде. — Нәрсә, тути, мин уйлап тапкан закун дип уйлыйсыңмы? Әнә арбага багып ал, күрерсең... Төшкә кадәр районнан килеп саклап тордылар. Баласын җибәргән ата-анасын орышыгыз, мине түгел. Кушканны эшлим.

Яшьләремә тыгылып, Тулганайны күтәреп алдым. Маңгаеннан кан тасмасы

сузылып төшкән, күзе ачык, алар яп-якты, миңа аптырап карап торалар. Тулганайны күтәргән килеш өй ягына борылдым.

— Кая барасың, малай актыгы? Этең капут, бетте, җан тәслим кылды. Укол кадагач, җәфаланып ятмасынга торба белән сыйпап алам, — диде Шәүкәт абый, юлыма каршы төшеп. — Арбага ыргыт үләксәңне!

Этне күкрәгемә кысып тора идем, Шәүкәт абый Тулганайның сыртыннан эләктерде, кулларымнан каерып алды да, йөгерә-атлап барып, эт гәүдәсен арба эченә томырды. Мин аның артыннан йөгердем, тәгәрмәченә басып, арба өстенә сикереп менгән идем, андагы өелеп яткан песи, эт үләксәләрен күреп, өнсез калып, кире җиргә сикердем. Бер читкәрәк тәгәрәгән Тулганайның гәүдәсен шәйләп калдым, өем өстендә үк башын артка ташлап Актырнак ята иде...

Өйгә кич, караңгы төшкәч кенә кайттым. Дөньяның яме юк иде инде минем өчен. Хәлне аңлаган әткәй белән әнкәй мине тынычландырып азапландылар. Камил абый Тулганайны илттергән өчен әнкәйгә үпкәсен белдерә. Әткәй:

— Белә торып нигә баланы җибәрдең, — дип, әнкәйне орыша. Әнкәй хатасын таныган кебек, эндәшми, минем башымнан сыйпап тик утыра.

Атна буе авырып яттым. Күзне йомыйм дисәм, Тулганай белән саташа башлыйм. Беренче көннәрне кызыштым. Фельдшер Фәнисә апа көненә өчәр тапкыр яныма килә торган булды. Мине шаяртырга, сөйләштерергә тырыша. Беркемне күрәсем, беркемгә эндәшәсем килми. Күз алдымда тулган ай кебек йомарланып яткан Тулганай тора. Ни өчен сикереп, йөгереп уйнап йөрми ул, һич төшенә алмый изаланам.

Фәнисә апаның:

— Бер дә булмаса районга, больницага илтергә кирәк Фирүзне, — дигән сүзләреннән айнып киттем. Миңа да укол кадаргамы? Анда Шәүкәт абый ишеләр беткән, ди. Сикереп тордым:

— Юк, анда бармыйм. Авырмыйм ла мин! — дип елый башладым. Көч-хәл белән тынычландырдылар. Районга алып китүләреннән курку көчле булды, ахры, шул көннән аякка басып йөри башладым.

Бераздан авылны күсе басты. Күрше-күлән безнең Акколакка чират тора.

— Бер генә төн булса да безнең чоланда кунсын әле, — дип кергән әнә Кәлимулла абзый да. — Тычканнар дөбер-шатыр килеп чабышалар бит. Йокыга китеп булмый, шаштылар бөтенләй. Песи исе керсә, бераз куркырлар иде дигәннең эше инде. — Үзе кемнедер сүгә. — Песиләрне кырдырып бетерергә дип әмер биргән түрәләрнең үзен ябып куярга иде дә бит чоланга. Аларга буй җитми шул. Алар югарыда. Башларына ни килә, шуны эшләп аталар. Нәрсә уйлап эшләделәр микән бу эшне? Район белән башкорт ягына чыгып, эт, песи юллап йөри хәзер халык. Әнә үткән төнне авылга бүреләр килгән. Әгъләм кордашның өч сарыгын буып киткәннәр. Этсез авылга бүреләр иялəшә аңа.

Ике-өч айдан төрле яклардан этләр алып кайта башладылар. Төне буе авыл өстендә эт тавышы. Аларга — безнең авыл, безгә алар ят. Үзләренең авылларын сагынып өрә торганнардыр инде. Эт тавышына уянып, кабат йокыга китә алмый ятам. Тәрәзәгә сырышам. Күктән чекрәеп миңа тулган ай карап тора. Айның йөзе сүрәнләнгәннән сүрәнләнә бара. Ком белән ялтыратканчы ышкып чистарткан табакка охшаган ул. Аннан берара Шәүкәт абыйның кызыл йөзе чагылып ала. Табак йөзенә таратып ташланган ит кисәкләренә үрелә, беләкләреннән кан ага. Ит түгел, учында эт йөрәге сулкылдап тибә икән бит, йөрәк симез кулларыннан ычкынмак була, тартыша, җонлы беләккә кан сиптереп тора. Тулган ай түзми, бу хәлдән йөзен чытып, болыт арасына кереп качарга әзерләнә. Тиз генә сузылып, миңа караш ташлый. Шелтәләп карый ул миңа, Тулганайның соңгы карашы хәтергә төшеп, йөрәк сулкылдый...

*Хөрмәтле укучыларыбыз! «Ак җилкән» әдәби әсәрләр конкурсына эшләр кабул итү тәгәлләнде. Әлегә нәтиҗәләр ясалмады. Сезнең игътибарга конкурста катнашучы яшьләрнең кайбер әсәрләрен тәкъдим итәбез.*



***Илфат МӨГЫЙНОВ** 1997 елның 14 февралендә Аксубай районы Кызыл Тау авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килгән. Иске Кыязлы урта мәктәбенең XI сыйныфында белем ала. Беренче шигырьләрен VI сыйныфта укыганда яза. Хыялы – укытучы яисә журналист булу.*

## Язлар җитсә...

Язлар житсә, киртләч тау итәге
Балитәкле чуар күлмәк кебек...
Итәк асларына кача-поса,
Уйный бала-чага, чыр-чу килеп.

Язлар житсә, болын түшәгендә
Каз бәбкәсе изри «пи-пи» килеп.
Ата казы бии тыпыр-тыпыр,
Кояш күзен кыса аннан көлеп.

Язлар житсә, бер ярыннан елга
Тугайларга жәелә дингез кебек.
Каршы яры тауга сыенып күзли,
Сыңарысын жуйган игез кебек.

...Язлар житсә, били жинел халәт,
Таралырга торган томан кебек.
Яз яктысы сыга жан карасын,
Гажиз калып шуна торам кебек...

## Урал диюләрең юкка булмаган...

*Хәсән Туфанга*

Урал диюләрең юкка булмаган ла:
Урау юллар сиңа юраган.
Домналарның кайнар кызыллыгы
Ялкыннарга сине ураган...

Ялкыннарга сине ураган да
Алып менгән тау башларына...
Истәлекләр язган шунда йөрәк
Уралтауның ак ташларына.

Урал диюләрең юкка булмаган ла:
Урал биеклеге ымсыткан...
Илһам дигән яллы акбүз атың
Уралдан да табып үз иткән.

Чүкеч кыскан шул «пролетар» кулын
Каләм зәукын тойган анда да.
Станоклар шавын жыру итеп,
Чишмә типкән нәүмиз жанда да.

Урал диюләрен юкка булмаган ла:
Үзе бер чор, үзе бер дәвер...
Лысьва туфрагында уелып калган
Газизләрдән газиз бер кабер...

Сабый чакта шул газизен үзе
Йолдызларга дәшкән, биеккә...
Ана күнеле бала дия-дия
Кала белгән һаман биектә.

Урал диюләрен юкка булмаган ла:
Сөю чишмәсенен башлары...
Кем уйлаган Урал чибәренен
Чуалтасын шагыйрь башларын.

...Юраганнар гел юш килә икән,
Күрәселәр чиксез дөньяда...
Алмашынса алмашынсын дәвер –
Хәтер генә калсын өр-яңа!

---



*Инзилә МӘҖИТОВА 1997 елның 24 февралендә Актаныш районы Актаныш авылында туган. Тугызъеллык мәктәпне Меңнәр авылында тәмамлап, бүген Актаныш 1 нче урта мәктәбенең X сыйныфында белем ала. Буш вакытларын хикәяләр, шигырьләр, газета-журналларга мәкаләләр язу белән үткәрә.*

## Меңе белән кайтыр!

«Авылыгызның иң шук малайлары кемнәр?» – дисәгез, һич икеләнмичә, Айрат белән Ильяс, дип җаваплар идем мин. Шуклыклары аркасында аларның башлары ни генә күрмәде! Әти-әниләреннән дә шактый эләкте, бер-берсенең кулларын да сындырышып туктадылар. Ләкин үпкәләү дигән нәрсә сизелмәде үзләрендә. Шуклыклары дошманлашырга юл куймагандыр инде, күрәсең.

Менә авылга яз килде. Кошлар да туган якларына кайтып оя кордылар. Тик менә Айрат белән Ильяс кына һаман да ниндидер этлек эшләргә йөри. Түзмәгәннәр бит ташбашлар: кайсыдыр бер кошның оясын җимереп тә төшергәннәр. Аларны күреп торган Сәлимә әби бик шелтәләгән үзләрен.

– Балалар, бер дә дөрес эшләмисез бит. Табигатебезне, кошларыбызны сакларга кирәк. Ә сез киресен майтарасыз. Кошларның рәнҗеше төшсә, ни булыр? Вакытыгызны изге гамәлләр эшләп үткәрегез. Шул вакытта гына рәнҗеш сездән ерак торыр, – дигән Сәлимә әби.

Айрат белән Ильяс тирән уйга калып китеп барганнар. Чишмә буена төшеп, бик моңсу гына утыра биргәннәр. Шулвакыт Ильяс Айратны үз янына дәшкән.

– Карале, җир өстенә нинди су бәреп чыккан икән? – дигән ул.

– Чишмәдер бу, әйдә без аны күмеп куябыз. Ятмасын теләсә кайдан чыгып! – дигән Айрат.

Шулвакыт Ильяс Сәлимә әби әйткән рәнҗеш турында исенә төшергән. Дустының тәкъдимен хупламаган. Алай гына да түгел, чишмә тирәсен яхшылап чистартып, югалмаслык итеп билгеләп куярга кирәклеген аңлаткан. Айрат та, дустының бу сүзләре белән килешеп, аңа булышкан. Шушы гамәлдән соң аларның күңелләре бераз булса да тынычланган. Тик менә кош оясы белән булган хәл генә уйларыннан китмәгән. Өйләренә кайтып барганда, каршыларына Сәлимә әби очраган. Малайлар аңа нинди эш башкарулары, тик күңелләрен һаман да нидер кимереп торуы хакында сөйләгәннәр. «Теге кош безгә нык рәнҗер инде...» – дигәннәр алар. Сәлимә әби үзенең акыллы киңәшен әйткән: «Чишмәгә кылган изгелегегез үзегезгә меңе белән әйләнеп кайтыр, балалар. Ә кош инде яңа урынга оя корды. Ул сезнең чын күңелдән үкенүегезне сизде, шуңа күрә рәнҗемәс», – дип, малайларны тынычландырган.

Шушы вакыйгадан соң шук малайларыбызны алыштырып куйдылармыни?! Алар башкаларны да ияртеп агач утыртырга, урманнарны, чишмәләрне чистартырга йөри башладылар. Ә инде үзләре тапкан чишмәгә «Дуслык» исеме куштылар. Авыл халкы да хәзер челтерәп аккан чишмә суы эчеп, сихәтләнеп яши.

## Их, син!..

Ах, бу кызлар! Үртәргә дә, чәчләрен тартырга да, төртеп егарга да ярамый шуларны. Соң, без болай гына, яратып кына шаярабыз бит инде сезнең белән. Ник безне – егетләрне аңламыйсыз соң сез?..

Менә шундый чираттагы шаяруы аркасында эләкте дә инде Шамилгә. Зиләне яратып кына чеметкән иде ул. Тегесе чәрелдәп елап та җибәрде. Һәрвакыттагыча гауга купты һәм нәтиҗәдә укытучы Шамилне почмакка бастырды. Почмакка басу аның өчен берни түгел иде инде. Шундый шаярулардан соң ул үз урынын белеп, гел почмакка баса торган булды. Почмагы да аны үз иткәндәй, гел үзенә дәшеп, тартып торды.

Бу юлы эшләр зургарак киткән шул. Икенче көнне мәктәпкә Зиләнең әнисе килде. Шамилгә бик каты гына эләкте. Ул башын иеп, кызарып класс алдында басып торды. Шулвакыт укытучы Зиләдән гафу үтенергә кушты аңа. Ә Шамил Зилә алдына килеп басу белән катып калды. Авызыннан бер генә сүз дә чыкмады. Кинәт ул класстан йөгереп чыгып китте.

Ә урамда – кояш, яшел шәлләргә төренеп утырган агачлар. Шулвакыт ул юл читендә үсеп утырган ромашка чәчәкләрен күрде һәм аларны кочак-кочак итеп җыеп алды. «Бу хуш исле чәчәк бәйләмен Зиләгә бирергә кирәк», дигән уйга килде. Дуслашуларының бер билгесе булыр, дип фикер йөртте Шамил.

Кире класска керде. Бер сүз дә дәшми генә, җыйган чәчәкләрен Зиләгә сузды. Кыз чәчәкләрне елмаеп кабул итте. Дәресләр тәгәлләнгәч, Шамил Зиләне өенә озатып куярга булды. Тик өйгә кайтырга ашыкмадылар алар. Күлгә төшеп, каз бәбкәләрен карап кайттылар, җирдә пыр тузып чабып йөргән кырмысканы да кызыксыну белән бик озак күзәтеп тордылар. Кинәт яңгыр ява башлады. Балалар агач ышыгында басып торган арада, яңгыр туктап та куйды. Шулвакыт кечкенә генә күлдәвек җыелганын күреп алдылар. Икесе дә шул күлдәвектә үрдәкләр кебек чыпыр-чыпыр уйнарга керештеләр. Кинәт Шамил, артык мавыгып, кызны ничек суга төртеп екканын да сизми калды. Зилә ачы тавыш белән елап җибәрде. Шамил ни булганын абайламыйча аптырап китте. Зиләне тынычландырырга тырышса да, кыз күз яшьләренә батып өйләренә йөгерде.

– Шулай инде, ни генә булса да егетләр гаепле! Белмиләр шул алар үзләренең елак икәнлекләрен. Их, син! Зилә, Зиләйлүк! Мин бит ни, шаярып кына инде! – дип Шамил кызның артыннан йөгерде.

Ictimagi-mədəni tormışıbızdan

# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

***

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов 5 мартта Ак мәчеттә Кырым хөкүмәте белән килешүгә имза куйды һәм Кырымтатар Мәҗлесе әгъзалары, дин әһелләре, Казан татар оешмалары вәкилләре белән очрашты. Мәҗлес рәисе Рифат Чубаров: «Украинага, кырымтатарларның йортына мондый авыр вакытта хуш килдегез. Кырымтатар халкы сайлаган, ярымутрауның җирле халкы булган кырымтатарларның вәкаләтле органы — Мәҗлес әгъзалары белән очрашуда катнашкаңызны хуш күрәм. Кырымтатар халкы һәм татар халкы — якын кардәшләр. Йөз елларча булган тарихи бәйләнешләребез безгә рәхәтләнеп сөйләшергә, фикерләр уртаклашырга мөмкинлек һәм форсат бирә. Бүген Татарстан — Россия эчендә зур һәм дөньяда танылган республика. Бу форсаттан файдаланып, без Кырымнан һәм кырымтатарлар исеменнән Татарстанда яшәгән кардәшләргә хөрмәтебезне һәм сәламнәребезне җиткерәбез», — диде.

***

Мәскәүдә 12 март көнне Украина Радасы депутаты Мостафа Җәмилев Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев белән очрашты һәм очрашу барышында Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин белән телефоннан сөйләште.

***

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премияләре буенча комиссия, тапшырылган әсәрләрне һәм хезмәтләрне карап тикшергәннән соң, 2014 елда бу премияне дәгъва кылуга түбәндәге кандидатларны тәкъдим итте: Булатова Клара Гариф кызы. «Сайланма әсәрләр» китабы өчен (2 том. Казан: Татар.кит.нәшр., 2011 ел); Вәлиәхмәтов Фән Гавис улы. Татар халкының музыкаль мәдәниятенә зур өлеш керткәне һәм борынгы җәүһәрләребезне, сирәк башкарыла торган җырларны пропагандалаганы, шулай ук Беренче Бөтендөнья сугышы, Бөек Ватан сугышы турындагы җырларны башкарганы өчен; Гыйззәтуллина Флёра Сабирҗан кызы. «Күз нурларым: шигырьләр, поэмалар» (Казан: Татар.кит. нәшр., 2002 ел) һәм «Башкаемда — дөнья исәпләре: шигырьләр, поэмалар, балладалар» (Казан: Татар.кит.нәшр., 2007 ел) җыентыклары өчен; Ильясов Рафаэль Зариф улы. «Олы юлның тузаны», «Тәфтиләү», «Сандугач», «Уел», «Камәр», «Урман», «Галиябану», «Хәмдия», «Рәйхан» һ.б. татар, башкорт халык җырларын оста башкарганы, шулай ук башка концерт программалары өчен; Имамов Вахит Шәех улы. «Утлы дала» ике томлы тарихи романы өчен (Казан: Татар.кит.нәшр., 2012 ел); Самакаев Илгизәр Майбер улы. «Сара Садыйкова портреты» (1983 ел), «Юрий Никулин портреты» (1983 ел) һ.б. картиналары өчен; Сибагатуллин Фатих Сәүбән улы. «От Аттилы до Президента» тарихи-публицистик китаплар сериясе өчен (1 нче китап — «Великие хунны и Золотая Орда», Казан: Идел-Пресс, 2008 ел; 2 нче китап — «Легенды и мифы религий», Казан: Идел-Пресс, 2009 ел; «Великие татары — строители и защитники Государства Российского», Казан: Идел-Пресс, 2012 ел; «Татары и евреи», Казан: Идел-Пресс, 2013 ел); Сладковский Александр Витальевич. Татарстан Республикасы композиторлары антологиясе өчен; Попов Владимир Александрович. Каллиграфик серияләр композициясе өчен: «Тугра-шамаиль-память. Шигаб Ад-Дин Марджани — выдающийся учёный-историк, философ» (2013 ел), «Тугра-шамаиль-память. Баки Урманче» (2013 ел), «Тугра-шамаиль-память. Ильдару Ханову» (2013 ел), «Тугра-шамаиль-память-древо жизни. Шакирджан сын Ахмеджана Тагиров» (2013 ел) һ.б.; Хәсәнов Нурислам Габдулла улы. «Бәхилләрме йөрәк?: повестьлар» китабы өчен (Казан: Татар.кит. нәшр., 2011 ел).

***

15 март көнне Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында «Шүрәле» балеты күрсәтелде. Ул тамашачыларга Фәрит Яруллинның 100 еллыгы уңаеннан тәкъдим ителде. «Шүрәле» сәнгать тарихына татар балеты һәм композитор Фәрит Яруллинның сәхнә өчен иҗат иткән бердәнбер әсәре булarak кереп калды. Композитор үз әсәрен олы сәхнәдә күрә алмый. Егерме тугыз яшендә ул Бөек Ватан сугышы кырларында ятып кала. Сугыш кырында һәлак булган Фәрит Яруллин 1958 елда Тукай премиясе белән бүләкләнде. «Шүрәле» исә классик әсәр булып танылды. Кыска гына гомерендә Ф.Яруллин — камера-инструменталь әсәр-

ләр, романслар, жырлар язган, шулай ук халык жырларын да эшкәртеп, татар музыкасы үсешенә зур өлеш керткән композитор. «Шүрәле» балеты беренче тапкыр сәхнәгә 1945 елның 12 мартында куела.

***

X Халыкара Казан мөселман кинофестивале быел да, традиция буенча, сентябрь аенда узачак. Дөньяның төрле почмакларыннан кинематографлар килүе көтелә. Фестивальдә катнашу өчен гаризалар килә башлаган инде. Бүгенге көнгә дөньяның 9 иленнән 40 гариза кабул ителгән. Кинопроектта Казан мэрының махсус бүләге дә тапшырылачак. «Татаркино» дәүләт оешмасы үзенең 90 еллыгын август аенда билгеләп узарга жыена. 1924 елда Татарстанда оешкан Кинематографлар берлеге үз тормышында бик күп үзгәрешләргә дучар булды. Шуна да карамастан, эшчәнлеген туктатмады. Фестивальнең юбилей программасында Татарстан киносы коллекцияләре дә күрсәтеләчәк. Казандагы «Мир» кинотеатрына да быел 55 ел тула. Хөкүмәт карамагында калган әлеге бердәнбер кино йорты заманча фильмнар һәм югары сәнгати кинокартиналар тәкъдим итүе белән аерылып тора. Биредә даими рәвештә дөньякүләм әһәмиятле фильмнар, төрле кинематография чаралары оештырылып килә. 2009 елда кинозалны «Татаркино» үз канаты астына алды.

***

Төркиядә Төрки дөньяның әдәби журналлары конгрессы узды. Биредә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов һәм «Сөембикә» журналының әдәби мөхәррире Эльмира Закирова катнашты. Әлеге чара инде алтынчы тапкыр уздырыла. Ике көн дәвам иткән жыен «Казан — 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы» чаралары кысаларында мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспралының вафатына 100 ел тулуга багышланган иде. Конгресс Евразия Язучылар берлеге, ТӨРКСОЙ халыкара мәдәни оешма һәм Искешәһәр хакимияте тарафыннан оештырылды.

***

14 мартта Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институтында «Казан утлары» журналы белән тагын да тыгызрак элемтәләр урнаштыру максатыннан, очрашу уздырылды. Институтның ректоры Ф.З.Мостафина булачак белгечләрнең һөнәри әзерлеге процессында милли-әдәби басмаларның әһәмияте турында чыгыш ясады.

Журналның баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, драматург Мансур Гыйләжев, прозаик Айгөл Әхмәтгалиевалар да үзләренең чыгышында бүгенге көн әдәби процессының торышын яктырттылар, студентлар һәм укытучыларны «Казан утлары» журналы белән ижади бәйләнештә торырга, хезмәттәшлек итәргә өндәделәр.

***

15-16 март көннәрендә Чаллы татар дәүләт драма театрында Аяз Гыйләжевнең «Өч аршын жир» әсәре буенча куелган спектакль премьерасы булып узды. Күп еллар элек язылып, бүген дә актуальлеген югалтмаган әлеге драманың режиссёры — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фаил Ибраһимов. Кеше язмышлары белән курчак уены уйнаган дәүләт сәясәте, адәм баласының күзен һәм акылын томалаган байлык, чит жирләрдә яшәп, гомер буе күңелдән китмәгән жирсү һәм сагыну тойгысы — болар барысы драманың умыртка баганасын тәшкил итә. Спектакльдән соң тамашачылар алдында театр режиссеры Фаил Ибраһимов, күренекле язучы Айдар Хәлим, Аяз аганың уллары галим һәм язучы Искәндәр Гыйләжев, драматург Мансур Гыйләжевлар чыгыш ясады.

***

Арча районы Яңа Кырлай авылы китапханәчеләре мәктәп укучылары өчен «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре белән очрашу оештырды. Кичәдә журналның бүлек мөхәррирләре Гөлзадә Бәйрәмова һәм Ләйсән Фәтхетдинова үз шигырьләрен укыдылар. Мәктәп укучылары үзләре ижат иткән әсәрләр белән дә таныштырды, әдәбият белән кызыксынуларын күрсәтте.

5 мартта 53 нче яшендә Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, виртуоз баянчы **Рөстәм Вәлиев** вафат булды.

10 мартта тарихчы, археолог, академик һәм язучы **Равил Фәхретдинов**ның йөрәге тибүдән туктады. Р.Г.Фәхретдинов Болгар, Иске Казан археологик тикшеренүләре нәтиҗәсендә фәнни ачышлар ясады. Аның тарафыннан язылган тарих дәреслекләре мәктәпләрдә иң популяр дәреслекләргә әйләнде.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Казань — столица тюркского мира в 2014 году»: статьи Д.КАСЕИНОВА, А.СИБАГАТУЛЛИНА, Р.ВАЛЕЕВА; на вопросы редакции журнала «Казан утлары» отвечают М.ТАИШЕВ, И.ТАРХАНОВ.
«Литература родственных народов»: стихи А.АКБАША, КЫСАКУРЕКА, Б.МАШРАБА, ЧУЛПАНА, М.ЖУМАБАЕВА, М.БЕППАЙЛАНЫ, Д.ОСМАНОВА, Т.ДАВЛЕТБИРДИНОЙ, П.ХУЗАНГАЯ.
«Проза и поэзия»: АХИР. Роман «Город — пожиратель душ»; стихи М.ГАЛИЕВА, Р.БАШАРА.
«Конкурс на повесть малого формата»: БАТУЛЛА. «Двое чокнутых»; А.ЗАРИПОВ. «Мои воспоминания».
«Литературная критика»: З.РАМИЕВ. «На пути создания энциклопедии Тукая»; Р.ГАНИЕВА. «Турецкие мотивы в творчестве Г.Тукая»; Ф.ХАСАНОВА. «Образ Тукая в творчестве Ф.Гиззатуллиной»; Н.ЮСУПОВА. «Образ Тукая в татарской поэзии XX века».
«80 лет Союзу писателей РТ»: Р.КУРБАНОВ. «Служим нации».
«Искусство»: статья Ф.НАФИЕВА, посвящённая 100-летию со дня рождения Х.КАЗАКОВА; Л.ХАМИДУЛЛИН. «Соловей двух народов».
«История»: И.ГИЛЯЗОВ. «Мусульманские пленные в Германии в Первой Мировой войне».
«Белый парус»: повесть Ф.САФИНА; стихи И.МУГИНОВА; рассказы И.МАЗИТОВОЙ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Г.Тукай. Фотография 1912 года; участники IV Конгресса литературных журналов тюркского мира. 2014 год.

## IN THIS ISSUE:

«Kazan is the capital of the Turkic world in 2014»: articles by D.KASEINOV, A.SIBAGATULLIN, R.VALEEV; questions of «Kazan Utlary» are answered by M.TAISHEV, I.TARKHANOV.
«Literature of related peoples»: poems by A.AKBASH, KYSAKUREK, B.MASHRAB, CHULPAN, M.ZHUMABAYEV, M.BEPPAYLAN, D.OSMANOV, T.DAVLETBIRDINA, P.HUZANGAY.
«Prose and poetry»: AHIR. Doman «City, the Soul Eater»; poems by M.GALIYEV, R.BASHAR.
«Competition on a story of a small format»: BATULLA. «Two crankies»; A.ZARIPOV. «My memoirs».
«Literary criticism»: Z.RAMIEV. «On a way of creation of the Tukay encyclopedia»; R.GANIYEVA «Turkish motives in G.Tukay's creativity»; F.KHASANOVA. «Image of Tukay in F.Gizzatullina's creativity»; N.YUSUPOVA. «Image of Tukay in the Tatar poetry of the 20th century».
«80th anniversary of the Union of writers of the Tatarstan Republic»: R.KURBANOV. «We serve the nation».
«Art»: article by F.NAFIEV devoted to the 100th anniversary of H.KAZAKOV; L.HAMIDULLIN. «Nightingale of two peoples».
«History»: I.GILYAZOV. «Muslim captured in Germany in World War I».
«White sail»: story by F.SAFIN; poems by I.MUGINOV; stories by I.MAZITOVA.
From photoarchive of the magazine.
Diary of social and cultural life.
On our covers: G.Tukay. Photo of 1912; participants of the 4th Congress of literary magazines of the Turkic world. 2014.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Г.Тукай. 1912 елгы фоторәсем.


*Тышлыкның дүртенче битендә:* Төрки дөнья әдәби журналлар конгрессында катнашучылар. 2014 ел.

# Яңа китаплар




**Габдулла Бубый.**
**ХАТЫННАР. – I том.**
*– «Отечество» нәшрияты, 2013. – 356 б.*

Танылган мәгърифәтче Г.Бубыйның «Хатыннар» исемле тирән мәгънәле бу фәлсәфи әсәре XX гасыр башы татар җәмгыятендә төп урынны алып торган мәсьәлә – хатын-кызның гаилә һәм җәмгыятьтәге хәлен тасвирлауга багышланган. Милләтебезнең зыялы заты гаиләнең әхлакый нигезләре, тәрбия һәм белем бирүнең бер-берсеннән аерылгысызлыгы хакында уйлана, гаиләнең һәм җәмгыятьнең бөтенлегендә хатын-кызның ролен ачык күрсәтә. Китапның фәнни мөхәррире – социология фәннәре докторы Ф.Ә.Илдарханова. Текстны эшкәртүче һәм тәрҗемә итүче – тарих фәннәре кандидаты А.Х.Мәхмүтова




**Ризаэтдин Фәхретдин.**
**ГАИЛӘ. – II том.**
*– «Отечество» нәшрияты, 2013. – 238 б.*

Галим, мәгърифәтче, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Р.Фәхретдин татар халкын алдынгы карашлы, белемле, динен һәм әхлагын, милли үзенчәлекләрен саклап яшәүче милләт итеп күрергә тели. Аның эшчәнлегенең төп темасы – гаилә мәсьәләсе. Китапта күренекле мәгърифәтченең гаилә, ир белән хатын вазифалары, бала тәрбияләү, гаилә әгъзаларының үзара мөнәсәбәтләренә багышланган хезмәтләре урын алган. Галим фикеренчә, ныклы һәм әхлаклы гаилә көчле милләтнең нигезен тәшкил итә, әхлак югалган икән, милләт тә бетә. Китапның фәнни мөхәррире – социология фәннәре докторы Ф.Ә.Илдарханова. Текстны эшкәртүче һәм тәрҗемә итүче – тарих фәннәре кандидаты Л.Ф.Байбулатова.

Әлеге хезмәтләр ТР Фәннәр академиясе каршындагы «Гаилә һәм демография фәнни тикшеренү үзәге» оештырган «Гаилә – милләтнең нигезе» исемле проектка нигезләнеп дөнья күргән. Проект XIX гасыр азагы – XX йөз башында яшәгән татар мәгърифәтчеләре тәҗрибәсен өйрәнүне күздә тотып тәзелә.

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2014
МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)